www.kazanutlary.ru

# КАЗАН УТЛАРЫ

*ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ*

*1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА*

## Бу санда

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Рәшит БӘШӘР. Сыена уем кошлар җанына. *Шигырьләр.* ....3
Камил КӘРИМОВ. Исемсез хат. *Роман-элегия.* ....8
Ләбиб ЛЕРОН. Һәрвакыт иңдә йөк... *Шигырьләр.* ....53
Рөстәм СҮЛТИ. Ком күчә, бархан күчә... *Шигырьләр.* ....94
Айдар ХӘЛИМ. Искитмәле Исмәгыйль. *Хикәя.* ....98
Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА. Туры сүз дә кайчак ялый. *Шигырьләр.* ....120
Максим ШИКАЛЁВ. Мулла кызы. *Хикәя. (Русчадан Нурия Хәйруллина тәрҗемәсе.)* ....124

ДРАМА ӘСӘРЛӘРЕ

Илгиз ЗӘЙНИЕВ. Туганнар-тумачалар. *Татар тормышыннан сәхнәләр.* ....58

ЯҢА ИСЕМНӘР

Надия ВӘЛИЕВА. Яшәүдән туймагыз! *Шигырьләр.* ....129
ГҮЗӘЛӘ. Мин чиксезлек кадәр синдә. *Шигырьләр.* ....132
*Җәһәт тәнкыйть:* сәхифәне Дания ЗАҺИДУЛЛИНА алып бара. ....135

«ШИФАЛЫ КУЛЛАР» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Зәбир ГЫЙМАЕВ. Кендек бабай. *Хикәя.* ....137
*«Сабантуй»га (элекке «Яшь ленинчы» газетасы) – 95 ел: фотоархив.* ....148

«ТАТАРСТАН. ТАРИХ. ШӘХЕСЛӘР» ӘДӘБИ ОЧЕРКЛАР КОНКУРСЫ

Айсылу ЗӨФӘРОВА. Күңел кушканны тыңлап... ....150
*Кайтаваз:* Илһам ФӘТТАХОВ. Язмыштан узмыш юк... ....151

БАЛАЛАР КИТАПХАНӘСЕ

Илсөяр ИКСАНОВА. Сәпит. *Хикәя.* ....152

МОСТАЙ КӘРИМНЕҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ

Роберт МИҢНУЛЛИН. Кадерле истәлекләрем... ....156

ЮБИЛЕЙЛАР

Венера ӘМИНЕВА. «Язу – акыл һәм йөрәк эше...» ....162
*«Якутлар табыладыр вакыт белән...»:* Кәрим СӘГЫЙД. Атаклы татар әдибе Фатих Әмирханның авыруы, үлүе, күмелү мәрәсиме. ....168
*Бәләкәйләр:* Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ. Бәләкәй Әлфәт. ....182
*Музейларыбыз:* Халидә ГАБИДУЛЛИНА. Мөхәммәт Мәһдиев музее. ....187
*Шаян сәхифә:* Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ алып бара.* ....188
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

КАЗАН УТЛАРЫ
*(«Огни Казани»)*
*№ 10 (1164) 2019*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*

**Ирада Әюпова**
**Рабит Батулла**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Ринат Закиров**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Данил Салихов**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**

*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**

*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Фирүзә Җамалетдинова, Айсылу Имамиева, Камил Кәримов.**

*Мөхәррирләр:* **Лилия Вагыйзова, Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева.**

*Сайт мөхәррире:* **Рәзилә Хәйретдинова.**

*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Мөдәррисова** (өлкән бухгалтер)**.**

*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир – 222-05-50 (өст. 1618).*
*Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1617).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1266), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---


Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Казан, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 25.09.2019, график буенча 25.09.2019, басылып чыгу вакыты 11.10.2019.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108$^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ О-2616. Тираж 4367.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекслар: 73210 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен), П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), 16262 (Татарстаннан читтәге юридик затлар өчен), П2368 (Татарстандагы юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.

12+

© «Казан утлары», 2019 ел



Рәшит
Бәшәр

# СЫЕНА УЕМ КОШЛАР ҖАНЫНА

## Бөек Дала рухы

*Ай, бик еракта идек без...*
Халык җыры

Бик ерактан, әйе, килдек без,
Алтай тауларыннан – биектән.
Булган заман... Бөек төркиләр
Далаларда аю биеткән.
Күз күреме җитмәс далалар
Килеп керә минем төшемә.
Кылган арасыннан Ак бүре
Сикерә дә җылы түшемә,
Уйнап кына болай, яратып,
Ялап-ялап ала борынны.
Хыялымның нурлы мәле ул –
Бу төшләрем бик-бик борынгы.
Бик ерактан, әйе, килдек без,
Сибелештек дөнья йөзенә.
Дастаннарың, халкым, җырларың
Моңлы дисбе булып тезелгән.
Булган заман... Илләр кайнаган,
Дисбеләр дә канап өзелгән.
Кылган арасыннан Ак бүре
Алга чапкан дисбе эзеннән.
Бабамнарның горур авазы
Геннарымда минем, ишетәм.
Бөек Дала: «Яшә улым!» – дип
Төшергән ич мине бишектән.
Йөгем авыр... Ничә гасырлар
Кичәм диңгез, менәм тауларга.

---

Рәшит БӘШӘР (1949) – *шагыйрь һәм прозаик; «Сандугачлы бишек», «Ачык капка», «Былбыл оясы» һ.б. китаплар авторы. А.Алиш исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Чаллыда яши.*

Җир тынычсыз, илләр тынычсыз...
Бүреләргә кыргый ау бара.
Бик ерактан, әйе, килдек без,
Бик еракка китеп барабыз.
Юкка сөенәсез, иблисләр,
Без исән бит! Исән! Карагыз!
И Дала! Синең исне, төсне
Вакытлыча гына җуйдык без.
Канлы яуда ауды байраклар...
Байракларны тик вакытлыча
Йөрәкләргә урап куйдык без.
Кылыч ега, әйе, халыкны,
Ега алмый ләкин моңнарны.
Без җырлыйбыз... Көйдергеч эссе
Капласа да кайчак тыннарны.
Сөртенәбез хәтта тигездә,
Арабыздыр, әйе, арабыз.
Каната-каната тезне без
Бөек Дала рухын җаннарда
Киләчәккә илтә барабыз.
Кай төбәктә икән Ак бүре?
Ерак микән әле арабыз?
Йөгерегез, ап-ак кылганнар!
Нәсел исән! Исән! Карагыз!

## Казанда урыс теле бәйрәме

*Пушкин илә Лермонтовтан үрнәк алам,*
*Әкрен-әкрен югарыга үрләп барам.*
Г.Тукай

Июнь җиле... Июнь чәчәкләре...
Гөрләп тора һәйкәл тирәсе.
Пушкинга баш ия, валлаһидыр,
Бу дөньяның бөтен түрәсе.
Татар теленә дә шундый хөрмәт
Булса икән урыс илендә.
Сыйпап-сыйпап китә Тукай сынын
Кабан яклап искән җил генә.

## Йокысызлык

Иярәсең дә кошлар төркеменә,
Көн чигенә барып җитәсең дә
Кояш чыгаралмый тилмерәсең
Кап-караңгы төннәр төрмәсендә.
Кемдер яккан ялгыз учак дөрли,
Ал шәүләле таулар эргәсендә.
Шәүлә бии, оча, тирбәлә,
Күбәләктәй очып килә дә
Ачык тәрәзәмнән җил бәрә.
Уйга ияреп очып китәсең дә
Кунасың килеп кошлар янына.

Агач кара... кош оясы җылы,
Сыена уем кошлар җанына.
Сүнә теге ялгыз учак та,
Күбәләктәй очып арган җил
Оеп йоклый минем кочакта.

## Фәрештә

Йолдызлы күк сыеп беткән икән
Фәрештәнең зәңгәр күзенә.
Ярымайны ап-ак калфак иткән,
Җилләр оеп йоклый тезендә.
Галәм тып-тын... Чиксез караңгылык...
Җиргә карап тора фәрештә.
Төн хакимлек итә гарептә һәм
Таң сызылган инде гарештә.
Төн каплаган төштә йоклый бөҗәк,
Йоклый хайван, үлән, адәмнәр.
Аунап ята сугыш мәйданында
Тишкәләнгән ертык әләмнәр.
Һәм гәүдәләр ята канга батып,
Актарылган, янган үзәндә.
Йолдызларның салкын шәүләсе бар
Йомылмыйча үлгән күзләрдә.
Көн яктырган төштә гүли дөнья.
Машиналар чаба, кешеләр
Баскычлардан менәләр ашыгып,
Һәрберсенең җитди эше бар.
Чырык-чырык килә бала-чага,
Агач төпләрендә – күләгә.
Ерак алар сугыш мәхшәреннән,
Ерак әле, әйе... әлегә.
Ә фәрештә карап тора өстән,
Күзләрендә яшьме, очкынмы?
... Һәм югалды... Канат җиле калды...
Кай тарафка китте? Гөнаһсызрак
Бәндәләрне эзләп очтымы?
Сөт исләре килгән сабый гына
Күз яше күк чиста, саф әле.
Саф дөньядан кырыс чынбарлыкка
Юнәлгән ул кеше сәфәре.
Әле сүнә, әле яна йолдыз,
Канатларын җилпи фәрештә.
Гарептәме оча? Гарештә?

## Идел

Идел өсләренә иртән сарыла да ак томан,
Шул томаннан Идел һич тә арына алмас сыман.
Дулкын да юк, упкын да юк, томанлы Идел тыныч,
Җан тынычсыз әллә нигә, юк күңелдә куаныч.
Җилләр исәр, нур сибелер, ачылыр Идел йөзе,

«Кем идегез, кем булдыгыз?» – битәрләр Идел безне.
«Булды дәвер, чит-ятларга бирдегез илегезне,
Инде менә тыныч кына җуясыз телегезне.
Мин дә агам бер көйгә, баешыма табан агам,
Мин дә инде сезнең сыман бик тиз саега барам».
...Сискәнәм дә күзем ачам кап-караңгы төннәрдә,
Иделгә кояр инешләр кибеп яткан мәлләрдә.
Тукта, шагыйрь, куй каләмең, аһ-зарларны язма син,
Аһ-зарларны тыңлый-тыңлый, халык күңеле сызмасын! –
Дим дә мин янә ашыгып үреләм каләмемә,
Әрнүле яңа бер җырым сулкылдый калебемдә.

## Ватансыз

*Сөт калыр, Ватан китәр!*
Дәрдемәнд

Телгәләнә йөрәгем
Өзлексез телем-телем.
Үз җиремдә, илемдә
Үги тел – туган телем –
Мин бәхил түгел, халкым!
Савыкмас хаста бу ил,
Тома ятимнәр чутсыз.
Капшанып алга барыш
Көн яктысыз һәм утсыз –
Мин бәхил түгел, халкым!
Кош оялары тузгый
Туктаусыз искән җилдә.
Нинди шайтан туе бу
Без туып-үскән илдә? –
Мин бәхил түгел, халкым!
Этешеп тә төртешеп,
Тәхеткә үрмәлиләр
«Әни» сүзен татарча
Әйтергә иренгәннәр –
Мин бәхил түгел, халкым!
Биләүләре сүтелгән,
Тыпырчына сабыйлар.
Маңкорт ана сөтеннән
Күчә чит кавем теле,
Сула милләтнең гөле –
Мин бәхил түгел, халкым!

## Ак төннең көмеш аты

Әкияти төн бу. Юк бер өн.
Төнне нурлый йолдыз көлтәсе.
Үләннәргә кереп югалды
Тын болынның көмеш кәлтәсе.
Саксыз гына гөлгә кагылдым,
Чуар күбәләкне уяттым.
Әкияти төннең ак атын
Көмеш үләннәрдә уйнаттым.
Тояклардан нурлар сибелде,
Төн тузгытты ефәк ялларын.
Ак атымның җылы сулышы
Тибрәндерде инеш талларын.
Көнгә каршы чапты аннары,
Берьялгызым таңны аттырам.
Нур көлтәсе күкләр катында,
Әкрен-әкрен мин дә яктырам.

* * *

Тотып алам да мин урман җилен,
Шарф итеп урыйм муеныма.
Җилкәй аннан, йомшак тиен булып,
Кереп ята минем куеныма.
Саргайтмыйм дип, яшел көннәрне мин,
Таң нурына бәйлим гөлләрне мин.
Уйчанланды җәйләр, тып-тын җәйләү,
Сагышлы моң кунар йөзебезгә.

Сары күзләр төлке баласыдай
Ятып аунар безнең эзебезгә.
Чумып уйнар яфрак диңгезенә,
Көз хакимлек итәр үзе генә.

## Теләнче

И дөнья, дөнья, иттең ятимкәй,
Иптәшем диеп, кемгә әйтим, әй?
Сүз каттым байга, тапмадым мәнен,
Карашы сөмсез, теле гел – әрем.
Тук беләмени ачларның хәлен,
Оныттым күптән ипинең тәмен.
Тагын бер явыз очрады юлда,
Төкереп китте сузылган кулга.

Яныма килеп утырды бер эт,
Күземә карый нан өмет итеп.
Көне суытты. Эткәй дерелди,
Йоны коелган, күзе эренле.
Ашардай булып миңа төбәлгән,
Арына алмыйм коры ютәлдән.
– Берни дә сиңа бирә алмыйм бит...
Бушлыкка карап өрә ала эт.

## Еллар чатында

Картлык баскач, уйга чумып торам:
Дөньясының чите кителгән.
Бик күпләргә, хәтта танышларга
Кул бирмичә үтеп кителгән.
Сукбай этне кысып күкрәгемә,
Җилләр ерып салмак атладым.
Эт җылынды минем кочагымда,
Үзем генә җылы тапмадым.
Ялган, мәкер чорнап алган безне,
Уртакуллар даһи булмакчы.
Гаделлекне, намус, хакыйкатьне
Зинданнарга бикләп куймакчы.
Килер бер көн, күкләр аязыр да
Чүп-чарларны ташкын агызыр.
Җиргә иңәр яңа пәйгамбәр һәм
Якты маяк илдә кабызыр.
Чистарынып калган җир йөзенә
Шытып чыгар чыклы яшь үлән.
Ямьнәр генә тулар күзегезгә
Тармакланып үскән яшь гөлдән.
Күтәрелеп килә кояш әнә,
Тагын бер көн яшәп карагыз.
... Аксый-аксый серле офыкларга
Китеп бара Бәшәр бабагыз.

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

Камил Кәримов

# ИСЕМСЕЗ ХАТ

РОМАН-ЭЛЕГИЯ

***

Дүртенче камераны карап тормадым инде... Бу җан өшеткеч газаптан тизрәк котыласы, челләгә чыгып, җир асты кешеләрен онытасы килә. Хәер, мин төш кенә күрәм бугай, Ташкент икмәгеннән соң тән авырайды да аягүрә йоклап йөрим... Егылып киткәнче тизрәк берәр ятак табасы иде.

Ишегалдында тугарылган «ГАЗ-52» машинасын күргәч, сөенечемнән уянып киттем, «Ура!» кычкыра яздым. Беләм мин моны, иске «ГАЗик»ларга алмашка чыгарылган, алты цилиндрлы, яңача кабиналы әрҗәсенә комбайнның өч бункер икмәге сыя. Безнең колхозга өчәү кайтты инде алар. Председателебез Сакал Шәйхи техника мәсьәләсендә гел киләчәккә карап яши. Районның «Марс», «Искра», «Ильич байрагы» колхозлары тарантаслы ат җиккәндә, безнеке «Бобик» кушаматлы, брезент бөркәүле «лёгкийда» (җиңел машина) йөрде, күршеләр «Бобик»ка күчкәндә, Шәйхи әниләребез эшләгән хезмәт көненә сөтле чәй төсендәге өр-яңа «Победа» алып кайтты...

Тугарылган машина дүрт аягында нык басып тора, двигателен генә салдырганнар, яңасына алыштыралардыр инде, бик тиз шакылдап чыга торган гадәте бар, дип сөйлиләр иде. Берсе-берсе матрас чаклы утыргычын-арка терәгечен кузовка ыргытканнар, сизелеп тора – кемнәрдер ял иткәләгән монда.

«Машина түгел, менә дигән карават бу. Рөхсәт итсәгез, шушында гына яшәр идем», – дигәч, Сергей да җиңел сулап куйды.

«Тиз хәл иттек әле без шконканы (ягъни ятак), иртәнге якта салкынчарак булыр инде дә...»

«Һәй, тамагы тук кешегә буран да ни почём!»

Мин көпчәкле караваттан төшкәндә, Ташкент кояшы ярты юлын үткән иде, мине махсус уятмаганнар. Кызганыч, отрядның эшкә киткәнен күрми калдым.

Миләүшә апай эштә иде инде. Ул миңа башланмаган кер сабыны һәм мунчала белән сөлге бирде. Душның бер генә краны бар иде, торбасы түбәдәге кара мичкәдән килә икән, кояшлы су колакны пешерерлек түгел иде, әллә ярты сәгать басып тордым яңгыры астында... Апакайның тавык фермасында чокыр казып кайткач, егетләр дә Үшнә елгасында су коеналардыр инде... Мин югында Зәрияне кемнәр озата икән?!.

Бу оешмада корал йөртүче кеше күрмәдем. Миңа йөкләнгән эш шушы тирәдә генә. Көндез ишегалды себерәм. Иртә-кич, поварга ияреп, чәйханәдән

---

*Ахыры. Башы узган санда.*

аш алып кайтырга булышам. Повар дип дөресен әйтәм, ул пешекче түгел, әзер ризыкны бүлеп бирүче генә.

Кагыйдә буенча мин монда ике атна яшәргә тиеш. Тагын ике атнадан хәбәрсез югалуыма 21 көн була. Үзбәк җизни мине эзләп килмәячәк. Әни гүр сәдакасы бирәчәк тә йөрәген тотып авачак. Фатыйма әби Коръән чыгачак...

Фәрештә апай бар бит әле.

Отряд эштән кайтыр алдыннан табын әзерләгәндә, ипи-тоз йә май-суган җитешмәсә, чәйханәгә үземне генә дә җибәрәләр хәзер. Кәгазь тартмага кирәк-яракларны тутырган арада, кикерә-кикерә, шәһәрне күзәтәм. Бу чәйханә дигәннәрен һич аңлап бетерә алмыйм. Зур алачыкта, сәке өстендә аяк бөкләп утырган агайлар берәр тапкыр өйләренә кайталар микән? Килгән саен шул ук кешеләр бит анда. Туктаусыз сөйләшәләр үзләре. Саманнан өелгән морҗалы сарайдан пионер яшендәге бер малай, бил япкычына кулын сөртә-сөртә туктаусыз чәй ташый. Күпме эчеп була инде ул суны?!. Ара-тирә минем якка карап хихылдашып та алалар...

Тагын өч көнем өч сәгать кебек кенә үтте дә китте.

Иртәнге якта мине «кызыл почмакка» дәштеләр. Сергейҗан белән Миләүшә апай икесе. Нәкъ беренче көнемдәгечә, линолеумга багынып утырам. Беренче сүз Миләүшә ападан чыкты. Ул «Балакаем» дигәнен генә үзебезчә әйтте.

«Балакаем! Кайтасың киләдер инде...»

«Әнием өчен генә борчылам. Шулхәтле сагындым... Авылны».

«Вәт. Унике көн эшләде дип, табель тутырырбыз да... Балакаем, син җизнәң ягына Ургәнечкә китәргә телисеңме, әллә Казангамы?»

«Юк-юк! Миңа бернинди җизнәйләр дә кирәкми. Казанга! Казанга...»

«Оешма хисабына Казан поездына утыртып җибәрербез. Үпкәләмә инде, балакаем, самолёт билетлары безнең сметада каралмаган».

«И апай, рәхмәт яусын сезгә! Ашарга булса, җәяү дә кайтып җитәм мин, борчылмагыз.»

«Кайтырсың, кайтырсың! Бер поездан икенчесенә күчеп утырасы да булмас, туп-туры Казан вокзалына килеп төшәрсең...»

Шулчак, Сергейҗан, персональ эш тикшерелгән җыелышның комсоргы кебек урыныннан сикереп торды.

«Ул юнәлештә безнең зона Куйбышев станциясе белән чикләнә. Анда да, нәкъ безнеке кебек, «приёмник распределитель» эшләп тора, балакайчикны Казанга озатырлар. Ә Ургәнечкә, дисә – вообще проблема юк».

Фәрештә апайның күзләрендә Бөгелмә факеллары уйнап алды.

«Беләм, Сергей! Министрлык куйган шартларны бик яхшы беләм! Билетны Казанга чаклы алабыз, үз акчамны өстим. Егеттән сукбай ясамыйк әле!»

Кайту, поезд, Куйбышев, Казан, сукбай дигән сүзләр тезмәсеннән башым әйләнеп, нindидер сихри көч мине урамга куып чыгарды... Машинадагы «караватыма» йөзтүбән капландым... Анда бәхәс, анда мин тыкшына алмый торган хакыйкать, анда минем язмыш хәл ителә...

«Балакаем, җиргә төш. Шимбә-якшәмбедә ял итәм бит мин. Әгәр бүген озата алмасам, сиңа тагын ике көнгә артыграк сагынырга туры килә. Бүгенге поезд сине көтеп тормас».

Поезд дигән сүзгә машинадан сикереп кенә төшәсе идем дә, сабыр, минәйтәм, аякларыңның кирәге чыгар әле, ерак юл көтә түгелме?!

«Апай, бүгенгегә билет та юктыр инде анда...»

«Булыр. Син минем кайда эшләгәнемне беләсең ич!»

Вокзалга килгәч, мин Миләүшә апайдан бер адым да артка калмадым, расписаниене тикшерсә дә, кассага басса да, тагылып йөрдем, аны югалту минем өчен һәлакәткә тиң! Поезд кузгалып китәргә нибарысы ярты сәгать кенә калган иде, ничекләр итеп билет алалгандыр, белмим?..

Ниһаять, менә ул вагон! Ишеге ачык, вожатые көтә.

Фәрештә апа алтын балдак кигән бармагын уйнатып, минем маңгай чәчемне туздырып алды – бу аның үзенчә саубуллашуы иде.

«Бүтән адашып йөрмә, йәме! Сакла үзеңне...»

«Ярар апай, бүтән беркайчан да адашмам! Апай, Казанга кайтсагыз, туп-туры безгә килегез. Шәле олы юл өстендә генә. Совет урамы, 13 нче йорт. Яңа өй салдык, шифер түбәле. Әнием авылга бер аш-су остасы».

Минем аны үземнән ерак җибәрәсем килми. Сагынычлы хат укыган кебек туктаусыз нидер сөйлим. Ә ул һәр җөмләмә башын селкеп: «Ярар!» – дигәндәй итә.

Вожатыйның: «Кузгалабыз!» дигән сүзенә буйсынгандай, поезд бөтен гәүдәсе белән йолкынып алды. Баскыч колгасына җан ачысы белән ябышып вагонны кулдан ычкындырмый торам. Тагын бер сүзем калды...

«Фәрештә апай! Ник син минем апам булмадың икән?!»

Ул мине ишетмәмешкә салышты.

«Балакаем, билетыңны югалтма! Тагын адашырсың!»

Вагонга кергәч, билетымны күрсәтим дип кесәмә тыгылсам... 3 сумлык акча килеп чыкты. Миләүшә апай аны билетка төреп биргән, ахрысы. Проводник акчаны шундук шәйләде.

«Ресторан 7 нче вагонда», – диде.

Нинди ресторан! Минем бит әле Казаннан автобус белән кайтасым бар! Миләүшә апа анысын да уйлап куйган...

Үземә тиешле астагы урынымны бер әбигә калдырып, урын-җиремне иң өскә – багаж тезә торган өченче сәндерәгә җәйдем.

«Әбекәй, Казанга җитәрәк уятырсыз әле, зинһар!» – дидем дә мендәремне сәндерәсе-ние белән кочакладым... Мәктәптә без ун ел буе Туган тел турында шигырьләр ятладык, җырлар өйрәндек, музейларда йөрдек. Ватанны саклаучыларга багышлап, иншалар яздык... укытучыларыбыз кушканга күрә...

Шушы – унҗиденче җәйдә мин беренче тапкыр үземнең туган көнем барлыгын белдем, офыкның икенче ягында яшәп алдым һәм фәрештәдәй Миләүшә апага бүтән адашмам, дип алдаштым. Бөтен кеше дә Туган җирендә генә яшәсә, фаҗигаләр азрак булыр иде. Язучының һәр әсәрендә – югалту фаҗигасе.

Ә хәзерге минутта: Ватаным, әнием, туган авылым, кыскасы, бөтен киләчәгем шушы вагон инде минем өчен...

***

Нәкъ ун ел узгач, институтта кышкы имтиханнарны тапшырдык та Нуриәхмәт кызы белән икәүләшеп, Ташкент каласын үртәп, акча туздырып кайтырга булдык. Самолёттан төшүгә, теге эскәмияне таптык – урыныннан күчмәгән, буяулары гына калынайган... Февраль Үзбәкстан өчен иң салкын ай икән, мосафирлар фонтанын сүндереп куйганнар... «Приёмник-распределитель»гә килгәч, минем белән ишек аша гына сөйләштеләр. Миләүшә апа күптән инде ялга киткән булып чыкты, бәби көтәләрдер дип аңладык. Адресын сораган идек, шундый итеп сүгенделәр – калай ишек зыңлап торды.

Тәрәзәдән булса да, Үзбәк-хан биләмәләрен карап барырбыз дип, Шаватка

поезд белән китәргә иде исәп. Билет юк, диделәр. Фамилиямне хөрмәт итегез, дигәч, паспортымны сорадылар. Ул елны инде Үзбәкстан компартиясенең Беренче секретаре Ислам Кәримов иде... Билет таптылар... (Хәер, поезд вагоннары яртылаш буш иде.) Ташкент – Шават арасы да Мәскәү – Казан арасы чаклы икән. Яшермим, безнең сәяхәтнең төп максаты, тыныш билгеләре кыйммәткә төшкән теге телеграмма хакында белешү иде. Баштан ук элемтә бүлегенә кереп ачыкларга исәп бар иде дә, кире уйладык. Җизнине күреп сөйләшик, дидек.

Таш пулатка охшатып салынган саман өй, эче-тышы измә белән сыланып агартылган. Халык идәндә яши. Киләсебезне телефоннан сөйләшеп, хәбәр итеп өлгергән идек, безнең өчен җайның (өйнең) бер почмагына «урыс өстәле» куйганнар. Апамның инде дүрт баласы бар, бишенчесе дә туачагын сиздереп тора. Җизнинең, кайчан карасаң да, тел астында насвае, берәр сорау бирсәң, урамга чыгып, тиз генә төкереп керә.

Студентның вакыты санаулы, иркенләп кунак булырга исәп юк. Икенче көнне үк Нуриәхмәт кызы урамдагы балаларга конфет өләшеп йөргән арада телеграмма хакында сүз кузгаттым.

Апам дәшмәде. Тәрәзә төбенә барып таянды. Җизни насваен тартып өлгермәде.

«Телеграмма җибәргән сәгатьтән башлап, җиде көн көттем».

«Ун ел элеккене хәтерләмим инде».

Апам тамак кырып куйды. Җизни нәрсәдер исенә төшерде кебек.

«Ә-ә, телеграмма! Срочные да, простое да тигез йөри аның. Кәгазен китермиләр. Районнан безнең почтага телефоннан гына шалтыратып әйттеләр бугай».

«Ул вакыт эчендә Ташкентны ике-өч тапкыр әйләнеп кайта ала идегез».

«Мин шаяртасың дип уйладым. Шутник ич син».

«Телеграмма белән шаяртып булмый».

«Соң, яшь егеткә Ташкент – Шават арасы, товарный поезд белән дә килә ала идең инде. Ә болай миңа туда-сюда...»

Җизнинең бөртек чәйдән бушаган калай савытында насвае беткән иде, күршегә үтечкә кереп китте.

Апам, ләм-мим, ике тәрәзә арасындагы агач рамлы көзге артында актарынып, миңа дүрткә бөкләнеп кипшегән телеграмманы алып бирде.

«Җизнәңә күрсәтеп торма инде. Үзеңә алып кит...»

***

Кайтканда, без Нуриәхмәт кызы белән Ургәнечтән Ташкентка да, Ташкенттан Казанга да самолёт белән генә очтык. Ни хикмәттер, икебезне дә кисәк кенә Казанны сагыну, андагы дусларны, туганнарны күрәсе килү шаукымы биләп алды...

Инде ун елга өстәп, тагын кырык ел үтеп китте. Җиңгәгез белән Караком чүленә барып килергә һич кенә дә вакыт таба алмыйбыз...

## Әгәр дә мәгәр...

Әгәр мәктәпне тәмамлаган елны ук хәзерге акылым булсамы?! Мин үз-үземә киңәш бирер идем: «Синең өчен генә үскән кызны эзләп табам дисәң, иң әүвәл институт бетерергә кирәк! Шул ук вакытта, укытучыларыңны сөендерәм дип, аттестатыңны кабул итү комиссиясенә илтеп бирергә ашыкма. Классташларыңнан үрнәк алма, алар син түгел... Син – сабырсыз – кулыңа

кергән һәр яңа техниканың тизрәк эчен ачып карыйсың килә; яңа кызлар белән танышкан көнне үк, илһамланып, мәхәббәт хатлары яза башлыйсың; кызганучан йомшак күңелең мин-минлегеңнән көчлерәк; Зәмзәмияләрнең яшьлек хатасын төзәтәм, дип, үзең хаталанырсың; «Ир кешенең өч мактанычы бар – өй салу, агач утырту һәм бала үстерү» дигән кагыйдәнең син берсен генә үтәп өлгерерсең, өең салынмаган, агачың утыртылмаган килеш калыр... Әгәр егерме алты яшеңдә көндезге бүлеккә укырга керсәң, экологик яктан иң чиста районда туган һәм синең өчен генә үскән Нуриәхмәт кызы көтеп торыр! Язмышыңны ашыктырма!» – дияр идем мин үз-үземә.

Әгәр дә мәгәр беренче елны ук университетка керә алган булсам, мине – егерме ике яшьлек «белгечне», Чулман аръягындагы алимент түләтә торган төбәкләрнең берсенә, район газетасы хәбәрчесе итеп җибәрәселәр иде... Түбә мәсьәләсе соңрак хәл ителер, әлегә менә шушы Фәлән Фәләнова апаның курчак өе кеби фатирында яшәп торырсың, диярләр иде... Әлбәттә, ул апаның утлар-сулар кичкән, әмма җиләк рәсеме кебек бер кызы булачак... Кыскасы, бер ел эчендә үк мин: «мәхәббәтнең гарантиясе тугыз гына ай», – дип, «кияү бәпкәчем»нән «бәдбәхет лөхер»гә әверелеп, ошбу курчак өеннән Чулманның бирге ягына кайтып егыласы кеше. Кечкенәдән шагыйрь булырга хыялланган малайның канатлы аты Фәлән апа Фәләнованың бәрәңге бакчасында буразна ерып, гомер буе ябылуда ята алмаячак. Мин, пегаслар-дөлдөлләр көтүенә кушылып, тургайлары сайрап торган болытларга карап, Мишә тугайларында тышауланырга, Идел аланнарында бәйге тотарга телим...

Әгәр дә мәгәр миңа хәзерге акылым белән яңа баштан яшәргә мөмкин булсамы? Шушы ук тормыш юлым кабатланыр иде...

Безне кечкенәдән кемнәрдер яшәргә өйрәтә: алай итмә, болай ит; монда түгел, анда кит; мине тыңла, аны санла; эшлә дә эшлә, каршы дәшмә! Һәркем безне үзгәртергә тели, һәр остаз безнең үзенә охшавыбызны тели. Остазлар күбәйгән саен Үзең булып калуы кыен...

Чү, энекәш, күрәчәгеңне алдан ук язып куйган язмыш бар бит әле, диярсез... Дорфалыгым өчен кичерегез, зинһар, мин икмәк, гаилә, кайгы-хәсрәт, табигать һәм язмыш дигән иң борынгы сүзләрне бүгенгечә аңларга тырышам. Язмыш дигән төшенчәне: табигать стихиясе каршындагы көчсезлектән; котылгысыз хаста; төзәтә алмаслык хата; вакытсыз үлем фаҗигасе алдында чарасызлыктан куллану – кайгылы халәттә бер юаныч ул. Һәм бу язмыш чиксезлек белән идарә итүче Ходай кодрәтендә.

Ә инде үзебез бозган әхлак кануннарын, кылган җинаятьләрне, гаилә низагларын, байлык корбаннарын, мәхәббәт маҗараларын язмышка сылтап, без акланабыз гына. Бу очракта ул язмыш түгел, ә холкыбыз, темпераментыбыз; тумыштан килгән каныбыз, ягъни җиде буынгача сакланып киләчәк нәселеңне хәл итә торган генетик материал һәм алган тәрбиябез нәтиҗәсе генә... Хәтта бөтендөнья сугышларының башлануы да холыксыз җитәкчеләр ялгышы...

Алтмыш миллион нәсел агачын кыйган Бөек Ватан сугышы афәте дә, сыйнфый дошманнар кулыннан шәһит киткән агайларым да бар биографиямдә... Болар барысы да гаделлек кагыйдәсен бозган шәҗәрәләр бәрелеше генә.

Әтинең бер фотосы исән калган, мин үземне шуңа карап кына төсмерлим. Ә холкын әнием теленнән генә ишетә идем.

...Атаңның сүзе үтә торганые.

...Байлыкка исе китмәде, ризыктан өзмәде.

...Туры сүзле, җор телле булуы аркасында күпме кыен алды. Үҗәт иде.

...Үз эшенә ялкау гына, ну кешегә ярдәмчел иде.

...Атаңа охшасаң, өч хатынга җитәрсең әле.

...Өй салу турында үлгәнче хыялланды.

...Юмарт иде. Сараннарны, куштаннарны, усалларны җене сөймәде түлке. Йомшак күңелле, кызгана торган кеше иде, мәрхүм... Авыр туфрагы җиңел булсын...

Әни боларны кат-кат сөйли торган иде. Бактың исә, әтинең холкы минем биографиямнең программасы кебек(!). Моны аңлау өчен әүлия булу кирәкми... Дөрес, мин мал врачына укымадым. Ләкин улым Ветеринария институтын Кызыл дипломга бетерде. Барыбер дә әтиемнең фамилиясе үзенекен итте...

Әнинең гөманлавына ышансаң, мин әти язмышының өч хатынлы программасын кабатларга тиешмен икән... Агач курчаклар да өчәү иде. Димәк, исемсез хатны юллаучы ханым үзен дә кушып саныйдыр. Һәм ул хатны хәзер Нуриәхмәт кызына тоттырсам, «Өченчесе кем?!» – дип, төгәл җавап ишеткәнче тынычланмаячак.

***

Егерме җиде яшемдә бала-чагалар арасында студент булып йөрүемнең әллә ни җайсызлыгын күрмәдем. Педагогларның күбесе миннән биш-алты яшькә кече һәм алар миңа «Сез!» дип дәшәләр иде. Семестр саен имтиханнарда өстәмә сораулар биреп интектермәделәр, турысын әйтсәм – мактадылар, ялгыш сүз ычкындырсам – ишетмәмешкә салыштылар. Берсендә ике студентыбыз чит ил әдәбияты тарихыннан зачёт тапшыра алмады. Икесе дә стипендиясез кала дигән сүз...

Ул елны (1978) «Казан утлары» журналында «Тәнәфес» дигән күләмле хикәям басылып чыккан иде, конкурска эләгеп, өченче урынны да яулаган иде әле абзагыз... Кыскасы, ул хикәя өчен дүрт айлык стипендиягә торырлык гонорар алгач, партадашларыма мактанганымны хәтерлим. Шуны искә төшерделәр дә «Усалка»ның өенә җибәрделәр. «Усалка» дигәнең, Миләүшә Шәйхиевна, үзе турында сөйләргә бик яратмый, шәхси тормышына ишарәләп сорау бирсәләр, чит ил әсәрләреннән алынган канатлы җөмләләр белән генә җавап кайтара. Үз фәнен генә өзелеп сөя, семинар дәресләренә әйтелгән романнарны укып чыкмасаң, чыраең читкә бора да минут дәшми тора, өйгә бирелгән эшне әзерләп килгән балаларны алдына утыртып, көнбагыш чәчәге төсендәге кулъяулыгы белән борыннарын сөртергә дә риза. «Усалка» дигәнебез – Шәйхи Маннур кызы булып чыкты. Төркемебезнең старостасы – Миләүшә, аның адресын деканатка кереп белешкән, әти-әнисе белән яшәми, аерым фатирда тора, диделәр.

Журналдагы хикәям читенә: «Күренекле язучыбызның сөекле кызына!» дип култамга салдым да ике зачётка янына лафсан букчага шудырдым. Зур сынауга киттем. Йә институттан куалар инде мине, йә җиңүче булып кайтам – икенең бере! Беткән баш беткән – юл уңае «Токайское» дигән шәраб белән бер шоколадны да журнал янына кыстырдым.

«Усалка» кушаматы тиктомалдан гына кушылмагандыр, кыңгырау төймәсенә баскач та, «Кем анда?» дигән сорау ишетелмәде, шундук ишек ачылды.

«Сез?!» – дип аптырап калуы хак анысы, көткән кешесе мин түгелдер. Бусагада басып калдым.

«Журналдагы хикәямне бүләк итмәкче идем...» – Каушавымнан шуннан ары аклану сүзе табылмады.

«Иртәгә лекциям бар ич, шунда... – Миләүшә Шәйхиевна тагын бер сүз

әйтсә, каушавымнан гафу үтенергә дә онытып, чыгып йөгерә идем инде. – Әйдәгез, әйдә, керегез».

«Шәйхи Маннурның безнең Шәле мәктәбенә килгәне бар, Муса Җәлил турында кызык итеп сөйләгән иде».

«Усалка» гүя мине ишетмәде дә.

«Ә сез түргә узыгыз. Ботинкагызны салыгыз. Әнә анда җиңел аяк киеме бар».

«41»ле аягыма «38»ле тапочка элдем, никтер ирләр өчен дигәне бөтенләй юк иде.

Әле кояш баемаган, ләкин өй эче эңгер-меңгер генә, яшел түбәле лампаның яктысы язу өстәленнән ары таралмый. Шуңа күрәдерме, бүлмә эчке яктан калын кара бәрхет белән түшәлгән кебек. Ул эңгердә югалып, минем өчен каяндыр такта табуретка алып килде, ә үзе өстәл артындагы күн кәнәфиенә чумды. Әлеге тынлык тагын имтихан вакытына охшап калды.

Журналдагы култамганы укыгач, ул көрсенгән рәвеш китереп кенә елмаеп куйды. Аннан күз алдындагы кәгазьләрен тәртипләп, читкә өйде.

«Ашыйсың киләме? Кәтлит җылытам. Чәй куям, тартынып торма... Әйт.»

Чәй сүзеннән, тәнемә шундук җылы йөгерде.

«Юк, юк, рәхмәт! Тамагым тук!»

«Студентлардан «тук» дигән сүз ишеткәнем юк.»

«Мин бит укудан соң эшкә йөрим. Укырга кергәнче дә су бораулаучы булып эшләдем».

«Алайса, бай студент инде».

«Ну, байлыкны үзең белән күтәреп йөреп булмый... Мин аны калдырып киттем... фатирым белән бергә. Хәзер яңадан яшим... Тамак тук, өс – бөтен!»

«Минем әти кысмыр иде шул. Кибеткә чыкканда, 28 тиене кефирга, 16 тиене ипигә, 3 тиене трамвайга, дип, санап кына бирә иде».

«Нигә, иде, дисез? Ул исән бит әле?»

Минем сорауны караңгы бүлмә йотты.

«Менә сез укудан соң эшләп тә йөрисез. Ә үзегез зачётларны, имтиханнарны да вакытында тапшырып өлгерәсез».

Педагогның мактау сүзләреннән кыюлана төштем.

«Мин бары тик үземә үзем генә таяна алам. Нәселебез шундый. Миләүшә Шәйхиевна, сез – язучы кызы белән хикәямнең сөенечен уртаклашырга теләгән идем».

Һәм мин, курку хисем уянганчы дип, күчтәнәчемне тизрәк өстәлгә куярга ашыктым. Ул шешәне кулына алды. Әгәр кире бирсә... Берьюлы ике бала стипендиясез кала бит инде... Юк, әйләндереп-әйләндереп, этикеткадагы бөтен текстны кычкырып укып чыкты.

«Педагогик практикамда беренче тапкыр...»

«Мин дә беренче тапкыр... Миләүшә Шәйхиевна».

«Йә, ачыгыз инде алайса. Ришвәт түгел ич!»

Кыска торыклы, юан фужерлар күз алдымда калган... Секундлары минутка торырлык вакыт... Шоколад ашалып бетте, ә шәраб яртылаш тора.

«Миләүшә Шәйхиевна, стипендиясез калалар бит!»

«Ник килгәнеңне баштук аңладым инде. Китер, зачёткасын. Кайсы кызны яклап йөрисең икән!»

«Икесен дә шул...»

«Икәү?! Ужас! – Тагын тынлык. – Йә, ярар. Надан кеше барыбер укымый инде. Укыганы – эшләп тә укый!»

«Миләүшә Шәйхиевна, кафедрага кереп, ведомостька да кул куярга онытмагыз инде, зинһар. Юкса «незачёт» булып күренә бит...»

«Борчылмагыз, бу хурлыкка түзгәнне, анысына гына ничек тә чыдармын...»

***

Минем өчен иң авыр фән – КПСС тарихы иде. Коммунистлар партиясе 27 тапкыр съезд үткәргән. Һәм аның һәркайсы имтихан вакытында аерым сорау булып бирелергә мөмкин... Шушы 27 игезәкнең кайсы кем икәнен танып кара да кемнәр чыгыш ясаганын, нинди карарлар кабул ителгәнен, иң мөһиме – 27сенең дә тарихи әһәмиятен сөйләп бирергә әзер тор. Әгәр тарихтан «2»ле куйсалар... тагын биш-алты ел хыялланасы була, җитмәсә, көндезгә бүлеккә утыз өч яшькә чаклы гына кабул итәләр. Ә мин бары тик көндезгә бүлектә укырга тиеш! Читтән торып уку минем өчен ул – читән аркылы карап йөрү кебек; сөйгән кызың белән хатлар алышып, читтән торып сөю сыманрак нәрсә.

Тарихи хурлыктан мине шәҗәрәм коткарды. Имтихан алучы педагог – милли каһарманыбыз, тарих фәннәре галиме Марат Мөлеков булып чыкты. Марат Абдурәсүл улының Шәле мәктәбендә директор булып эшләгәнен беләм. Ә минем әби (әниемнең әнисе) мәктәптә бик кирәкле кеше, гомер буе мич ягып, классларны җылыткан, мәктәп атын караган, көн саен берүзе төнге каравылда торган һәм күрше авыллардан килеп укучы балаларга күз-колак булыр өчен интернатның бер бүлмәсендә яшәгән.

Марат абый минем кем оныгы икәнемне белгәч, Миңлебикә әбиемнең үзен күргән кебек сөенде. Ун минут буе авыл турында сорашты. Сорауларына кызык итеп җавап биргәч:

– Сезгә «дүртле» җитәме? – диде.

Бик җитте! Укырга кердем... Әти сызып биргән язмыш программасын әкренләп үтәргә тотындым.

Филология факультетларына кул селтәп, Мәдәният институтына барып керүемнең сәбәбе бик гади – язучы булалмасам, сәхнәгә ябышып калырга исәп. Дин – халык өчен әфьюн ул, дип, нык ялгышкан Ленин бабай, сәхнә ул – әфьюн! Бер мендәңме, төшәсең килми, ике ягыңнан ике гармунчы тотып чыгарганчы тәки йөрисең. Үлгәч кенә, сәхнәдән табутка салып төшерәләр, алкышлардан туя белмәдең, дигәндәй, дәррәү күтәрелеп, кул чабып, мәңгелеккә озаталар...

Композитор Зиннур Гыйбадуллин тырышлыгы белән 1977 елда «Шәле тәрәзәләре» дигән җыр яздык. Мирсәет Сөнгатуллин башкаргач, җыр тиз таралды, концертларга чакыра башладылар. Укулардан качып кына якын-тирә авылларда концертлар куябыз. Шаян шигырьләремне, юморескаларымны сыныйм; Фәридә Кудашева, Габдулла Рәхимкулов, Усман Әлмиевләрне үртәп җырлыйм да хәтта! Ә инде Мәхмүт ага Хөсәен булып сөйли башласам, кемлегемне дә онытып җибәрәм... Кыскасы, әкренләп икенче профессияне дә үзләштерәм, эстрада берәүне дә ачтан үтермәгән.

Ләкин... Бәхетсезлек бәхет эзләүдән башлана...

Минем һәвәслекне студентлар сизеп алды. Читкә йөрмә, имеш, үзебез бер төркем оештырабыз, кассаны тигезләп бүләбез, янәсе. Институтка керү өчен таләпләр зур, вокал, уен кораллары, хореография бүлекләрендә талантлар шыплап тулган – филармонияң бер читтә торсын.

Кыскасы, төзелеш оешмасының тулай торагына Казан дәүләт Мәдәният институты дигән баш астында белдерү элдек, билет бәясе – 50 тиен, кечке

алтыда башлана, катнашучыларның исемлеген төзедек... Коеп куйган компромат!

Концерт куясы көнне иң ашыккан «артист» мин идем. Тулай торакның бусагасын атлап керүемә, ачу китергеч матур итеп киенгән, мин килгәнне ишек артында гына качып көтеп утыргандай, капылт, бер чиновник каршыма килеп басты:

«Комсомолның Идел буе райкомы секретаре Шәрәфетдинов... Ә сез кем буласыз?» – дигән соравыннан, бер мәлгә, кулга алынган гаепләнүче кебек, коелып төштем... Аннан соң бу начальник минем яшьтәштер әле, дигән уйдан кыюланырга теләдем.

«Нинди документ? Мин бит кызлар янына килдем».

«Ну, катыргың булмаса, хәзер милиция чакыртабыз. Кемлегеңне ачыклар өчен алып китәрләр».

Милиция дигән сүздән минем табан астым кычыта башлый. Чыгып качсам, куып тотарлар да 15 тәүлеккә ябып куярлар, минәйтәм. Аннан – хуш, институт, «прощай молодость».

Ике кесәмдә ике катыргы бар: берсе студент билеты; икенчесе... өч атна элек кенә бирелгән, кызыл күн тышлы, кургаш хәрефләр белән тутырылган, КПСС Өлкә комитеты органы, миллион тиражлы «Чаян» журналының штаттан тыш хәбәрчесе дигән таныклык.

Озак уйлап торасы юк, үз кулларым белән үземне институттан кудырта алмыйм бит инде...

«Чаян» кәгазен кулына тоткач, теге Шәрәфетдиновның ничек сөенгәнен күреп, елмаеп куйдым хәтта: менә шундый мактаулы кеше инде мин!

Сөенеч шул мизгелдә көенечкә әверелде.

«Әһә, редакция! Димәк, концерт билетларын типографиядә бастыргансыз!..»

Алга таба ике ай гомеремне биографиямнән сызып кына ташлар идем мин... азагы сәнгати маҗара белән бетмәсә!

Иртәнге унга алты кешелек халтура төркеме Ректорат хөкеменә чакырулы идек. Эшнең зурга китәсе билгеле, утырыш алдыннан бер киңәшеп алырга кирәк иде. «Кызыл почмакка» җыелып, кеше күзенә артык чалынасыбыз килми, Ирнат Даушов, Марат Яхъяев һәм Вәсиләнең (Пәрәү авылы кызы, фамилиясе хәтердә калмаган) диплом аласы еллары – еламыйлар гына. Ә биюче кызлар, мин күрмәгәндә, елап та алалар бугай. Бөтен хыяллары чәлпәрәмә килә тегеләрнең... Әгәр эти 1950 елда туган булса, хәзер нинди карарга килер идеме?!. Бөтен гаепне минем өскә өяргә, дип сөйләштек, оештыручысы да, үгетләүчесе дә, билет ясаучысы да – мин, берүзем! Нишлисең бит, чынга ашмаган хыяллар күп инде ул... Кире борылырмын да су бораулау эшенә китәрмен. Акча түләп укытып, прораб итәбез сине, китмә, китмә, дип ялынып калганнар иде. Эстрадага да минем кебек дипломсызлар кирәк... Югалмам.

Институт тарихында ректор бүлмәсенә чакыртылган студентлар бик сирәктер ул. Бу яктан караганда, мин бераз бәхетлерәк тә әле(!). Беренче булып мин җавап тоттым.

Ректор баш хөкемдарролендә түрдә утыра, ике якка проректор, партоешма секретаре, деканнар урнашкан, урындыклары тирән эчле, өстәлләре елкылдый. Миңа утыргыч табуретка да юк... Хөкемнәрен көтеп басып торам. Биектау судында Зәмзәмия белән аерылышкан минутларым искә төште... Алты айдан кабат килерсез, бәлки, татуланырсыз, дип кайтарып җибәргәннәр иде. Хөкемдарларның чыраена караганда, бүген татулык турында сүз бармас...

Рәхилә Абдулловна миннән ярты сәгать буе сорау алды. Ректорат дигәннәре балбал кебек өнсез утыра...

«Сиңа уку мөһимме, әллә акча эшләүме?»

«Алты кешегә бүлсәң, сигезәр сумлык билет сатылган иде инде. Шул да булдымы акча?! Мин буровойда аена алтышар йөз алып эшли идем».

Балбаллар фән өлкәсендә әрәм ятабыз, дигәндәй, кинаяле елмаю белән Рәхилә Абдулловнага төбәлделәр.

«Акча яраткач, Мәдәният институтына кермиләр аны. Һөнәрне дөрес сайламаган син!»

«Дөресен дөрес иде дә... 40 сум стипендиягә калгач, җайсызрак икән шул... Әле бит 25 процентыннан алимент та түлим, рәсми төстә».

«Тукта, стипендиядән алимент тотыламыни? Ун ел буе ректор булып эшләп, минем практикада мондый хәлнең булганы юк иде әле...»

Әлбәттә, алимент алу кагыйдәләрен белмәгән хатын-кыз юк, Рәхилә Абдулловнаның балбаллар арасындагы берәүне үзенчә чеметеп алуы иде бугай. Һәм ул гаепләүнең икенче өлешенә күчте.

«Сине концертка кем чакырды?»

«Мин үзем... Аудиториядән-аудиториягә кереп, үгетләп йөрдем. Берсенең дә барасы килмәгән иде, мине кызганып кына ризалаштылар».

Җавабым ректорга бик ошады.

«Әйе, без – талантлар институты. Һөнәри фәннәрдән укуы бик авыр. Сизәм, бик күбесе халтурага йөри. Нәтиҗәдә, өлгереш түбән, «койрыклар» күбәя, имтихан-зачётларны кабат-кабат тапшыру шуннан килә».

«Мин өлгереп барам. Койрыкларым юк».

«Син башкаларны артка сөйрисең, димәк. Әйт әле, билетларны кайда бастырдың?»

«Тулай торакта. 29 нчы бүлмәдә».

«Нәрсә? Син типографиядән клише эшләтеп чыктыңмы? Бу бит уголовный эш!»

Рәхилә Абдулловна ярсуын тыя алмыйча, утырган җиреннән сикереп торды.

«Гафу итегез, клише кургаштан коела. Ә мин амбарда ашлык төйи торган транспортёр каешыннан эшләдем».

Ректор апа җыеп алынган билетларны әйләндереп-әйләндереп карады.

«Ялган сөйлисең. Болар типография әсәре...»

Безнең нәсел агачы борчак чеме түгел, шәҗәрәбездә ялганчылар юк. Шаяртып, үртәп сөйли алам, вәләкин, моңарчы, ялганлап котылу минем уен түгел иде. Гаепләүнең җавапка тарттырырдай соравы нәкъ шушы булачагын алдан ук белдем. Билет калыбы кесәмдә иде, ректорның кулына тоттырдым. Һәм каеш дәлилем кулдан-кулга күчте. Балбалларым аны күзлекләрен бер салып, бер киеп, җентекләп карадылар. Ышандырыр өчен мин аңлатма биреп тордым. Чынлап та, ялгансыз – дөнья файдасыз икән.

«Башта, билет, контроль, бәясе 50 тиен, дигән сүзләрен яздым. Һәр хәрефен лезвие белән юнып утыруы бик мәшәкатьле иде, шуңа күрә институтның исемен кыскартып, КГИК дип кенә яздым».

«Талант! Коеп куйган художник икәнсең».

Кая инде ул миңа андый талант... Кояш рәсемен дә ясый белмәгән кешегә. Әлеге каеш штамп, баянчыбыз Ирнат Даушовның ике көнлек хезмәт җимеше. Институтта рәсем дәресе кермәгәч, шәкертләрнең бу төр һөнәрен кем белсен?!

«Бу экспонатыңны сейфка биклим. Бар, чык! Яхъяевны чакыр!»

Төп оештыручыны ачыклагач, калган халтурщикларны алай озак интектермәделәр. Килешенгәнчә, бөтен гаепне минем өскә өеп чыктылар. Ләкин Ректорат үзенең катгый карарын әйтмәде. Тәнәфес саен «Белдерүләр тактасы» янына килеп басам. Әле ике ел элек кенә шушы тактада кабул ителүче абитуриентлар исемлегендә минем фамилиям дә балкый иде. «Институттан куарга!» дигән приказ чыгарып элсәләр...

«...За систематически пропуск занятий и грубое нарушение студенческой этики» дип...

Хурлыгыңнан тагын Магаданга китәрсең...

Менә нинди була икән ул билгесезлек тынлыгы: мин бар да, юк та, үзем аудиториядә утырам кебек, ә күңел эш эзли; төннәр буе уйланып ятам, көндез аягүрә йоклап йөрим; тәнем бар, җаным юк... Ә шулай да лекцияләрне язып барырга тырышам, бер-ике көн генә булса да, югары белемне эләктереп калырга исәп. Курсташлар, дәрес барышында миңа борылып-борылып карыйлар, әллә кызганып, әллә «Корыч»лыгыма сокланып – аңламассың.

Бер атнадан минем эш комсомол комитетында яңадан кузгатылды. Бу юлы үзем генә җавап тотам. Төркемдәгеләрне гафу иттеләр! Сорауларын да көтмичә, ректорат алдындагы аклануларымны тагын сөйләп бирдем. Хәер, минем сүзнең әһәмияте юк иде инде. Комсомол секретаре Пичугинның әмере алдан ук язылып, машинкада басылып, имзасы куелган иде:

«За недостойное поведение... исключить из комсомола...» Укыган кешеләр белә булыр, комсомолдан чыгару – институттан куылу дигән сүз.

Маҗара бетмәде әле... Приказ укылгач, кинәт кемдер якам белән муен арасына боз сөңгесе шудырды кебек – сискәнеп уяндым гүя.

«Мин бит комсомол түгел!»

«Ничек инде?! Институтка ничек кердең соң син, комсомол булмаган килеш?!»

«Рабфакта сорап тормадылар... Безнең буровойда мин бердәнбер билетлы кеше идем. Минем өчен генә комсомол ячейкасы оештырмадылар. Башка оешмага барып учётка басарга кушканнар иде. Кая инде ул, җыелышларына кайтып йөрү? Елның 365 көне кырда уза. Еллык отпусканы да ял итмәдем, акчалата гына ала идек... Билетым кесәмдә йөреп тузды...»

Пичугин әмерне беркетмә язып утыручы егетнең битенә бәргәндәй итте.

«Немедленно комсомолга алырга! Аннары куып чыгарырга!»

«Гафу итегез, комсомол яшеннән уздым бит инде мин...»

Шуның белән шул, утырыш тәмам.

Тагын теге тынлык...

Минем эшне деканатка тапшырганнар. Ә декан... курсташлары хәл итсен, дигән.

Менә кайда икән ул чын хөкем! Академ-җитәкчебез (Ленинград институтын тәмамлап килгән сеңелкәш) «куарга!» дигән фикерен җиткерүгә гаугa җәнҗалы купты. Ярты сәгать кычкырышкач, тавышка куйдылар. Фифти-Фифти! Унөчкә-унөч.

Төркемебезнең старостасы Миләүшә муенындагы челтәрле шарфын салып, тәрәзә төбенә ыргытты да җыелышны яңадан башлады.

«Акылыгызга килегез! Беләсезме, кемне югалтабыз? Аның киләчәге билгеле! Ә без диплом алгач, «затейниклар» булып йөриячәкбез! Бу кеше белән бергә укыган идек, дип горурланачакбыз әле без...»

Арттырмыйм, киресенчә, Миләүшә өндәмәләренең әчмухасын гына әйттем...

Яңадан тавышка куйдылар. Бер кешенең күңеле йомшарды, күрәсең, ул

минем якка авышкач, баягы ничья 12 гә 14 белән мине яклап чыкты. Рәхмәт сиңа, Миләүшә сеңлем!.. Миләүшәләр мине гел коткарды.

Юк, мажара бетмәде әле...

***

Стипендия алганда, алиментчы буларак оялып, мин гел чиратның ахырына басам. Бер ведомостька кул куйганнан соң, кассирша миңа тагын бер кәгазь сузды, анысына да имза салдым.

Сөйләсәң, кеше ышанмаслык инде... Стипендия күләмендә «матди ярдәм күрсәткәннәр». Бу юлларны язганда, билләһи, җылыйм хәзер... Мин бит ярдәм сорап, гариза язмаган идем... Стипендияләре дә үзләренә булсын! Миңа бит Ленин бабай әйткәнчә: «Укырга! Укырга һәм укырга!» гына кирәк иде.

Институттан куарга теләгән кешеләрнең «матди ярдәм күрсәтергә!» дип фәрман чыгаруларын мин үземчә фаразлаган идем. Димәк, боларны бөтен халык алдында рисвай итсәк, башка студентларга да сабак булыр, дип кенә үткәрелгән бу «хөкем – шоу».

Ректор апаның аналарча тәрбия ысулы, ягъни мәсәлән... Һәрхәлдә, башкача җавабым юк иде ул чакта. Уку ахырындагы өч айлык практикам да Балтачта уңышлы гына үтте. Сәхнәләштерелгән «юмор кичәсе» өчен җитди генә бәя алдым – диплом эшемне «Отлично!»га кабул иттеләр.

«Сугышчан Дан ордены», «Батырлык өчен» медальләрен тагып төшкән бердәнбер фотосын кулыма алдым да: «Әти, без җиңдек!» – минәйтәм. Әти никтер күңелсез, ашыкма әле, диде, ахрысы.

Казанда калып, үзең теләгән эшкә урнашыр өчен Кызыл тышлы диплом алырга кирәк. Ә минеке ише шәмәхә катыргылыларны кайдан кадрлар кача – шунда эшкә куялар. Комиссия теге Зәмзәмиянең кайсы районнан икәнен белә булып чыкты, юлламаны Чулман аръягына бирделәр. Тагын әтинең тавышын ишетәм кебек: «Улым, Чулман кичүен чыккач та, алимент түләтә торган районнар башлана. Исән калсам, миңа 74 яшь тулган булыр иде, ну, мин дә анда китмәс идем. Җир йөзе кырыкка төрләнсә дә, ул якның кыз-кыркыны үзгәрмәс...» Әти әйтә моны...

Мин әти малае ла!.. Дипломымны дипломатка салдым да «Яшь ленинчы» редакциясенә киттем.

Шул көнне үк эшкә алдылар, икенче көнне командировкага да чыгарып җибәрделәр. «Холостой» кеше «холостой» патрон кебек бит ул, беркемгә зыяным тими, өйдә елап көтеп торучыларым юк. Әгерҗе, Актаныш, Яңавыл (Башкортстан) кебек иң ерак алты районның мәктәпләре – минеке, кайтып та кергәнем юк. Моңарчы хәбәрчеләр барып җитмәгән төбәкләрдән саллы язмалар әзерләнә, балалардан күпләп хатлар килә башлады. Баш мөхәррир Роза Туфитуллова аркамнан гына сөйми инде... Гәҗитнең гонорары да, хезмәт хакы да башка матбагаларга караганда шәбрәк. Берәр ел институтның күзенә чалынмавың да хәерлерәк, качып яткан яшь белгечне эт белән эзләтмәсләр әле дигән булам... Ә нужаның «кара сакалын» кая куярсың?!

Шулай, гонорар алу сәгате җитәрәк егетләр белән «мактау тактасы»ндагы юлъязмаларны санап торганда, коридорның Чулман ягына караган тәрәзәле ишегенә күзем төште. Кулларын кер чайкагандай җилпеп, туп-туры безнең өскә ыргылгандай килә бер ханым... Кем дисәң, теге – Зәмзәмия! Мин аны инде күптәннән күргәнем юк, тиз генә танымадым. Хезмәт хакым белән тәбрикләп, берәр сүз әйтә хәзер дип торганда, кырт борылып, баш мөхәррир

бүлмәсенә керде дә китте. Ярты сәгатьләп утыргандыр... Зөлфәт белән Госман Садә бүлмәсендә качып утырам. Зәмзәмия белән бергә-бер калсак, «кыска ялганыш» чыгарга мөмкин... Ниһаять, әллә ничә тапкыр ишекләр ачылып ябылды. Чүкеч үкчәле адымнар лифт ягына китте... һәм мин редактор янына атылып-бәрелеп кердем, бу «төшне» нәрсәгә дә булса юрарга кирәк ич инде. Роза Рәхмәтулловна «Вьетнам бәлзәме» сылаган кебек ике чигәсен ышкып тора. Үзе мине күрмәгәндәй генә сөйләнә:

«Каян эзләп таптың соң син аны?.. Миңа туган тиешле бит әле ул. Шул гына җитмәгән иде... Ярар, бар, мыштым гына эшләп йөр».

Бу сөйләшүне Зөлфәтләр ишетеп алган булса, «Редактор кияве» дигән кушамат тагалар иде инде миңа...

Өлгермәделәр...

«Яшь ленинчы»га, елына уналтышар мең хат килә иде... Ә бу хатны хәрби киемле курьер китерде. Прокуратурадан! Юллама белән озатылган җирдә өч ел мәҗбүри эшләргә тиешле яшь белгечне качырып яткырганыгыз өчен... Кичекмәстән эшеннән азат итәргә... Кисәтү үтәлмәгән очракта баш мөхәррирнең персональ эше парткомиссиядә тикшереләчәк.

Аңлашыла инде, кемдер минем өстән жалоба язган...

«Иптәш... эшеннән азат ителде» дигән приказның күчермәсен алгач, район прокуроры тынычланды. Ә мин, берни булмагандай, һаман эшкә йөрим. Редактор кушты. Җан тартмаса да, кан тарта дигәндәй... бөтен редакция белән туганлашып өлгергән идем шул.

Ул арада, беренче китабым басылып чыкты. Язучылар союзында урынбасар булып эшләүче Фәрваз Миңнуллин минем хикәяләрне бик ошаткан. Чакыртып, председатель Гариф Ахунов янына алып керде, ул Туфан Миңнуллин белән сөйләшеп утыра иде. Туфан абый мине күргәч: «Ә, Шәле кешесе, нихәл?» дип, сүзне «Идел» яшьләр лагерендагы иҗат семинарына борып җибәрде. Андагы биш ел элек булган мәзәк хәлләрне яңартып, көлә-көлә кинәнде. Гариф абый көлмәде, аны семинарга Шаһидә апа җибәрмәгән иде. Ландышлар чәчәк аткан чорда ирләренең бер атнага югалып торуын бик күп язучы хатыннары авыр кичергәндер...

Батулла, Разил, Сәхәби, Гөргөри дип, һәркайсын мәзәкләштереп утырган арада, мин үземнең прокуратурадан качып йөргәнемне сөйләп бирдем. Аңа да рәхәтләнеп көлделәр. Аннан, көлеп ардылар бугай, Туфан абыйга «партийное поручение» бирделәр: «Какраз Мәскәүгә барышың, Культура министрлыгының кадрлар идарәсенә кереп чык, хатны хәзер үк әзерләп бирәбез, көтеп тор бераз гына...» Ике Миңнуллинның кул биреп килешкәне күз алдымда калды.

Атна эчендә РСФСР Мәдәният министрлыгыннан Г.М.Самарин имзасы белән җавап килеп төште. 1981 елның 27 нче мартыннан Корыч малаен ТАССР Язучылар союзы карамагына күчерергә дигән рөхсәт хаты ул. Элеккеге аксакаллар менә шундый мәрхәмәтле иде.

Ике-өч хикәямне редакцияләп, «Яшь ленинчы»да бастырган балалар шагыйре Хәкимҗан ага Халиков белән бергә эшләргә насыйп булмады. Мин килгән елны ул инде пенсиягә киткән иде. Хәкимҗан абый үзенең 60 яшьлек бәйрәмен өендә генә үткәрде. Мине дә Нуриәхмәт кызы белән парлап чакырды. Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев һәм Туфан Миңнуллиннар арасында тост әйтергә чират көтеп утырам. Ниһаять, таралышыр вакыт җиткәч кенә, миңа сүз бирделәр. Минем ише яшь язучыны араларына сыйдырганнары өчен һәм дә яклап, Мәскәүдән хат алып кайтканы өчен аеруча рәхмәт әйткәч, Туфан абый сүз кыстырып алды:

«О, далеко пойдёшь!» – диде.

Мактанчык малайга күп кирәкме инде? Корыч канатланып тотындым шапырынырга. Бу бит әле минем беренче банкетым! Беренче дигән сүз бу очракта арифметик сан түгел, ә эмоциональ күрсәткеч буларак әйтелә: беренче укытучым, беренче китап, беренче мәхәббәт, ягъни мәсәлән...

«Хөрмәтле абыйлар! Безнең нәселдә интеллигентлар юк, язучы булырга хыялланучылары да – беренчесе мин, әби май язган, әни йон язган, абый очучы була язган. Шушы хыялым аркасында гаиләбездә «сөйкемсез сөяк» идем. Әти – сугышчы, әни – колхозчы, гомер буе хезмәт көненә эшләгән, 1971 елда 3 сум 40 тиенлек уртача айлык хезмәт хакы белән пенсиягә чыккан... Ә мин хыялыма чыдый алмыйча, ай саен 600-700 сум акча ала торган эшемне ташлап, 40 сум стипендияле укуга барып кердем...»

«Ну и дурак!» – дип куйды Туфан абый, башын як-якка боргалап...

Алдан ук әзерләнеп килгән нотыгым шушы урында өзелде, ачудан түгел, безнең Шәледә: «Җүләрем... И, дурак та инде син!» – дип, яраткан кешегә генә әйтү гадәте бар... Ә Нуриәхмәт кызы, җан кисәгем, экологик чиста яктан – Әгерҗедән бит. Ул якта дурак дип, бары тик дуракларга гына әйтәләр икән... Хәләлкәем сикереп тә торды, ванна бүлмәсенә йөгереп кереп тә китте. Мин аның артыннан... Краннан су агызган хутка такмаклый-такмаклый елый бу:

«Нишләп ул сине бөтен кеше алдында «дур-рак» дип хурлый. Бөтен кеше дә «карт язучы булып тумый. Без дә баербыз әле...»

Туфан абый килеп басты.

«Ну, сеңлем, шушындый шуткыны да аңламагач, ничек язучы хатыны булырсың икән син, ә? Ирең сәхнәдән юмор сөйләп җөри, ә син – шутки күтәрмисең. Каешланырга кирәк, сеңлем. Иҗат дөньясы «әлли-бәү» бишеге түгел ул... Җә, җә, бәйрәмне бозмагыз. Чык почмактан...»

«Үзегез аны Мәскәүләргә барып яклап кайткансыз, ә үзегез «дур-рак» дисез...» – Бу Нуриәхмәт кызының соңгы үпкәләү сүзе иде...

«Идел» альманахының җаваплы редакторы булып эшләгәндә, минем хезмәт хакым 100 сум иде. Ә Туфан абый Миңнуллинның айлык партвзносы гына да 300 сум. Һәм КПСС таралгач, иң нык сөенгән кеше – Туфан абый булды.

***

Ярый, инде 90 нчы еллар тирәсенә җиткәч, институтка керүем турындагы ошбу хикәямнең йомгагы кулга сыймый башлады, фикер очын төенләргә вакыт.

Союздаш республикалар СССР гаиләсен ташлап, аерым хуҗалык кора башлагач, безнең ил, ниһаять, демократик үзгәрешләргә әзерләнде. Татарстан Югары Советына депутатлар сайлау чын-чынлап бәйгегә әверелде...

«Чаян» журналында җаваплы секретарь булып эшлим. Хезмәт хакым – Туфан абый көнләшерлек!

Кичкырын ишекне шакыйлар. Ике телле журналда эшләгәч: «Да, да, заходите», – дигән булам.

Уртача буйлы, базык гәүдәле берәү керде. Ыспай киенгән, урамда яз уртасы булса да, ботинкасы ләпеккә басмаган, кар суы чәчрәмәгән, димәк җәяүле түгел... Алдан шалтыратып та килмәде, димәк, зур җитәкче дә түгелдер... Татарча чырайлы, русча сөйләшә торган, димәк, шәһәрдә туып үскән кешедер, дип, «Чаян» күзлегеннән сыный карадым.

– Мурат мин, «Сиразин компания» может слышали?

– Әйе, кайдадыр ишеткәнем бар...

– Ну, Куркачида, ЖБИ... Минеке краскалар чыгара. Балтач, Арча... Сары домнар... Минеке краска. Мин прессаны уважаю. Тарихны да. Трактирымда Бухарин музее бар, Татарстанда больше юк ул...

Кыскасы, Шәле теленә күчереп сөйләшкәндә, егетнең кунакка килү сәбәбе бигүк простой түгел. ТССР (хәзергечә ТР) Югары Советына сайлаулар якынлаша, ә Сираҗин иптәш депутатлыкка альтернатив кандидат булып катнашырга тели. Сайлау округы Казаннан ерак түгел – Биектау районы гына, рәсми теркәлгән кандидат шул районның исполком председателе иптәш Зәйниев икән...

Яшьлек әүхәте белән рухланып, урындагы түрәгә каршы либераллар байрагы күтәрергә тели икән – анысы инде Сираҗинның үз хокукы, ә мин монда «причём» дигән уй аптыраштa калдырды. Мурат мине бөтенләй белмәве өчен үкенде һәм гафу үтенде, моннан ары «Чаян» журналына ел саен язылачагына вәгъдә дә бирде һәм комарлы уен тәкъдим итте. Зәйниевнең «ышанычлысы» һәм дә якташы данлыклы артист Равил Шәрәфиев икән, алар төркеменә каршы йөрер өчен бүтәннәрнең хәленнән килмәс дип, мине үгетләп карарга кушканнар. Чын әгәр, ялганласа – гөнаһы Мурат Сираҗинга булыр.

Сайлау мәрәкәсенең уен кагыйдәләрен дә өйрәнермен бераз, журнал укучылары белән очраштык диярмен, үземә күрә түгел – күңел чормасында посып яткан мин-минлек коткысы да Шәрәфи феномены белән бил алышып карарга куша бит әле... Кыскасы, ризалаштым.

Беренче турда җиңүчеләр булмады...

Икенче турга чыгып киттек... Язның бик холыксыз чагы, юлларда карлы ләпек боламыгы, урамда эссе, клубларда газ мичләре сүндерелгән...

Ә халык йөри, көнгә икешәр юмор кичәсе карый. Равил Шәрәфиевнең койрыгы театрга бәйләнгән, ул авылларда көндез генә йөри ала. Тегеләр – иртән, мин – кич, тегеләр – кичә, мин – бүген... Равил абый салган сукмактан, Зәйниевнең вәгъдәләрен оныттырып, сайлаучыларны үз ягыма авыштырып барам... Татар авыллары булгач, кандидат өчен дә үзем сөйлим. Ләкин күңелне бер нәрсә кимерә: кайсы гына авылга барсак та, беренче рәттә минем онытылмас ректорым Рәхилә Абдулловна утыра!.. Чыгышларымны башыннан ахырынача тыңлый, кеше елмайган урында елмая, хәтта кул чаба! Сайлау комиссиясе җибәргән вәкилме ул, ун ел элек диплом алган һәм заманында институттан куылырга тиеш булган студенттан элеккеге ректор өстәмә имтихан аламы?!.

Һәрхәлдә мин каушамадым, ректор апага күңелсез булмасын өчен чыгышларымны кабатламадым. Телевизион «Шаян сәхнә»нең гөрләгән чагы: язган юморескаларым, монологлар, үртәүләрем тагын ике депутат сайларга җитә... Сайлаулар гадел узган очракта...

Икенче турда Мурат Сираҗин җиңде

Коркачыктагы «Трактиръ»да бу җиңүнең тантанасына җыелдык. Табын тирәли урнаштык. Ни күрим: минем каршыда тагын ректорым утыра. Пенсиягә чыккан кешегә охшый, әмма дә ачу китергеч чибәр һәм төзек үзе!

Сираҗин белән янәшә утырудан файдаланып, ректорга ымлап сорап куйдым:

«Мурат, син дә Культура институтын бетердеңме?!»

«Юк. Ул минем тётя!» – диде яшь депутатым, горурланып.

...Менә, әти, тагын бер түти...

«Әгәр белгән булсам... Ни шагу бы с тобой!» – дидем дә русчалатып, ачуымнан кырт сикереп тордым.

Кунаклар мине тост әйтә дип белеп, кул чаптылар. Ходай сабырлык бирде, табынны ташлап чыгып качмадым, ни дисәң дә, «культурный» дигән дипломым бар.

«Уникe көн буе сөйләдем... Сүз бетми ул... Якты дөньяга килгән икән – кеше һәрвакыт нindидер исемлектә теркәлеп торырга тиеш... Исемлеккә кермәгән кеше – ул хәбәрсез югалган солдат кебек. Сираҗин бүген яңа исемлеккә керде. Җирдә югалган шәһәрләрнең, югалган авылларның, югалган олы шәхесләрнең исемлеге бар. Ләкин югалтучыларның исемлеге юк...»

Һай, мин, Чирәм җир сөргән малай, тракторым читкә каера, буразнам кыегая...

«Бер генә кеше дә үзенең җитәкчесен сөйми. Әйе, әйе, бу турыда ачыктан-ачык әйтмәсә дә, сөйми... Ну хөрмәт итә! Культура институтына рәхмәтем зур, мин анда үзем өчен генә үскән Нуриәхмәт кызын очраттым... Ауган агачка тукран да кунмый... Әгәр дә мине институттан куган булсалар (сәхнә кануннарын бозып, чамасыз озын пауза ясадым)... бүген Мурат Сираҗин депутат була алмый иде...»

«Шулай! – дип хуплады Мурат. – Што верно – то верно! Зур рахмат!»

Рәхмәттән соң бокаллар да күтәрелде үзе. Ләкин инде мәҗлес ректорат утырышына борылды. Рәхилә Абдулловна сүз алды.

«Сез мине гафу итәргә тиеш! Бер потокта, читтән торып укучыларны да санап, мең ярым студент. Барысы да конкурс белән сайлап алынган талант! Сәнгать – ул рухи азык. Талант – ул тиз бозыла торган ризык кебек. Аны саклавы җиңел түгел. Талант – ул борынгы Грециянең акча берәмлеге дә. Студентлар дәрестән кача, концертлар куя, банкетларда уйнап-җырлап акча эшләргә тотына. Успеваемость түбән. Бер имтиханны икешәр-өчәр тапкыр тапшыралар... Мәгариф, Мәдәният идарәсеннән бер-бер артлы инспекторлар килә башлады... Нәкъ шул вакытта... сез кайнар кул астына эләктегез... Но, группагыз саклап калды бит үзегезне... Сез мине дә аңларга тиешсез...»

Тост түгел иде бу, бокаллар чәкешмәдек. «Айфара» төркеменнән килгән егет бию көе җибәрде. Мәҗлес озату тәнәфесенә күчте.

«Трактиръ»дан безне 24 урынлы автобус белән алып кайттылар. Беркемнең дә яныма утыруын теләмәдем, шофёр янәшәсендәге ялгыз урынга постым.

Институттан куарга теләмәгәннәрдер, башка студентларга сабак булсын өчен генә хөкем уены оештырганнардыр, дип, мин шушы көнгә чаклы үз-үземне алдалап килгәнмен. Шул ук вакытта, ректорның кунаклар алдында «студенттан» гафу үтенә алуы миңа мәрхәмәт өстәде, сокландырды.

Коркачыктан Казанга чаклы 35 чакрым, диләр. Юктыр, алай гына түгелдер, бик озак кайттык без аны. Шул көннән яшь депутат белән арабыз өзелде.

Мурат Сираҗин Югары Советында бер срок утырып чыкканнан соң ял итте. Һәм өченче чакырылышта тагын миңа килде, янә депутат булырга иде исәбе. Ләкин мин инде алга таба андый уеннарда катнашудан ваз кичкән идем. Сәясәт – ул бик хыянәтчел өлкә. Анда уң як күршеңә керсәң – сул як күршеңнән ерагаясың, бер дустыңа йөрсәң – икенче дустыңны югалтасың! Сәясәттә сыйнфый дошманнар юк, сыйнфый дуслар гына бар. Ә дуслар белән көрәшүе җиңел түгел.

Әгәр дә мәгәр мин мәктәпне тәмамлаган елны ук институтка керә алган булсам, ошбу хакыйкатьне тәки аңламый кала идем әле...

## Җитмеш тугызынчы ялкын

Ишектән керүгә: «Кайттыңмы, Камка?» – дип каршылаулар бетте...

– Почта ящигын карадыңмы?

– Реклама кисәкләре дә юк анда. Бүген үзең алгансың, ахрысы.

– Иртүк кибеткә чыгышлый ачып караган идем шул.

– Суң, көнгә икешәр тапкыр йөрерлек хат ташучылар бармыни хәзер? Мин кызларга хат язудан туктагач, почта бүлекчәләрендә штатлар кыскарып бетте, хезмәт хаклары да фитра сәдакасы хәтлек кенә, ди.

– И, мактанчык та инде син...

– Үзем дә беләм...

Чынлап та беләм... Әгәр хәзер үк шушы диалогны читкәрәк борып җибәрмәсәм, «туры сөйләм»ебез кыегаеп, «матрёшкалар» алып килгән исемсез хатка килеп төртеләчәк. Аннан соң шушы анонимканы язган авторны эзләү, кырык еллык иҗатның баш геройларына әверелгән кызлар исемлеген төзеп, кемнең кемлеген ачыклау башланачак. Көнчелек ул – оясыннан бүленеп чыккан умарта күче кебек. Орынма, тавышыңны күтәрмә, әйләнеп үт, җый җиләгеңне, юлыңда бул, берәү дә моны куркаклыкка санамас!..

– Әллә иҗат йортына путёвка сорап карарга инде?

– Иҗат йортларын сөймим, Нуриәхмәт кызы янында гына яза алам дип, интервьюлар өләшкән кеше – син түгелме соң?

– «Ливадия» безнең фатирдан дүрт тукталышта гына. Яныма килеп йөрерсең... Ну, өйгә кайтып кунармын.

– Бәлки, киресенчә, өйдә язып, иҗат йортында кунып кына кайтырсың? Син бит төн кошы, берәр йокысыз бытбылдык табып сайрашырсыз шунда. Ярата белмәгән башың белән һаман мәхәббәт турында язасың.

– Әстерхан даласыннан, мәхәббәт-сагыну белән шыплап тулган хатларны сиңа кем язды? Ике ай эчендә 27 бит ул!

– Син үгетли беләсең.

– Белми ни?!. Син әле Казанга яңа гына авылдан килгән, күзең ачылмаган, провинциаль самимилек, бәйләнчек егетләргә иммунитетың юк, үзең өлгереп пешкән! Әлбәттә, инде сине ерак араларны якынайтырлык итеп үгетләп сакладым. 27 урынына 25 кенә хат язсам да, югалтырмын кебек иде.

– Ышандым инде. Син олы кеше идең. Малай-шалай булсаң, үртәп тик йөрер идем шунда...

– Олы дип, беләсең ич, мин яшьтәшләремнән сигез елга артка калып яшәдем. Үзем өчен генә үскән кызның да сигез яшькә кечерәк буласын чамалый идем.

– Чамалыйсыңдыр. Әле дә бөтен фотоларың яшь кызлар арасында, бер дә әбиләр кочагына кереп төшмисең.

– Базарда кемнеңдер карт үгез йә карт сыер ите сораганын күргәнең бармы?!.

Шушы урында күңел өчен генә булса да елмаерга кирәктер бит инде... Нуриәхмәт кызы кем белән яшәгәнен яхшы белә, ул сүз беткәч кенә елмаеп йөри башлый.

– Туры килгәнбез инде. Үземнең яшьтәшләремне малай-шалайга саный идем мин.

– Хәтерлисеңме, тулай торакта мин өченче катта, ә сезнең бүлмә нәкъ безнең өстә иде. Бәрәңге кыздыргач, торбаны шыкылдата идең.

– Һәм син коштабак чаклы зу-ур «Татарстан» торты алып менә идең... Беренче курстан башлап, диплом алганчы гел мине каравыллап йөрдең.

– Укыганда гына түгел, эш урыныбыз да бер түбә астында иде. Редакцияләребез генә аерым. Шуңа күрә әйтүем дә, бездән көнләшүчеләр күптер, әле арабызны бозарга теләүчеләр дә табылыр, телефоныңны теләсә кемгә әйтмә, анонимкалар килә калса, ачып укырга ашыкма.

Нуриәхмәт кызы тагын минем күзне эзли башлады. Мавыгып китеп, умарта күченә орына яздым.

– Әллә?! – диде ул, шушы сүзгә биш-алты сорауны сыйдырып...

Күпне күргән кешенең хаталары да күбрәк булган кебек, күп сөйләшкән кеше дә, әйтте диярсең, берәр ярамаган сүз ычкындыра.

– ...Ыслушай, җимешем, безнең күршедә бала еламыймы?

– Юк. Бөтен подъездыбызда тынычлык.

– Алайса эштә алҗыганмын инде. Кулъязмалар укыганда, колагыма гел бала елаган тавыш керә.

– Хатын-кыз авторлар узып китте үзегезне, шуңа шулай ул. Ирләр язудан туктадыгыз бит...

– Молдавиядәге каникулның фотоларын гына табып бир әле, – дидем мин, бала елаган тавыш ишеткәндәй, сискәнеп. Тагын бераз гына әйткәләшсәк, теге хатны тәки кулына тоттыра идем...

Бер фоторәсемгә 350 кешене сыйдырып буламы? Була икән! Дәфтәр бите хәтлек кенә кәгазьгә студентларның «Ялкын-79» дип аталган төркеме рәхәтләнеп сыйган ич! Әнә алар – тау бите кебек авыш җиргә хәтта җәелешеп утырганнар; һәммәсенең йөзе аерым ачык; командир, комиссар, звено җитәкчеләренең күкрәгендәге махсус тамгалары да укыла; бөтенесе дә, игезәкләр кебек, пардан киенгән – Казанга кайтып җиткәнче махсус форманы салмаска кушылган. Рәсем тулаем төксерәк чыккан, бу Молдавия белән саубуллашу сагышыннан түгел. Алар йокламаган. Ут уйнатып, яшел помидор суты белән шакраеп каткан эш киемнәрен ягып, җырлап-биеп, юл биштәрләрен барлап төн үткәргән отряд инде ике сәгатьтән вокзалга төшәргә тиеш. Бу фотода тагын дүрт студент күренми, алары – урын-җирләре завхозга тапшырылган ялангач караватка бөгәрләнеп «оеган» булырлар... Нуриәхмәт кызы белән без дә чак өлгердек – һәр ике якка да җәннәт җимешләре алып кайтыр өчен «күчтәнәч тартмасы» тутырып, онытылып киткәнбез... Шуңа күрә дә хәтер фотосының рамка читендә калдык...

Хәер, нигә әле Нуриәхмәт кызы белән бергә бүтән бервакытта да кабатланмаячак, төшләргә кереп сөендерәчәк, дусларга сөйләп көнләштерәчәк иң гүзәл истәлекне азагыннан ачтым? Җылы якка кайтып төшкән торналар кебек каңгылдашып, бии-бии канатланган башлангычы бар бит аның!

***

Кышкы озын кичләрдә, мин әнигә ияреп, күршебездәге Фатыйма әбиләргә «кич утырырга» керә идем. Кечкенә эт – һаман көчек, дигәндәй, гәүдәгә кәй булгач, берәр почмакта урын табалар. Дүрт-биш әби һәм дә Мөхәммәтҗан бабай арасында тынымны чыгармый гына тыңлап утырам... Төш юраулар, хатирәләр, көннеке көнгә кабатланмый торган авыл хәбәрләре китап сүзләре белән бетә иде. Азактан ул барчабызга да шәфкать-миһербанлык, саулык-тазалык, дәүләт-мөлкәтле, хәвеф-хәтәрсез гомер теләп, дога кыла.

Кызлар белән хат алышырга өйрәнгәч, мин әнигә ияреп йөрүдән туктадым. Китапларның да инде догасызлары кызыксындыра башлады.

Без Фатыйма әбинең хәер-фатихасын һәрдаим тоеп яшәдек. Ләкин ул

догалар аның үз кызын афәттән йолып кала алмады. Хаҗәр апа Казанга китеп урнашты. Тизрәк фатир бирсеннәр өчен таң алдыннан урам себерде, трамвайда кондуктор булып эшләде... Милициядән куылган берәү аңа йортка керә. Ике малайлары була. Ләкин үстереп өлгерә алмыйлар. «Берәү» дигәнебез эчүгә сабыша. Кая гына урнашса да, эшеннән куалар. Өйдә көн саен ызгыш-талаш куба. Ахыр чиктә, ир бер ялгыз хатынга ияләшә. Үз өендә чит хатын белән тоткач, Хаҗәр апа түзми, сөяркәне чәченнән сөйрәп урамга алып чыга. «Разбойга» участковый килә, күршеләр кул куя... Һәм аны алты елга хөкем итәләр... Мин бу фаҗигане бик яхшы беләм. Әйе, без Фатыйма әбинең күршесе; әйе, Хаҗәр апага атап, әнисе әйтеп торган хатларны язучы да мин. Ләкин кызын югалткан остабикәгә авыр сораулар бирергә башым яшь әле минем. Кич утыра йөрүчеләр дә бу турыда сүз кузгатмадылар. Хаҗәр Казанда яши һәм гүя авылдашларның анда эше юк кебегрәк иде.

Ләкин Хаҗәр апаның язмышын әнисеннән дә ныграк, төгәлрәк белә идем. Чөнки мин аның интернатта үскән олы малае Юныс белән Оренбург якларына «Чирәм җиргә» киттем. Ул төрмәдә утырган әнисен кызгана, ләкин никтер сагынмый; энекәше белән икесен интернатка илтеп тапшырган көннәрен күз яшьләре кипкәнче сөйли; син – бәхетле, синең әтиең үлгән дип, миннән көнләшә иде... Юныс җәй көннәрендә Фатыйма әбисе янына кайта. Укулар башланганчы гел бергә. Авыл эшенә ялкау үзе, әмма дә телгә җор. Интернатта өйрәнеп кайткан шигырьләрен урамыбыз белән ятлыйбыз...

Когда я был большой дурак,
Носил ворованный пиджак.
В этом самом пиджаке
Меня поймали в кабаке...

Пошёл козёл в кооператив,
Купил себе аперитив.
Пошёл потом в козий двор,
Показал всем свой набор...

Некрасов шигырьләре түгел инде сиңа, ятларга җиңел, илле ел узса да, хәтердә кала торган... Ә без аның интернат тормышыннан көнләшә идек...

Кешенең авырткан җире алдан йөри, дигәндәй, Молдавия каникулын сөйләп торган килеш... хәсрәт дәрьясына кереп барам.

Кагул шәһәреннән ерак түгел, Прут елгасы буенда, «Правда» дигән совхозның барлыгын эшелоннан төшкәч кенә белдек. «Ялкын – 1979» отряды быел Молдавиягә бара дигәч, ахрысы, артыгын төпченеп тә тормаганбыздыр. Бактың исә, «Правда» – ул хуҗалыкның кушаматы гына, ә географик яктан караганда: «Алма пеш, авызыма төш!» – дип кенә яши торган бер оазис икән!..

Фатыйма әбинең оҗмах турында сөйләгән кыйссалары кылт итеп исемә төште... Анда... Баш очында алма-хөрмә эленеп торыр, йөргән юлларыңда аллы-гөлле чәчәкләр үсеп калыр. Уңга карасаң – йөзем, сулга карасаң – зәйтүн куаклары... Кәүсәр чишмәле күлләрдә аккошлар йөзеп йөрер, капкадан керүеңә 77 хур кызы каршы алыр...

Ләкин Фатыйма әбинең оҗмахына эләгер өчен изге җан булып теге дөньяга китәргә кирәк шул...

Ә Молдавия дигән җәннәт бу дөньяда бүленеп калган.

Без монда чегәннәрне күрмәдек, бөтен СССР буйлап таралып беткәннәрдер.

Җирле халык арасында шадра йөзле, җирән чәчле, кысык күзлеләр дә очрамады, бөтенесе дә татарларга охшаган – матурлар. Җылы якта яшәсәк, без дә ялкаулыкка чыгар идек, мондагылар совхоз кырына эшкә йөрмиләр, һәр хуҗа өенә терәлгән бакчасында гына йөзем үстереп, вак-вак заводларга тонна-тонна ярым шәраб ясап сата. Ул шәрабны үзләре эчми, әйтәм ич ялкау алар, хәтта китап кибетләрендәге дөнья классикларын да укырга иренәләр – киштәләрдә өелеп ята. Молдаваннарга Казан кибетләрендәге китап чиратын күрсәтсәңме, әллә монда китап ашаучылар яшиме дип, хәйран калырлар иде.

***

Без – буыныбыз белән фронтовик балалары, лагерь, отряд, комиссар, командир, байрак дигән төшенчәләргә тиз ияләштек. Иртә-кич үткәрелә торган «строй»ларда безгә хәзер «бойцы» дип кенә дәшәләр.

Бер түбә астына корылган озы-ы-ын казармага «эшелоныбыз» белән сыйдык. Авылча әйткәндә, бөтенебез дә бер өйдә яшәп ятабыз, юк, ятабыз дигән сүз гупчим туры килми, «Хур егетләре» аерым йоклыйбыз. «Хур кызлары» уникешәр кешелек бүлмәләрдә. Фатыйма әби вәгъдә иткән 77се дә кирәкми, мин монда Нуриәхмәт кызын яулар өчен килдем, ә калган 76сы, әнә, Мәхмүтов Заһидка булсын! Ул Кукмарадан. Миннән ун яшькә кече. Беренче курсны гына бетерсә дә, теле-телгә йокмый, бөтен кызларны авызына каратып тота. Молдавиягә килеп урнашкан көнне үк «Советлар союзындагы формализм һәм бюрократия» дигән темага доклад сөйләде, кәгазьдән укымыйча гына. Институтны бетергәч, йә акыл иясе чыгар моннан, йә шагыйрь булыр ул.

Хөррият монда! Ашау-яшәү бушлай, форма казнадан – анысын да июль кояшы салдырып атты, Кагул шәһәренә барганда гына киябез. Утын-печән әзерләмибез. Хәтта Нуриәхмәт кызына хат та язасы юк – гел янымда. Бөтен отряд алдында, ярәшелгән парлар кеби, алай гына да түгел – гүя ике айлык никах сәяхәтенә килгәнбез!..

Көн саен күрешә торгач, җан җанга үтеп керә икән ул; арaларыбыз кушыла, телескоптан йолдыз караган кеби араларыбыз якыная... һәм бу көндәлек халәт яшәү рәвешенә әверелә бара. Мин инде, журнал битләрендәге чибәркәйләрнең рәсемен карап юана торган яшьтән узган. Җанымда су эчеп кенә басылмый торган сусау бар... Нуриәхмәт кызы янында бу сусау көчәйгәннән-көчәя бара.

Институтлар тарихында студентларның туй үткәрү очраклары әллә ни сирәк күренеш түгел. Ләкин мин ул юлага туры килмим. Беренчедән, лагерьда комсомол туе үткәрер идең, мин инде комсомол яшеннән чыккан; икенчедән, Нуриәхмәт кызының әнисе (ә ул гомер буе укытучы булып эшләгән), диплом алмыйча, кызына һичнинди хәер-фатиха бирмәячәк!..

***

Узган гасырның урталарында югары уку йортлары тирәсендә бер шаярту таралган иде: «Сезгә экскаватор бирикме, әллә ике студент та җитәме?» Моның үзенә күрә аңлатмасы бар. Җәйге каникулда акча эшләр өчен студентлар төркеме ил күләмендә барган зур төзелешләргә, тел яшермичә генә әйткәндә, иң авыр эшләргә җибәрелә торган булган төзелеш отряды, ягъни «ССО» дигән аббревиатура бүгенгәчә яши. Әстерханга да, Молдавиягә дә студентларны иң авыр эшкә җибәрделәр. Ул якларда җирле халык яратмаган иң авыр эш нәрсәме? Әлбәттә, помидор җыю! Аның да яшелен! Җыеп, төяп, китереп җиткергәнче, юлда оятыннан кызарып пешәргә мәҗбүр ул...

Әгәр мин, утызга җитеп килә торган мужик, кыз-кыркынга ияреп, буразнадан яшел помидор җыеп йөрсәм һәм бу хәбәр авылыма кайтып ишетелсәме?!. «Корыч» дигән кушаматымны сызып ташлап, аның урынына кеше алдында әйтергә ярамый торганнарын тагачаклар.

Узган ел Әстерханда баржа төяүчеләр бригадасы төзеп, үземне генә түгел, тагын җиде малайны «авыр» эштән коткардым әле мин. Дөрес, төгәл график белән килә торган баржаны тәүлек эчендә төяп җибәргәндә, алар помидор буразналарын сагынып искә алалар иде. Ләкин берәү дә кире чигенмәде! Причалдан лагерьга кайткан чакта миңа рәхмәт әйтерлек хәлләре дә кала иде хәтта...

Ә Молдавиядә... Аның Кагул дигән бер кечкенә шәһәрендә, кырлардан җыелган яшелчәне дә, җиләк-җимеш заводы чыгарган тәмле тауарларны да тимер юл вагоннарына төяп җибәрү җайга салынган. Румыния чиге белән ике арадан елан кебек кенә шуып үтә торган Прут елгасының баржа керерлек тирәнлеге юк...

Беренче көнне үк отрядны совхоз буразналарына тезә башлагач, мин бригадир Доничны читкәрәк дәшеп алдым да бүтән эш сорадым. Ул бераз аптырап калды бугай. Рапорт кабул иткәнише генә сөйләште.

«Иван Павлович, мин помидор җыеп йөрергә оялам».

«Педагог штоли син?»

«Юк, ун ел эшләгәч, рабфактан кердем».

«Нинди эш кирәк?»

«Су бораулый беләм», – дигәч, аның исе китмәде, суга кытлыгы юкмы, әллә артезиан коеларның ни икәнен аңламадымы?

«Тагын ниләр эшли беләсең?»

«Тракторист, дизелист, сантехник, плотник», – дип саный башлаган идем, кинәт туктатты.

«Шо? Әллә өй дә сала беләсең?»

«Беләм!» – дидем, Шәле шабашникларына ияреп йөргән кеше буларак.

«Үзеңә иптәшкә бер кеше сайлап ал», – диде дә, басу читендә чиләк өләшүче завхоз апа янына алып килеп, чиләгемне кире бирде.

Малайлар арасында эре сөякле, калкурак гәүдәле, бәдән ныгыткан берәве, кулына эләккән калай цилиндрга юынтык су чиләгенә юлыккандай чирканып карап тора иде: «Әйдә, бригадирга өй салабыз», – дигәч, сөенеченнән чиләге кулыннан төшеп китте. Егет минем адаш булып чыкты, Мөслимнән икән үзе.

Культура институтына 350 чиләк өләшеп чыккач, Донич, безне йолкыш алашага җигелгән такта арбага утыртып, авылга алып китте. Безнең якта ат җигүчеләрнең арба төбенә һәрвакыт, хәтта кыш көне дә печән түшәлгән була иде. Ә монда болыннар юк. Печән урынына баклажан, помидор, баллы борыч, кавын-карбыз үсә... Шуңа күрә атлары да йолкыш... Авыл читенә җитеп, йөгәнне бәйләп куйган тирәк тә ярты гасырлык чикләвек агачы булып чыкты: үзе гел тупылга охшаган, төсе-кабыгы, юанлыгы нәкъ бездәгечә, яшькелт-соры, шома, биек... Менә кайда үсә икән ул «Әчтерхан чикләвеге» дигәнебез!.. Яфрак саен яшел бәрәңге бәйләп куйган кебек. Узган юлы Әстерханда без күргән чикләвек агачы бөтенләй башкача, ул чыпчык миләше кебек кәрлә куак кына, ботаклары да үзара чуалып беткән иде. Хуш исле яфракларын чебен-черки сөйми икән. Ял итәргә теләгән халык шул чикләвек төбенә карават куеп йоклый.

Молдовада, берәү дә Әстерхан чикләвеге дип сөйләшми, монда аның исеме «грецкий». Озаклап сокланып торырга ирек бирмәде Иван Павлович:

«Сез кайтып киткәч кенә өлгерә әле аның чикләвеге, – дип, безне ияртеп китте. – Әйдәгез, Колялар, йорт урынын күрсәтәм».

Бу урам яр читен хәтерләтә иде, йорт урыны булырга тиешле өлеше дә авыш, чирәм белән капланган тау бите кебегрәк.

Өй салуны нидән башларбыз икән, диебрәк, яңа урамга сәяхәт кылып алдык һәм аңладык... Монда бүрәнәләр юк, такталар санаулы, борыслар тамгалы, кая карама, өстәл-өстәл таш өеме, кызгылт ком чүмәләсе...

Һәм без, адашлар – ике «Коля», төзелешкә тотындык, бригадирга өй салабыз...

Өй салуның ние бар? Безнең якта чутлыйсы да мүклисе... Ә Молдова – таш өйләр дәүләте, аның кышлары яз кебек, язы-көзе җәй кебек. Студентлар җәе нәкъ чилләгә туры килә, кояшы йомшак күңелле – сөтсел пыяла аркылы балкыган кебек кенә, кызынырга теләгән кешенең тәнен өлгергән чикләвек төсенә кертсә дә, артыгын көйдерми; җилләре талгын – җиләк-җимешләрне, яшелчә чәчәкләрен серкәләндерерлек кенә, сулар һавасыннан йөзем исе килә. Тәмле, татлы, җылы ил булганы өченме, Румыния белән Украина икәүләшеп, аны беркемгә дә бирмәслек итеп, Җир харитәсендә кочаклап алганнар.

Молдова – йөзем иле. Идел буеннан килгән һәр инсан рәт-рәт тезелеп яткан плантацияләрне күргәч, үзен гастрономга кергән ише хис итәр дә: «Бәй, бездәге Изабелла, Ркацители, Саперави, Каберне, Рислинг шәраблары куакта үсә икән ләбаса», – дип шаклар катар. Бактың исә, һәр эчемлекнең үз йөземе бар икән. Авыл кибетләренә пожарный чаны хәтле имән мичкәләр белән кайтарыла торган шәрабның гына «Разливной» дигән сортлы виноградын күрмәдек. Ел саен миллион ярым тонна виноград үстерә торган союздаш республика шул тиклем уңышны ничек җыеп ала, ничек эшкәртә, саклый һәм сатып өлгерә дип баш вата идек. Бактың исә, дүрт-биш тәрәзәле, акшарланган, беренче карашка бик гади генә күренгән таш өйләр тирәнгә тамыр җәйгән... Яңа җыелган виноград тиз бозыла, шуңа күрә аннан шәраб ясап, вак заводларга тапшыру күпкә табышлырак икән.

Хезмәт каникулы беткәнче, без, адаш белән икәү, дүрт казык кагылган авыш җирне казып, гаражлы, мунчалы һәм иң мөһиме – шәраб базыннан торган таш өй салып өлгерергә тиеш идек.

Нишлибез, адаш, дип киңәшеп торырга вакыт юк, шул көнне үк эшкә тотындык. Таш тигезләп киселмәгән, аны кирпеч ише генә аккурат салып булмый, опалубка сыман ике такта арасына тезеп, цемент измәсе белән күмәбез. Бер якны ярты метр чамасы өйгәч, кибәргә ирек бирәбез. Һава коры, цемент тиз ката. Тактаны кубарып, өскәрәк күчергәнче, өмет итмәгән җирдән генә ял көне килеп чыга. Бригадир Донич кеше алдында күзгә чалынып йөрүебезне теләми, совхоз буйлап сәяхәткә алып китә.

Беренче ялда брынза цехын күрсәтте. Цех димәсәң, хәтере калыр. Йөз сарык сыешлы, әлеге дә баягы таш сарай. Куйларны савып, көтүне куганнар. Өч бидон, яңа савылган, үзебезчә генә әйткәндә, сарык сөте. Әле суынып та өлгермәгән. Донич килә-килешкә үк чөйгә эленгән калай кружка белән чумырып алып, эчәргә тотынды. Адаш шундук читкә борылып укшый башлады. Бригадир кружканы янә мөлдерәмә тутырды. Бу юлысы миңа сузды. Сер бирмәдем. Студент елларымны искә төшереп, Нуриәхмәт кызы тирәсендә узган гамьсез көннәремне сагынып, вакытында көндәлек язып бармасам да, хәтеремә сеңгән һәр көнен, гомергә вак хайван асрап та куй сөтенең җете тозлы тәмен тоюымны – һәммәсен-һәммәсен кайчан да булса бер язасымны белә

идем инде мин ул чакта. Түздем. Кружканы төбенә чаклы бушаттым да Иван Павловичның кәефе күтәрелсен әле дип, авыл агайлары сыман кул сыртым белән авызымны сөртеп куйдым.

Бригадир барыбер кружканы адашка сузды:

– На, Коля, попробуй хоть чуть-чуть. Это же жидкая брынза. Очень полезная.

– Куй сөте файдалы бит ул, – дип, мин дә кыстадым.

Адаш, гүя утлы күмер тоткандай, кружканы кая түгәргә белмәде, үзе, әйтергә теләгәнен тиз генә оештыра алмыйча, каушап такмакларга кереште:

– Ни, ни, ни... куя не надо! Коровье молоко могу!

Ул кичне без кыр каравылчысының шалашы янындагы әрәмәлектән ярты чиләк чамасы кыргый өрек җыеп алып кайттык. Мин аны Нуриәхмәт кызына булыр, дидем. Кич йокы алдыннан ике сәгатьлек ял бирелә. Шул чакта кукуруз кыры читендәге кысыр болынлыкка иптәш кызларым белән чыгармын, диде. Адашның чыраенда елмаюы белән уйлануы бер төсмердәрәк чагыла. Әйтә куйды бу:

«Көтү кайткач, танабыз өйне үтеп китмәсен өчен ипи тотып, капка төбенә каршы алырга чыга идек», – ди.

«Файдасы тидеме соң?»

«Көн саен каршы ала торгач, көзгә таба кулга ияләште инде».

Көннән-көн кул шомара, эшнең җаена төшендек, подвал әкренләп үсә. Вакыт әрәм итмәс өчен өйлә вакытында лагерьга кайтып йөрмибез, төшке ашны калай буржуйкага учак ягып, урамда гына әзерли Доничның хәләле. Мондый да кара тутлы, каен корымыдай чем-кара чәчле, үткен кара күзле хатынны Казанның колхоз базарында күрсәң: «Чегән!» – дип әйләнеп үтәр идең... Исеме сәер үзенең – Рәйсә! Рәйсә Донич! Ни дисәң дә, бригадир хатыны, «отчествосын» сораган идек, Иван Павлович кырт кисте: «Аның этисе кирәкми сезгә! «Раиса» дип эндәшегез!» – диде. Мин рәхәтләнеп, Рәйсә генә дим үзенә, картаеп укырга керүемнең бер җайлы ягы инде бу. Ну, адашка кыен, үзеннән ун яшькә олы кешегә «син!» дип эндәшә алмады, ни дисәң дә, Культура институтында укыйбыз шул. Ике ай буе сыйланып, адаш «Исәнмесез», «Сау булыгыз»ны, «рәхмәт»не бисмилла урынына төгәл кабатлады, әмма дә ләкин ялгышып та Рәйсә, син, дип эндәшкәне булмады. Кирәк-яракны минем аркылы гына соратып ала иде.

Болон плащ итәгеннән тегелгән яшел букчаны гел кесәдә йөртәбез. Безнең күчтәнәч алып кайтканны өч кыз көтеп тора: адаш Хәлимәгә кызыга башлады; Рәмзиягә иптәш юк, аның Актанышта егете калган, хатларын гел кесәсендә йөртә; ә Нуриәхмәт кызы... Ну, беләсез инде, аның хакына көн саен күчтәнәч күтәреп кайтучы – мин.

Кыргый өректән соң, төче чия коела башлады. Аннан кара җимеш пеште. Изабелла йөземенең иртә өлгерә торган сорт икәнен дә кызлар беренче булып бездән белделәр. Букчаны көн саен юып киптерәбез...

Кавын ашаганыгыз бармы, дип сорасам, үпкәләрсез инде. Юк, мин аның кибет идәнендә әрдәнәләп өелеп торганын әйтмим, ә сабагыннан өзеп, кулдан төшермичә генә, җаяүләп алып кайтып, Нуриәхмәт кызы кулына тапшырганын күзаллап әйтәм. Аның кабыгын пычак сизми – ул гүя атланмайга манылган... Өлгергән орлыклары оясы белән ишелеп кенә төшә, үтә күренмәле телемнәре күз карашыннан эреп тора. Һәм шуңа мактанчык Франциянең бер генә парфюмеры да ирешмәгән, кабатланмас хуш исне өстәргә кирәк! Рәйсә Донич кебек бик күп кызларның язмышын үзгәртә алырлык аромат бу!.. Ә карбыз өчен

букчабыз бик кечкенә иде, цементтан бушаган катлы-катлы кәгазь капчыкны каезлап, шуңа көчкә сыйдырдык. Ләкин кызларыбыз аңа тимәде, иртәгә Кагул читендәге күл буенда Сабантуй үткәрәбез икән, шунда мактанырбыз, диделәр.

Отрядта су кытлыгы юк үзе. Студентлар кырда душ кергәндә, пары очып тора хәтта... Дөрес, су салкынын тоярдай Прут елгасы да ерак түгел, ул буеннан буена Румыния белән Молдавиянең чик сызыгы булып тора, ләкин яр тирәсенә бару студентлар өчен катгый тыелган.

Ике арадагы шомлы киеренкелек безгә дә тоела иде хәтта. Прут аша салынган «Дуслык» күперендә хәрәкәт сизелми. Кичләрен, студентлар йокыга талгач, азык-төлек амбарының таш стенасына ядрә килеп тигән очраклар булгалады. Снайперлар эше, дигән булабыз инде үзебезчә фаразлап, без бит әле фронтовик балалары. Иртән хәрбиләр килеп, ядрә чокырын фотога төшерәләр, үлчиләр, траекториясен гөманлап, йодрык күрсәтәләр дә... Тәмам. Әлегә ядрә тиеп, кемгә дә булса зыян китергәне булмады, диләр.

Студентлар ел саен килгәч, Кагул халкы инде Сабантуйга катнашырга өйрәнгән. Ләкин күчмә бәйрәм бездәге кебек озак бармый икән, саубуллашу хоры җырлаганда, теге карбыз ашалып та бетмәгән иде әле.

Көн кызуы халыкны өйләренә ашыктыра. Бәйрәмне район администрациясе оештырмый. Студентлар кулына калгач, куас, лимонад, туңдырма сатучылар күренми. Без җирле халыкка ияреп, район эчендә су эзләп йөрибез. Бер катлы райүзәк, тәбәнәк читән, җилкапка... Кул җитәрлек арада гына, кояш астында, биш чиләкле ферма бидоны тора. Капкачы ябык, тик ни кружка, ни чүмече юк... Хуҗаларны нинди телдә чакырырга да белмибез.

Биш кеше шул без, тәрәзәдән күренгәнбездер, ашыкмыйча гына ишек ачылды һәм, молдован биюенә әзерләнгәндәй киенеп, бер апа чыгып басты. Биш куллап бидонга төртеп күрсәткәч, хәлебезне аңлады булса кирәк, көттермичә генә алюмин чүмеч алып килде. Адашның хәле мөшкел иде, күрәсең, апаның кулыннан чүмечне тартып алгандай итте. Кабаланып бидон капкачын ачам дигәндә генә, кәефем азынып әйтеп ташладым:

«Адаш, куй сөте бу, кояшта брынзага әйләнә».

Җөмләмә нокта куеп өлгермәдем, Адаш шундук укшый башлады, кызу суккандыр инде...

Чүмеч миңа күчте, батырып алдым... Йөзеп йөргән йомычкаларын өрә-өрә йоткылыкны киереп чөмерәм. Үзем эчәм, үзем кызларга карыйм, ут йотсам да, сиздерәсем юк! Безнең алда – гәрәбә тәлгәшләрен каты күзләрдән яфрак астына яшергән, чык суларыннан сут җыйган, Карпат ташларыннан төшкән җилләрне сулап өрелгән татлы йөзем ширбәтенең әле балигъ булып җитмәгән, ягымлы шәрабкә әверелеп барган мәле... Һәм шешәләп түгел, ә мичкәләп!

Адаш – эти белән үскән малай, өлгермәгән шәраб дисәң дә, әчкелтем исне сизеп өлгерде, шуңадыр инде, сусаган кызлар алдында әдәп саклап торуны кирәксенмәде – рәттән ике чүмеч состы.

Аннан соң... янә чиратка борылып бастык... Чут-чут көлешүләреннән чамалап, эчемлекнең кем кулына күчә барганын фаразлау кыен түгел иде инде. Һай, бу тамашаны Әстерханга киткән курсташлар күрсә... Киләсе юлы без дә Молдавиягә барабыз дип, исемлеккә бер ел алдан язылып куярлар иде... Бушлай сыйлыйлар бит! Рәхмәт әйтеп китим дисәң, хуҗасы да юкка чыккан хәтта...

Кыскасы, Кагул Сабан туеның банкеты шәп булды, сусау басылды, тамак та туйды кебек. Без генә түгел, капка төбендәге сый-хөрмәтне һәркем күреп, татып өлгергән. Бәйрәм бараклрыбыз янында дәвам итте. 350 кызлы «авыл»

бер булып җырлый-җырлый бии. Сәнгать һөнәренең бер казанышы иде бу. Йокы сәгате таңга таба күчте. Башка вакытта, «салганыгызны» йә тәмәке тартканыгызны күрсәм, институттан кудырам, дип өркетеп торган комиссар Миргалимов үзе дә безнең чамада – бер чүмечне каплаган иде бүген.

Көн сүрелә төшкәч, кызлар да суынды, биюләр җырга күчте, җырларны тыныч вальс алыштырды. Кызларны кызлар танцыга чакыра; Адаш Хәлимәгә виноград тләсе кебек ябышкан; Кукмара Заһиды ике кызны берьюлы әйләндереп, лекция сөйли; минем ике кулым да Нуриәхмәт кызының билендә; калган дүрт малай кул алмашка китте...

Мин... син һәм музыка... Кыска гына вакытка булса да, бәхетле минутларны татып карар өчен шушы өч шарт җитә! Музыка беткәнче, кулыңдагы кошың синеке, туктадымы – оча да китә. Сөйләшеп кал, мөнәсәбәтен сиземлә, өметеңә юаныч тап, тагын күрештерерлек матур сүзләр эзлә... Бу кагыйдә әлегәчә бер генә кодекска да язылмаган, бу кагыйдә мәхәббәттән туа...

Мин һәм син!

Сигез минутлык музыка... Ундүрт яшемнән бирле эзләгән, өметләнгән, һәм минем өчен генә үскән кыз шушымы? Сигезле саны чиксезлек билгесе... Көнозыны ял итеп алҗыгандыр инде, башын минем күкрәгемә салды, яңагы тиеп торган төштә тән тәнгә, җан җанга кушылды. Мин аның чәченә чумдым. Калын, тыгыз һәм дә күпереп торган, җиде толымлап үрерлек чем-кара чәч... ул монда өч йөз илле кызга бер генә. Укырга кергән елны озын тәнәфестә бөтен ашханә чираты ошбу чәчнең кыргый матурлыгына сокланып карап тора иде. «Үзенекеме? Буялгандыр. Имтиханнар башлангач кистерә әле ул аны», дигән пышылдауларга баштагы мәлне ияләшә алмады, шуңадыр чиратның койрыгына басарга тырыша иде... Чәч – ул табигать, чәч – холык, чәч – мәхәббәт компоненты...

Музыканың бишенче минуты...

«Ислемаеңның исемен әйт әле?»

Ишетмәмешкә салыша. Җавапсыз калган тынлык серләрне көчәйтә генә...

«Лесной ландыш? Серебистый ландыш?»

Нуриәхмәт кызы кинәт күтәрелеп карады да көлемсерәп, күзләрен яңадан яшерде... Димәк, Ландыш, энҗе чәчәк. Чәчәк исләренә борын сизгер минем, ислемай исләрен әллә кайдан таныйм... Мин инде сары, көрән, көлсу, шомырттай кара чәчләрне Оренбурга, Магаданга, Ростовка, Актанышка, Уфаларга барып иснәп кайттым... Мактанчык уйларым белән мавыгып, санаулы минутларны әрәм итәм...

«Әйдә, Молдавиядә яшәп калабыз! Мин хәзер өй сала беләм...»

Нуриәхмәт кызы кинәт кенә сынын катырды, бөтен кеше биегән җирдә туктап калды да әйтте:

«Мин җитди сүзне шаярып әйткәннәрен сөймим!»

«Җүләрем! Үпкәләмәдем. Һич юк», – дигән сүз дә кайвакыт сөекләңне яраттыра ала. Нуриәхмәт кызының «сөймим» дигәнен язмыш белән алай җиңел шаярма, мәгънәсендә кабул иттем... Юкса урта мәктәпне тәмамлаган татар кызы «сөймим»нең синонимнарын яхшы беләдер: бар кит, күземнән югал, бүтән минем тирәдә йөрисе булма, дияр иде.

Биюләр бетте. Көй алышынды. Кәеф үзгәрде...

Вальста бөтерелгәндә, Шәле малаеның башы әйләнгәндер, димәгез, Нуриәхмәт кызы белән бу җәннәттә яшәп калырга чын-чынлап әзер идем. Минем кебек су бораулаучылар кайда да кирәк, ә ул китапханәче булып

урнашыр иде. Кагулдан ерак та түгел Болгар шәһәрчеге бар, без аңа сәяхәт ясадык инде, җирле халкы – гагаузлар, безгә аңлаешлы итеп татарча сөйләшәләр. Күчәр идек шунда...

Казанда иске нужам көтә.

Минем анда үземнән унсигез яшькә генә яшьрәк малаем үскәнен дә, Магаданга ни өчен киткәнемне дә, Зәмзәмиянең кем икәнен дә белми бит әле Нуриәхмәт кызы... Казанга кайтып төшү белән перронда ук югалтырга, әйе, бөтенләйгә югалтырга мөмкин бит мин аны. Малайлыгым хатасын төзәтер өчен мин тагын да зуррак хата ясарга йөрим, ахрысы. Югалган яшьлекне кайтарырга теләп иләсләндем генәме? Нишләп әле мин Әгерҗе флорасының бер табигать баласын Казаннан ике мең чакрымдагы чит мәмләкәткә килеп сөеп йөрим? Мәхәббәт каникулы беткәч, белем аласы, акыл эстисе, имтиханнар тапшырасы һәм сынаулар кичәсе барын белә торып?!. Минем белән янәшә барыр өчен аңа бик көчле булырга кирәк! Нуриәхмәт кызы – минем өчен генә үскән һәм мин аны никах кичenә чаклы исән-имин килеш сакларга риза! Мәктәп елларында язган хатлар җилгә очкан кебек, Сәвияләр, Илсөярләр, Гөлназлар да юк. Хәзер Нуриәхмәт кызы гына бар. Мәхәббәт – ул хәзерге заман фигыле! Аның үткән заманы да, киләчәк заманы да бүген: яшьлегемдә берәүне яраттым, димә, син аны бүген дә сагынып сөяргә тиеш; мин сине мәңге сөярмен дип, бүгенге мәхәббәтне генә олылап була!..

***

Мәхәббәт каникулының тагын өч көне бар иде әле. Яңа өйгә дигән зур подвалны җир өстенә чаклы күтәрдек. Өске нигезнең тигезлеген тикшереп чыккач, Донич безгә уч тутырып акча биргән иде. Адаш белән күзгә-күз караштык та санамыйча гына кесәгә салдык.

Рәйсә виноград яфрагына туралган ит төреп, табада кыздырган. Милли ризык, диде, исемен дә әйткән иде – долма кебегрәк хәтердә калган. Адаш белән без аны пилмән дип ашадык. Бригадир, сыйланганда, еш-еш рәхмәт әйтеп, аркабыздан сөеп торды. Ә Рәйсә... читкә борылып, керфек кадалган ише кыланып, озак кына күзләрен сөртте. Ләкин ике күзгә дә берьюлы керфек керми, аны елатырдай сәбәпне без вокзалда гына белдек...

Табада кыздырган бәрәңге ашап, сөтле чәй эчеп, Мишәдә бер су коенсам дигән беркатлы хыял күптән борчый иде инде. Ниһаять, иртәгә көндез Казаннан эшелон киләчәк. Унҗиде вагонның бишесе безгә, калганнары – күрше совхозлардан җыелган студентларга. (Молдавиядә совхозлар гына икән. Ул элек Украина составындагы Автономия булган, СССРга 1940 елда гына кушылган, шуңа күрә дә колхозлашу афәтен күрмәгән.)

Иртәгә кайтып китәбез дигән көнне зур чигенү алдыннан хәрбиләр казармасын эвакуацияләү белән генә чагыштырып булыр иде. Ә чигенер өчен – Туган җирең булу кирәк!

Казан вокзалында безне ректор Рәхилә Абдулловна үзе каршы алачак. Һәр студентның пардан киенгән обмундированиесе юып үтүкләнгән булырга тиеш (ә казармада ике генә үтүк), күкрәк кесәсе өстендәге «ССО Ялкын -79» дигән тамгаңны югалткан булсаң, кайтып та торма, барыбер институттан куачаклар... Помидор яшеле сеңгән күлмәк-ыштаннарны, җыелган хатларны, хәтта иске кулъяулыкларны да берсен-бер алып кайтмыйча ягарга! Мин цементланып каткан сандалиларны футболка, чалбарга төреп, утка ыргыттым. Ә чалбар кесәсендә ачылмаган бер хат бар иде. Күрәсең, Зәмзәмия институтка килеп, адресыбызны белешкәндер. Укымадым. Чөнки 350 «ихахайга» ияреп киткән

«хыянәтче» мужик хакында аның ниләр уйлаганын, үткәнемне фаш итеп чыгарган хөкем карарын мин яттан белә идем инде. Ә Нуриәхмәт кызы андый хатларны укырга, һай, әзер түгел иде шул әле...

Бу якларда утын урманнары юк, өйләре-мунчалары торф кирпечләр, йә ташкүмер яга торган мичләргә көйләнгән. Безнең кием-салымнардан сүрелә башлагач, казарма тирәсенә өелгән ватык әрҗәләргә ябырылдык. Бәлки, ул кадәр үк тырышасыбыз да калмагандыр, берьюлы йөзәрләгән кочак такта ыргытмасак та, дөрлисе иде. Без малай чакта бәрәңге күмгән учаклар әлеге ялкынның бер очкыны кебек кенә булган. Утның хәвефле тавышы көчәйгәннән-көчәя барып, тыелгысыз ялкын теле күк капусын ялый башлады. Гүя, җәннәттәй аланга Фатыйма әби кисәтеп куйган тәмуг уты килеп керде. Төнге күбәләктәй кызлар, канатлары өтелеп, читкә сибелде. Без Нуриәхмәт кызы белән учакның ике ягында аерылып калдык. Мин аны ут аша яп-якты итеп күрәм.

«Син мине күрәсеңме?»

«Күрәм, Камка, күрәм».

«Ишетәсең дә, әйе бит?»

«Яхшы ишетәм».

«Нәрсә уйлаганымны да тоясыңмы?»

«Әйе. Кеше ашамыйча 40 көн, су эчмичә 7 генә көн түзә ала, ә мин синнән башка бер көн дә яши алмыйм, дисең...»

«Зәмзәмия исемле ялгышым бар. Гафу итәрсеңме?».

«Әллә кайчан җиткерделәр инде. Мин сиңа ышанам!»

«Әйдә ут аша кочаклашабыз! Җаныбыз нишләр икән?»

Комиссарның: «Туктагыз! Житте!» – дигән әмере әйтелеп беткәнче безне учак читендәге чирәмлеккә селкеп ыргытканнар иде инде...

Ике тәүлеккә җитәрлек провизия-припасларны, бүләк-трофейларны, биштәрләрне вокзал мәйданына өйдек. Поезд составы ишек-тәрәзәләрен йомып йокымсырый... Исемлек буенча перекличка башланды: «Мин! Мин! Әйе! Монда!..» дип 350 тапкыр кычкырткач, комиссарның: «Бойцы – вперёд!» – дигән катгый приказы яңгырады.

Менә ни өчен эшелон дип атала икән ул!.. Билетлар кулга бирелми, алдан кергән кызлар, тәрәзәләрне ачып, дус кызларын сөйрәп алды. Вагон саен 72 кеше – өченче каттагы шүрлеккә дә матрас җәйгәннәр. Казанга кайтып җиткәнче станцияләрдә тукталыш юк, ишекләрне ачмаска, тәрәзәдән чүп ташламаска, бит юа торган суны эчәргә ярамый!

Проводник дигән кеше безнең арадан үтә алмас, ләкин кемдер вагон ишекләрен бикләп йөрде. Эшелоныбызга локомотив тагып маташалар бугай, кузгалу юк. Бөркү. Кавын ашаучылар бер бүлемгә эләктек, тырыштык инде. Адаш белән без тәрәзә янында, өченче шүрлеккә менеп яткач, урыннарыбыз Хәлимә белән Нуриәхмәт кызына кала, дип киңәштек.

Шулчак Адаш утырган җиреннән сикереп торды: «Әнә, әнә! – диде ул, вагон тәрәзәсен коеп төшерердәй булып. – Бригадир аты!»

Чынлап та, перрон буйлап йолкыш алашабыз теркелди. Ләкин арбада Иван Павлович үзе түгел, ә аның хатыны иде. Сизелеп тора, ул кемнедер эзли. Мин тәрәзәгә сыйган кадәр үрелдем дә: «Ра-и-са!» – дип кычкырдым.

Ни хикмәттер, бу минутта мин янәшәмдәгеләрнең гаҗәпсенүенә игътибар итеп өлгермәдем дә бугай.

Йолкыш алаша туктаган җирендә басып калды. Рәйсә безнең тәрәзәгә йөгереп килде дә ап-ак сатин белән тышланган посылка сузды.

Адаш та инде тәрәзәгә тыгылган иде:

«Ни надо, спасибо, ни надо, у нас всё есть!» – дип өзгәләнә башлады.

«Колялар! Бу посылка әтикага. Адресы язылган. Сезне каршы алыр, димим, ул авырый бераз. Пожалысты, өенә илтеп бирегез. Әтикам яшь грецкий орехны ярата, файдалы ул, йомшак та, зрелые каты була. Быел әтика үзе килмәде, да авырый».

Адаш белән без Рәйсәне бүлдерергә куркып, телсез кала яздык. Татарча сиптерә бит бу!

«Рәйсә, ник син моңарчы безнең белән үзебезчә сөйләшмәдең?» – дип бәйләнә башлады Адаш.

«Ваняның рөхсәте юк. Телеңне оныт әйтә. Юкса Казанга качасың, ди. Ой, долго сөйләргә...»

«Вәт, цыганский барон, ә?! – ди Адаш, һаман үҗәтләнеп. – Сине урлап апкайткандыр әле ул».

«Юк, Колялар! Мин сама. КАИдан стройотряд белән булдык. Калдым. Ваня яхшы ул. Әтиканы алып кайтабыз әйтә. Яңа домга чыккач... Через год тагын кайтыгыз Кагулга. Домны салып куярсыз».

Бер елдан диплом алам шул инде мин, дип әйтергә исәп бар иде, поезд йолкынды.

Рәйсә: «Мин сиңа ышанам инде», – дип әйтергә теләгәндәй, кул сыртымнан сөеп алды. Безне озаткандай, бераз ияреп барды. «Тагын килегез!» – дип кычкырмады, кул болгап калмады. Донич статусына лаек булып, горур басып калды.

Тәрәзәдән башны алгач, кызларга да җан керде.

«Егетләргә ышансаң! Икәүләшеп бригадир хатынының башын әйләндереп йөргәннәр болар...» – Бу сүзләрне Хәлимә әйтте бугай.

«Диплом аласың да күчеп киләсең. Монда яшәп калырга исәбең дә бар бугай...» – Монысын минем яндагыдан ишетәм.

«Минем өчен генә үскән кызлар монда да бардыр әле», – дидем мин, Нуриәхмәт кызына җавап итеп.

Өчебез дә шаяртырга омтылып карадык. Ләкин Рәйсәнең сагышы кызлар җанына кереп поскан иде инде.

Вагонда һәр пассажир тәрәзә янына сыенырга тели. Үзенчә романтика бит инде бу. Гүя, тавышы бозык телевизорның киң экранына багасың да тәүлекләр буе «сәяхәтчеләр клубын» карап утырасың... Ләкин мин бүген тәрәзәле урын алыр өчен якын дусларым белән дә дуэльгә чыгарга әзер идем. Күршеләрем белә инде моны...

Казаннан килү уңаена Бендеры станциясендә дөм караңгы иде. Ә бүген без аны көпә-көндез үтәбез. Бендеры шәһәрчеге – Днестр елгасы буенда. Бу елганы Карпат тауларыннан агып төшкән сыек боз дип йөртәләр икән... Диңгезчеләр Одесса причалындагы суның салкынын Днестр елгасыннан күрәләр, имеш.

1943 елның язында (әни аны апрель ае булган, дип сөйләде), әти хезмәт иткән штрафбатка, елганы кичеп, каршы ярда ныгып калырга дигән приказ бирелә. «Кантары кубарылып, боз ага торган суда, әле бер, әле икенче якка йөзеп, өч көн һәм өч төн буе сугыштык. Дошманның кайсы яктан атканын, снарядның кайсы ярдан төшкәнен дә белгән хәл юк, кругом ут эчендә калганбыз. Өч көн дигәндә генә, ниһаять, регуляр Армия килеп, ярны яуларга җитештек. Штрафротадан биш-алты гына кеше исән калды», – дип сөйләгән әти. (Әлбәттә, үлем түшәгендә яткан әтинең соңга калган хикәятләрен тыңларга кеше дә булмагандыр инде –

апага өч яшь, абый әле 2 нче класста гына укый, ә мин туарга өлгермәгән...) Әти шушы һөҗүмдә үпкәсенә салкын тидерә, госпитальдә ятып чыга да янә үзләренең частен (бу юлысы инде регуляр Армиядә) куып җитә...

Студентлар эшелоны Казанга кайтарып куеп, бездән тизрәк котылырга теләгәндәй ашыга иде. Никтер акрынайды, вагон көпчәкләре тырпаеп торган болтларга төртелеп алгандай итә, рельслар да саташып чуала башлаган кебек күренә. Тераспольгә борыла торган чуен юл тыкрыгына җиткәнбез. Эшелон Тераспольгә кермәде, димәк, Кишинёв аша кайтабыз... Бендерыдан чыгуга, мине дә уздырып, кемдер:

«Днестр!» – дип кычкырды.

Бөтен халык тәрәзәгә ябырылды. Хәтта вагон да шул якка авышып калгандай тоелды.

Гадәттә, без танышларыбызны очратсак, үзара охшашлык эзли башлыйбыз: әнисенә охшаган, гел әтисенең холкы, йөрешен генә күр – нәкъ кодагый инде, килен кебек хитрый бу, ә?..

Днестр да кайсыдыр ягы белән Чулманны хәтерләтә, бигрәк тә Сарапул тирәсендәге өлешен. Каян беләмме? Су бораулаган елларда, яз көне Актанышның аэродромы бер айга ябыла торган иде. Казанга кайтыр өчен Агыйдел аша «сират күперен» җәяүләп кичкәч, ни очраса, шуңа утырып, Камбарка станциясенә килә торган идек. Сарапулга җитәрәк, поезд Кама аша салынган чуен күпердән уза. Ул тиклем дөбердәүгә, мәрткә киткән кеше дә уяныр, елганы күрми калу мөмкин түгел.

Шөкер, Чулман – тынычлык елгасы!

Ә Днестр?!.

Без исән калу хокукыннан мәхрүм ителгән, кемнәрнедер кемнәрдәндер азат иткән, приказ белән утка кереп, суга бата торган мәхлуклар хәленә җиткерелгән әтиләребезнең кан койган кырларына комсомол җырлары белән килдек... Һәм үзебез үк тересләрен түгеп, җирләрен эшкәртеп, яшелчәләрен җыеп биреп, нигезләрен таштан коеп, ике айлык стипендия хакына ялкау союздашларның ялчысына әвереелдек. Дошманнарны ачык капка, якты чырай белән шәраб бокаллары күтәреп каршы алган халык, безне чиләк-капчыкларын өеп, илле көнгә җитәрлек макарон шулпасы белән арпа боткасы пешереп, ярты телем ипигә 20 грамм май ягып көтеп тора иде. Безнең кем балалары икәнне беләләр идеме алар – беләләр! Әле сугыш беткәнгә нибарысы утыз гына ел...

Һәм менә без, эшелонның 45 урынлы вагонында 72 җан иясе, юл капчыкларын коридорга өеп, кабымлыкларыбызны аяк астына тезеп, сүрүләре теткәләнгән тышсыз мендәргә баш салып, өч катлы сәндрәләрдә саташып, чегән таборы кебек кайтып киләбез...

Яр читенә салынган шпалларны санап, фәлсәфи акрынлык белән барган поезд тизлеген арттыра төште һәм комсомоллар – сулга, Днестр – уңга, дигәндәй, читкәрәк каерды.

Ә Днестр суы, кояш баешында тимгел-тимгел, әйтерсең лә, 1944нең канлы бозлары һаман да эреп бетмәгән иде әле...

***

Узган гасырның «Ялкын – 79»ы истән чыкмый: Молдавиянең җәннәттәй бакчалары; Нуриәхмәт кызының хур кызыдай чагы; тәмуг утыдай учаклары; әтиләрне гомерсез иткән Днестр сулары... барысы бергә кушылды да кәгазьгә сыймаслык хатирә булып калды...

Әти Бөек җиңүдән соң биш кенә ел яшәп өлгерә. Шәле зиратының капкасыннан кергәч, ерак та түгел «Кәримов Әдһәм Кәрим улы, 1906 – 1951» дип язылган йолдызлы мәрмәр күрсәгез, ул минем әтинең кабере булыр. Без Нуриәхмәт кызы белән кайтып, хәлдән килгәнчә зиярәт кылабыз.

2017 елның җәендә зират капкасыннан керсәк, шакмаклап коелган таш плитәләрне тезеп, шәһәр тротуары кебек тигез һәм туп-туры сукмак салганнар... Ак түфлиләреңә тузан кундырмыйча гына атласаң, мөслим-мөслимәләрне оҗмахка өндәүче рухани авылдашымның туганнары каберлегенә килеп терәләсең.

Мавыгып, әтинең каберен үтеп киткәнбез.

Дөресрәге, югалтканбыз!.. Йолдызлы мәрмәре исән, чардуганы гына... сукмак турайтучылар аны көньякка борып куйганнар. Һәм әтинең бозлы Днестр суында өшегән аяклары таш тротуар астында калган. Әтинең рухы рәнҗиме – рәнҗи! Сез бит җанны рух дип өйрәтәсез! Җан ул, димәк – уй, аң, аваз, сүз... Димәк, рух учак аша үтә ала!.. Әтинең рухы исән... Әгәр мин 1906 елда туган булсам, Днестр суын кичәсе идем. Әгәр әти 1950 елда туган булса, Бөек җиңү көнне үткәрелә торган «Үлемсез полк» агымында ул минем орденнар тагылган портретымны күтәреп йөриячәк иде...

## Каравыл! Яз килә!

Каравыл!

Тыныч кына яшәп ятканда, кар көртләренә ияләнеп, озын төннәрнең куелыгына җайлашып, көздән килгән татлы хәзинә белән сыйланып, тәүлегенә уналтышар сәгать телевизор карарга күнеккәч кенә, көтмәгәндә, тагын Яз килә дә җитә! Урамда ияреп йөри, тәрәзәдән карап тора. Картаеп беткән тал-тирәкләрдә япь-яшь бөреләр уяна, кыш буе йокы симерткән инеш икенче ягына борылып ята... Җылы җилләр өйгә кереп пышылдый: Яз! Яз! Яз-з-з инде, зинһар!

Ә мин яза алмыйм, кәгазьне каләм белән җәзалап, гаеп эзлим, саргайганын акка, агын яшелгә алыштырам. Начар яза дигән булып, ручкаларның әле берсен, әле икенчесен сайлыйм. Чуаланып беткән фикернең җеп очын табалмыйм. Мин бит прозаик, димәк, соңгы сулышыма чаклы язарга хөкем ителгән илһамият колы... Шагыйрьләр башкача – алар кырык яшькә чаклы кабаланып яза да, аннан соң барлыгын иллегә тапкырлап, трибуна саен күкрәк кагып яши... Монысын ихластан, ак көнләшү белән әйтәм. Әйбәт шигырь язар өчен шагыйрь булып туарга кирәк. Ә прозаиклар тумый (!), үсәләр генә...

Ерак сәфәрнең вак-вак тукталышлары була. Иҗатта да шулай – ике әсәр арасында еш кына юл өзеге килеп чыга. Ул арада, фикер туплыйсың, уйланылган сюжетны тыгызлыйсың, хәтта язылачы әсәргә исем таба алмыйча да интегәсең. Соңгы тукталышның сәбәпләрен әллә кайдан эзлисе юк – ике зур күчеш нәтиҗәсе бу.

Шушы яшемә җитеп, минем бер генә тапкыр да иҗат йортларына барганым юк. Зарлануым түгел – үзем теләмим. Һәм мактануым да түгел, мин бары тик үз өемдә генә яза алам... Ә соңгы елларда туган авылымда йорт салып куйгач, канатлы атым бураннага төште. Шәле белән Казан арасында йөреп, атна саен урын алыштыру иҗат өстәлемне ашханә итте. Моңа кем гаепле, дисез – әлбәттә, Нуриәхмәт кызы!.. Алмагач чәчәкләрен кырау сукса да, корылык ел килсә дә, баганалар авып, ут бетсә дә... ул гына гаепле, үземә үзем җикеренә алмыйм бит инде мин. Ә ул минем әйтер сүземне, ни уйлаганымны, кыласы гөнаһларымны алдан ук сизеп тора, һәм мин аның сизгәнен сизенеп, намус газабы кичерә башлыйм.

– Авылга кайткач та, һаман телевизорга багынып утырма инде!..

Нуриәхмәт кызы бу. Мине, бары тик мине генә тәрбияләр өчен табигать аңа арфа тембрлы тавыш биргән. Бу тавыш мине буйсындыра, тынычландыра һәм әллә кайлардан эзләп табып: «Кайчан кайтасың инде?» – дип чакырып тора, үткен телемне коралсызландыра, гади эшчеләр арасында йөреп, сигез ел буе ятлаган шыксыз лексиконымны сызып ташлый.

Моннан өч йөз чакрымдагы Әгерҗенең кечкенә генә Чаж елгасы буенда туып үскән кызы Шәлене тәмам яратты: җирен хөрмәтли, миңа ияреп, тургайларын тыңлый, каен җиләкләре белән сабыйлар телендә сөйләшә, оныкларыбызга күбәләкләр тотып бирә. Болары җәйгә чыккач... Ә бүген әле Мишә буе яз әсирлегендә! Нуриәхмәт кызына каты бәрелеп булмас, ул әнә – яз өлешенә кереп, фанера көрәге белән парник эченә кар ташый. Бит алмасы да әнис сорты кебек алсуланган...

– Телевизор да карамагач... бүтән кәмит юк ич авылда. Җир ачылмаган, үсентеләр тәрәзә төбендә гөрләп үсә, симәнә бәрәңге баздан чыгарылган килеш буразнасын көтеп ята.

– Эш юк дип, өйдә ятма инде. Кичке сериаллар җитмәгәнме сиңа?!.

– Сериаллар – алар синең өчен. Ә миңа маҗаралар, яңалыклар кирәк.

– Маҗара, яңалык кирәксә – үзең яз. Соңгы романың чыкканга да дүрт былтыр инде.

– Яшь бара бит! Эштән кайткач ял итәсе дә килә.

– Вагон бушатмыйсың ла! Эшкә бит сез күңел ачарга гына йөрисез. Юбилейлар, иҗат кичәләре, банкетлар – көн дә бәйрәм... Язуыңнан туктасаң, беркемгә дә кирәгең калмас.

– Язып кем баеган хәзер? Җүнләп гонорар түләнмәгәч, язучылык кыз-хатын һөнәренә әверелде. Ирләр мал табуга китте. Тагын егерме елдан Язучылар оешмасында бер ир-ат та калмаячак.

– Алайса бөтенләйгә күчеп кайтыйк авылга. Мал асрарбыз, бакчаны зурайтырбыз. Ачтан үлмәбез. Оныклар да безнең янда үсәр иде.

– Син үзеңнең колхоз стипендиясенә укыганыңны оныттыңмы? Диплом алгач та, язылышып өлгермәсәк, «Коммунизмга» колхозында китапханәче булып, пенсиягә чыкканчы эшлисе кеше идең. Миңа кияүгә чыгуың да Казанда төпләнеп калыр өчен генә булгандыр әле?!. Ә хәзер авылга китәргә дә риза үзең.

– Абау, Камка! Бер дә серкәң су күтәрми инде. Күптән язганың юк, дигәнем өчен әллә кая борып куйдың...

– Әйе, бөтенләй кайтсам, Корыч малае язучылар арасына сыймады, кулыннан килмәде, әллә кем кебек йөргән иде, диярләр...

– Соң, шулай булгач, ник язудан туктадың?! Көпә-көндез телевизор карап ятасың. Сүндер әле шул Кытай тәрәзәсен! Бар, бикләнеп ятма. Урамда яшь вакыттан калган берәр сюжетың очрамасмы? Уйларың җилләнеп керсен.

Мин көн җылысы белән өй җылысы тигезләнгәндер, дип, иңгә «дежурный» пинжәкне элеп, яланбаш кына кузгалмакчы идем, шундук ишек белән ике арага килеп басты.

– Бик җиңеләймә әле, курткаңны ки, мә, кепкаңны да ал, кояш кичкә авышкан чак, көн кыркулангандыр.

– Син мине бөтенләй куып чыгарасың мәллә?

– Салкын тидереп ятсаң, язмавыңнан да хуҗерак булыр, җылы киенеп йөр.

«Куып чыгарасың мәллә» дигән сүзне уенга бора ала иде инде. Юк шул, кәефсез чакта юмор дигәнең тел очында боегып тора бит ул. Юкса хат ташучы

курчаклар алып килгән анонимка турында сүз башларга җиңелрәк буласы. Бу турыда мөмкин кадәр тизрәк әйтәсе иде. Әле бит гайбәт бомбасының шартлыйсы бар, ул шартлагач, гауга төтене таралганчы да атна-ун көн үтәр. Ә хат җибәргән кеше ерак йөрмидер, озак көтә алмас, монысы адресатка (әлбәттә, Нуриәхмәт кызына) барып җитмәде, ахрысы, дип, яңасын – тагын да көчлерәген, гаилә нигезен чәлпәрәмә китерердәен язып салырга мөмкин... Ярар, бүген генә булса да тынычлап яшәп калыйк әле. Иртәгә әрләшербез, иртәгә...

Өй эчендә колак томалана икән ул, ә урамда – симфония белән какофония бергә кушылган: сыерчык ояларында өй туе; тавыклар җырлый; ата казлар бии; этләр әрләшә, ындыр артында атлар тамак кыра; туры түбәләрдә өелеп калган кар көртләреннән язның соңгы йөрәк тибешедәй тамчы тама – «тып-тып», «дөп-дөп», «леп-леп».

Йа Хода! Нуриәхмәт кызының самимилеген күр – шушындый язга ирнең үзен генә куып чыгаралармы инде?!.

Өй түрендәге гөрләвеккә ияреп киттем...

Авылда өйләр саны мең ярымга җиткән, диделәр. Бүген мине аларның өчесе генә кызыксындыра: Оренбург далаларында Чирәм җир сөреп йөргән арада урланган Хәмдия... Кавышсак та, монда яшәргә ирек бирмәячәкләр, алып кит мине дөнья читенә, дип, кыш уртасында Магаданга озатып калган Сәвия... Һәм гипнозга тиң тәэсир итү көченә ия булган, теләсә, мине бик җиңел генә үз ихтыярына буйсындыра ала торган исем бар, ул – Гөлназ!

Безнең авылда элек-электән нинди дә булса берәр исем модага кереп алган... Әбиемнәр чорында, Биби, Бикә исеме нык таралган. Әниемнең чордашлары арасында Мәдинә, Хәдичә, Зәйтүнәләр иде. Соңрак Әлфия, Сания, Тәнзиләләр күбәйде... Аларга алмашка Роза, Илсөяр, Сәрияләр килде... Бүген исә Алсу, Диләрә, Алияләрдән дә күбрәк исем юк...

Мин яшәгән мохиттә алай ук очрамасалар да, Гөлназ дигән исемнән әле дә сискәнеп китәм. Беренче тапкыр мин бу исемне, 4 нче классны бетереп, җәйге каникулга чыккач ишеттем. Ул вакытта инде Шәледә 26 урынлы участок больницасы эшли иде. Инештә карбид белән уйнаганда, шампан шешәсе шартлап, Климның (укытучылар булып килгән керәшен гаиләсеннән) кулы ярылган иде. Тиз генә врачка йөгереп мендек, Климның ярасын бәйләгәннәрен урамда көтәбез, этисенә кайтып әйтергә котыбыз алынып тора. Без көткән арада Гөлҗамал апа бала күтәреп чыкты, аңа ак халатлы, ак калфаклы, ап-ак чырайлы бер шәфкать туташы ияргән иде. Гөлҗамал апа урамның бөтен бала-чагасын таный, чөнки чана шуа торган иң текә тау аларның өйләре каршыннан башлана. Ике яшьлек кызын ник күтәргәнен аңлыйбыз, күзен дә ачмыйча, туктаусыз елый теге, суга төшкән күбәләк канаты ише, керфекләре ябышкан бугай. Мин аның каш өстенә шомырт төше ябышкан дип уйлаган идем, ул миң булып чыкты. Гөлҗамал апа кабат-кабат такмаклый: «Елама инде, Миңниса кызым, тәпи йөргән бала елаудан туктарга тиеш. Нинди генә дарулар биреп карамадык инде, авырткан җиреңне тапмаган килеш тә...» – дип, кат-кат әйтүе без ишетсен дә бөтен авылга җиткерсен өчендер инде... Авыл ишеткән, Миңнисаның исемен алыштырырга киңәш иткәннәр. Чынлап та, мулла булып йөрүче Фатыйма абыстай Миңнисага кайтармыш дога укып, аңа Гөлназ дигән яңа исем кушкач, бала елавыннан туктаган. Еламаганын үз күзләрем белән күрдем, чын әгәр... Шуннан бирле авылда Миңниса дип исем кушулар бетте.

Алга таба Гөлназ дигән аһәң мине эзәрлекле башлады. Адашкан мосафир офыксыз буранда юл эзләгән кебек, юк, кыргый аланда кеше күзеннән качып

үскән иң эре җиләкнең барлыгына инангандай, як-ягыма каранып, гавамнан шушы исемне эзләдем. Мин бу халәтне балачакның самими алгысынуы гына димәс идем... 1995 елда мине Университетның татар журналистикасы бүлегенә укытырга чакырдылар. Сәер бит, кайчандыр укырга керә алмаган уку йортында «Чаян» журналының җаваплы секретаре «Сатира һәм юмор» буенча лекцияләр укыйм, зачётлар куям. Үземә дә кызык була башлады. Төп эшемә зыян китермәсен өчен минем лекцияләрне расписаниенең соңгы сәгатьләре итеп куялар иде. Өч ел укыган студент өчен соңгы сәгатьләрнең ни икәнен аңлатып торасы юктыр... Мәгәр минем дәресләрдән кемнең дә булса качып киткәнен хәтерләмим... Педагог рәвешенә кереп мавыгуым шул дәрәҗәгә җитте ки, мин инде «Чаян»нан бөтенләй китәргә дә риза идем. Ләкин! Гөнаһ шомлыгына каршы, араларында Гөлназ исемле Казан кызы бар... Баштагы мәлләрдә мин аны күргәч, Гөлҗамал апаның ике яшьлек елак кызын гына күз алдыма китерә идем, хәтта каш өстендә шомырт төше кадәр генә миңе дә бар кебек. Дөресрәге, шулай тоела гына иде миңа. Ике яшьлек бала образы ни арада унтугыз яшьлек кызга әверелгәндер, белмим. Ләкин көннән-көн сокланып, лекцияләремне гел аңа карап кына укый башлавымны студентлар да сизгәндер дип уйлыйм. Дүрт семестр түздем! Исәп-хисапны да өзмичә китеп бардым, анысын алдашмыйм. Декан Флорид абый Әгъзәмовның: «Ник китәсең инде?» дигәнен дә хәтерлим... Ә Гөлназның күзләре нинди төстә, чәче сарымы, чем-карамы, ияк очында мәхәббәт чокыры бар идеме-юкмы, нindirәк күлмәк кия иде – боларның берсен дә хәтерләмим, күрмәдем дә бугай. Ул минем өчен Гөлназ исеменең гәүдәләнеше генә иде. Чибәр иде бугай ул. Чөнки шушы яшемә җитеп, минем әле Гөлназ исемле ямьсез кызларны күргәнем булмады. Зинһар, дорфалыгым өчен гафу итегез, бәхетсезләр арасында чибәр кызлар күбрәк. Яшьлектә һәр егет үзенә чибәрне эзли. Ә бер кеше бары тик бер генә кешене бәхетле итә ала – бу аксиома! Табигый сайланыштан узмаган бүтәннәр Гөлназларын гомер буе сагынып интегә, кабат күрешербез әле, бәлки, соңлап булса да, кавышырбыз дип, янында гомер кичергән тугры хәләлен югалтырга әзер булып яши. Чибәр кызларга күз тия, дибез, юк, күз тиюдән бигрәк аларга сөелми калган гашыйкларның сагыну сагышы каргыш булып төшә. Җир шарына җиде миллиард бәхетле сыеша алмый, бәхетнең дә үз квотасы бар...

Мин ияреп киткән гөрләвекнең юлы кыска булды, Мишә ярына җитәрәк кар астына төшеп югалды... Өйдән куып чыгарган кеше юксынсын бераз... Кояшның эше бетмәгән әле, ә минем эш беткән. Бүген шимбә. Күпләп кунаклар кайта, атна буе бушап торган авыл ял көннәрендә тагын тыгызлана.

Авылда туып-үскән, шәһәрдә гомер кичкән һәм ахырда кабат «яшел бишегенә» кайтып егылган, минем ишеләр өчен күңел юаткыч урыннар юк. Татцикта мәчет бар барын, ләкин минем әле анда йөрер өчен яшем җитми. Белгән догаларымны укып, федераль юлны исән-имин кичеп чыккач, Шәле үзәгенә теркелдим. «Совет» урамы бу. Иң зур урам... Ул Шәле үзәгеннән башланып, «КамАЗ» юлы аша чыгып, Татцик авылында буеннан-буена дәвам итә. Бүген мин аның 58 нче йортында яшим, ә менә монысы 13нчесе – мин туып үскән нигез. Ике авылга бер урам, икесе дә минеке... Әтием, әбием җан салган нигез урыны ишегалдына әверелгән. Безнең өйне кибетче Сәгъдәт апа алган иде, кызы кияүгә чыккач, алар яшәп караганнар, тик ярты елдан аерылганнар... Аннары классташым Салих сатып алган... Төнге берләрдә ут чыгып, соңгы эргәсенә чаклы янып беткән... Беренче карашка, үземә генә

кагылышлы кебек тоелган өй язмышын ни өчен артык тәфсилләп язам? Хикмәте алда... «Корыч» нәселенең шәҗәрәсен аз булса да ишеткән-белгән күршеләр бу урынны каргышлы дип табалар, 13 нче сан булганы өчен түгел, урам исемнәрен калайга язып, капка баганасына номер сугу 70 нче елларда гына башланды әле. Классташым Салих сул тарафка җиде адым китеп, яңа нигез казый башлый... Мин белә-белгәннән әлеге җир буш ятты. «Ул урында кар базы барые, атаң күмде, анда әйбер үсми» дигәнен әнидән бер-ике кат ишеткәнем булды. Түбән өй астын тирәнрәк итәм, дип, җиң сызганып казый башлаган җиреннән, Салих кинәт күрәгеен тотып ата, чырае ап-ак булып, сыны катып кала... Әрдәнәләп күмелгән баш сөякләре тегендә... Юк, юк, кешенеке түгел! Аллам сакласын! Тәүбә-тәүбә! Сыер, үгез, ат башлары...

Әтинең сугыштан кайткач та, ветврач булып эшләвен әйткән идем инде. Колхоз заготконторага ит тапшырса, берәр сыер бозаулый алмаса, йә күбенсә, ферма малларын «ат духтыры» суя бит инде. Көн саен түгелдер, әлбәттә. Бавырын-картасын ферма мөдире алып китә, ә эре терлекнең баш сөяген туныйсы бар – анысы әтигә. Барлы-юклы кырык дүрт яшьлек гомере тулаем Сталин чорына туры килгән штраф рота солдаты каезланган мал сөякләрен урамга чыгарып ыргытсынмы?!. Тайный милиционер Мөхәрләм малайлары шундук барып чага бит аның өстеннән, өч бала тагын ятим кала... Корыч малае авыз тутырып ит ашап үскән, дияргә ашыкмагыз, мин әтидән ярты яшьлек кенә булып калган...

Әйе, шуннан соң классташым Салих иске нигезнең уң ягына, «плугарь» җиренә йорт күтәрә. Өй туе үткәреп, атна-ун көн узгач, йокыга киткән җиреннән ул да уянмый.

13 нче санга туры килгән безнең нигез язмышы гынамы бу?!. Юк, бу – миллионнар язмышы. Өен, гаиләсен, илен югалтканнар язмышы. Йортны кем салган – шуның нәселе нигезне сакларга тиеш! Илдәге һәр күчеш, кискен яңалык, һәр сәяси үзгәреш зур югалтулар хисабына килә. Бу дөньяда һәрбер инсан үз нигезендә генә яшәсә, Җирдә сугышлар булмас иде...

Кичерегез, авыл үзәгендә, янгын сүндерүчеләр каланчасының чаң күләгәсендә бераз тукталып торган идем, бу күңелсез уйлар шуннан гына.

Үткән заманны сүгәбез, киләчәк заман белән мактанабыз... Менә шушы инде ул Указлы демократия. Хәзерге заман михнәте һәрвакыт гади халык җилкәсендә. Ярлылар бәхете өчен көрәштә байлар җиңүче була...

Бүгенгене саклавы иң кыены. Абзагыз язгы җилләрне куып йөри дип уйлыйсызмы? Совет урамының 58 нче нигезенә тынычлык даулап йөрим мин. Нуриәхмәт кызына исемсез хатны укытканчы, мин аны кем язганын ачыкларга телим. Ә, бәлки, шушы хәйлә белән үз-үземне алдап кына йөримдер. Беләм бит инде, Гөлназны күрәсем килә. Кайда яши, кем булып эшли, кем белән яши, олыгайгач үзгәргәнме, иң мөһиме... Мине югалтканына үкенмиме?.. Ә күңел түрендә «Үкенсә иде...» дигән әдәпсез өмет үз сәгатен көтеп ята. Әйе, эгоист мин, әйе, мактанчык, җитмәсә – көнчел. Һәм рөхсәт итсәгез, ахыргача үзем булып калыр идем.

Гөлназларның капка төбеннән уздым, ашыкмыйча, инфаркт илә инсульт арасында калган кешедәй, авыру адымнар белән. Таныш өй, тышланган такталары яңа гына буялган, ләкин төсләре һаман да шул ук... Узып киттем, борылып килдем, мине сискәндерерлек ым юк...

Кинәт кенә башыма килгән уйдан канатланып, адымымны кызулаттым. Без бит укытучыларга «абый», «апа», дип эндәшә торган идек. Абый-апалар

барысын да белеп тора... Караңгы төшеп, халык телевизор каршында мәрткә киткәнче, мин Гөлназның яраткан абыйсын күреп өлгерергә тиеш.

Мөхәммәт Садыйков биш литрлы су күтәреп, ерак чишмәдән кайтып килә. Әле ике генә ел элек авылның мәдәният йортында без аның 80 яшьлегенә багышлап, ике сәгатьлек иҗат кичәсе үткәргән идек. Мине алып баручы буларак чакырдылар. Кичәсе гөрләп үтте. Соңыннан аркамнан сөеп, рәхмәтен дә әйтте хәтта.

Ул мине ерактан ук күреп өлгергән, шуңадыр, шат, рәшәткәле капкасын ачарга ашыкмыйча көтеп алды. Сәламләшү сүзләребез сценарийларда языла торган әзер җөмләләр кебегрәк иде, аларны кабатлап тормыйм. Гөлназга кагылышлысыннан башлыйм.

– Аның турында юбилей кичәмдә үк сорашырсың дип көткән идем... Дару эчеп тә бетерә торган чир түгел бит ул, каһәр суккан гыйшык... Мә, чишмә суын йотып куй.

– Июль чылләсе түгел бит әле, Мөхәммәт абый.

– Янган йөрәгең басылсын, дип әйтүем.

– Бөтен кеше су эчеп кенә онытыр иде.

– Миллион ел узгач, кеше яңадан туа, диләр. Кавышырсыз әле. Буйдакмыни соң син?

– Юк шул! Диплом алгач өйләндем. Инде кырык ел яшибез. Оныкларыбыз гына да өчәү.

– Алайса һаман сайланасың икән әле.

– Юк инде! Сайланмыйм да, эзләнмим дә...

– Мәхәббәт турында язасың, димәк...

– Фатыйх ага Хөснине беләсез бит, әйеме?

– Белмәскә. Ул чаклы ук инде син, авыл укытучысы дигәч тә. Мәктәбебезгә очрашуга да килгәне бар... «Йөзек кашы» дәреслеккә кергән.

– 1982 елның март ае иде, монысын төгәл беләм, ул безгә:

«Егетләр! Хатын-кызның бөтенләй кирәге юк икән аның! Вакытыгызны әрәм итмәгез. Языгыз сез, языгыз», – диде.

Үз күзләрем белән күргән хәлне Мөхәммәт Садыйковка сөйләп бирдем дә инде аның бәяләмәсен көтәм. Ул ирен читен дерелдәтеп кенә елмаю рәвешен китерде.

– Әллә син дә гелән язуга күчтеңме? – дип куйды.

Мактанчык кеше мактанганда яшәреп ала, ләкин 80 яшьлек мөгаллим каршында мактанып тору аны кимсетү кебегрәк кабул ителер иде, шуңа күрә дә ташка басардай сүзләр белән җавап кайтардым.

– Мин Гөлназны күргәннән бирле язам инде. Әгәр язучы булып китсәм, ул гына гаепле...

– Тирән кайгыңны уртаклашам.

– Бу кайгының тирәнлеген кем үлчәгән инде?..

– Ә ул бит сиңа хат язды. Үзен урларга йөргәннәрен сизгәч, клубка да чыкмый башлаган иде. Гөлләр кибетендә, иртәрәк ачылмасын дип, гөләп чәчәкләрен җеп белән бәйләп куялар да бит... Кыз бала чәчәк атса, аны бау белән бәйләп тә тота алмыйсың. Урладылар Гөлназыңны. Бүтән кайтмыйм дип киткәнсең ич. Ә ул сине көтте, паспортларын әзерләп көтте. Хат язгач, миңа синең адресыңны сорап килде. Культура институтының адресын гәҗиттән үзем күчереп бирдем: Оренбург тракты, 59 нчы йорт. Бүгенгедәй хәтерлим... Кайтырга иде шул чакта.

«Алмадым мин ул хатны, алмадым. Юкса төн уртасы булса да, җәяүләп кайтасы идем», дип акланырга теләгән идем, шагыйрь укучы кызы өчен рәнҗүен, шуның аркасында миңа карата уянган ачуын күрсәтмәскә тырышып, саубуллашмый-нитми генә өенә кереп китте.

СССР чорында почта шултикле төгәл йөри торган иде. Посылкалар югалмады, бандерольләр ертылмады. Питрәчнең элемтә үзәгеннән сигез чакрымдагы Шәле почтасына елның теләсә кайсы аенда газета-журналлар, хатлар-пенсияләр төялгән ат көндезге 12 гә төп-төгәл кайтып җитә иде. Көн саен! Әгәр инде дүрт тиенлек марка ябыштырылган хатың тиешле кешеңә барып җитмәсә, «Адресат выбыл» дигән тамга белән хуҗасына кире әйләнеп кайта иде... Шагыйрь абый адресымны дөрес әйткән, димәк хат, мин укыган җиргә барып җиткән, димәк, аны кемдер алып укыган... Әле минем исемнән, мыскыллаулы җавап та язган булыр иде, димәк, Гөлназ үзенең адресын күрсәтмәгән. Ул «кемдер»не куктән эзлисе юк. Зәмзәмия инде...

Рабфакта укып йөргән чакта мин институттан ерак түгел генә Косогорная урамында ялгыз әби янында яшәп тордым. Әби шактый олы яшьтә, урамга чыгып йөрми, кирәк-яракларны гастрономнан үзем алып кайта идем. Беренче курска кабул ителгән студентлар исемлегендә үземнең фамилияне күргәч... Ниһаять... мәктәпне тәмамлаганнан соң ун ел үткәч... мин көндезге бүлек студенты! Сөенечтән күзгә яшь тыгылды, шатлыгымны уртаклашырга, дисәм, ичмасам фойеда бер таныш кешем дә юк... Кемгәдер мактанасым, сәгатьләр буе елмаеп торасым килә. Авылга кайтсаң, классташлар миннән көләчәк кенә, алар арасында инде фәннәр кандидаты да бар... Ә мин I курс студенты, укып чыга алсам әле...

Киндерле бистәсендә яшәүче абыем янына киттем... Ул этиләр сугышы башланырга ярты ел кала туган бала. Минем Культура институтына керүемне өнәп бетермәде:

«Ни ветврач син анда, адвокатлар, инженерлар әзерли торган җир дә түгел. Безнең нәселдә сәхнә тирәли йөгереп йөрүчеләр бөтенләй юк! Кемгә охшап үстең соң син шулхәтле?» – дип, сөенечемне томалап куймакчы булды.

Мин каршы дәшмәдем, мактанасын мактанып эчемне бушаттым да электр самавырының ялтыравыгында үз чыраемнан үзем көлеп утырам. Абый һаман да мине әрли әле.

«Төзелеш институтының гидрогеология факультетына кергән булсаң да, аңлый алыр идем, су тирәсендәге һөнәрләр – акчалы! Ай саен 600-700 сум акча алып эшләгән мужик бала-чагалар арасында 40 сум стипендиягә йөгереп йөр инде хәзер».

«Абый, борчылма, ярдәм сорап килмәм. Студентларны төнге охранага алалар икән. Сөйләшеп куйдым инде».

«Ну, да, ярдәм сорамассың, беләм. Горур бит син, Зәмзәмияңә бөтен җиһазлары белән өч бүлмәле фатирыңны калдырып чыгып качтың... Стипендияңнән алимент та түләтәчәк әле ул, менә күрерсең. Миңа кире кайтмаса, бүтән беркем белән дә яшәтмим, барыбер араларын бозам, дигән».

«Беренче ире артыннан да шулай эзәрлекләп йөргән булса, бәлки, минем язмышка килеп тә җитә алмас иде дә бит».

«Хатын-кыз янында күзеңне ачыбрак йөрмәсәң...»

«Юрган астында күз йомыла бит ул, абый», – дим, ниһаять, сүзне икенче юнәлешкә борырга телим.

Абый як-ягына каранып алды.

«Саграк, энекәш, җиңгәң кухняда гына, безнең «хрущёвка»ларның стенасы

юка. Хатын-кыз һәрвакыт хатын-кызны яклый, – диде ул пышылдап. Аннан, тавышын көчәйтә төшеп өстәп куйды. – Җаен тапсаң, җүләр кеше белән дә яшәп була. Теләсәң, түзә ала идең инде».

«Хыялым исән бит әле, абый! Җиденче класстан бирле тынгы бирмәгән хыял, һаман үртәп тора.»

«Аңлыйм, энекәш. Минем дә хыял бар иде...»

«Беләм. Очучы булырга теләгәнсең!»

«Әйе. Әле бүген дә самолёт күрсәм, муеным каерылганчы карап калам. Ә һөнәрем икебезгә дә уртак, гомер буе җир астын бораuларга туры килде. Ярар безнең нәселдә дә берәү үзенең чын хыялын тормышка ашырырга тиештер инде... Ә Зәмзәмияң мәсьәләсендә, артыңда күзең булсын, ул синең эзеңнән йөри. Монысын точно беләм. Всё! Акыл өйрәтүне туктаттым. – Абыйның почмак ягына борылып: – Кая, Гөлдәлия, энекәшкә дигән сыең? Чыгар инде!» – дип дәшүе булды, шундук көмеш подноска тезелгән нигъмәт каршыбызга килеп кунды. Хәтта абый, гомердә булмаганны, җиңги алдында рюмкаларга «Экстра»дан эчемлек салды, ә җиңги, гомердә булмаганны, өстәлдә шешә күрә торып, абыйга бер сүз әйтмәде...

Һәм миңа ул кичне алпавыт малае шикелле итеп, ястык өстенә урын җәеп бирделәр.

Икенче көнне фатирыма кайтсам, әби, мишәр әйтмешли, караватка яткан да матчага баккан, үз-үзеннән сорау алып, җавабын да биреп маташа. Бер-ике җөмләсен ишетеп калдым.

«Гаиләм юк, дигән кебегие?»

«Мин аның хатыны, ди бит».

«Ник ялгыз суң ул, алайса?»

«Мин аны укырга гына җибәрдем».

«Кайтканын көтик, алайса».

«Ашыгам. Машина көтеп тора. Керләрен юып китерәм, чемоданы кая?»

«Һм-м! Хатыны кебек сөйләшә. Юмарт. Ачык йөзле үзе...»

Әби һаман да мине күрми әле. Караваt кырыендагы өстәлдә бер тәлинкә зефир, шырпы тартмасы зурлыгында, көмеш кәгазьгә төрелгән ике-өч сыр, ярты кило чамасы «батончик» конфеты... Иң сәере: миләш рәсеме төшерелгән озын муенлы шешә иде. Шешә ачылган, янында ике чәркәсе дә бар.

Димәк, минем абыйларда кунганны белеп, фатирга Зәмзәмия килгән!

Туфлиемне салырга да онытып, үзем урнашкан бүлмәгә ыргылдым һәм авыз тутырып сүгендем...

Чемоданны идәнгә селкеп нидер эзләгән, әйберләрне кире тутырып та тормаган. Урын-җирне катлам-катлам актарып, «инвентаризация» үткәргән, фотоаппаратымны, төргәкле негативларны, рәсемнәрне, иң хәтәре – хатларны алып киткән. Ни эшләргә җыена ул, тагын кемнәрнең кәефен бозарга уйлый, мине кире кайтарам дип, гасабиланып, кемгә, нәрсә исбатларга тели? Негатив кем кулында – шул позитивка хуҗа, дип, яманатымны чыгарудан ләззәт табамы?

Әле дә ярый, сагынганда карарсың, диптер инде, үзенең Казанга килгәч тә төшкән фоторәсемен минем хезмәт кенәгәсе арасына кыстырып киткән. Анысы ярап куйды, мин аны институтка килгәч, вахтада утыручы абыйга күрсәттем. Таныштык. Юрий Фёдорович – сугыш инвалиды, күпне күргән, ягымлы, туры сүзле кеше. Исемемне бик тиз отып алды. (Укулар башлангач, әллә кайдан күреп сәламли торган иде.) Зәмзәмияне рәсеменнән Юрий Фёдорович шундук танып алды.

– Килде, бик ягымлы сөйләште ханым. Русчасы акцентсыз гына, ди. – Паспортындагы фамилиясенә туры килгәч, сиңа адресланган хатны биреп җибәрдем шул, – ди.

Хат... тагын хат. Мине гомерем буе хатлар эзәрлекли. Язмышым да Татар Совет Әдәбиятына кургаш телемнәре белән язылган: «Киләчәккә хатлар», «Хат ташучы», «Тапшырылмаган хатлар», «Соңгы хат»... (Һ.Такташ, М.Җәлил, Г.Кутуй, Х.Вахит.) Шушы эзлеклелек бөтен иҗатымның эчтәлеге сыман...

Укытучы абый белән сөйләшкәннән соң мин инде исемсез хатның кемнән килгәнен аңладым кебек иде. Әйе, бик мөмкин. Институтта китапханәчеләр факультетындагы бер кызга кызыгып йөргәнемне, аның белән студентлар отрядына кушылып, Молдавиягә барып кайтканымны да ишеткәч, Зәмзәмия тулай торакка кереп, институтка килеп, җәнҗаллар кубарып йөргән иде. Юрий Фёдорович милиция патруле чакыртты. Беркетмәгә кул куйдырдылар да китеп бардылар, ә Зәмзәмия һаман фойеда калды. Милиция дә җиңә алмагач, Юрий Фёдорович студентларның озын тәнәфесендә, Зәмзәмияне пәлтә якасыннан эләктереп, урам ягындагы баскычтан томырды... Шуннан соң гына икегә бүленгән гаилә арасында гауга тынып калды. Исемсез хатның авторы – Зәмзәмия... Ләкин! Ах, шушы ләкин... 45 ел үткәннән соң, яшьлек елларын исенә төшереп, Зәмзәмия әбекәй, иренмичә, почталарга барып, агач курчаклар эченә төреп, хат җибәреп йөриме? 45 ел үткәч... 45 – Бөек Җиңү елы!..

***

Олыгайгач, кеше барометрга әверелә инде ул. Аңа синоптикларның фараз кылуы кирәк түгел. Этләр әрләшүдән туктады. Җилләр урманга качты. Күктә йолдызлар атышы башланды. Тамчылары төерләнеп калган боз сөңгеләренең чатнаганы ишетелә. Мин ияреп чыккан гөрләвекнең улагы корыган. Иртәгә яз челләсе булыр. Татцик урамына аяк басуга, Нуриәхмәт кызы әмере белән диярсең, иңнәренә чыбык күтәреп тезелешкән баганаларда гөлт итеп заман лампалары кабынды...

58 нче йортка җиткәнче, бүгенге хатирәләрнең уйланып бетәсе урыннары калды...

Институтта укулар башлангач, курсташлар белән ике арадагы яшь аермасын еш кына тоярга туры килде.

Мәктәптә укыганда, мин ун ел буе беренче партада укытучылар күләгәсендә утырдым, окулистлар сайлап-сайлап карадылар, тик миңа яраклы күзлек таба алмадылар... Институтта еракта күрдең ни дә якыннан күрдең ни – такта янына чыгып, мәсьәлә чишүләр юк, шуңа күрә дә тәнәфес бетүгә, иң соңгы рәткә утырып өлгерәм, лекцияләр шәп ишетелә, кыштыр-кыштыр конспектлаштырып тик утыр... Педагогларның күбесе Ленинградның Н.К.Крупская исемендәге институтын бетереп килгән яшь укытучылар, аларга әле нибарысы 22-23 яшь кенә, аудиториядә үзләреннән олырак абзагызны күргәч, деканатның берәр кураторы утыра дип шикләнәләр идеме; дәресне бүлеп, еш кына: «Извините, Вы кто?» – дип сорый торганнар иде. Андый чакта яшь курсташларымның миңа таба борылып, кумәкләшеп көлгәннәре әле дә хәтеремдә.

Укуның беренче көнендә үк студент билеты тоттырдылар, ә аның белән көндезге укудагылар өчен 1 сумлык «проездной» алып, шәһәр эчендәге бөтен транспортта бушлай йөреп була иде. Авылга кайтам дисәң дә, юл хакының яртысын гына түлисе иде... Түләвен түлим, ләкин кондукторлар каршыма килеп баскач, яшь шәкертлегемә ышанмыйча, һаман саен студент билетын

күрсәтергә кушалар. Ярый, хуш, моның ише көндәлек сынауларга ияләшергә дә була. Тугыз катлы тулай торакның дүрт караватлы кына сыешлы бер бүлмәсеннән урын бирделәр. Эштән кайткач, кәнәфигә кырынаеп, «Рекорд» телевизоры каршында гәҗит укырга һәм: «Аягыңны күтәр, идән кипмәгән әле!», «Ашарга чык, ризык суына!», «Сал бу күлмәгеңне, якасы керләнгән!» кеби әмерләрне генә үтәргә күнеккән мужикның студент егеткә әверелүе – яңадан туып, тәпи йөрергә өйрәнүе кебегрәк икән ул. Студент күлмәген дә үзе үтүкли, ашарга да үзе пешерә, Акмалов Нәсимнең шагыйрь абыйсы таптап чыгып киткән протекторлы ботинка сукмагын да саплы чүпрәк белән юарга тиеш икән!.. Бактың исә, хыял гап-гади чынбарлыкта гамәлгә аша һәм аның шушы рәвешле сынавына хыялың алдан ук әзерләнергә тиеш. Кыр казлары очып үткән болында чирәм чүпләп йөрүче йорт казы ич мин хәзер... Аудитория дип аталган уку залларына кергәч, агач мәктәбемнең утын яга торган бүлмәләре искә төшә, тулай торакның сыңар тәрәзәсеннән тулган яктылык та салам түбәле өемдәге кебек...

Икмәк кибетләрендә авылдашлар капчык тутырып ипи ала, октябрь ае, мал симертергә әзерләнә халык. Мин – сакаллы сабыйны күргәч, тәмам димче карчыкка әвереләләр: Ботан бакчасы янында гына белгән кешем бар, үзе матур, аерылган, баласы да елар яшьтән узган; әнә, институтыңнан ерак та түгел, Мирный бистәсендә... ире үлгән, өч бүлмәле фатирда әнисе белән генә калды. Төскә-биткә чибәр, буе да сиңа таман, баласы да юк... Күрәсең, минем мужиклыгым йөземә чыккандыр. Ашханәгә кергәч тә, симез-симез апалар, минем чират җиткәч, сосмаларын читкә куеп, шулпа парыннан тирләгән маңгай чәчләрен ак кәпәч астына яшерә башлыйлар.

Ә шулай да Нагорный бистәсендәге Җиләкле урамына барып карадым мин. Яучыларым әйткән «үз йортлары белән яшиләр»не бик тиз эзләп таптым. Сәхнә бизәлешенә охшаган тәбәнәк юка капканың киләсен бавы өзелмәслек итеп кенә келтерәтә торгач, маңгай турысы ак мулине белән чигелгән, ак яулыклы, әниемә яшьтәш булырдай апа чыгып алды. Күрәсең, өйләрендә телефоннары да бар (димәк хәлле гаилә, кемнәредер зур урында эшли), минем киләсене хәбәр итеп өлгергәннәр.

«Ә, синме?» – дип елмаеп каршылады ул.

Капкадан болдыр баскычына чаклы җәелгән такта сукмакны балавыз төсенә кертеп юганнар. Ишегалларындагы алмагачка караганда, өй салып кергәннәренә утыз еллап бардыр, шәт, миңа димли торган кызлары да шул чамадыр. Ул арада агачның иң очында онытылып калган бер алма аяк очына сикереп төште.

«Күр әле, Ходайның фалын, соңгы алма бит ул. Ал әле аны, ал. Әминәмә үз кулларың белән бирерсең» – дип, апа мине ияртеп керде.

Өйләре өч бурадан салынган иде, уртадагысы чәйханә хезмәтен үти бугай: савыт-саба шкафлары түшәмгә чаклы, нигъмәт өстәле уртада калган, тәрәзәнең ике ягында отышларга гына эләгә торган ике суыткыч – ишеген ачсаң, азык-төлеге ишелеп төшәдер... Үземне өй сатып алырга килгән вак сәүдәгәр кебек хис иттем... Як-ягыма каранып торуымны үзенчә юрады хуҗабикә:

«Алдагы өйдә – зал, кече кызым шунда йоклый, Әминә бүлмәсе – әнә тегесе... Әминә, чык әле кызым, синең янга килгәннәр».

Кулына алма тоттырасы өлешем: «Нәрсә бар, әни?» – дип, белмәмешкә салышып чыкса да, кыз инде кичтән үк киенеп-ясанып, төне буе йокламыйча, мине көткәнгә охшаган иде. Вакытны әрәм итмичә генә, алманы Әминәгә суздым. Ул аны, әллә каушавыннан инде, шундук тешләп тә алды:

«Мин бу алмага күптән кызыгып йөри идем инде, чеме нык идеме, коелмады, сезнең килгәнне көткән».

Әминә елмаюын югалтмый торган арада мин аны фотоаппарат тизлеге белән генә күздән кичереп өлгердем. Гәүдәсенә караганда «апа» дип эндәшәсе килә үзенә. Тезенә тияр-тимәс күлмәге диңгезчеләр «тельняшка»сы тукымасыннан тегелгән кеби аклы-каралы киң сызыклары таза тәнен телем-телем бүлеп күрсәтә, итәге дә, җиң очлары да кулдан чигелгән.

«Сез кул эшләренә бик оста икән, матур итеп чиккәнсез», – дидем, аптырагач.

«Бераз бардыр инде... Төннәр озын ич... – Бу юлысы Әминә елмаерга онытты. – Утырды инде бу күлмәк. Яраткан кием тиз туза, диләр бит...»

Синең алда ыспай күренергә теләп, берәр размерга кечерәеген кидем, дисә, мин дә елмаясы идем. Әминәнең сурәте авылдагы кызлар, институт ашханәсендә күренгәннәр, альбомдагы рәсемнәр, Илсөяр, Сәрия, Тәнзиләләргә охшаган сыман; майлы корым сылангандай елкылдап торган чем-кара чәче дә, күкрәгенә салган калын толымы да үзенеке ләбаса инде; ияк очында мине үртәп торган мәхәббәт чокыры да бар хәтта... Ләкин Гөлназы юк. Ник сайланам соң шултиклем? Һәркем үзе өчен генә үскән кызны эзли, ләкин кеше өчен үскәне белән гомер кичә. Сине «Ачы! Ачы!» дип сөендереп торганда, кемдер ачы күз яшьләрен йотып кала. Мәхәббәт ятимнәренең исәбен алучы юк, алар күләгәдә кала... Менә хәзер дә үз-үзеңне яучылап килгән егет, ярәшү йоласын уйнап, «колагын тешлә» дә Әминәңне күтәреп (юк, кирәкми, буровойда билеңне сындырдың, сиңа врач авыр күтәрергә кушмады, култыклап) йокы бүлмәсе дип аталган зиннәтле зинданга алып кер. Шәледә андыйларны «йортка керде» диләр, «Корыч» кушаматыңны онытырлар... Юк, әле өйләнмәгән килеш тә Әминәдән инде аерыласым килә...

Йа Хода, ник рәхәт чакларда мөрәҗәгать итмибез икән без Сиңа?! Ник кыен чакларда гына ялынабыз?! Инде дә бүген ярдәмеңнән ташлама, коткар мине бу йозактан. Насыйп ит бер сәбәбен!..

Кинәт... Күпне күргән ишекне төбенә чаклы каерып ачып, бер фәрештә очып керде. Без – өйдәгеләр, өчебез бер булып, аның каршысына килеп бастык.

«Гөлназ?!!» – дидем мин, сокланыуымны тыя алмыйча.

«Әйе, Гөлназ. Исемә төшерә алмыйм. Сез мине каян беләсез?»

«Белмим. Тик исемегез җисемегезгә туры килә».

«Ах, хәсис! – дип, миңа ябырылды әни кеше. – Әминәмнең башын әйләндереп утырды да хәзер кече кызыма үреләү! Бармагында балдак эзе дә бетмәгән килеш, бабник! Сине өйгә кертсәң?! Вон, общежитиеңә!»

Ике кызы ике бүлмәгә йөгерде. Ә мин туфлиемне капка төбенә чыгып җиткәч кенә киеп өлгердем... Һәм сө-ен-дем!

Кайтам, бүген үк Шәлегә кайтам! Гөлназга өйләнәм! Парлашып укучы яшь гаиләләр күп ич ул...

Атна азагында авыл клубы өч көн гөрләп ала. Ялга каршы лекцияләр дүрт кенә пар. Мине түшәмдәге кыңгырау тавышы озатып калды, пар ат дугасындагы кебек тыңлап түгел, әлбәттә, «гражданнар оборонасы»ның «һәлакәт» ораны кебек каравыл кычкырып.

Гөлназ клубта юк иде. Алай да берәр сәгать чамасы карт егетләр арасында домино уйнаган булып көтеп карадым, ул һаман да юк. Ял көннәрендә клубка чыкмас өчен, ай-һай, җитди сәбәп кирәк! Киттем. «Дуслык» урамына, шул сәбәпне эзләп.

Тиз йөргән кешенең кимчелеген күреп өлгермиләр, мин үзем тумыштан әкрен йөри белмәдем. Туктаганда да тик тора алмыйм. Хәтта гәүдәмнең «авырлык үзәген» бер аяктан икенчесенә алмаш-тилмәш күчереп, баскан җиремдә тыпырдап торам. Кыбырсык чире түгелдер ул. Төпчек малаем кечкенә дип, әни колхоз эшенә йөрүдән туктамаган, мине абый белән апа кулына тәрбиягә калдырып, хезмәт көне җыйган. Тәрбиячеләр үзләре дә бала бит әле, әни күздән югалуга, мине бикләп калдырып, урамга чыгып сызганнар. Әнидән алдан кайтып керсәләр ярый да, тик еш кына соңга калалар икән дә, әнидән «эләгә» икән үзләренә. Минме? Җәен-кышын капкадан чыгармаганнар, ишегалдында, бәрәңге бакчасында кызык табып, әнинең эштән кайтканын көткәнмен... Инде җиде яшь тулгач, сумка тотып мәктәпкә йөгергәч, урамдагылар: «Карасана! Мәдинәнең төпчеге тәпи йөри башлаган!» – дип хәйран калганнар имеш. Шуннан бирле бүгенге көнгәчә йөгереп кенә йөрим, әкрен атласам, буыннарым ойый кебек. Ә аягымның кәкрелеге – тиз йөргәннән түгел, тал-тирәккә күп менгәннән... Кул белән ябышып, аяк белән кочаклап күпме чәүкә оясына сукмак салдым инде мин... Югарыга менгәч, авылдагы гамь онытыла, гел ерактагыны күрәсе килә.

***

Гөлназларның өй түрендә йөреп әллә җаным чыга инде – тәнем суына башлады, кул өши, кояшның баеганын гына көткән октябрь җиле «Дуслык» урамында ноябрьне эзләп йөри. «Әбиләр чуагы» озын гомерле булды дип, кыска җиңле күлмәк өстеннән юка пинжәк элеп кенә килгән идем... Свитер-мазар киясе калган... Гөлназларның капкасын кадаклап куйганнармы соң – егетләрнең кызлар куар сәгате җитә... Их, йон якалы калын куртка киеп кайткан булсам... Кесәсенә колакчынлы бүрек кыстырып... «Их, бер өйләнәсең килә башласа, шундый кыен икән ул! Көтәм, таң атканчы, капка төпләрендә өшегән күчән булганчы көтәм», – дигән соңгы өметемне аяз күктәгеләр ишетте, бер фәрештә җибәрделәр... Төн эченнән песи хәтлек кенә этен ияртеп, янгын каланчасында сакта торучы Хисам абый тамак ялгарга дип, өенә кайтып килә. Гөлназларның күршесе. Мине шундук танып алды:

«Нишләп йөрисең бу тирәдә?»

«Гөлназны көтәм, лайон газетасы чыгалам дигәние, минем шигыйльләр чыккан санын».

«Күптән көтәсең, ызначит – «р» хәрефең төшеп кала... Ә син бит, шыттырасың, малай актыгы, Гөлназның бүген төнге сменасы, ул бит хәзер урман авызындагы заправкага урнашты».

«Беләм, Хисам абый, – дигән булдым хәбәрнең сөенечен сиздермәскә тырышып. – Илсөял сеңлесенә әйтеп калдылган ул гәҗит билелгә».

«Башта янгынны сүндерәләр, агайне, аннан утның сәбәбен эзлиләр», – дип саубуллашты ул. Аңлавымча, мине Гөлназ белән җитди сөйләшү көтә иде.

Хисам абыйның өенә кереп киткәнен генә көттем дә бензинга сусаган машина кебек «КамАЗ» юлындагы заправкага йөгердем. Авылдан өч чакрымда әле ул, ләкин машиналарга кул күтәрмим, Гөлназ янына барып җиткәнче җылынасым бар...

Баш очына «касса» дип язылган ярымтүгәрәк тәрәзәдән Гөлназ карап тора. Ул мине күргәч елмаймады, ә көлемсерәп куйды.

«Бензиның бетте мәллә? Мышнагансың».

«Синең янга ашыктым».

«Кайтырсың дип кем уйлаган инде?! Казаныңда кызлар күп ич».

«Вакыт булмады... Тәки укырга кердем бит!»

«Сигез ел узгачмы?»

«Әйе. Мин яшьтәшләремнән сигез елга соңарып яшим. Ашыкмыйм, үземә насыйбын сигез ел көтәм».

«Алайса хатының да үзеңнән сигез яшькә кече булачак...»

«Бәлки шулайдыр да... Юк, юк, Гөлназ, син миңа таман гына. Әйдә, өйләнешик!»

«Тукта, тәрәзә ярыгыннан гына сөйләшә торган сүз түгел бу».

Ул ишек төбендә кроссворд чишеп маташкан каравылчыга нидер әйтте дә миңа ком тутырылган кызыл мичкә янындагы тар эскәмиягә утырырга кушты. Бу вакытта олы юлдан бимазалап килүче машиналар азая, күрәмсең.

«Алдан хәбәр иткән булсаң, эш көнемне берәрсе белән алмаша идем. Заправкада телефон бар ич».

«Кайда эшләгәнеңне бүген генә белдем... Әйдә өйләнешик, Гөлназ! Бүген үк! Хәер, бүген син буш түгел инде. Әйдә иртәгә!»

«Нинди бүген, нинди иртәгә?! Ычкындыңмы әллә? Беләсең ич, әти-әни риза түгел».

«Революциядән соң 60 ел узгач та, нинди борынгы йолалар инде ул?! Сиңа гомер итәсе ич, үзең хәл ит!»

«Һаваланма! Без авылда яшибез. Ни өчен каршы икәннәрен беләсең. Бердәнбер кызларына егет тапмадылар дип, күз ачтырмаслар».

«Мин – хыянәтчегә хыянәт иткән хыянәтче генә... Паспортым чиста».

«Акланып торма. Беләм. Аңлыйм. Ошыйсың. Сагындым да».

«Суң шулай булгач, инде араны өзәбезме?»

«Араны өзәсең килмәсә... Башкалар урлый ич әнә...»

«Гөлназ! Сине бер урлаганнар иде инде, этиең бәреп кереп, алып киткәч, авыл «шау» килде. Ул егетне төрмәгә утырта яздылар. Ярый ла, сиңа тиеп өлгермәгән, диделәр».

«Яраткан кешем түгелие. Ә сине... Ә син такси белән кибет тыкрыгында торасың да апкитәсең. Берәр сәгать узгач кына, иптәш кызым Сәрия әниләргә кереп әйтә... Аннан соң кем эзләп тапсын ди безне?!»

«Комсомол башым белән кыз урлап йөргәнемне ишетсәләр... шул сәгатьтә үк институттан куалар мине. Инде, ниһаять, укырга кердем дигәндә генә...»

Ул арада, бөркәүле «КамАЗ» килеп туктады. Кирәкмәгән чакта гына, ачу китереп йөриләр шунда. Йөртүчесе, куначадан очып төшкән тау әтәче ише генә, җиргә сикерде дә Гөлназ тәрәзәсенә килеп кунды.

«Матурым, миңа ялгыш җәйге солярка сала күрмәгез, яме», – дигән була. Ә үзе егерме өч тиенлек шоколадны акча өстенә салып шудырмак була, яннарына мин килеп баскач кына кире алды.

Машина соляркага туенып китеп барганчы, биш минутлык тынлык урнашты. Шул арада зиһенем ачылып, башыма килгән уйдан сөенеп куйдым. Гөлназ кабат чыгып баскач, җәһәт кенә әйтеп өлгердем. Тагын йә берәр «дальнобойщик» килер дә бүлдерер.

«Гөлназ! Әйдә шыпырт кына барып, Күн авылында язылышабыз. Бу турыда беркемгә дә әйтмибез. И, аннан соң мин сине урларга кайтам. Икебез генә белгән уен булып калыр».

«Юк! Күн авылында сер сакланыр, димә. Башта урла, аннары – ЗАГСка...»

«Юк! Алдан язылышабыз да, урлыйм!»

«Юк! Ябышып чыккан, дигән даным таралуын теләмим!»

«Юк! Институттан куалар... Хуш! Бүтән кайтмыйм!»

«Мин көтә беләм. Сиңа гел хат язып торырмын...»

Әнә шулай, Гөлназлы киләчәк «юк»ка чыкты. Каз өмәләре башлангач, көзнең буранлы төнендә, түрле чанага толып белән каплап тәки урлаганнар үзен. Инде икенче тапкырга киткәч, этисе кызы артыннан чыгып чапмаган... Гөлназ этисе кушкан язмышка буйсынып, яшәп калган. Нәселенең бәясен төшермәгән...

Хәмдия, Сәвия, Гөлназ... Авыл миңа аларның өчесенең берсен дә бирмәде... Салам түбәлеләр өчен кызлар әкрен үсә... Сигез ел чамасы көтәргә туры килер. Үзем үсә торыйм...

Татциктагы өебез маяк кебек балкып тора, үтеп китә күрмәсен тагы, дигәндәй, бөтен лампочкаларны да кабызып көтәләр булса кирәк. Капканың салкын келәсенә кулым тигәч, Гөлназлы шыксыз көзге кич назлы язга әверелде... И, үзең дә бигрәк беркатлы бала инде син, Нуриәхмәт кызы... Шушындый язда ирне урамга куып чыгаралармы инде, җә?!.

***

Бигрәкләр дә озын инде Шәле урамнары, хискә бирелеп кенә атласаң, бөтен гомереңне искә төшерергә җитә...

Яшьлегемнән кайтып киләм...

Миңа кызларын жәлләгән калай әтәчле өйләрнең нигезе сытылып, күләгәле якка авышкан. «Сыер күле»нә терәлгән элеккеге колхоз басуында, ярыша-ярыша салынган зиннәтле йортлардан яңа бистә үсеп килә... иске авыл калага качып бетә бугай инде...

Яшьлек узгач, яшәүнең кызыгы калмый дип уйлый идем мин. Ялгышканмын! Олыгайгач, яшьлекнең бөтенләй дә кирәге юк икән аның... Тигезлек белән генә яшәсәң, бөтен проблемалар да хәл ителгән була. Түтәлләрдә җиләк пешкәнне көтеп тик утыр янкорма кәнәфиеңдә! Ни кирәк тагын?! Җитте, түздек. Алты яшьтән каз көттемме – көттем! Җәй узганчы берсен генә дә тилгәнгә бирмәдем. Әни миңа ышанып, бәбкәләр чыгуга, ата каз штатын кыскарта иде. Укыганда, өйгә бирелгән эшләргә кем булышты – үземә үзем! Геометрия, химия, физика формулаларын, билләһи менә, пенсия кенәгәсе белән ант итәм, мин аларны төнге сәгать уникедә уятып сорасалар да, яттан беләм. Әлбәттә, кирәклеләрен генә! 6 нчы класстан башлап, җәйге каникулларда прицепщик булып акча эшләдемме? Трактор җене кагылгангадыр, нибарысы дүрт малайга аттестат белән бергә «сельский механизатор» дигән катыргы бирделәр. Су бораулаучы булып эшкә урнашканда бик ярап куйды әле ул!

Мәхәббәттәме бәхет?!

Ныклап уйлап караганда: бар, дисәң – бар, юк, дисәң – юк ул бәхет... Чагыштырып торып карыйсың да... тегеләрдән лутчырак, болардан хужерак килеп чыга. Апакай кызы Зәрия идеме минем бәхет?.. Мәктәпне тәмамлагач, совхоз аңа паспорт бирдермәгән. Берәр ел авылда эшләргә кушканнар. Ә ул шәп биюче – үзешчәннәр смотрында җиңүче! Биюче кызларны коммунистлар да ярата иде. Банкеттан банкетка йөртеп, паспорт биргәч тә китә алмаслык итеп симерткәннәр кызны. Соңында һөнәри училищеларның берсендә завуч булып пенсиягә чыккан, ди. Зәрия белән дә кавыша алмагач, бәхетсез инде мин... Ә Нуриәхмәт кызы белән – бәхетле, и Ходаем, минем өчен генә үскән берәр кызны насыйп ит, дигәнемне ишетте Раббым, теләгем рас килде.

Дөрес, ялваруыма биюче кыз булсын иде, дип тә өстисем калган. Вәләкин, Нуриәхмәт кызы, минем белән чагыштырганда, Ханәкә иде. Аннан туган оныкларыбыз да матурлар: малай ягыннан ике кыз, кыз ягыннан бер малай! Кызларыбыз мәктәпкә йөри, еладылармы соң, юкмы – онытылган инде. Ну малаебыз – тугыз ай булды инде, өч смена рәттән елый, имгәндә генә туктап тора да сиренасын кабыза! Тавышы таш стена аша үтеп чыга. Нигә еламасын сабый – эче авырткач, ник авыртмасын, ди, әти-әнисе вегетариан булгач?!. Аның ныклап үсәсе килә, малай кеше бит ул, җаны-тәне ит ашы сорый. Социализмның гөрләп чәчәк аткан чорында, бөтен ил талонга калган чакта да без балаларны иттән-майдан, шикәрдән-чәйдән мәхрүм итмәдек. Хатын белән икебез дә редакция паёгын алгач, пәрдәне корып, чәйнең фил сурәте төшкәнен генә, аны да «күгәрчен сөте» дигән конфет белән эчә идек... Үсеп буйга җиткәч, тәненә ит кунгач кына, кызым үлән ашаучы бер егет белән танышып-кавышып, фамилиямне шарга бәйләп очырды. 1921 елгы ачлыкның йөз еллыгын искә алабыз дигәндә генә, табыннарыбыз икегә бүленде. Ничава, тәпи йөри башлагач, ияртеп чыгып: елкы ите, люля кебаб, каклаган каз, үрдәк бәлеше, шулпалы өчпочмак, бәрән итеннән шашлык ашатам әле мин аңа... Әлегә түзәрбез, авылда ял көннәре генә очрашабыз, атна буе һәр гаилә Казанда аерым яшәп ятабыз. Әнә, үкерә, капка калае зыңгылдап тора хәтта... Чү, туктады түгелме? Дәү әнисе казылык кисәге чәйнәп каптырды мәллә? Булыр аннан, ул оныкның әнисен дә елаудан бик тиз туктата иде... Үзе ишетмәгәндә, мактасаң да ярый хатынны. Иҗат кичәләренә, театрларга ияртеп йөрер өчен менә дигән әле ул. Буфетларга кергәч, коньяк та сораганы юк, тәүбә-тәүбә! Бик экономный үзе – малаебызга йөкле вакытта ризык талымлый башлагач, 50 тиенлек акбур кимереп йөрде. Шагыйрь хатыннары кебек диңгез суы эчеп карыйсым килә, димәде... Ә машинага права алгач, беренче тапкыр шәһәр эчендә йөреп карыйм, дигәч... ике баланы да кочаклап, арткы рәткә кереп утырды: бетсәк, бөтенебез дә бергә бетәбез, синнән башка яши алмыйбыз, ди бит, җимешем. Теле белән юмагайлана белмәсә дә, фигыле белән сөйдерә. Булды, җитте, оныкйокыга китте, хәзер керәм дә исемсез хатны кулына тоттырам, террасага чыгып әрләшербез...

Өйгә кердем. Сукыр лампочка яктысында Нуриәхмәт кызы балет биючесе кеби, аяк очында гына йөри. Балдаклы кулын изәп: «Кил әле монда!» дигән ишарәсен шәйлим. Мин хат кисәген бөгәрләп тоткан килеш үзем ясап элгән бишек янына килдем. Анда бөтен дөньяның тынычлыгын үзенә җыеп, сөенеч канатына сыенып, нәсел агачының яңа җимеше нур бөркеп ята; сулыш алганы да сизелми. Ул гүя бу минутта инде бөтен хөрмәттән дә канәгать; бар хәрәкәтен тыеп йоклый; сокланучыларга сиздермичә генә үсә һәм көч җыя...

«Бердәнбер» төшенчәсенең «Иң...» дигән игезәге бар. Бу дөньяда Иң зур Матурлык – бишегендә йоклап яткан Онык икән! Аны күреп, калебең чистара; аңа ияреп, яңадан яши башлыйсың; әрәм үткән көннәрең, чын күңелдән кылган хаталарың өчен кемнәрдәндер гафу үтенәсең килә.

– Сөйләшәсе бар... – дидем мин, бишек офыгыннан ерагайгач.

Без террасага чыктык. Язгы караңгылык һәм Совет урамын кисеп үтә торган «КамАЗ» юлының өзлексез гөрелтесе Нуриәхмәт кызы белән икебезнең арада кабыначак бәхәскә бер минутлык тынлык бирде.

– Әллә бөтен кеше юлда яши инде хәзер, олы юлда буш урын юк.

– Үзебез дә олы юлда инде... Туктап, бер сөйләшеп утырырга да вакыт таба алмыйбыз. Хат килде бит миңа...

Бишек тынычлыгын онытып сискәнергә тиеш иде Нуриәхмәт кызы, ләкин ул үзен ифрат сабыр тотты, «М – 7» агымына караган килеш миңа таба борылмады да хәтта. Ну, сабырлык монда...

– Анонимка килде, дим, мин сиңа!

– Кайчан?

– Бер атна элек... Извещение алгач, ГАИдан штрафтыр, дип йөгереп бардым, ә ул...

– Атна буе тел яшереп йөрдеңме?

– Яшерергә теләсәм, әйтеп тормасыем. Ерттың да ташладың! Кем язганын беләсем килде... Эш урынымдагыларның язу рәвешен дә чагыштырдым, тискәре геройларымнан җыелган хатларны да актардым, бөтен биографиямне «сөреп» чыктым... Юк, кемнән икәнен тәки белә алмадым... Мә, укы!

Нуриәхмәт кызы әле һаман да җилкә аша сөйләшә.

– Мин аларның нәрсә язасын беләм, җыртып ташла...

Менә сиңа вәт! Атна буе эзәрлекләп йөргән «шайтан өермәсе», өйгә кереп тормыйча гына, бакча артыннан үтеп китте; гәүдәм турайды, сулышым иркенәйде; мине ишетергә лаек булган әр-зарлар тагын берәр елга ерагайды, ә бәлки, бөтенләйгә үк югалгандыр да... Мине кинәт кенә шагыйранә хисләр биләп алды.

– Әйдә, апак, таңны каршы алабыз. Төн түрендә учак ягабыз. Чыбыкка тезеп сардельки кыздырабыз... Оныклар өчен дә борчыласы юк, әти-әниләре яннарында. Баздан үзебез ясаган йөзем шәрабын алып чыгам... Бүгеннән тагын яңача яши башлыйбыз!

– Төннәр кыскарсын инде бераз. Таңын да аттырырбыз әле, балалар белән бергәләп... Яңача яшәү дигәнеңне – яңа мажараларың көтә дип аңларгамы инде?.. Карале, син ул матрёшкаларны ташладың мәллә?

– Юк, эштә калды.

– Алып кайт, балалар өчен матур уенчык бит ул. Өчесенә дә җитә...

Һәм Нуриәхмәт кызы, «Ярар!» дигәнемне дә көтмичә, гөрләвекләр аша сикергәләгән кызчык ише генә ашыгып, өйгә кереп китте.

...Бәй, без бит әле исемсез хат турында гына сөйләштек. Агач курчакларны каян белә соң ул? Санына кадәр әйтеп бирде... Менә бу ичмасам, дипломатия!..

***


Өебезнең икенче катында, сыерчык оясы чаклы гына иҗат бүлмәм бар. Иртәнге кояш тәрәзәмне ачтырды. Көн җылысы җәй ягыннан килә. Ягымлы җил яңа гына кардан ачылган түтәлләрдән җиләк, кишер, бөтнек, алма, яңа бәрәңге исләрен җыеп алып керде, гүя бакча өстендәге болытларга кунып, тургай сайрый, аңа охшарга тырышып, сыерчык кушылды. Ул да булмады, койма артындагы тал-тирәккә кайтып урнашкан кара каргалар кавеменә эш кушкан бригадирдай, бер ала карга тавышы өскә чыкты.

«Кар-р!.. Кар!.. Кар!...»

Мине үрти бит ул! Ярты фамилиямне әйтеп бирде. Теле булса җөмләсен дә тутырып әйтер иде! «Кар-римов. Яз үтеп бара, яз! Яз инде! Язмасаң, акылыңнан язарсың», – дияр иде.

Биш йөз хат язардай кәгазьнең төргәген сүттем дә миләүшәләр төсендәге язу карасы белән «Исемсез хат» дип башладым.

Яшәлгәнен яза торам...



Ләбиб
Лерон

# ҺӘРВАКЫТ ИҢДӘ ЙӨК...

## «Зәңгәр шәл»не мин карадым кичә...

*«Зәңгәр шәл» – татарны*
*яшәтүче көч бит ул.*
Марсель Сәлимҗанов

*Карагыз инде ул «Зәңгәр шәл»гә.*
*Кемнәребез генә юк анда безнең.*
*Барысы да үзебезнекеләр...*
Туфан Миңнуллин

*Марсель Хәкимович әйтте:*
*– «Зәңгәр шәл»не куйдым,*
*куячакмын, һәм син дә, Фәрит,*
*онытма сүзләремне, син дә*
*куячаксың!*
Фәрит Бикчәнтәев

Укыганым, бәлки, аз булгандыр,
Караганым булды әллә ничә...
Онытылып һәм йотылып, кабат,
«Зәңгәр шәл»не мин карадым кичә.

Мин карадым тагын, еллар кичеп,
Кичәгесен газиз татарымның! –
Бер «Зәңгәр шәл» ачып сала гүя –
Бөтен татар җанын, татар моңын!

Кәрим Тинчуринны сагынумы,
Сәйдәшне бу юксынумы әллә?! –
Нинди сере, нинди тылсымы бар,
Ни хикмәт бар шушы «Зәңгәр шәл»дә?

Ләбиб ЛЕРОН (1961) – *шагыйрь, прозаик, драматург; «Сине генә сөям», «Сөяксез тел», «Бәхеткә биш минут кала» һ.б. исемдәге күпсанлы китап авторы. М.Җәлил исемендәге әдәби премия лауреаты. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Казанда яши.*

Моның серен белеп булмас кебек,
Утырсаң да озак уйга батып...
Тәүге тапкыр уйналганга инде
Үткән икән гасырга тиң вакыт.

Гасыр кадәр вакыт үткән ләса...
Ә ул исән – яши сәхнәләрдә:
«Зәңгәр шәл»гә сәхнә генә түгел,
Тардыр кебек хәтта сәхрәләр дә!

Заман башка.... Әмма төнге күктә
Шул йолдызлар яна, балкый шул ай...
«Зәңгәр шәл» ул – үксез үткәннәрне
Хәтерләрдә бер яңарту шулай!

Хәтер барда булыр әйтер сүзем,
Әйтер сүзем барда әйтим бүген:
«Гомер буе үксез яшәсә дә,
Театрлы халык – ятим түгел!»

Театрлы... Димәк, аның хәле
Ул кадәрле мөшкел түгел әле...
Театрлы – димәк, уятырлык
Мәрткә киткән халык күңелләрен!

Караңгылык төшмәс күңелләргә,
Безнең төннәр якты булыр һәрчак:
Киләчәккә гел театр белән,
Халык җыры белән бергә барсак!

«Зәңгәр шәл»не мин карадым кичә...
Һәм аңладым кебек татарымны:
Халык белән шыгрым тулы залны
Биләп алган иде... Татар Моңы!

## Тукайча яшим, дип...

*Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым.*
Габдулла Тукай

Җиңеллек эзләмим:
Һәрвакыт иңдә йөк.
Пакьлим дип, дөньяны
Тырышам мин дә бит.

Халкым дип, милләт дип,
Туган тел дип яшим.
Бик авыр мәлләрдә
Вөҗданым – иптәшем.

Җаныма тисәләр,
Кабынам ут булып:
Тартылам җәядәй,
Атылам ук булып!

Татарча һәр иртәм –
Хөр итәм үземчә:
Бисмилла, оныклар,
Күрәгә, йөзем, чәй.

Дөньяны пакьлим, дип
Үземчә тырышам.
Аллага шөкер, дим,
Канәгать тормыштан.

Бик күпләр шикелле,
«Акча!» дип шашмадым.
Беркайчан беркемнең
Үпмәдем башмагын!

Бик авыр чакта да
Күрсәтмәм күз яшен.
Яшәмәм һичкайчан
Һичкемнән көнләшеп.

Әгәр дә кирәксә,
Әйтермен бер көнне:
– Аллага шөкер, – дип, –
Сатмадым беркемне!

Пакьлим дип, дөньяны
Тырышам мин дә бик...
...Авырлык эзләмим –
Һәрвакыт иңдә йөк.

## Аккош яктылыгы

Кесәләр – буш һаман,
Күңелләр – бай...
Көннәр ага шулай үз көенә.
Юк байлыктан, сукбайлыктан туеп,
Шигыремә кайтам – үз өемә!

Шигыремдә – ак кыш яктылыгы,
Җанга төшә – аккош күләгәсе.
Сагындырган шигырь...
Газиз өем!
Тормыш –
Язмышымның матур кинаясе.

Үз өемдә иркенәеп китәм...
Аккош яктылыгы – күңелемдә.
Гомер касәсеннән уйлар ташып,
Түгелергә тора, түгелергә...

## Тере нокта

Борынгы мич торбасына
пичәтләнеп
ябышып каткан корым кебек кап-кара төн
йолкып алды бүгенге көн сурәтеннән –
ач шом йотты ишегалдын
капка артын.

Тапкан алтын
кемгә бәхет,
кемгә ләхет –
яшәү язган ак-карага бергәләшеп,
мәңге туймас карун сыман
комсызланып,
ай үзенә тартып алган
җир кәләшен.

Һич күренми
авыл өсләп эреп аккан
төтен эзе
һич күренми бу төн үзе.
Төн нәрсә ул
мин күренмим үз-үземә

бөтен йөзем бүтән,
бүтән сүзем.

Мин кушылдым бүген
сәер бер бушлыкка,
биһуш булып тормыш бардан тормыш юкка,
уяу йокы булып ойыйм бер ешлыкта,
мин
бу төпсез галәм гамәл дәфтәрендә –
тере нокта.

## Хат

*Эдуардас Межелайтистан*

Ап-ак кар. Зур юрган. Киндердән.
Хакыйкать. Хаттагы юлларда.
Җил. Буран. Хат. Хәбәр. Боз кебек.
Кич. Суык. Файда юк юрганнан.

Кар. Тышта. Урамда. Һәр төштә.
Бөркелә. Торбадан. Күк төтен.
Тәрәзә. Шакымый. Беркем дә.
Бик суык. Битемнән. Үпте төн.

Кешегә. Бик кирәк. Җылылык.
Дөньяда. Җылылык. Бик кирәк.
Кеше дә. Бик кирәк. Кешегә.
Ник беркем шакымый? Түз, йөрәк.

Кар. Буран. Хат. Хәбәр. Боз кебек.
Кич. Суык. Котыра. Чамасыз.
Кар. Ап-ак. Зур юрган. Киндердән.
Хакыйкать. Кара төн. Чарасыз.

## Өзеклек

Бер гаярь бозауның
көтүдән кайтмыйча
төн ката кайдадыр йөргәне шикелле
хис итәм үземне бүген мин –
шуңамы
бу мәлдә
бар уем
икеле-микеле.

Күңелем
тузгытып ташланган фатир күк,
бүгенем
туфрактан йолкынган тамырдай
борчулы,

чыр-чулы тынгысыз халәтем
мискидән бүселеп ташыган камырдай.

Өшегән,
күшеккән,
йончыган кош сыман
бөкшәеп сыенам сыкылы дөньяга:
мәңгелек мосафир-дәрвиш күк
бу төннең
йолдызлы күк йөзен өстемә мин ябам.

Вакытлы өзеклек
илдә дә,
миндә дә
гүя ки урнашты вакытлы хөкүмәт.
Сүк-сүкмә
дөньясын,
каһәрле тормышны –
син түгел барыбер тартучы хөкемгә.

Өзеклек дөньяда,
илләрдә канкоеш,
юлларда һәлакәт,
гаиләдә кырын эш,
сәрхушлык,
хыянәт,
акчага табыну,
кыскасы –
кырылыш.

Түзәргә, түзәргә, түзәргә, түзәргә,
түземлек... көч-куәт бирсәнә,
Илаһым,
сабырлык, сабырлык, сабырлык, сабырлык...
Бисмилләһир-рахманир-рәхим.

## Балачак

Үземә үзем сабый мин,
Үземә үзем – ятим.
Үземә үзем абый мин,
Үземә үзем – әти.



Илгиз
Зәйниев

# ТУГАННАР-ТУМАЧАЛАР

ТАТАР ТОРМЫШЫННАН СӘХНӘЛӘР

**Катнашалар:**

М и н с а б и р – егерме җиде яшьлек ир-егет, көтүче.
И с м ә г ы й л ь – Минсабирның бертуган энесе, егерме өч яшьләрдә.
К ә р и м ә – аларның бертуган апалары, егерме тугыз яшьләрдә.
М и р з а – аларның аталары.
М ә х р ү з ә – Мирзаның хатыны.
Җ ә м и л ә – Исмәгыйльнең хатыны.
М ә ү л ә – Мирзаның карендәше.
Ә н с ә р – Мәүләнең улы.
Ш ә р и ф ә – беренче сәхнәдә унсигез яшь, соңрак 3 бала анасы.
Х ә с ә н ш а – Шәрифәнең атасы.
Ш ә м с е р у й – Хәсәншаның хатыны.
С ә л и м – Хәсәншаның олы улы, балта остасы.
С ә й я р – Хәсәншаның икенче улы, балта остасы.
Ә л ф и я – Хәсәншаның кызы.
Ш ә й д у л л а – Әлфиянең ире.
Г о с м а н – Шәйдулла белән Әлфиянең сукыр малайлары, унөч-ундүрт яшьләрдә.
З ә й н ә п – Сәярның хатыны.
Ә м и н ә – Кызылсу авылы кызы.
М а р а т – Кызылсу авылы егете, гармунчы.
А р с л а н – Кызылсу авылы егете.
Ә м и р – Кызылсу авылы егете.
М ө х е т д и н о в  Х ә б и б р а х м а н – «Кызылсу» колхозы председателе.
Ш а г и в ә л и е в  Р ә ш и т – Кызылсу авылы сельсовет председателе.
М ә л и к ә – Кызылсу авылы хатыны.
Л у и з а – Кызылсу урта мәктәбе немец теле укытучысы.
Кызылсу авылы егет-кызлары.
М о н г о л – алаша, юкка пырдымсызланмый, хуҗасының алыштыргысыз

Илгиз ЗӘЙНИЕВ (1987) – *драматург, режиссёр. «Бәби» исемле китап авторы. Казанда яши.*

терәге, чыдам, акыллы карашлы, чабышкы булмаса да, кирәк чакта шактый гына җилдерергә сәләтле.

Й о л д ы з – бура хәтле аклы-кызыллы сыер, көтүдән соңга калмый, качмый, сауганда типми, үз дәрәҗәсен белеп кенә, сабыр гына атлап йөри;

М а ш к а – чагыштырмача яшь, кара сыер, тәкәббер холыклы, ике елның берендә кысыр кала.

К е ч к е н ә – башта тана, аннан сыер.

Һәм башкалар.

*Вакыйгалар 1954 елда башланып китә.*

## БЕРЕНЧЕ БҮЛЕК

### I

*Кыш. Авыл урамы. Кич. М о н г о л капкага бәйләнеп куелган.*

М о н г о л. Салкын... Салкын... Эһе... Декабрь... Аннан гыйнвар, февраль, март... апрель... Бәлки, шул арада дөньяны матурлап та бетерербез... Эһе... Аннан инде җиңелрәк булачак... Менә шунда яшәп карыйбыз инде, боерган булса... Апрель гына җитсен... Аннан инде җылыта башлый... Әйе, апрельдә инде җылыта, ә майда инде бөтенләй суык түгел... Майда рәхәт... Апрельдә әле суык та, юллар да юк, авыр... Ә майда рәхәт... Алай дисәң, хәзер чана үзе шуа, суларга гына салкын... Ә җәй көне эш тә күп, черки, кигәвен, дөбер-шатыр арба сөйрәп йөрисе – кыш рәхәтрәк... Салкын гына... Алай да, буран булмаса, түзәрлек... Бүген ничәләргә кайтып җитәрбез икән?.. Сузмасалар ярый... Буран гына башланмасын... Чыгалар ахры. Шулай бик тиз генә булды микәнни?

*Капкадан шәл кебек нәрсәгә гармун төреп тоткан М а р а т, Ә н с ә р, М и н с а б и р керәләр.*

М и н с а б и р. Син, яшьти, әйдә, җайла инде...

М а р а т. Ә мин нәрсә? Утырмага алып барам. Анда үзең чамалыйсың инде... Күзләп куйганың юкмы соң, ә? Юкка гына нәкъ безнең авылга килмәгәнсеңдер әле?!

Ә н с ә р. Бар инде, бар! Кара син аңа, май кояшымыни, нур чәчеп тора! Бүген миңа килеп кермәсенме, күзе-башы акайган: «Әйдә, Кызылсуга!» – ди. Нәрсә булган дип торам: чалбарына ут капкан икән!

М и н с а б и р. Җитте инде!

М а р а т. Кем соң ул? Әйт инде!

Ә н с ә р. Юл буена интектердем, әйтми, яхшы киленмени, тел яшерә!

М а р а т. Әйт инде, барыбер беләбез бит!

М и н с а б и р. Ташлагыз инде, җегетләр!

М а р а т. Минекенә күз салып куймадыңмы тагын? Әйт, юкса бармыйм...

М и н с а б и р. Чәчләрен генә хәтерлим, җегетләр. Кап-кара, бил тиңентен, ефәкмени... Исемен белмим, күрсәм – таныйм!.. Безнең килүгә җегетләрегез ничегрәк карар соң?

Ә н с ә р. Кызылсулар безгә кыз күзләргә килсәләр, син ничегрәк карар идең соң?

М а р а т. Әйе!..

Ә н с ә р. Син юкка борчылма, Минсабир! Кыйный башласалар, монда чап. Монголга кадәр килеп җиталсаң, котылдың дигән сүз, аны инде берәү дә куып тоталмас!

М о н г о л. Хәлдән килгәнчә чабарбыз инде анысы, сүз дә юк... Суларга гына салкын...

М а р а т. Әйдә, юкны сөйләмәгез әле. Өйләнергә дигән җегет андый нәрсәдән куркып тора димени?

Ә н с ә р. Бигрәк тә сезнең авылдан өйләнергә риза булган җегет!

М а р а т. Болай сөйләнсәң, сезгә бүген эләктермичә җибәрмиләр, малай!

М и н с а б и р. Әнсәр, кара аны, телеңне тый!

Ә н с ә р. Беләм инде, беләм! Әйдәгез тизрәк, туңып беттем бит...

М о н г о л . Салкын шул...

М и н с а б и р. Әйе, сузмыйк...

М а р а т. Әйдәгез соң!

Ә н с ә р. Тукта... Хәзер, Монголның алдына бераз салам салып калдырыйм, әле кайчан кайтырбыз, билгесез... *(Чанадан салам алып, ат алдына сала.)* Аша, җаным!

М о н г о л . Рәхмәт!

Ә н с ә р. Әйдәгез!

М и н с а б и р. Аллага тапшырдык!..

М о н г о л . Алай да, буран башланганчы тормагыз инде...

## II

*Авыл өе. Утырма. Егетләр-кызлар йөзек салыш уйныйлар.*

Ә м и н ә. Кемдә йөзек, сикереп чык!

*А р с л а н атылып чыга, аны тотып өлгермиләр.*

К ы з л а р. Кая моны тотып каласың! Кулдан җылан кебек шуып чыга!

А р с л а н. Утырыгыз, мин салам!

*Уйныйлар. Берничә кешене тотып калалар. Аларга җәза бирәләр. Янә уйный башлыйлар.*

К ы з л а р д а н б е р ә ү. Кемдә йөзек, сикереп чык!

*Кыз әйтеп кенә бетерә, ишек ачылып китә. Салкын һава болытларын куертып, М и н с а б и р, Ә н с ә р, М а р а т килеп керәләр. Барысы да аларга төбәлә. Йөзекле кыз сикереп чыга, аңа игътибар итмиләр.*

М а р а т. Сәлам бирдек!

К ы з л а р д а н б е р ә ү. Марат килде, хәзер биибез!

И к е н ч е б е р ә ү. Марат, әйдә, уйна гармуныңны! Сагындырып кына йөрисең!

М а р а т. Җегетләр-кызлар, гармун ерак юлдан килде, аңа җылынып алырга кирәк! *(Гармунны бик зур хөрмәт белән, төргәннәрен чишеп, өстәлгә куялар.)*

К ы з л а р д а н б е р ә ү. Мич яккан, әйдә тыгып торабыз, хәзер җылынып чыга! *(Көлешәләр.)*

Ә м и н ә. Әйдәгез, алайса, гармун җылынганчы йөзек салыш уйныйбыз!

М а р а т. Әйдәгез! Уйнарга дип килдек ләбаса! *(Арага кереп утыра.)*

*Минсабир белән Әнсәр читтә калалар.*

Ә м и н ә. Марат, әллә кунак егетләрең карап торырга гына килгәнме?

М а р а т. Утырыгыз, әйдә!

Ә н с ә р. Кая, кызлар! Туңып килдек, җылыгарак утыртыгыз әле үземне!

*Әнсәр әрсезләнеп, кызлар арасына ук кереп утыра. Кызылсу авылы егетләре, моны бик үк яратып бетермәсәләр дә, эндәшмиләр. Минса–бир иң ахырга утыра. Уен башлана. Бераз уйнагач, Арслан эләгә.*

Б е р ә ү. Эләкте тәки!

К ы з л а р д а н  б е р ә ү. Әтәч булып кычкыртыйк!

И к е н ч е  б е р ә ү. Әйе! Урындыкка басып!

Ә н с ә р. Әтәч булып кем дә кычкыра, чучка булып чинасын!

А р с л а н. Кит әле...

Б а р ы с ы  д а. Әйдә, әйдә! Элэктеңме, җәзаны үтә! Чучка булып чина!

Ә н с ә р. Өстәл астына кереп!

Б а р ы с ы  д а. Әйдәле, әйдә!

А р с л а н. Хәзер менә... Чинаган ди...

Ә м и н ә. Эләктең бит!

Б е р ә ү. Йә җәзаңны үтисең, йә уеннан чыгасың! Чина!

А р с л а н. Тапканнар...

*Арслан ачуланып, ишекне каты итеп ябып чыгып китә.*

Ш ә р и ф ә. Үпкәләттек!..

Ә м и н ә. Үпкәләүчегә үпкә ашаталар!

Ә н с ә р. Әй, шуңа да үпкәләп торырга инде! Үзем булсам...

Ә м и н ә. Нишләр идең?

Ә н с ә р. Минме?! Менә шунда кереп утырыр идем дә... *(Өстәл астына керә.)* Менә шулай чинап күрсәтер идем! *(Чинап күрсәтә.)* Беркөн чуваш авылына барып, махсус тыңлап кайттым!

Ә м и н ә. Чуваш авылына нәрсә тыңларга йөргәнегезне белмиләр, ди!

*Барысы да көлешәләр. Уен дәвам итә. Берничә кешегә җәза бирәләр, берничәсен тоталмыйлар.*

К ы з л а р д а н  б е р ә ү: Кемдә йөзек, сикереп чык!

*Әнсәр сикереп чыга, аны тотып калалмыйлар.*

Б е р ә ү. Кара син бу чикерткәгә!

Ә н с ә р. Безне тотар куллылар тумагандыр әле ул!

*Кызылсу авылы егетләре аңа карап куя. Янә уен башлана. Әнсәр Шәрифәгә сала. Шәрифәне тотып калалмыйлар. Шәрифә йөзек сала.*

Ш ә р и ф ә. Кемдә йөзек, сикереп чык!

*Минсабир атылып чыгып өлгерми, аны Әмир дорфа гына тотып кала.*

Б а р ы с ы  д а. Нишләтәбез?! Нишләтәбез?!

М а р а т. Җырласын, матур җырлый!

М и н с а б и р. Кит инде...

М а р а т. Әйдә! Оялып торма!

К ы з л а р. Җырла!

М а р а т. Гармунны да бирәм, җылынгандыр инде!

К ы з л а р. Әйе, гармун бирегез үзенә! Уйнап җырласын!

М и н с а б и р *(гармунны алып, утырганда шигырь итеп сөйли)*.

Җырла-җырла дип әйтәсез,
Җыр капчыгым ертылган;
Кичә бер җыр откан идем,
Ул да булса онытылган.

Җырла-җырла дип әйтәсез,
Җыр чәчмәдем бакчама;
Җыр чәчмәсәм дә бакчама,
Сатып алмыйм акчага.

*(Минсабир гармунны бер тартып куя. Аннан тынып кала. Уртак тынлыкта, тавыш белән тирән итеп бер сулап куя һәм башлап җибәрә).*

Иртә буран, кич тә буран,
Мамык шәлеңне уран шул,
Мамык шәлеңне уран.
Кигән киемең күрсәм дә,
Җаныем, бәгърем,
Үзең күргәндәй булам.

Ишек алдында йөримен,
Карлар яуса, көримен шул,
Карлар яуса, көримен.
Синнән башка ямь табалмыйм,

Җаныем, бәгърем,
Ямансулап йөримен.

Тимер чана карны яра
Бу йөрәгем ник яна шул?
Бу йөрәгем ник яна?
Бу йөрәгем белеп яна,
Җаныем, бәгърем,
Сөйгәнем ятка кала...

*Җыр вакытында Шәрифә үзен һаман Минсабирның карашы астындагыдай хис итә. Ул, шуны дөресме икәнлекне тикшерергә дип, сәхнә буйлап күчеп йөри, аның саен тойгысының хаклыгына инана бара. Җыр тәмамлангач, барысы да шау-гөр килешәләр.*

Ә м и н ә. Әйдәгез, Уртада уйныйбыз!

Б а р ы с ы  д а. Әйе, әйдәгез, бибез! Буыннар катып бетте! Күпме утырырга була!

*М а р а т бию көен сыздыра, яшьләр әйләнә булып басалар, берәү уртада. Ул биеп тора, аннан әйләнәдән берәрсен үзе янына алып чыга, икәүләшеп биилләр, шуннан икенче булган кеше берүзе кала һәм шулай яңа баштан кабатлана. Минсабир Шәрифәне биергә алып чыга. Аннан үзе алга атылып чыга, Шәрифә башка берәүне биергә чакыра.*

М и н с а б и р. Толымнары! Һавадагы карлыгач канатымыни, шомыртмыни – чем-каралар, ефәк тасмалардан үргәнмени – ялтырыйлар, карурманмыни – куелар, фикерләрне чуалталар, күңелемне урап алды шул гөнаһсыз толымнар...

*Биюләр дәвам итә.*

**III**

*Урам. Капка. Ә м и н ә белән М а р а т Ш ә р и ф ә н е озата киләләр. Капка төбенә килеп җитәләр.*

Ш ә р и ф ә. Рәхмәт! Зинһар, мин өйгә кереп җиткәнче китми торыгыз.

Ә м и н ә. Бигрәк куркак инде үзең!

М а р а т. Безнең Шәрифә, эштән башка, бар нәрсәдән дә курка!

Ш ә р и ф ә. Чыннан, зинһар, китми торыгыз! Иң курыккан җирем шул ишегалды...

Ә м и н ә. Бар инде, бар! Беркая да китмибез!

М а р а т. Озатып куйыйммы? Капкагызны бикләп, өстән генә төшәрмен!

Ш ә р и ф ә. Юк, кирәкми. Йә пәлтәңне ертырсың.

Ә м и н ә. Шәрифә, ахир, бар инде, туңдырып үтерәсең бит!

Ш ә р и ф ә. Киттем! Иртәгә нәрәттә күрешербез...

Ә м и н ә. Ярый. *(Шәрифә капканы япканда.)* Кара аны, урлап китә күрмәсеннәр үзеңне!

Ш ә р и ф ә. Әминә!

М а р а т. Куркытма инде! Кер инде, курыкма, Шәрифә, мондый салкында кемгә кирәгең бар синең!

Ш ә р и ф ә. Урлап китсәләр, белерсең әле менә! Тыныч йокылар!..

Ә м и н ә. Сиңа да! Без монда, син кереп китмичә, беркая кузгалмыйбыз!

*Шәрифә капканы ябып, бикләп куя. Борыла һәм шунда гына капка артында күзләрен ялтыратып посып торган кешене – Минсабирны күреп ала. Кыз сүзсез кала, кычкырмакчы була – тавышы чыкмый. Егет аңа тавышланмаска кушып ишарә ясый. Кыз икеләнә. Алар ишарәләр белән бәхәсләшеп алалар: Егет тынычланырга куша, Кыз: «Юк, мин хәзер кычкырам!» – ди...*

*Капканың икенче ягында Марат Әминәне кочакларга маташа,*

*тегесе карышкан була, шулай ук ишарәләр белән аралашалар.*

Ә м и н ә. Керденңме әле?

*Егет кызның кулыннан тотмакчы була.*

Ш ә р и ф ә. Юк.

*Егет иптәшләрен кайтарып җибәрергә кушып, ишарәләп.*

М а р а т. Керденңме инде?
Ш ә р и ф ә. Юк...
Ә м и н ә *(кычкырып диярлек)*. Шул гомер нишләп басып торырга була инде, Ходаем! Керәсеңме инде, юкмы?!

*Кыз Әминәнең тавышыннан каушап куя, качмакчы була, Егет, куркудан үзе дә бик үк аңлап бетермичә, аны кочаклап кала.*

М а р а т. Керденңме?!
Ш ә р и ф ә *(кочаклаудан)*. Соң, кердем бит инде, күптән кереп киттем бит инде!
М а р а т. Ә-ә, ярый алайса...
Ә м и н ә. Әйдә инде, киттек...

*Әминә йөгереп китә, Марат аның артыннан.*
*Капка артында Егет һаман да Кызны кочаклап тора. Калын, кышкы киемнәрдән алар буранда кабарынып, өй кыегында утырган күгәрченнәрне хәтерләтәләр.*

Ш ә р и ф ә. Син ничек монда килеп эләктең?
М и н с а б и р. Капкадан кердем!
Ш ә р и ф ә. Эт өрмәдеме?
М и н с а б и р. Этегез бармыни?
Ш ә р и ф ә. Юк...
М и н с а б и р. Шулай булгач?
Ш ә р и ф ә. Ә булса, син бит белмисең?..
М и н с а б и р. Булса, өрер иде!
Ш ә р и ф ә. Әйе... Нишләп йөрисең?
М и н с а б и р. Сине кочакларга дип килдем!
Ш ә р и ф ә. Ә, бәлки, мин кочаклатмасмындыр?
М и н с а б и р. Менә, кочаклап торам бит!
Ш ә р и ф ә. Әйе... Син кем соң?
М и н с а б и р. Утырмада күрмәдеңмени?
Ш ә р и ф ә. Күрдем...
М и н с а б и р. Кызлардан кемлегемне сорамадыңмы?
Ш ә р и ф ә. Сорадым...
М и н с а б и р. Нәрсә диделәр?
Ш ә р и ф ә. Яңа Дума авылыннан, Минсабир, диделәр...
М и н с а б и р. Ә нишләп кабатлап сорыйсың?
Ш ә р и ф ә. Синнән ишетәсем килде...
М и н с а б и р. Димәк, күзең төште?
Ш ә р и ф ә. Кая?
М и н с а б и р. Миңа?!
Ш ә р и ф ә. Яңа кеше булгач, сораган идем инде...
М и н с а б и р. Алдашма.
Ш ә р и ф ә. Алдашмыйм...
М и н с а б и р. Алдашасың! Бер күрүдә үк ошаттың! Утырмада гел миңа гына карап тордың!
Ш ә р и ф ә. Карамадым ла...
М и н с а б и р. Карадың, мин бит күрдем! Караганыңны да күрдем, күрсәтмәскә тырышканыңны да! Күз кырые белән генә күзләдең!
Ш ә р и ф ә. Шулаймы? Башкалар да күрде микәнни?
М и н с а б и р. Юк! Башкалар башкаларны күзләде! Мин дә сине бер күрүдә ошаттым!.. Нигә кызарасың?!
Ш ә р и ф ә. Салкын...
М и н с а б и р. Миңа кияүгә чыгасыңмы?
Ш ә р и ф ә. Ничек? Хәзер үкме?.. Минем... иртәгә нәрәткә барасым бар...
М и н с а б и р. Кайчан әйтәсең, шунда.

Ш ә р и ф ә. Ә этиләр?

М и н с а б и р. Нәрсә этиләр? Телисеңме, иртәгә үк сорарга киләм?

Ш ә р и ф ә. Бирмәсләр бит... Минем әле абыйлар да өйләнмәгән, апалар да...

М и н с а б и р. Алайса, урлап алып китәм!

Ш ә р и ф ә. Ә этиләр?

М и н с а б и р. Нәрсә этиләр? Бер алып киткәч, кире сорамаслар инде!

Ш ә р и ф ә. Мин оялам...

М и н с а б и р. Нәрсәсеннән ояласың? Йола шулай куша! Урлап алып китәм! Йә, ничек? Йә инде, нигә эндәшмисең?

Ш ә р и ф ә. Бер күрешүдән үк ул турыда сөйләшәләрмени?

М и н с а б и р. Тимерне кызу чагында сугып калырга кирәк!

Ш ә р и ф ә. Тимерче түгелсеңдер бит?

М и н с а б и р. Юк, мин көтүче... Андый эшне озак уйлап торырга ярамый, күңелгә шик керә.

Ш ә р и ф ә. Ә син каян беләсең?

М и н с а б и р. Җегет кеше барын да белергә тиеш!

Ш ә р и ф ә. Мин сине күптәннән беләм. Беренче тапкыр яз көне урман эшләрендә очрашкан идек.

М и н с а б и р. Эссе иде, бер читтә чәчләреңне туздырып үргән идең... Җете кара толымнарың әле дә төшләремә керә...

Ш ә р и ф ә. Алдарсың бит. Сез җегетләр шундый... Оста сөйләнәсез дә кочаклагач, таясыз...

М и н с а б и р. Ә син каян беләсең?

Ш ә р и ф ә. Шулай диләр...

М и н с а б и р. Шулай диючеләрне күбрәк тыңла. Телисеңме, бүген үк алып китәм...

Ш ә р и ф ә *(паузадан соң)*. Нигә калтырыйсың?

М и н с а б и р. Мин түгел, син үзең калтырыйсың. Әнә, тешең-тешкә тими...

Ш ә р и ф ә. Синеке дә!

*Минсабир кызны иреннәреннән үбеп ала. Шәрифә аны этеп, читкә тайпыла.*

Ш ә р и ф ә. Мин өшедем. Бар! Кит!

М и н с а б и р. Җавап бирмәдең...

Ш ә р и ф ә. Соң инде. Минем йокым килә...

М и н с а б и р. Ярый, яхшылап уйла! Мин хәбәр салырмын...

Ш ә р и ф ә. Ярый, бар... Әй, тукта, китмә...

М и н с а б и р. Нәрсә?

Ш ә р и ф ә. Мин өйгә кереп киткәнче генә шунда тор әле...

М и н с а б и р. Ярый!

Ш ә р и ф ә. Капка бикләгән, өстән төшәрсең...

М и н с а б и р. Ярый!

Ш ә р и ф ә. Мин киттем. *(Кереп китә.)*

М и н с а б и р *(артыннан)*. Уйла, мин хәбәр салырмын!

*Шәрифә кереп китә. Минсабир капка аркылы менү юлларын карый. Җайсыз гына менә. Икенче якка төшәм дигәндә Шәрифә ишектән башын тыгып:*

Ш ә р и ф ә. Егыла күрмә! Саграк кылан!

*Минсабир капканың кире ягына капчык сыман килеп төшә.*

Ш ә р и ф ә. Минсабир!

М и н с а б и р *(яткан җирдән)*. Әү!

Ш ә р и ф ә. Син ничек?

М и н с а б и р. Әйбәт...

Ш ә р и ф ә. Ярый...

М и н с а б и р. Тыныч йокы...

Ш ә р и ф ә. Тыныч йокы!..

*Шәрифә кереп китә. Минсабир торып, аксаклап китеп бара. Ш ә р и ф ә атылып керә. Нишләргә белми, тиле сыман бераз кар туздырып уйный, ишегалдында әйләнгәли дә кереп сыдыра. Әкренләп буран күтәрелә.*

## IV

*Монгол капка төбендә басып тора. Җил карны себереп йөртә.*

Монгол. Өлгермәдек... Буранга эләгәбез инде... Җитмәсә, җиле дә каршыга. Күзне дә ачып булмый... Ярар, безнең класска гомергә җил каршы булды, үлмәдек. Юллар билгеле, күзне йомган килеш тә кайтырбыз, боерган булса... Безне буран белән генә куркытып булмас. Кар көртләрен ерып чыгу гына... Әһе, берәү килә... Минем ристаным бугай...

*Әнсәр абына-сөртенә йөгереп килә, изүләре ачык, авыр сулый. Монголның муенына килеп асылына.*

Монгол *(аны бераз назлап)*. Нәрсә?! Әллә сагындың дамы?

Әнсәр *(аны маңгаеннан үбә)*. Минсабир һаман юкмы? *(Як-ягына карана.)*

Монгол. Юк шул... Берәр нәрсә булмагандыр бит?

Әнсәр. Нишләргә? Аны ташлап китеп булмый бит...

Монгол. Ничек инде ташлыйсың? Нәрсә булды соң?

Әнсәр. Кая, без әзерләнеп торыйк әле...

Монгол. Кара, әйт инде, ул-бу булмагандыр бит?

*Әнсәр капкадан дилбегәне сүтә. Шул арада артында килеп чыккан Арслан белән Әмирне күрми кала.*

Арслан. Кая җыендың, кунак җегете? Әллә китәсең дәме?

Әнсәр *(каушавын күрсәтмәскә тырышып)*. Китәргә кирәк, соң бит инде... Әллә озатырга килдегезме?

Арслан. Әйе! Сездәй кунакларны озатмый булмас, дидек.

Әнсәр. Рәхмәт инде, борчылмасагыз да була иде, җегетләр!.. *(Атны кузгатмакчы.)*

Әмир *(килеп, атны авызлык тирәсеннән кысып тота)*. Ашыкма инде, сандугач тел. Нишләп шулай бик тизлисең?

Монгол. Кара, җибәр әле! Ал кулларыңны!

Әнсәр *(акрын гына чанага таба чигенә)*. Буран башлана, китәргә кирәк...

Арслан. Әллә танымаслар дигән идеңме? Әмир, теге юлы Яңа Думадан сине кыйнап җибәрүчеләрнең берсе шул дисеңме?

Әмир. Шул, башлап сугучы!

*Әнсәр чанадагы сәнәккә ташлана. Арслан аны якасыннан сөйрәп алырга өлгерә.*

Арслан. Сәнәккә үреләсеңме, падлис! *(Аны Әмиргә таба селкеп җибәрә.)*

Әмир. Нәрсә ди, безне тотар куллылар тумаган, диме? *(Аны янә Арсланга селкеп җибәрә.)*

Әнсәр. Җегетләр, сез нәрсә инде...

Арслан. Менә, эләктеңме инде, сандугач! Безнең авылда кызлар күзләп йөрисезме?

*Әнсәр, кыйналачагын аңлап, беренче булып үзе сугыша башлый. Ул Арсланны җилкә аркылы җиргә әйләндереп сала. Шул арада Әмир Әнсәрнең йөзенә суга, ул сузылып ята. Арслан инде аякка баскан, ул ачу белән Әнсәрне торгызып, тагын сугып ега. Алар барысы да авыр сулыйлар, калын киемнәрдән бик җайсыз хәрәкәтләнәләр, нидер сөйләнәләр... Икәүләшеп җирдә яткан Әнсәрне типкәли башлыйлар.*

Әмир. Мә! Рәхәтме?

А р с л а н. Чучка булып чинатам мин сине хәзер!.. Кара, падлис, ни кыланган була...

*Шулчак М и н с а б и р чабып керә. Ул сугышучыларны ерактан күреп алган.*

М и н с а б и р. Нишлисез?..

М о н г о л. Үтерәләр! Үтерәләр!..

*Чабып килгән җирдән Арсланны якасыннан сөйрәп ала, сугып җибәрә, ул кар көртенә барып төшә. Аннан Минсабир Әмирнең йөзенә суга, ул егыла. Минсабир Әнсәрне торгыза башлый.*

М и н с а б и р. Син исәнме? Тор әйдә! Тизрәк, киттек!

М о н г о л. Әйдәгез! Әйдә, тизрәк! Җилләтәм генә!

*Арслан кесәсеннән пәке чыгара.*

А р с л а н. Мә, падлис!

*Арслан чабып килеп, Әнсәрне торгызып маташкан Минсабирның аркасына пәке кадый.*

Ә м и р. Нишләдең?!

А р с л а н *(шашкан күзләр белән карап тора)*. Нәрсә?

Ә м и р. Ташла пәкеңне, тайдык!

*Ә м и р  берни аңламый катып торган Арсланның кулындагы пәкесен алып, читкә ата. Алар чабып чыгып китәләр.*

Ә н с ә р *(Минсабир аның кочагына ава)*. М и н с а б и р!.. Нишләдең? Чәнчеделәрме? Син исәнме?

М и н с а б и р. Исән...

Ә н с ә р. Хәзер, хәзер... Больниска... Күп кердеме... Хәзер... Районга...

М о н г о л. Районгамы? Тизрәк чанага яткыр! Хәзер, минутта... Егерме чакрым нәрсә ул безгә...

Ә н с ә р *(Минсабирны чанага яткыра)*. Хәзер... Хәзер... Ярый әле син килеп чыктың, малай. Кыйнап үтерәләр иде... *(Монголга.)* Әйдә, малкай!

М о н г о л. Их, җегетләр... Шулай ярый димени соң?..

*Барысы бергә кузгалып китәләр.*

Ә н с ә р. Син йоклама, йоклама, дим, Минсабир... Танып алдылар бит, каһәрләр... Ярый, бер очрарлар әле! Шулай бит, яшьти!.. Әйдә, малкай! Син, кара, йоклый күрмә... Ә, үзеңнең эшләр ничек соң, булдымы? Күрештеңме?

М и н с а б и р. Сөйләштем...

Ә н с ә р. Менә бит! Ничек соң, кирегә сукаламыймы?

М и н с а б и р. Юк... Тиздән килеп алып китәбез!..

Ә н с ә р. Инде ансын да сөйләштегезме?! Ну, син җегет, булдырасың! Урлап китәбез, боерган булса... Андый эшне безгә куш!..

М и н с а б и р. Син аның чәчләрен күрдеңме?

Ә н с ә р. Күрдем... *(Монголга.)* Әйдә инде, җаным!

М о н г о л. Чабам бит инде, чабам...

М и н с а б и р. Шул ике толым өчен берни жәл түгел, малай... Шомыртмыни – чем-каралар... Ефәк тасмалардан үргәнмени – ялтырыйлар... Карурманмыни – фикерләрне чуалталар... Шул чәчләргә йөзең чумырып, бер сулар өчен берни жәл түгел, малай...

Ә н с ә р. Буран да кузгалды бит, җитмәсә... Нишләтә бит, ә? Хәзер...

М о н г о л. Ярый, безне буран белән генә куркытып булмый. Без күз йомып та... Эһ, җегетләр...

*Буран эченә кереп югалалар.*

## V

*Клуб. Яңа ел киче. Сәхнәдә кызыл җәймә җәелгән өстәл. Иптәш Ленин һәм иптәш Сталинның сурәтләре эленгән. Өстәл артында авылның җитәкчеләре. Зал тулы халык. Җыелыштан соң булачак тамашада катнашучы артистларның башлары күренеп тора. Иптәш председатель, Мөхетдинов Хәбибрахман, үзенең чыгышын тәмамлап килә.*

Хәбибрахман. Иптәшләр, инде сүземне йомгаклап, тагы бер кабатлап үтәсем килә: «Комсомолец» колхозы белән берләшүебез дөрес адым булуын бүгенге көндә барыбыз да ап-ачык күрәбез! Безнең күрсәткечләр бермә-бер артты! Бу гади саннар гына түгел, ә беренче чиратта, безнең дөрес юлдан тайпылмавыбыз күрсәткече. Бары тик хезмәт җиңүләре белән генә без каршыбызга куелган максатларга ирешә алачакбыз! Илебез кара кайгы кичергәндә, без бердәнбер дөрес юлны сайладык: төшенкелеккә бирелмичә, күңелгә кечкенә генә шик тә кертми, тагы да ныграк берләштек, идеалларыбызга тугры калдык! Татария колхозчылары иптәш Сталинның үлеменә башкача җавап бирергә тиеш тә түгелләр иде! Безнең юлыбыз билгеле һәм без шул юлдан нык адымнар белән алга барабыз!

*Әминә белән Шәрифә янәшә утыралар. Председатель сөйләгән арада алар пышылдашалар.*

Шәрифә. Көнләшәсеңме?

Әминә. Кемне?

Шәрифә. Соң, синеке бит, әнә, гел хатын-кыз арасында...

Әминә. Исем дә китми...

Шәрифә. Шыттырасың!...

Әминә. Чүт кенә дә көнләшмим! Гармунчы тирәсендә хатын-кыз күп була инде ул! Һәрберсеннән көнләшә калсаң...

Шәрифә. Алып китсәләр?

Әминә. Кая китсен?! Миннән башка берәүне дә күрми бит ул! Барыбер селәгәйләрен агызып, минем янга килеп җитәчәк! Ә син нәрсә?..

Шәрифә *(боргалана)*. Нәрсә, нәрсә... Мин бернәрсә дә түгел. Мин нәрсә...

Әминә *(кечкенә паузадан соң)*. Т-с-с!

Шәрифә. Нәрсә?..

Әминә *(җитди нәрсә хәбәр иткәндәй, паузалар белән)*.

Коридор, коридор,
Коридор бүлмәләре.
Күз төпләренә уелган
Мәхәббәт сөрмәләре...

Шәрифә. Әй, юньсез...Тыңла, әнә, иптәш председатель сөйли...

Әминә *(бераздан, елмаеп)*. Тсс! Әйтергә онытканмын!

Шәрифә. Нәрсә, нәрсә тагын?

Әминә.

Дулкынланып сулар керә
Пароход идәненә.
Ышанмагыз егетләрнең
Яратам дигәненә...

Хәбибрахман. Барыгызны да котлыйм, иптәшләр!

Рәшит. Иптәшләр, мин иптәш Мөхетдиновның сүзләренә кушылам һәм барыгызны да уңышлы ел белән тәбрик итәм! Киләсе еллар да шулай ук шатлыклы булсын, дип теләп калам! Ә хәзер сезнең алдыгызда Кызылсу урта мәктәбе укытучылары көче белән оештырылган концерт! Рәхим итеп каршы алыгыз!

*Председательләр сәхнәдән төшеп, залда урын алалар. Чаршау корыла. Аның артыннан аяк тавышлары, сөйләшүләр, әйбер күчергән тавышлар ишетелеп тора.*

М а р а т *(чаршау алдына чыгып)*. Колхозчы кызлар биюе!

*Кереп югала. Кечкенә пауза. Чаршау артыннан берничә пышылдашкан тавыш ишетелә. Гармун тавышы. Чаршау ачыла. Инде өстәл юк, ләкин иптәш Ленин белән иптәш Сталин портретлары калган. Марат бер читтә гармунда уйный. Берничә кыз шул көйгә бииләр. Шәрифә урынында тик кенә утыралмый. Аны мең төрле уй интектерә. Кызның күңеле кая барып бәрелергә белмәгәндәй тоела.*

Ш ә р и ф ә. Нишләргә? Нишләргә? Нишләргә? Хәдичә тыкрыгында көтәм, дигән... Ничек шулай бөтен нәрсәне ташлап китәргә кирәк? Ә ул бит көтә... Инде килгәндер дә. Туңып тора торгандыр. Шулай була микәнни соң ул? Бөтен авыл нәрсә дияр? Хәсәншаның кызы сорамый-нитми, күрше авыл егетенә тагылып киткән, диярләр. Аннан әтинең күзенә ничек карарга? Мондый җәфаларсыз гына булмый микәнни соң? Әгәр дә соратып алдырсам?.. Апаны бирделәр бит әле... Юк шул, бирмәсләр. Апа иң олысы иде, аннан соң өйләнмәгән абыйлар бар бит әле. Йөриләр һаман, ыштан туздырып, ачуым да бер килмәгәе. Барыйм микән, юк микән? Барам! Ничек сөйләште бит, ә ничек җырлады... Кочагында эреп төштем инде. Минсабир анда көтеп тора, клубтан чыгуга, Әминәдән аерылып, Хәдичә тыкрыгына йөгерәм. Йа Ходаем! Мин генә аны ошатам дип торам, ә юк икән, икебезнең дә күңел тарткан... Әнә бит, апа әйтә, юләр чакта чыгып калсаң гына, ди. Әйе шул, аннан акыллы да булырсың, беркемгә кирәгең дә калмас. Барам! Килен булып төшәм. Әстәгъфирулла... Бер дә белмәгән, күрмәгән өйгә... Апа сөйләвен сөйли дә, үзе бик йөрешеп, белешеп, соратып кына чыкты. Ә мин ике-өч мәртәбә күрешкән кешегә, япят йортка... Бәлки ул усалдыр? Җүләрлегем белән аның кимчелекләрен күрмим генәдер? Туктале, Шәрифә... Алай тиз генә хәл итәргә уен эшмени язмыш? Юк... Син нәрсә? Юләр дә инде. Җегет дигәч тә... Чынлап торып яратса, үпкәләмәс, көтәр. Юк, бармыйм... Хәдичә тыкрыгына якын да бармыйм... Өйгә башка яктан урап кайтам. Юк... Уйламаган-нитмәгән, беренче чакыруга кияүгә чык та куй, имеш. Юк! Ике аягымның берсен дә атламыйм!..

*Сәхнәдә бию дәвам итә.*

## VI

*Кызылсу авылы. Төн. Тыкрык. М и н с а б и р, Ә н с ә р, К ә р и м ә, чанага җигелгән М о н г о л .*

К ә р и м ә. Ә килмәсә?

М и н с а б и р. Ничек инде килмәсен? Марат артыннан язу җибәрдем.

К ә р и м ә. Язу. Язу җибәрүе авыр түгел ул...

М и н с а б и р. Әй, апа, син дә күңелгә шом салып тормасаң... Нигә ияреп килдеңдер...

Ә н с ә р. Ничек инде нигә?! Кызык кына син. Безне Кызылсу җегетләреннән сакларга дип килде...

К ә р и м ә. Сакларга шул. Сез бит бер-берегезне саклый алмыйсыз. Әнә, үпкәсенә пәке кадап җибәргәннәр иде бит әле, итек балтырына кадәр кан аккан иде, яңа гына аякка басып килә.

Ә н с ә р. Үзләренә дә управа табылды. Ябып куйдылар бит, тиздән суд. Тыгып куярлар менә үзләрен!

М и н с а б и р. Тавышланма...

Ә н с ә р. Минсабир, син бар, чанага утырып тор, толып белән ябынып...

К ә р и м ә. Бар, хәлең юк бит, егылырсың тагын...

М о н г о л. Ят әйдә, йомшакка!..

М и н с а б и р. Юкны сөйләмәгез әле, нинди утырып тору ди ул... Апа, син бит өшегәнсең, бар әле хәзер үк, ябын толыпны! Бар дим! Тагын йөткереп ятарсың аннары...

Ә н с ә р. Әйдә...

*Кәримәне чанага таба алып китә. Минсабир урам яктан күзен алмый. Әнсәр әйләнеп килә.*

Ә н с ә р. Киләләр.

М и н с а б и р. Куркып калмаса ярый...

Ә н с ә р. Куркытырсың Кызылсу авылы кызларын!..

*Урам якка карап торалар. Алар янына толыпка төренгән К ә р и м ә килеп баса.*

К ә р и м ә. Әнсәр, сине кайчан өйләндерәбез?

М о н г о л. Өйләндерәсе иде шул, көне-төне чапмас иде хет...

Ә н с ә р. Чыкмыйлар бит...

К ә р и м ә. Сиңамы? Синең тел белән дә кыз башын әйләндералмыйсыңмы?

Ә н с ә р. Хәзергеләрнең башлары әйләнми шул, нык тора.

К ә р и м ә. Әйдә соң, урлыйбыз!

М о н г о л. Әйе! Шунда беррәттән берәрсен салып кайтыйк, ике килеп йөрмәс идек!

Ә н с ә р. Юк, Кәримә апа, яшь бит әле мин!

М и н с а б и р. Шым! Кемнәрдер килә бугай...

К ә р и м ә. Әйе, әнә, киләләр...

Ә н с ә р. Клубта җыелыш беткәндер, әнә, әртилләре белән кайталар.

К ә р и м ә. Ходаем, күреп алмасалар ярый инде.

Ә н с ә р. Җитмәсә, бигрәк якты да бүген.

М о н г о л. Безнең киләчәк шикелле...

К ә р и м ә. Шулай шул... Безнең Исмәгыйль тәрәзә каршында, Ай яктысында китап укып калды.

М и н с а б и р. Апа, тыныч инде... Сөйләшмәгез. Басып тормагыз, чүмәшегез инде хет...

*Утырып, койма ярыгыннан күзәтәләр. Урамнан сөйләшеп, көлешеп, җырлашып клубтан кайтучы кешеләр үтә.*

К ә р и м ә. Юкмы?

М и н с а б и р. Юк...

К ә р и м ә. Бу түгелме?

М и н с а б и р. Түгел. Тукта... Ә, юк...

К ә р и м ә. Син аны таныйсыңмы соң? Исеңдә калдымы?

М и н с а б и р. Әй, апа, бик кызык инде...

Ә н с ә р. Ну, Кәримә апа...

К ә р и м ә. Соң, озаклап йөрергә вакытыгыз булмады бит.

Ә н с ә р. Үтеп беттеләр. Бәлки, ул башка урам белән киткәндер?

М и н с а б и р. Нинди башка урам инде? Хәдичә тыкрыгында көтәм диелгән бит аңа.

К ә р и м ә. Тагын киләләр...

*Урамнан М а р а т , Ә м и н ә , Ш ә р и ф ә , тагын берничә егет-кыз көлешеп, үртәшеп, нидер көйләгән булып үтеп китәләр.*

М и н с а б и р. Ул! Әнә!

К ә р и м ә. Ә кая бара соң ул? Үтеп китә түгелме соң?

Ә н с ә р. Безнең якка карамый да бит бу. Марат язуны бирде микән соң?

М и н с а б и р. Ничек бирмәсен инде. Нәрсә соң бу?..

Ә н с ә р. Әллә бик тиз тәкъдим итеп ашыктыңмы, яшьти?

К ә р и м ә. Куркып калмадымы икән? Минем дә киләсемне яздыңмы? Хатын-кыз булгач, тынычрак бит ул.

М и н с а б и р. Яздым инде, яздым.

М о н г о л . Киттеләр...

Ә н с ә р. Нишлибез?

М и н с а б и р. Туктагыз әле... Күрдегез бит, үзе генә түгел иде.

К ә р и м ә. Әйе, бәлки, иптәшләреннән аерыла алмагандыр?

Ә н с ә р. Клуб – авылның теге очында, шуннан бирле аерылып киталмаган микәнни?

М и н с а б и р. Сабыр...

К ә р и м ә. Җитмәсә, өйдә аш-су әзерләп калдылар...

Ә н с ә р. Аш-суны ашарга кеше табылыр...

*Тыкрыкның икенче башыннан абына-тора берәү йөгереп килә – Ш ә р и ф ә. Аның тавышларын беренче булып Монгол ишетә, аннан күреп ала – киң итеп елмаеп, хуҗаларына таба борыла. Аннан Минсабир, Кәримә, Әнсәр дә, кар шыгырдаганын ишетеп, әйләнеп карыйлар, елмаялар, тезелешеп басалар. Шәрифә алар каршына килеп җитә.*

Ш ә р и ф ә. Хәзер... абыйлар... кайтып җитәчәк... Мин өйдә юклыкны күргәнче... Тизрәк булырга кирәк...

М и н с а б и р. Ә н с ә р...

Ә н с ә р. Без әзер! *(Чанага менеп, дилбегәләрне тотып утыра.)*

М и н с а б и р. Апа!

К ә р и м ә. Мин әзер! *(Чанага менеп утыра.)*

*Минсабир Шәрифәнең кулыннан тотып, апасы янына утырта. Толыпны икесенә ябынып утыралар. Минсабир үзе Әнсәр янына менеп утыра.*

М и н с а б и р. Йә!

М о н г о л . Мин әзер!

М и н с а б и р. Аллага тапшырдык!

Ә н с ә р. Әйдә, малкай!

М о н г о л. Һәй! Җиллләтәм генә хәзер! Нинди көннәр килеп җитте бит! Их, җегетләр! Иртә буран, кич тә буран, мамык шәлеңне уран шул, мамык шәлеңне уран...

*Яңа Дума авылына таба җилдерәләр.*

## VII

*Яңа Дума авылы. Шул ук төн. Тәрәзә, тәрәзә кырыенда рамада вак фотолар, аш-су әзерләнгән өстәл, ястык, түшәкләр җәелгән карават, күкеле сәгать – Мирзаның өе. Тәрәзә кырыенда И с м ә г ы й л ь калын китап укый. М и р з а өстәл кырыенда артсыз урындыкта черем итеп утыра. Сәхнәнең икенче читендә абзар. Абзарда Йолдыз белән Машка.*

Й о л д ы з. Безнекеләр бүген никтер йокламыйлар...

М а ш к а. Хуҗаның малае өйләнергә җыена, шуңа әзерләнәләрдер...

Й о л д ы з. Ә син каян беләсең?

М а ш к а. Ишетеп калдым...

Й о л д ы з. Мин тагын хыялга бирелеп, берни белми калганмын. Әйбәт! Әйбәт! Кирәк нәрсә!

М а ш к а. Нәрсәсе әйбәт? Тагын берәр имчәк тә тарта белмәгән маңка борынны алып кайтып утыртырлар астыңа да белерсең...

Й о л д ы з. Ярар. Тартыр, тартыр да өйрәнер. Беркем белеп тумый. Гаилә кору – әйбәт гамәл. Матур киләчәкне якынайтыр өчен безгә яшьләр кирәк, бәбиләр!

*Мирза кинәт уянып китә.*

М и р з а. Мәхрүзә!

М ә х р ү з ә. *(почмактан атылып керә)*. Әү!

М и р з а. Аш-суларың әзерме?

М ә х р ү з ә. Әзер!..

М и р з а. Ярый... *(Мәхрүзә почмакка кереп китә. Өстәлне карап*

*үтә, өстәлдәге нәрсәләрне үзенчәрәк урнаштырган була)*. Мәхрүзә!

М ә х р ү з ә. *(почмактан йөгереп керә)*. Әйе, нәрсә?! Нәрсә бар? Кайталармы әллә?..

М и р з а. Исмәгыйль кая?

М ә х р ү з ә. Менә бит, китап укып утыра... *(Кире кереп китә.)*

М и р з а. Улым...

И с м ә г ы й л ь *(китабыннан аерылмыйча)*. Әү, эти?!

М и р з а. Улым...

И с м ә г ы й л ь. Әйе.

М и р з а. Бар әле...

И с м ә г ы й л ь. Кая?

М и р з а *(тиз)*. Улым, бар әле, карап кер, абыеңнар кайтмыймы?!

И с м ә г ы й л ь. Хәзер, эти!.. *(Кузгалмый да, укуын дәвам итә.)*

М и р з а *(аңа бераз карап торгач)*. Исмәгыйль!

И с м ә г ы й л ь. Әйе, эти!

М и р з а. Карап керәсеңме, юкмы?

И с м ә г ы й л ь. Хәзер, эти, кызыл юлга кадәр генә укып бетерим.

М и р з а. Кызыл юлга кадәр булса, укы...

*Мирза урынына барып утыра. Исмәгыйль укуын дәвам итә. Ул инде кызыл юлга менә-менә килеп җитә, якынайган саен урындыгыннан күтәрелә бара, тәмам торып җиттем дигәндә генә, бик кызык нәрсәгә барып төртелә һәм янәдән утырып укый башлый. Мирза уйланып утырганда, әкренләп йокыга китә.*
*Абзарда М а ш к а белән Й о л д ы з.*

Й о л д ы з. Машка, ә син киләчәкне ничегрәк күз алдына китерәсең?

М а ш к а. Берничек тә... Миңа болай да начар түгел...

Й о л д ы з. Ә тиздән тагы да әйбәт булачак. Җир йөзендә бары тик көтүлекләр генә, чиста сулы елгалар гына булыр! Без чирәмнәрнең иң хуш ислеләрен генә сайлап ашаячакбыз... Ә, юк, җир йөзендә бары тик хуш исле үләннәр генә булачак!.. Тик моның өчен безгә үзебезгә дә тырышырга кирәк.

М а ш к а. Ансыз гына булмыймы?

Й о л д ы з. Юк, тырышкан табар, дигән! Без күп итеп сөт бирергә, берсеннән-берсе матур бәбиләр алып кайтырга тиеш!

М а ш к а. Бик кирәк иде, үз рәхәтем рәхәт!

Й о л д ы з. Алай ярамый, Машка...

М а ш к а. Ярамыйга карамый!

Й о л д ы з. Бераз оят бел. Без матур киләчәкне бергә, уртак көчләр белән булдырырга тиешбез...

М а ш к а. Кыл да кыймылдатасым килми.

Й о л д ы з. Машка, туры сөйләвем өчен үпкәләмә, мин сиңа дөресен әйтергә тиеш: безнең рәтләргә ялкаулар кирәкми.

М а ш к а. Мин сезнең рәтләргә бик үк ашкынып тормыйм әле!..

Й о л д ы з. Шулаймы? Болай булганда, матур киләчәк турында хыялланма да!

М а ш к а. Бик хыяллана торган нәрсә бит инде, әйтәм. Сезгә көтү булып йөрергә ошый икән, йөри бирегез, көтүче кая кушса, шунда борылып. Ә мин көтүдән качып, җаным теләгән болын-кырларда, күңелем теләгән үлән ашап йөрүдән дә артык нәрсә күрмим! Миңа якты киләчәк кирәкми, минем бүгенге көнем дә ап-ачык!

Й о л д ы з. Кырларда йөрисең дә, полевойлар тотып яба үзеңне. Хуҗаларга җәфа гына син...

М а ш к а. Исем китә...

Й о л д ы з. Оятсыз син, Машка. Өч литр сөтең юк, ике елның берендә кысыр каласың, көтүдән вакытында кайтканың юк. Һәм, гомумән, мин синең ише артка сөйрәүче элементлар белән сөйләшергә дә теләмим. Бетте, бүгеннән ләм-мим.

М а ш к а. Ихтыярың!

*Мирза уянып китә.*

М и р з а. Мәхрүзә!

М ә х р ү з ә *(кереп)*. Әү! Нәрсә?! Нәрсә?

М и р з а. Сәгать ничә?

М ә х р ү з ә *(күз алдында эленеп торган күкеле сәгатькә карап)*. Бер тула!

М и р з а. Исмәгыйль!

И с м ә г ы й л ь. Әү, эти?

М и р з а. Карап кердеңме?

И с м ә г ы й л ь. Әле генә кереп утырдым...

М и р з а *(аннан дәвам булмагач)*. Һәм?

И с м ә г ы й л ь. Күренмиләр.

М и р з а. Соңладылар... Мәхрүзә!

М ә х р ү з ә. Мин монда, кычкырма.

М и р з а. Аш-суларың әзер дисең инде?

М ә х р ү з ә. Бар да әзер, борчылма... Әллә ятып аласыңмы? Күренсәләр, уятырмын?

М и р з а. Нинди йөрәк белән йоклап ятарга мөмкин ди мондый төндә?! Менә-менә килен төшәргә тора, ә мин йоклап ят имеш...

*Ишек ачылып китә. Салкын һава болытлары арасында башта Ә н с ә р н е ң елмайган чырае күренеп ала, аннан К ә р и м ә н е ң йөзе, шуннан май кояшымыни – М и н с а б и р пәйда була.*

М и н с а б и р *(ишек артыннан)*. Эти! Әни! Киленегезне каршы алыгыз!..

*Өйдәгеләр нишләргә белми аптырап калалар. Аннан йөгерешә башлыйлар.*

М и р з а. Тукта, улым. Ашыкма. Мәхрүзә, нәрсәләрең кайда?

М ә х р ү з ә. Хәзер, хәзер... Шунда гына куйган идем ләбаса...

*Мендәр, бал белән май тотып ишек каршына басалар.*

М и р з а. Аллага тапшырдык!

*Ишектә Ш ә р и ф ә күренә.*

М и р з а. Кызым, үз теләгең беләнме?

Ш ә р и ф ә. Үз теләгем белән... *(Йөзен яшерә.)*

М ә х р ү з ә. Авызыңа бал да май, киленкәй! Түкле аягың белән!

*Шәрифәне мендәргә бастырып, бал белән май каптыралар.*

М и р з а. Әйдәгез, балалар, табын артына рәхим итегез! Аллаһы Тәгалә биргәне белән! Рәхим итегез!

*Бар да табын артына утырышалар. Шәрифә һаман карашын яшерә. Бар да үз эшен эшли, сөйләшкән була, ә күз кырые белән генә киленне сынаулы караш белән күзлиләр. Урамда җил кар себерә.*

## VIII

*Кызылсу авылы. Иртән. Өстәл, артсыз урындыклар, күкеле сәгать, вак фотолар тезгән рама, тәрәзә төбендә кызыл чәчәкле гөл – Хәсәншаның өе. Ш ә м с е р у й бер читтә басып тора. Ул нидер әйтергә тели, тик сүз башларга батырчылык итми. Ә л ф и я әнисе янында. Тау кадәр гәүдәле Сәяр артсыз урындыкта карашын идәнгә төбәп утыра. Табигый әдәплелек, гомерендә авызыннан сүгенү сүзе ишеттермәве белән билгеле Х ә с ә н ш а н ы ң бик ачулы чагы, бүлмә буйлап әле алга, әле артка китә. Ул идәннең бер тактасына баскан саен, тегесе сызгырып куя. Шулай берничә мәртәбә кабатлангач, С ә я р торып, мич артыннан балта алып килә, идәнне бераз кы-*

*сып, «шап» иттереп сугып куя, балтаны урынына илтә, кире барып утыра. Х ә с ә н ш а аның артыннан игътибар белән күзәтеп тора. Аннан кабат йөри башлый, идән сызгырмаудан аның тагы да эче поша. Сәяр янында туктап, аңа карап тора. С ә я р атасының карашын тоя, мөмкин кадәр озаграк башын күтәрмәскә тырыша, аннан чыдый алмый, кыюсыз гына күтәрелеп карый.*

Х ә с ә н ш а. Кая... сеңлегез?

С ә я р. Әти, абый Әминәләргә китте бит инде. Ул белсә генә...

Х ә с ә н ш а. Нишләп сезнең сеңлегезнең кайдалыгын сез түгел, Әминә белергә тиеш?

С ә я р. Соң, иптәш кызы бит...

Х ә с ә н ш а. Ә сез нәрсә карап йөрдегез?

С ә я р. Карадык инде...

Х ә с ә н ш а. Адәм хурлыгы... *(Карашы Шәмсеруйга төшә.)*

Ш ә м с е р у й *(тиз)*. Самавыр шаулады, чәй эчеп аласың мәллә генә димәкче идем... *(Хәсәнша бер сүзсез карап тора.)* Ярар, соңрак эчәрбез...

*Ишек ачыла. Ә м и н ә , М а р а т һәм Хәсәншаның олы малае, гәүдәгә кечкенә, җиңел сөякле, елан кебек С ә л и м килеп керәләр.*

Ә м и н ә. Исәнмесез...

М а р а т. Исәнмесез, Хәсәнша абзый... Шәмсеруй апа... Әлфия апа... Сәяр абый...

Х ә с ә н ш а. Шәрифә кая?

М а р а т. Без аны кичә озаттык...

Х ә с ә н ш а. Кая озаттыгыз?

М а р а т. Гелдәгечә...

Х ә с ә н ш а . Кая, гелдәгечә?

М а р а т. Соң...

Ә м и н ә. Без аны капкагызга кадәр озаттык, өйгә кереп киткәнен көтеп тордык.

Х ә с ә н ш а. Кереп киттеме?

М а р а т. Барыгыз, мин кердем, диде.

Х ә с ә н ш а. Алай булгач, кайда соң ул?

М а р а т. Урлап киткәннәрдер инде алайса. Соң, өйдә булмагач...

Ш ә м с е р у й. Әстәгъфирулла...

Х ә с ә н ш а. Кем урлаган? Йөргән егете бар идеме?

Ә м и н ә. Болай юк кебек. Бер... бер егет сүз кушкан иде бугай...

Х ә с ә н ш а. Кем?

Ә м и н ә. Думадан... Минсабир...

М а р а т. Ә, әйе шул. Шәрифә кичә бик борчулы иде. Бездән соң шуның белән качып киткән инде ул алайса! Менә бит...

С ә л и м. Күптән түгел Арсланнар пәке кадаган Минсабирмы?

Ә м и н ә. Әйе...

Х ә с ә н ш а. Мирза малае алайса...

С ә я р. Абый, әйдә, ат табыйк та Думага киттек...

С ә л и м. Әйдә... *(Ишеккә таба кузгалалар.)*

Х ә с ә н ш а. Кая киттегез?

С ә л и м. Думага...

С ә я р. Табып алып кайтабыз...

М а р а т. Бер урлагач... хәзер... кирәкмәстер инде... Мин, белмим дә инде...

Ш ә м с е р у й. Әстәгъфирулла...

*Хәсәнша ни әйтергә белми тора. Кинәт ишеккә шакыйлар. Барысы да тынып кала. Ишек ачыла. Аннан М и р з а белән М ә ү л ә килеп керәләр. Кулларында алып килгән күчтәнәчләре.*

М и р з а. Эһем, эһем! Әссәламегаләйкем, хуҗалар!

Алгы ишегегезне ачып килдем,
Арткы ишегегезне яба килдем,
Кызыгызга башкода булып килдем.

Х ә с ә н ш а. Кемнән башкода булып килдегез?

М и р з а. Улым Минсабирдан...

Х ә с ә н ш а. Димәк, кыз сездә... *(Авырсынып, ни әйтергә белмичә.)*

Үз теләге белән барганмы соң, хет?

М и р з а. Үз теләге белән, туган!

Х ә с ә н ш а. Үз теләге белән...

М ә ү л ә . Үз теләге белән!

М и р з а. Бусагадан атлап кергәч тә сорадым! Үз теләге белән!

*Шәрифәнең: «Үз теләгем белән!» – дигәне яңгырап ишетелә.*

Х ә с ә н ш а. Үз теләге белән булгач, мин нәрсә әйтә алыйм...

М и р з а. Димәк, сез риза?! Димәк, туй?!

Х ә с ә н ш а. Туй!..

Б а р ы с ы  д а. Туй!!!

**IX**

*Туй ике якта да булу сәбәпле, сәхнә ниндидер урталыкны белдерә. Туйда сый-хөрмәт, чирек аракы. Барысының да кәефе күтәренке. Биредә бөтен туган-тумача, иптәшләрдән берничә кеше күренә. М а р а т гармунда уйный, яшьләр бииләр. Уртада Ә м и н ә белән Ә н с ә р кыздыралар. Аннан уртада ике туган: аю кебек С ә я р һәм тал чыбыгыдай С ә л и м пәйда була, очып-очып бииләр. Шуннан Ә м и н ә М и н с а б и р н ы биергә алып чыга. Бу вакытта егетләрдән берәү Ш ә р и ф ә н е алып чыгып китә.*

Ә н с ә р *(кинәт Шәрифәнең юклыгын сизеп)*. Урлаганнар! Кызны урлаганнар!

М и н с а б и р. Кая? Кем?

*Шау-шу куба. Бар да йөгерешә башлыйлар. Кычкырышалар, кемнәрдер көлешә. Яшьләр өйдән йөгереп чыгып китә. Бу вакыт ике гармун тавышы ишетелә – бераз төшереп алган кодалар: М и р з а белән Х ә с ә н ш а , кара-каршы утырып, чиратлап такмак әйтешәләр!*

М и р з а.  
Аргы яктан бирге якка  
Йөгерә аксак куян...  
Ботак очы ападан соң  
Иң якын туган – кодам!  
Әй туганнар, туганнар ла,  
Туганнар-тумачалар,  
Сездән аерылса әгәр,  
Нишләр газиз башкайлар?..

Х ә с ә н ш а.  
Шәһәр базарына барсам,  
Әфлисун сатып алам.  
Кодамны күрсәм, шатлыктан  
Лимун булып саргаям...  
Әй туганнар, туганнар ла,  
Туганнар-тумачалар,  
Яшик мәзәкләр әйтешеп,  
Җырлашыйк шаян җырлар!

М и р з а.  
Сандугач телле бер чыпчык  
Төшеп кунган куакка...  
Кодамны җәфалап йөртмим,  
Үзем барам кунакка!  
Әй туганнар, туганнар ла,  
Туганнар-тумачалар,  
Сезнең белән очрашудан  
Яктырадыр дөньялар!..

*Яшьләр килеп керә. Минсабир Шәрифәне эзләп тапкан. М а р а т керүгә үк бию көе уйный башлый. Яшьләр такмак әйтеп, Минсабир белән Шәрифәне уртада биетәләр. Аннан барысы бергә бииләр.*

**Пәрдә.**

## ИКЕНЧЕ БҮЛЕК

### X

*Октябрь. 1961 ел. Й о л д ы з күшәп, уйланып ята. Тезмәдә И с м ә - г ы й л ь белән аның күптән түгел генә өйләнешкән хатыны Җ ә м и л ә ипигә май ягып, бик тәмләп ашыйлар.*

Й о л д ы з. Киреләнергә ярамый... Әнә Машка безнең дөньяны матурлаячагыбызга ышанмаган иде, менә кая ул хәзер? Юк. Ялгыш юлга басты һәм юк булды. Ә безнең белән иңгә-иң барган булса... Әйтик, пример, көтүеңнән вакытында кайт, сауганда тибенмә – авырмыни? Менә тәүлегенә 15 литр гына сөт бирсәң дә, ул бит атнасына 105 литр була, ә аена... әйтергә дә куркыныч – ким дигәндә 450 литр! Аннан бит күпме файда: каймагы, мае, эремчеге, катыгы. Ничәмә кеше шуның белән тукланып, тагы да яңа көчләр белән дөньяны бизәргә керешә. Гап-гади нәрсәләр. Машка шуларны аңламады... Менә кая ул хәзер?.. Юк ул...

*Исмәгыйль бик тәмләп ашап утырган җиреннән тончыга. Йөткеренә башлый.*

Җ ә м и л ә *(аның аркасына кагып)*. Нишләдең инде?.. Булдымы инде, юкмы? *(Каты итеп тондыра.)*

И с м ә г ы й л ь. Булды, рәхмәт... *(Бераз корсагын тоемлап, елмаеп тора.)* Кая, кил әле! *(Җайсыз гына сузылып, хатынын үпмәкче була.)*

Җ ә м и л ә *(чәйни-чәйни)*. Нишлисең инде, тончыктырасың бит...

И с м ә г ы й л ь *(сузылып ята)*. Ярый әле сине алып кайтканмын!

Җ ә м и л ә. Нәрсә?

И с м ә г ы й л ь. Мин әйтәм, ярый әле, дим, сине алып кайтканмын! Бергә кызыграк бит!

Җ ә м и л ә. Аңа кадәр кызык түгел идеме? Өйдә табор кебек, кешедән күбе юк. Бала-чага бер туктамый.

И с м ә г ы й л ь. Ярар, менә абыйлар башка чыгарга торалар.

Җ ә м и л ә. Безгә дә чыгарга кирәк...

И с м ә г ы й л ь. Кая?

Җ ә м и л ә. Авыл кырыенда теге йортны карадык бит. Бераз төзәтәсе, турайтасы җирләре бар барын, шулай да рәхәтләнеп яшәргә була.

И с м ә г ы й л ь. Безгә нәрсәгә ашыгырга соң? Хәзер абыйлар чыкса, инде биш кешегә кими, өй буп-буш кала. Өч балалары, аларга аерым йорт кирәк, ә безнең...

Җ ә м и л ә. Монда җыелып ятсак, мәңге дә булмас... *(Аны кочакларга маташкан Исмәгыйльгә.)* Үрелмә әле!..

*М и р з а белән М и н с а б и р керәләр. Аларны ишеткәч, Җәмилә май, ипиләрне тизрәк печән арасына яшерә, шым булалар.*

М и н с а б и р. Безнең йорт бит инде бер елдан артык әзер... Күчәргә вакыттыр...

М и р з а. Нәрсә дим инде, улым. Рәхмәт, әниегез авырганда ташламадыгыз, карап тордыгыз. Үз куышыгызны кору әйбәт!

М и н с а б и р. Без монда юл аркылы гына бит, кереп-чыгып йөрергә... Аннан, хәзер Исмәгыйль дә өйләнгәч... *(Мирза тезмә башына ишарә ясый, артыгын сөйләмәскә куша.)* Ике туган бер йортта яту килешмәс...

М и р з а. Улым, сез әнә теге сарайдагы башмак тананы үзегезгә алыгыз, бераз асрарсыз да сыер булыр, Аллаһы боерган булса... Тагын нәрсә инде...

М и н с а б и р. Юк, әткәй, рәхмәт! Болай да кара сыерны саткан акча шул безнең йортка кереп бетте. Барысы да

безгә булмас бит инде. Тананы үзегез кышка суярсыз, бер келәт ит булыр!..

М и р з а. Нәрсә диим инде?.. Алма кебек өч малаең, һәркем көнләшердәй хатының... башка чыгасың икән, бездән рөхсәт!.. Кирәк-ярагыңны үзең карап ал инде...

М и н с а б и р. Рәхмәт!

*И с м ә г ы й л ь белән Җ ә м и л ә керә.*

И с м ә г ы й л ь. Ишеттеңме?

Җ ә м и л ә. Мин ишеттем, син менә үзең ишеттеңме?

И с м ә г ы й л ь. Ишеттем! Абыйлар башка чыга, өйдә иркенләп калабыз. Алар урынына үзебезнең караватыбызны куярбыз! *(Үреләә.)*

Җ ә м и л ә *(аның кулына сугып)*. Ишетсәң, бар әнә, кара, аларга ниләр биреп чыгаралар икән.

И с м ә г ы й л ь. Борчылма, безгә тиешлесен алмаслар!

Җ ә м и л ә. Безгә тиешлесе әнә, басып тора.

И с м ә г ы й л ь. Йолдызмы? Тана диген инде хет...

Җ ә м и л ә. Ниткән тана ди ул? Абыеңа йорт салыр өчен сыер сатканнар бит... Ул тана сыер булганчы бер ел үтә бит әле. Ә бу сыерның ул гомер тагы бер бозавы була...

И с м ә г ы й л ь. Белмим дә инде...

Җ ә м и л ә. Белмәсәң, мине тыңла син. Көн кебек ачык – сыер безнеке. Шул йортны алабыз да аерылып чыгабыз.

И с м ә г ы й л ь. Ярар, шулай итәрбез... Сөйләшерсез шунда... Яратам да усалланганыңны! Кил әле! *(Үреләә.)*

Җ ә м и л ә. Ятмале өскә, болай да көчкә сулыйм. *(Яшергән нәрсәләрен чыгарып.)* Ашыйсыңмы тагын?

И с м ә г ы й л ь. Юк, рәхмәт!

Җ ә м и л ә. Ярый... *(Яшереп куя.)* Әйдә, кереп чәй эчик, саруым кайный башлады. *(Исмәгыйль тагы бер кат үрелеп карый.)* Әйдә инде, һаман юк белән...

*Җәмилә белән Исмәгыйль бик авырсынып кына төшәләр.*

## XI

*Минсабир белән Шәрифәнең өе. Кич. Өстәл, артсыз урындыклар, диварда икесенең фотолары, мич.*

*М и н с а б и р өстәл кырыендарак урындыкта итек астына салып утыра. Аның каршында биш пар итек. Ш ә р и ф ә кер уа. Ул мич буена сузылган бауга ике чалбар элеп куя: берсе биш яшьләр тирәсендәге, икенчесе ике яшьләрдәге баланыкы. Шулар янына тагын күкрәк баласының биләүсәләрен чайкап элә. Минсабир үз эшеннән аерылмый гына хатынын күзәткәли. Шәрифә керләр уып бетерә, тиз генә суларны түгеп керә. Аннан тагын әллә нәрсәләр эшләп, әле бер якка, әле икенче якка тыныч кына йөгереп үткәли. Минсабир итегенә төп салып бетерә. Кулына иң кечкенә итекләрне ала. Шуларга карап, үз көенә елмаеп утыра. Шәрифә аңа игътибар бирмәгәч, бер үтеп киткәндә, Минсабир аны, кулыннан тартып, үз янына утырта. Бер кулы белән башын күкрәгенә кысып, икенче кулындагы итекләрне аңа күрсәтә.*

М и н с а б и р *(итекләр белән уйнаклап)*. Боларның астына саласымы икән?! Ничек уйлыйсың?!

Ш ә р и ф ә. Белмим шул!.. Бигрәк тиктормас, кышка чабып китүе дә бар!.. *(Йөзен яшерә.)*

М и н с а б и р. Алты ел яшибез, һаман ояласың! Әти дә, килен тел яшерә, ди...

Ш ә р и ф ә. Ничек инде мин әти

каршында җәелеп китеп сүз куертып утырыйм, ди?

М и н с а б и р. Әйтер сүзең булгач, нәрсәсе бар аның?

Ш ә р и ф ә. Аңлашабыз бит әле. Кирәген әйтәм мин...

М и н с а б и р *(канәгать сулап куя, аны тагы бер кат коча)*. Каяле! *(Кулындагы итекләрне каршында үсә бару тәртибендә тезелеп торган итекләр рәтенә куя. Шуларга карап, икәү елмаешалар. Үрелеп өстәл астыннан гармун ала.)* Китмә, утыр!

Ш ә р и ф ә. Нишлисең? Минем камыр куясым бар...

М и н с а б и р. Куярсың, качмас. Бераз янымда утырып тор инде!

Ш ә р и ф ә. Әллә гармун уйнарга җыендыңмы? Малайларны уятасың...

М и н с а б и р. Курыкма, уянмаслар, мин тыныч кына!

*Минсабир мөмкин кадәр тыныч итеп яраткан көен уйный. Шәрифә аңа карап, елмаеп утыра. Минсабир җырлый башлый. Аның тавышы ишетелми дә диярлек, әйтерсең лә ул эченнән җырлый, ә кайбер авазлар ялгыш кына тышка яңгырыйлар, аерым сүзләрне генә аңларга мөмкин.*

М и н с а б и р.

Тимер чана карны яра
Бу йөрәгем ник яна шул?
Бу йөрәгем ник яна?
Бу йөрәгем белеп яна,
Җаныем, бәгърем,
Сөйгәнем ятка кала...

Ш ә р и ф ә. Ник һаман шул бер җырны җырлый torгансыңдыр?.. Җыр беткәнмени...

М и н с а б и р. Яратам!.. Ә сиңа ошамыйммы?

Ш ә р и ф ә. Әллә нинди ул...

М и н с а б и р. Нинди?

Ш ә р и ф ә. Белмим... Әллә ничек, күңелне борчып тора...

М и н с а б и р. Башкасына күңелем ятмагач, нишлим инде?!. *(Паузадан соң.)* Мин иртәгә урманга барам.

Ш ә р и ф ә. Урманга? Нигә?

М и н с а б и р. Утын әзерлибез! Тиздән бит кыш башлана, малайларны салкын өйдә яткырып булмас!

Ш ә р и ф ә. Соң, аны алданрак әйтсәң, булмый идеме? Җырлашып утырабыз... Камырым да куймаган. Иртәгә ашарга җыеп җибәрергә кирәктер бит.

*Шәрифә торып китә. Минсабир тагы бер кат шул ук куплетны нәкъ шулай ук җырлый.*

**XII**

*Урам. Й о л д ы з н ы җитәкләгән Җ ә м и л ә белән төрле төенчекләр, мендәрләр, кәрзин белән тавыклар, тагын әллә нәрсәләр күтәргән И с м ә г ы й л ь үтеп бара. Җәмилә бик канәгать күренә.*

Җ ә м и л ә. Әйдә, хайван, әйдәле!

Й о л д ы з. Атлыйм, атлыйм... Тизрәк ярамый... Теләсә ничек йөрергә безгә килешми. Матур итеп, уйнаклап кына атлап барырга кирәк. Сиңа карап, хуҗаңның дәрәҗәсен белердәй итеп, башны горур, карашны җиңелчә битараф итеп...

Җ ә м и л ә. Әйдә, җаным, әйдә!

Й о л д ы з. Болар мине кая алып баралар икән соң? Әллә дөньяның берәр читен матурлап бетергәннәр дә лаеклы дип санаганнарны әкренләп шунда күчерә башлыйлар микән? Көтүне Үри буена күптән чыгарганнары юк, шул тирәне бизәп яттылар микәнни?!. Менә мине хәзер Машка күрсә иде!..

Җ ә м и л ә. Әйдә, атла!

Й о л д ы з. Атлыйм гынамы соң!..

*Йолдыз белән Җәмилә китә.*

## XIII

*Минсабир белән Шәрифәнең өе. Ш ә р и ф ә утын күтәреп керә. Идән уртасында утыннары чәчелә. Ул тиз генә алдагы өйнең ишеген ачып карый, бала уянмаган, йоклый. Утыннарын җыя. К ә р и м ә килеп керә.*

К ә р и м ә. Ни хәлләрегез бар, сеңлем?

Ш ә р и ф ә. Апа, әйдә, утыр! Әйбәт кенә. Белмим нәрсәдер, көнозын кулымда тоткан әйберем тормый.

К ә р и м ә. Минсабир кая соң, эштәме?

Ш ә р и ф ә. Урман салалар... Апа, нәрсә булды? Нигә елыйсың? Бер-бер хәл булмагандыр бит?

К ә р и м ә. Тизрәк өйдән чыгып качтым, әти күрмәсен дип...

Ш ә р и ф ә. Нәрсә булды?

К ә р и м ә. Тегеләр, башка чыктылар бит... Йолдызны ияртеп чыгып киттеләр...

Ш ә р и ф ә. Туктале, ничек инде...

К ә р и м ә. Килеп, ярты ел тормаган килен бура хәтле сыерны ияртеп чыгып китте... Әти, бичара, миннән качып, абзарда елый... Мин тизрәк сезгә кердем...

Ш ә р и ф ә. Анда ук, мәйтәм, нишләп бүген күңелем тыныч түгел... Елама әле син...

К ә р и м ә. Еламыйсы иде дә бит... Башта маслозаводтан алып кайткан нәрсәләрен тезмә башында качып ашап яттылар... Исмәгыйль каян табып алып кайткандыр шуны. Бер күрүдә ошатмадым... Әткәйнең бит исәнлеге юк. Минем дә, торфларда йөреп...

Ш ә р и ф ә. Апа, елама әле син... Башмак танагыз бар, язга сыер булыр, Аллаһы боерса, Йолдыз барыбер кышка ташлатып торыр иде...

К ә р и м ә. Башмакны кышлык иткә дип тора идек бит...

Ш ә р и ф ә. Хәзер нишлисең инде. Әйдәле, чәй янына утыр... Нишләптер вакыт-вакыт күз алларым караңгыланып, хәлем китеп тора бүген... Малайлар, әти кайтмыйча ашамыйбыз, диләр. Алдап кына ашаттым үзләрен, уйнап утыралар. Әйдә утыр әле, чәй эчәбез. *(Урындыкта торган гармунны алып.)* Менә, аталарының гармунын шулай сөйрәп йөртәләр, уйныйлар, имеш. Орышам да, үзем күрмәгәндә, барыбер алалар... Әйдә, утыр...

*Шәрифәнең хәле китеп, кулыннан гармуны чыжылдап сузылып төшә. Ә н с ә р килеп керә.*

Ә н с ә р. Мөмкинме... Исәннәрмесез...

Ш ә р и ф ә. Әкрен генә, Аллага шөкер...

Ә н с ә р. Синеке, хәзер кайтып җитә, самоварын куя торсын, диде...

Ш ә р и ф ә. Ә? Самовармы? Кайнаган самоварым, хәзер яңартам... Ашарга да пешкән... *(Нидәндер каушап, нишләргә белми тегендә-монда таптанып ала.)* Әйдә, син дә утыр, бергәләп чәйләр эчәрбез...

Ә н с ә р. Юк, рәхмәт. Өйдә дә көтәләрдер...

Ш ә р и ф ә. Ул үзе кая калды сон әле, нишләп аерылды?

Ә н с ә р. Арбага... Урманда... Арбага салганда бүрәнә ычкынып, аңа беразэләгеп китте...

Ш ә р и ф ә *(урындыкка утыра)*. Кайсы җиренә?

Ә н с ә р. Ул ничек китеп өлгермәгәндер... Әллә ничек, көтмәгәндә генә ычкынып китте дә тәгәрәп...

Ш ә р и ф ә. Кайсы җиренә? Каты эләктеме, дим? Кая ул?

Ә н с ә р. Куркыныч түгел, дигән була. Хәзер дә әле, әйдә, өеңә кадәр илтәм, дим, кирәкми, ди... Мин күрмичә дә калдым. Тәгәрәп, башына эләгеп киткән... Ул хәзер, медпунктка сугылам да кайтам, диде...

Ш ә р и ф ә. Әстәгъфирулла... Нәрсә генә... Апа, балалар белән калып тор әле...

*Шәрифә чабып чыгып китә. Әнсәр дә, бераз нишләргә белми торгач, чыга.*

**XIV**

*Урам. Җил өрәңге яфракларын очыртып йөртә. Урам башыннан М и н с а б и р килә. Ул ава-түнә атлый, абынып китә, бер тезенә тезләнә.*

М и н с а б и р. Тимер чана... карны яра... бу йөрәгем... ник яна шул... Чәчләренә йөзеңне чумырып, бер күкрәк тутырып сулаудан рәхәте бармыни соң?!.

*Минсабир тора-атлый килә. Аңа эссе, фуфайкасын салып ташлый. Тагы абынып егыла.*

М и н с а б и р. Бу йөрәгем... ник яна... Шомырт кара, ефәкмени ялтырап торган чәчләреннән сыйпап, башын күкрәгеңә кысып, төне буена селкенергә дә кыймый ятудан да рәхәтрәк нәрсә бар?

*Минсабир тора, тагын алга атлый. Өс киемен бөтенләй салып ташлый, ак күлмәктән генә кала.*

М и н с а б и р. Иртән торып, чәчен тарап, үреп утырганыннан да самимирәк нәрсә күргәнең булды синең?!. Шуннан башка бу дөньяның тагын нинди рәхәтләре таныш сиңа?.. Толымнары! Һавадагы карлыгач канатымыни – кагыналар, шомыртмыни – чем-каралар, ефәк тасмалардан үргәнмени – ялтырыйлар... *(Алга атлый.)* Бу йөрәгем... белеп яна... Сөйгәнем... ятка кала...

*Йөзе белән җиргә барып төшә, көйләп барган көе өзелә.*

*Урам башында Ш ә р и ф ә пәйда була, ул Минсабирны күреп алып, тизрәк аның янына йөгерә. Аны әйләндереп сала.*

Ш ә р и ф ә. Ходаем, нәрсә инде бу?.. Соң... Минсабир... Самоварым куйган. Ашарга пешкән. Нәрсә инде бу? Ничек шулай була инде?.. Газинур, әти кайткач, мине гармунда уйнарга өйрәтә, дип, сине көтеп утыра. Болай булмый бит инде...

*Шәрифә нишләргә белми, елый, аны аңына китерергә тырыша. Урам башында Ә н с ә р күренә. Ул чабып килеп җитә. Минсабирны җилкәсенә салып, өйләренә алып кайта. Сәкегә яткыралар. Шәрифә аның кулын үзенең битенә кысып, елап утыра. Әнсәр нишләргә белми, таптана. Шәрифә Минсабирның кулын битеннән ала, аны күкрәгенә куймакчы була, кул шуып төшә, салынып кала. Шәрифә моның нәрсә аңлатканына ышанырга теләми, читләшә. Чигенеп барганда, ул Әнсәргә барып терәлә, борылып, аның күзенә карый, Әнсәр карашын яшерә.*

*Акрын гына бөтен булган туган-тумача, әти-әниләр, кода-кодагыйлар, күрше-күлән, таныш-белешләр кереп тула. Дога кылалар. Ирләр Минсабирны күтәреп алып чыгып китә. Алардан соң хатын-кызлар да юк була. Шәрифә өйдә берьялгызы кала. Ул әле мич буенда бауда эленеп торган чалбарларга күз төшерә, әле дивар кырыенда тезелеп торган биш пар итеккә, әле читтә торган гармунга. Аннан ул иң зур итекләрне мич башына алып куя, гармунны чиккән тастымал белән томалый. Өй шундый зур, дөнья шыксыз киң, һәм шул дөньяда ул берьялгызы кебек тоела.*

*Х ә с ә н ш а, С ә я р, С ә л и м керә.*

Х ә с ә н ш а. Кызым, менә без киңәштек тә шундый уйга килдек. Монда берүзең терлек тә асрый алмассың, балаларыңны үстерергә дә авыр булыр. Кодаларның үз хәлләре хәл. Җиде ят арасында торып калсаң, дөрес булмас. Ни дисәң дә, безнең янәшәдә булсаң, барыбыз да хәлдән килгәнчә булышып торыр идек. Көзе дә бик матур. Кызым, әйдә, йорт-җиреңне Кызылсуга күчерик. Менә абыеңнар балта эшенә оста, озакка сузмаслар. Бер дә булмаса, бер кыш кына бездә дә чыгарсыз... Миннән киңәш шул, кызым. Гаиләгездә хәзер син баш, син муен – ничек әйтәсең, шулай була.

Ш ә р и ф ә *(йөзен яшереп)*. Ярый, эти...

*Сәяр белән Сәлим әйберләрне җыя башлыйлар.*

## XV

*Кибет каршында. А р с л а н белән Ә м и р яшертен генә аракы эчеп торалар. Әмир кып-кызыл булып чыккан.*

А р с л а н. Әйдә, җиппәр! *(Рюмка суза. Әмир эчкәч, кабымлык биреп.)* Мә...

Ә м и р. Син күрдеңме соң әле?

А р с л а н. Нәрсәне?

Ә м и р. Шәрифә кире кайткан...

А р с л а н. Күрдем... Дөмеккәнме теге Дума хәерчесе?

Ә м и р. Дөреслек бар ул...

А р с л а н. Нинди дөреслек?

Ә м и р. Соң, теге вакытта бер дә юкка ике ел ярымга утыртып куйдылар бит...

А р с л а н *(эчеп куя)*. Бөтенләй үк бер дә юкка түгел инде...

Ә м и р. Бар нәрсә дә хатын-кыздан чыга. Шулар әллә кемнәрне җыеп яталар. Үзебезнең авылныкылар ярамый аларга. Әнә, хәзер нәрсә, бер өй бала-чага... Күп сикерсәң, шулай була ул...

А р с л а н. Хатын-кыз түгел, әнә, шуның ише ир була белмәгәннәр дөньяны бутап ята.

Ә м и р. Кая, кем?

А р с л а н. Әнә, Москвич пальтолардан, мин сиңа әйтим...

Ә м и р. Ә, падлис... Ничек кыланып йөри, ә... Әллә кем булган. Ну, берәр сәбәп табып, муен тамырына ямамасаммы!

А р с л а н. Булмас шул.

Ә м и р. Карап кына тор син!

*М а р а т керә, ул да бераз кызмача.*

Ә м и р. О-о, Марат! Сәлам, туган!

М а р а т. Сәлам! Нишләп торасыз? Әллә кибет биклеме?

А р с л а н. Акчалыга ачык!

Ә м и р. Арслан, әйдә, Маратка берне тутырып сал әле!

А р с л а н. Әйдә, күтәреп куй!

М а р а т. Бәйрәм мәллә сездә?

Ә м и р. Иреклегә көн дә бәйрәм, көн дә туй инде!

М а р а т. Ярый, сезнең исәнлеккә! *(Эчеп куя.)*

Ә м и р. Синең каян кайтышың сон әле бу?

М а р а т. Районнан. Концерт, аннан банкет, көчкә кайтып җиттем... Анда буталып, балаларга берәр нәрсә алырга онытканмын. Моннан булса да кереп алыйм, дидем...

А р с л а н. Эти куян күчтәнәче алып кайта, дип көтеп утыралар инде...

М а р а т. Соң...

Ә м и р. Арслан, әйдә, сал инде син!

А р с л а н. Каян алып салыйм соң?

Ә м и р. Бетте дәмени?

А р с л а н. Әллә син төпсез шешәдән чөмерәбез дип белдеңме?

Ә м и р. Ярар, менә Марат дус хәзер

алып чыгар. Аның безгә бурычы да бар бит әле!

М а р а т. Минем? Сезгәме? Нинди бурыч тагын?

Ә м и р. Кара, ничек авызын бөрә, оныткан! Соң, теге юлысы безне синең дускаең аркасында рәшәткә артына илтеп тыктылар бит...

М а р а т. Ә син нәрсә, кешегә пычак кадарбыз да иректә йөрербез, дип уйлаган идеңме?

Ә м и р. Әгәр дә син теләсә кемне авылда җыеп ятмасаң, берни булмас иде...

М а р а т. Бераз баш белән уйлап эшләргә иде аны... *(Китмәкче була.)*

Ә м и р *(аны пальто якасыннан тотып кала)*. Кая китте?

М а р а т. Җибәр яканы...

А р с л а н. Җибәр, Әмир, тизрәк кайтып, Әминәсенең итәге астына чумсын!

М а р а т. Соңгы тапкыр әйтәм, җибәр дим!..

Ә м и р. Юкса нишләтәсең? Хатыныңа әйтеп, кыйнатасыңмы?!

М а р а т. Җибәрәсеңме, юкмы...

*Марат бераз катырак тартыла, якасы ертылып, Әмирнең кулында кала. А р с л а н белән Әмир шаркылдап көлә башлыйлар.*

Ә м и р. Каян аракыга акчасы булсын моның, әнә, хатыны черек пальто кигезеп җибәргән!

А р с л а н. Аның каравы, Москвич пальто!

Ә м и р. Мә, якаңны! Кәнфитләреңне ал да сыдыр моннан! *(Яканы Маратның йөзенә ташлый.)*

М а р а т. Ах, син, хайван!

*Марат Әмирнең чыраена суга. Әмир көтелмәгән сугудан сузылып ук ята. Ярсыган Марат аны типкәли башлый. Арслан катнашмый, Әмирне котыртып кына тора. Әмир бер мизгелдә Маратның аягын тотып ала, аны чалып ега. Өстенә утырып, котырып, бик явыз итеп кыйный, йөзе белән балчыкка чумыра.*

А р с л а н. Бир, әйдә! Әмир, ныграк сук! Беткән баш беткән!..

*Әмир шул кадәр хәрәкәтләнүдән хәлдән тая, Маратны ташлап, Арслан янына атлый.*

Ә м и р. Кара, шавка, нишли, ә... Падлис...

*Марат янәшәсендә яткан күсәкне күреп ала, аңа сузыла. Соңгы көчләрен җыеп күтәрелә.*

М а р а т. Үтерәм, хайван!

*Марат күсәген күтәреп, Әмир өстенә йөгерә. Ут сүнә.*

## XVI

*Шәрифә өенең җилкапка төбе. К е ч к е н ә коймага бәйләнеп куелган. Ул озак кына, саклык белән тирә-якны күзли, теләсә кайсы җирдән дошманнар килеп чыгар төсле. Карашында сабыйларча җитдилек.*

К е ч к е н ә. Бернинди матурлык та күрмим әлегә. Барысы да шундый ук. Минем монда булганым да бар шикелле. Әни алдады микәнни? Сине чачаклы-чучаклы, матур җиргә алып китәләр, бездән әйбәтрәк яшәрсең, бәхетле булырсың, дигән иде... Әни алдадымы, әллә әнине алдаганнармы? Юк, әнине алдаганнардыр... Ул матур дөньяларында нишләп минем әниемә урын табылмады икән? Әнидән аерылгач, нинди дөнья рәхәт

булып тоелсын инде?.. Тукта, ә ничек минем әнием алдана алсын? Әни бит ул! Мин генә берәр нәрсә күрмимдер, йә булмаса, әле без ул җиргә барып җитмәгәнбездер...

*Җилкапкадан Ш ә й д у л л а , Ә л ф и я , Ш ә р и ф ә керә.*

Ш ә й д у л л а. Менә, Шәрифә, үзең кара. Безгә барыбер итлеккә генә тананы әрәм итү дөрес булмас. Риза булсаң, үгезеңне весага куеп үлчибез дә алмашабыз, веса күрсәткән аерманы инде акчалата түләрбез. Уйла.

Ә л ф и я. Балаларың тәгәрәп үсеп килә, өйдә сөт-катыксыз ярамый, ярты ел асрасагыз, сыер булыр.

Ш ә й д у л л а. Әлегә акчаң булмаса, аерманы соңрак түләрсең, ашыгыч түгел...

Ш ә р и ф ә. Әй, җизни, ни әйтергә дә белмим инде... Бигрәк көтмәгәндә, башым да эшләп бетерми. Әлегә акчам юк та... Чөгендер алырмын, бер-ике гектар, шуны эшләп түләрмен, җизни.

Ш ә й д у л л а. Ярый алайса, килештек. Үгезең көтүдән кайткач, весага бастырырбыз. Безнеке үлчәнгән, шикләнсәң, яңадан алып барып була.

Ш ә р и ф ә. Нинди шикләнү инде ул, җизни? Чөгендер алырмын... Шулай түләсәм генә, көтсәгез, җизни.

Ш ә й д у л л а. Көтәрбез... Безгә ашыгыч түгел. Алма кебек малайларың, сөт-катыксыз ярамый...

Ш ә р и ф ә. Малайлар кич белән сөт эчеп ятарга яраталар шул... Рәхмәт яугыры...

Ә л ф и я. Җизнәңә рәхмәт әйт, сеңлем, минем башыма да килгәне юк, ул барысын да кайгырта...

Ш ә р и ф ә. Ходай Тәгалә исәнлегеңнән аермасын, җизни!..

Ш ә й д у л л а. Ярый, кайтыйк без. Көтүдән соң килербез.

Ш ә р и ф ә. Ярый, җизни!..

Ә л ф и я. Бик сабыр, бик акыллы хайван. Без Кечкенә дип йөртә идек, син үзең кара инде...

Ш ә р и ф ә. Ярый, апа, рәхмәт яусын...

*Әлфия Шәйдулла артыннан китеп бара.*

*Шәрифә белән Кечкенә күзгә-күз карашып калалар. Шәрифә бу хәлгә һаман да ышанып җитә алмый. Ул Кечкенәне картина караган сыман күзләп чыга: аның аяклары да дүртәү, колаклары да икәү, койрыгы да урынында, гомумән, бәйләнерлек җире юк инде, малай, шедевр!*

Ш ә р и ф ә. Кечкенәм минем!.. Курыкма, җаным. Нәрсә аякларыңны терәп бастың?! Әллә берәрсе тияр дисеңме?! Курыкма, без бик матур яшәрбез...

*Шәрифә алъяпкыч чите белән шатлык яшьләрен сөртә.*
*Кечкенәне сыйпый.*
*Ә м и н ә килеп керә.*

Ә м и н ә. Шәрифә... Шәрифә...

Ш ә р и ф ә. Дустым, карале нинди шатлыклы булдык бит!..

Ә м и н ә. Шәрифә, балаларны сиңа китереп торырмын әле... И Ходаем, ничек кенә яшәп бетәрбез?..

Ш ә р и ф ә. Нәрсә булды, нишләдең?

Ә м и н ә. Үтергән бит, үтергән...

Ш ә р и ф ә. Әстәгъфирулла... Кем? Кемне үтергән? Ни сөйлисең?

Ә м и н ә. Марат... Әмирне күсәк белән сугып үтергән... Нишләп туры өйгә генә кайтмады икән соң, әй Аллам?.. Утыртып куялар инде үзен хәзер. Өч бала белән нишләп кенә бетәм инде мин хәзер, йа Ходаем?

Ш ә р и ф ә. Туктале, тынычлан әле. Изалама үзеңне. Милиселәр алып киттеме?

Ә м и н ә. Сельсоветка ябып куйганнар, алып китүләрен көтәләр... Ничек гомер итеп бетәргә кирәк?..

Үземнеке иде бит, үземнеке! Көнләшеп туялмыйлар иде бит. Тегенең янына барган, моның белән булган, дип колак итемне кимерәләр иде. Башкалар янына йөрсә дә, сөеп кенә кайта иде бит ул аннан, барыбер минем юрган астына кайтып ята иде... Күз генә тидерделәр микәнни?.. Балаларны ничек кенә үстерербез, йа Аллам, атасыз нишләп бетәрләр?..

Ш ә р и ф ә. Үсәрләр, Аллаһы боерган булса. Атасыз бала да үлми, ди...

Ә м и н ә. Атасыз бала үлми дә, ата рәхәтен дә күрми, ди шул...

Ш ә р и ф ә. Үсәрләр, Алла теләсә. Барысы да сау-сәламәт – шунысы мөһим. Минем Әлфия апаларның әнә, ничә баласы берсеннән-берсе кечкенә. Сабыйлар, йөгереп кенә йөрергә тотыналар, аяклары шешә, буыннары сызлана. Ничәү өйдә тилмереп утыралар. Безнекеләр тфу-тфу...

Ә м и н ә. Күпмегә утыртырлар икән? Ун еллап кына бирерләрдер шул...

Ш ә р и ф ә. Туктале син, тикшерерләр, белешерләр. Ул Әмирләрнең нинди зимагур икәнен бар да белә. Юкка гына эләгешеп китмәгәннәрдер... Бар кайт син, балаларыңны миңа алып кил. Хәзер мин тиз генә эшләремне бетереп куям. Бар, монда утырып кына берни үзгәрми. Бар...

Ә м и н ә. Ачуланма инде, Шәрифә, ярыймы? *(Китә.)*

Ш ә р и ф ә. Хәзер, берәр нәрсә пешереп тә куям... *(Кечкенәнең бавын сүтә.)* Менә бит, авырткан башка тимер тарак... Әйдә, җаным, әйдә... Хәзер ашарыңа да йолкып салырбыз, алдыңа эчәргә дә куярбыз... Әйдә...

*Шәрифә белән Кечкенә җилкапкадан кереп китә.*

**XVII**

*Чөгендер кыры. Көннең иң эссе вакыты. Ш ә р и ф ә бөгелеп чөгендер эшләп килә. Аның артында бауга тагылган иске тас, тагарак кебек нәрсә, ул томаланган. Шәрифә бераз эшләп бара да, туктап, тасны тартып китерә, янә эшләп китә. Арттан А р с л а н килеп чыга. Ул күпмедер вакыт тыныч кына Шәрифәне күзәтеп бара. Шәрифә баудан тарткач, тагарак Арсланның аягына бәрелеп, туктап кала.*

А р с л а н. Курыктыңмы?

Ш ә р и ф ә. Әллә куркытмакчы идеңме? Нәрсә карап торасың?

А р с л а н. Сокланып торам, бигрәк тырышып эшлисең!

Ш ә р и ф ә. Тырышмыйча гына булмый бит... *(Эшләп китә.)*

А р с л а н. Тукта инде, кая ашыгасың, хәл ал. Сөйләшик бераз...

Ш ә р и ф ә. Вакытым юк, әле печәнгә дә өлгерәсем бар...

А р с л а н. Эш бетми инде ул...

Ш ә р и ф ә. Синеке беткән, ахры, иң кызу вакытта сүз куертасың...

А р с л а н. Бу нинди таслар тактың, нәрсәләр уйлап чыгардың тагын?

Ш ә р и ф ә. Ә син ачып кара.

А р с л а н *(тас өстендәге чүпрәкне күтәреп карый)*. Әстәгъфирулла... Нишләп бу баланы болай тагып йөртәсең?

Ш ә р и ф ә. Ә кая илтим соң мин аны? Персидәтел балалар бакчасы була, балалар бакчасы була, түзегез инде, дип сөйләнә. Никтер әлегә эше күренми.

А р с л а н. Бигрәк авыр инде сиңа, ә? Өч баланы берүзең карап үстерергә. Янәшәңдә ир-атың булмагач...

Ш ә р и ф ә. Өлешеңә тигән көмешең инде. *(Эшләп китә.)*

А р с л а н *(аның аркасына кулын куеп).* Мин әйтәм, яныңда берәр ир заты булса, җиңелрәк булыр иде...

Ш ә р и ф ә *(аның ни теләгәнен аңлап, тураеп, уйнап сөйләшә)*. Сөйләмә дә инде, Арслан абзый!..

А р с л а н. Көчле ир-ат канаты астында булсаң, тел-теш тә тидермәсләр иде!..

Ш ә р и ф ә. Ирсезләргә кадер-хөрмәт юк инде ул...

А р с л а н. Аннан, менә бу ристаннарны аякка бастырырга кирәк бит!.. *(Тастагы баланың өстен ача.)* Әнә бит ничек корсагын киереп ята! Уть, аны! Елмаямы соң?

*Тастагы бала Арсланның йөзенә чаптыра. Шәрифә тыелырга тырышып көлә башлый.*

А р с л а н. Мать якаңны... *(Сөртенә.)*

Ш ә р и ф ә. Улым, шулай ярый димени?! Абыең безне кайгыртып... Үпкәләмә инде, Арслан абзый!

А р с л а н. Ничек сабый балага үпкәлисең ди инде?.. *(Аны кочаклап тота.)* Теләсәң, үз канатым астына сыендырырга да әзер...

Ш ә р и ф ә. Каян килеп безгә шундый хөрмәт, ди ул?! Шаяртма инде!

А р с л а н. Теге вакытта Минсабир килеп чыкмаган булса, үзем өйләнә идем мин сиңа... Бүген ишегеңне элмә, ярыймы?

Ш ә р и ф ә. Усаллар керер бит, куркам!..

А р с л а н. Усаллар кермәс, мин керермен!

Ш ә р и ф ә. Юк, алай йөрмик инде, Арслан абый, кешегә сүз ясап...

А р с л а н. Сүздән курыкма син!

Ш ә р и ф ә. Куркам шул. Мин алай риза түгел, Арслан абый.

А р с л а н. Ә ничек риза?

Ш ә р и ф ә. Әйдә, өйләнешәбез! Сельсоветка барабыз да языльп, туры миңа кайтабыз! Миңа ир, балаларыма ата булырсың! Әйдә, бүген үк барабыз, хәзер үк...

А р с л а н. Син нәрсә?

Ш ә р и ф ә *(көлүен яшерергә тырышып).* Үзең тәкъдим иттең бит! Мин риза, әйдә, өйләнешәбез!

А р с л а н. Кара ничек башын дуракка салып, биттән көлә! Кеше калдыгына өйләнеп йөрергә, кем дип белдең син мине?! Тапкан... Дума хәерчесенең көчекләрен ашатып ятарга башыма тай типкән мәллә минем? *(Тастагы балага карап.)* Монысы да ыржаеп ята. Күрсәтермен әле мин сезгә... Көлдерәм әле мин сезне! *(Китеп бара.)*

Ш ә р и ф ә *(тыела алмый көлә).* Кая киттең инде, Арслан абый?!. *(Баланың өсләрен томалап.)* Качты киявебез, улым! Әй, дөрес тә эшләдең, алтыным! Артына да карамый, тайды!

*Шәрифәгә бераз алдарак, чөгендер буразнасында Минсабирның сыны күренгән кебек тоела. Ул гармунын тартып, яраткан җырын көйләп утырадыр сыман...*

Ш ә р и ф ә. Борчылып ятасыңмы? Шаяртып кына әйттем. Өч бала белән кемгә барыйм да кемгә кирәк инде мин?.. Әнә бит, шундук табан ялтыратты. Болай әле бәйләнеп торган булыр иде... Шаярып кына әйттем, борчылып ятма... *(Тагын эшкә керешә.)* Менә чөгендерне эшләп бетерербез. Танабыз өчен бурычыбызны түләрбез. Язга үзебезнең сыерыбыз булыр, Алла теләсә... Өстәлдән сөт-катык өзелмәс...

*Шәрифә эшләп китә. Минсабир моңланып кала.*

## XVIII

*Төн. Шәрифәнең өе. Берәү тәрәзәгә чиртә. Алдагы өйдән* Ш ә р и ф ә *чыга.*

Ш ә р и ф ә. Бу вакытта... Аллам сакласын... *(Тәрәзәгә килеп.)* Кем бар?.. Кем?.. Зәйнәп?.. Нинди?.. Зәйнәп апа, синме?! Хәзер, хәзер ачам...

*(Барып ишекне ача.)* Апа, нәрсә булды? Бу вакытта нишләп йөрисең?

З ә й н ә п *(кереп)*. Биклә, биклә ишегеңне, артымнан килеп җитәр...

Ш ә р и ф ә *(келәне элеп)*. Кем, абыймы?

З ә й н ә п. Кем булсын инде тагын...

Ш ә р и ф ә. Ул калымда иде түгелме соң?

З ә й н ә п. Бүген кайтты. Сәлим абый белән ызгышканнар, котырып кайтып керде...

Ш ә р и ф ә. Нәрсә булган тагын?

З ә й н ә п. Һәрвакыттагыча инде: Сәяр тиз-тиз эшләргә ярата, Сәлим төпчелли, җиренә җиткереп эшли. Сәяр нәрсәдер ясап куйган, Сәлим, күрәсең, аны сүтеп, киредән җыйган.

Ш ә р и ф ә. И Ходаем, ике туган юк-бар өчен кеше көлдереп...

З ә й н ә п. Соң, Сәлимгә ни ярамаган инде, калымда да кыланмаса... Имеш, кул китә, җиренә җиткереп эшләргә кирәк...

Ш ә р и ф ә. Әстәгъфирулла!.. Син шулай яланаяк, өстеңә дә кимичә урам буйлап пычрак ерып килдеңме?.. Әйдә, утыр тизрәк, туңып беткәнсең бит. Хәзер самоварны яңартам...

З ә й н ә п. Кая анда өскә киеп торасың, эләктереп алганчы, тизрәк чыгып чаптым.

Ш ә р и ф ә. Балалар соң?..

З ә й н ә п. Елап калдылар инде. Күз алдында мин булмасам, тынычлана ул. Кычкырып сөйләшмә, балаларны уятасың, дигән идем, шул ярамады, китте тузынып... Эчсә, бер акылы калмый инде мескенкәйнең. Синекеләр йоклыймы?

Ш ә р и ф ә. Йоклыйлар...

*Ишекне тартып караган, аннан шакыган тавышлар, ниндидер ырат мыгырдаулары ишетелә.*

З ә й н ә п. Шул, шул килеп җиткән... Ачма, кыйнап үтерә...

Ш ә р и ф ә. Балаларны уята бит бу... Бар, алдагы өй идән астына төш, бар... Мә, толыпны ал, салкын тидерерсең тагын.

З ә й н ә п. Кертмә инде шуны, Шәрифә.

Ш ә р и ф ә. Бар, дим, шыңшыма...

*Шәрифә Зәйнәпне алдагы өйгә кертеп җибәрә. Кулына тимер кисәү ала. Ишек янына килә.*

Ш ә р и ф ә. Кем бар?.. Кем?.. Абый, синме? Нишләп йөрисең? Без йоклыйбыз, бар, кит... Шакыма, балаларны уятасың. Йөрмә монда...

*Ишеккә каты итеп шакыгач, келәне ычкындыра. С ә я р ишектән башын тыга, Шәрифә аңа керергә ирек бирми...*

Ш ә р и ф ә. Нәрсә кирәк бу вакытта?

С ә я р. Минеке кая?

Ш ә р и ф ә. Синеке монда нишләп йөрсен, ди? Бар кайт, өеңдәдер...

С ә я р. Өйдә юк, чыгып чапты бит... Чыгар әле монда, бәреп кенә үтерим...

Ш ә р и ф ә. Кычкырма, балалар йоклый. Кемне чыгарыйм?

С ә я р. Зәйнәпне чыгар.

Ш ә р и ф ә. Каян килеп монда Зәйнәп апа булсын, ди? Ике күзең акайган, кешегә күренергә оялыр идең ичмасам...

С ә я р. Кая, керим әле... *(Ишекне тартып ача, Шәрифә чүт кенә урамга чыгып очмый кала.)* Кая ул?

Ш ә р и ф ә *(алдагы өй ишеге янына басып, тимер кисәү белән яный)*. Балалар янына аяк та атлатмыйм. Сине түгел, аталарын да исерек килеш күргәннәре булмады аларның... Якын гына килеп кара, бәрәм дә үтерәм...

С ә я р. Абыеңнымы? Ә, сеңлем?

Ш ә р и ф ә. Син бит, туктале, сеңлемнең өч баласы, йоклыйлардыр,

аптыратып йөрмим, димәгәнсең, бәбәгеңне терәп килеп җиткәнсең...

С ә я р *(аптырап кала, урындыкка барып утыра)*. Кара, минем белән ничек сөйләшәләр. Тегендә абый канны кыздырып җибәрде, кайтып кердем, өйдә сүз әйтергә дә ярамый, хәзер монысы...

Ш ә р и ф ә. Абый белән нәрсә бүлешә алмадыгыз тагын?

С ә я р. Соң бит һаман төпчелли, бер мунчаны бер атна эшлибез. Мин бер нәрсә ясап кына куям, карыйсың, шуны төзәтеп ята. Икенчесен ясыйм, тагын... Мин бер атна эчендә ике калым эшлим, бу һаман шул чувашның мунчасында казына, ярамаган аларга тагын... Әле миңа: «Мин әти белән кара-каршы бура бураганда, син астыңа пес итеп йөри идең, молокосос, өйрәтмә!» – ди. Миңа шулай, ди, күз алдыңа китерәсеңме, өч бала атасына...

Ш ә р и ф ә *(үзе сизмәстән)*. Соң, шулай бит инде...

С ә я р. Син дә, кызый... Булса соң? Ул аны каян хәтерли? Миннән ике яшь кенә олы бит... Ундүрт яшемнән кулымнан балта төшкәне юк, мин эш җаен белмим буламы?..

Ш ә р и ф ә. Хатыныңның монда ни катнашы бар?

С ә я р. Аңа бераз кирәк... Калымга китеп торсаң, өйдә кемнең хуҗа икәнлеген онытa башлый, хәтерен яңартмыйча ярамый... Әйдә, бер чикушкаңны чыгар әле...

Ш ә р и ф ә. Каян килгән, ди?

С ә я р. Сиптермә, син запассыз тормыйсың... Чыгар, берне җибәрәм дә китәм. Әнә, капкаң да аварга тора, иртәгә килеп ясармын...

Ш ә р и ф ә *(тимер кисәү белән янап)*. Кузгаласы булма... *(Яшергән җиреннән чикуш аракы чыгарып, стакан, чуеннан бер бәрәңге белән телем икмәк китереп, каршына куя.)*

С ә я р. Менә рәхмәт, сеңелкәш! *(Ярты чикушны салып эчә, кабып куя.)* Калганын иртәгә килгәч бирерсең. Яшереп куй, балалар күзенә күренмәсен... Ух! Минем шомыртым кая соң? Идән астындамы? Дөрес эшләгәнсең, үзем дә бераз ярып, идән астына салып торырмын дигән идем!.. Иртәгә мин торган җиргә кайтып ашарга әзерләсен, әйт. *(Баса.)*

Ш ә р и ф ә. Ярар... Әй Аллам, урам буйлап ялан өс чабып йөрмәсәгез... *(Москвич пальто алып бирә.)* Мә, йөрмә күлмәктән...

С ә я р. Каян килде бу?

Ш ә р и ф ә. Минсабирныкы. Күптән сиңа бирергә дип торам, барыбер әрәм генә булып ята...

С ә я р. Рәхмәт, сеңелкәш!.. Ярый, иртәгә киләм...

Ш ә р и ф ә. Килерсең, бар...

*Шәрифә Сәярны озатып, келәне элеп куя. Алдагы өйдән З ә й н ә п чыга.*

З ә й н ә п. Киттеме?

Ш ә р и ф ә. Китте...

З ә й н ә п. И җаным, бераз эчсә, бер дә акылы калмый инде... Ярый, мин дә кайтыйм...

Ш ә р и ф ә. Тукта инде, кайтып йокласын хет...

З ә й н ә п. Хәзер куркыныч түгел инде! Шомыртым, диде бит! Тынычланган, димәк!.. Ул бит бик ярсыганда, ачуын чыгарыр өчен генә. Янәшәсендә хатыны булганда, ярсуын басар өчен кемне эзләп йөрсен инде, кая барсын?.. Кырысланса да, үземнеке бит... Кылана гына ул, усал булып күренергә тырыша. Беркөн мунчадан койрыгы пешкән мәче кебек атылып чыкмасынмы, нәрсә булган дип торам, җен күрдем, ди. Кереп карасак, лампа яктысыннан үз шәүләсе төшкән икән! Әй гарьләнде, мескенкәем!.. Йомшак күңелле ул. Барысы да чегән кебек кара дигәндә, ул бит, әнә, шомыртым, ди!.. Кайтыйм инде мин. Рәхмәт сиңа!

Ш ә р и ф ә. Бар, саграк бул инде, артыгын әйтеп ташлый күрмә.

З ә й н ә п. Иртәгә уятып җибәрермен, капкаңны ясар.

Ш ә р и ф ә. Ярый, рәхмәт!.. *(Зәйнәпне озата.)*

## XIX

*Шәрифәнең өе. Әлфия белән Шәйдулланың унөч-ундүрт яшьләрдәге* Г о с м а н *атлы сукыр малайлары тәрәзә янында урамнан килгән тавышларны тыңлап утыра.* Ш ә р и ф ә *килеп керә.*

Г о с м а н. Апа, синме?

Ш ә р и ф ә. Мин, акыллым. Малайлар кая?

Г о с м а н. Урамга чыгып чаптылар...

Ш ә р и ф ә. Көнозын берьялгызың утырасыңмы?

Г о с м а н. Мине дә алып чыкмакчылар иде, үзем калдым... Апа, мин аларга кызыл билле прәннек бирдем.

Ш ә р и ф ә. Әй, акыллым, үзең ашыйсың калган.

Г о с м а н. Мин бит аларны еш ашыйм, апа. Әти гел алып кайтып тора. Апа, ул прәннекне нигә кызыл билле дип атаганнар?

Ш ә р и ф ә. Кызгылт төстә булгангадыр, акыллым...

Г о с м а н. Бар да кызыл да кызыл, диләр. Нindirәк була соң ул кызыл төс?

Ш ә р и ф ә. Кызылмы? Җылы төс ул... Син соң, аз гына да күрмисеңме, акыллым?

Г о с м а н. Төпсез чиләк куеп, кояшка карасам, бераз яктылык күрәм!.. Беләсең бит инде, апа, минем күзләрем чәчәктән шулай булып калган. Күрше әби кереп караган да, сукырайганмын... Чәчәк вакытында балага карарга ярамаганны белмәде микән ул әби?

Ш ә р и ф ә. Белмим шул, акыллым, әйталмыйм...

Г о с м а н. Апа, ә урамнан нинди көй ишетелә ул?

Ш ә р и ф ә. Көй түгел, ирләр такта яралар, пычкы тавышы ул...

Г о с м а н. Пычкылар шулай моңланамы икән, әллә агач сыкранамы?.. Бигрәк моңсу көй бит апа... *(Пычкы көенә җырлап җибәрә.)*

Г о с м а н. Мин әти белән әнигә үпкәләдем бит әле, апа.

Ш ә р и ф ә *(яшьләрен сөртеп)*. Нигә?

Г о с м а н. Мин бит аларның апа белән абыйны чирлеләр йортында калдырып кайтырга киткәннәрен беләм. Ә мине нишләптер алып китмәделәр, калдырдылар. Сыкранып ятмагангадыр инде... Абый белән апа йөри алмый, буыннары шешә иде, мин күрмим – шулай көннәр буена сөйләшеп утыра идек өчәү. Алар миңа тирә-якта ни барын сөйләп бирәләр, мин тыңлыйм. Апа шигырь белән сөйләргә ярата торган иде... Хәзер ялгызым нишләп бетәм инде мин?..

Ш ә р и ф ә. Аларны бит дәваларга алып киттеләр, анда аларга җиңелрәк булачак...

Г о с м а н. Белмим шул, җиңелрәк булырмы икән?..

Ә л ф и я *(атылып керә, үзе елый, үзе шатлана)*. Исән-сау гына тордыгызмы? Әй, сеңелкәш, гөнаһ кыла яздык бит...

Ш ә р и ф ә. Кайтып та җиттегезме, апа?

Ә л ф и я. Кайттык. Әле дә ярый Ходай Тәгалә саклап калды.

Г о с м а н. Апа белән абыйны урнаштырдыгызмы, әни?

Ә л ф и я. Кире алып кайттык, балам, өйдә алар... Ходай Тәгалә саклады... Палатага кертеп яткырдык кына үзләрен, елапмы елыйлар. Икәүләшеп: «Кошлар да бит ...» – дип, шигырь әйтеп елыйлар сабыйлар. Коридорга чыккач, җизнәң белән икәүләшеп

үкерепме үкерәбез. Аннан җизнәң: «Күрәсең, Ходай Тәгалә безгә шулай кушкандыр», – дип, алып чыктык та үзләрен, кайтып киттек. Дүртәүләшеп юл буена елап кайттык... Ходай Тәгалә саклады, гөнаһ кыла яздык...

Ш ә й д у л л а *(килеп керә)*. Исәннәрмесез!

Ш ә р и ф ә. Исәнме, җизни!..

Ш ә й д у л л а. Балалар ничек, исән-саулармы?

Ш ә р и ф ә. Аллага шөкер!

Ш ә й д у л л а. Ярый!.. Әлфия, әйдә инде. Балалар, ашыйсыбыз килә, диләр. Умач булса да уып сал, тилмереп утыралар сабыйлар...

Ә л ф и я. Кайтабыз, кайтабыз...

Ш ә й д у л л а. Әйдә, улым, апаң белән абыең сине югалканнар, Госман кая дип, борчылалар.

Г о с м а н. Әти, мин Газинур белән Марска кызыл билле прәннек бирдем!..

Ш ә й д у л л а. Дөрес эшләгәнсең, улым, мин сиңа тагын алып кайтым! Ярый, исән-сау торыгыз! Әйдә, улым... *(Госманны алып чыгып китә.)*

Ә л ф и я. Ходай Тәгалә гөнаһтан саклап калды...

Ш ә р и ф ә. Аллага шөкер инде!..

Ә л ф и я. Ярый, кайтып ашатыйм үзләрен...

*Шәрифә Әлфияне һәм Шәйдулла белән Госманны озата чыга.*

**XX**

*Шәрифә йортының җилкапка төбе. Көз, баткаклык... Иске арбага җигелгән* М о н г о л *капкага бәйләнгән. Ул бик картайган, күзләрендә ак таплар, тән торышында ниндидер хәлсезлек, битарафлык.*

М о н г о л . Октябрь... Аннан – ноябрь… Аннан – декабрь... Шуннан соң – гыйнвар... Һаман шул ук айлар... Һаман шул бер куласа... Алаша булуларың бер дә кызык түгел икән шул... Башкалар шатлыгына куанып яшәсәң генә... Көннән-көн томанлана. Минем күз алдымда гына шулаймы, әллә дөньясы томанга чума барамы? Эх, күзләрнең махы бирә башлавыдыр шул... Бу бит аз гына да кызык түгел: дөнья матурланып, бизәкләнеп, яктырып китәр, ә без тәки күрми калырбыз... Шулай булыр микәнни? Кызганыч, күз кырые белән генә карап каласы иде... Ярар... Нишләтәсең... Без күрмәсәк, балалар күрер... Шулай да, алашага ничек тә бер инде...

*Ш ә р и ф ә белән М ә ү л ә җилкапкадан керәләр.*

Ш ә р и ф ә. Кереп, чәйләр эчәсе иде, Мәүлә абзый!..

М ә ү л ә. Юк, киленкәй, рәхмәт, кереп торырга вакыт тар... Мунчаларны калдырдым, хәзер башка йортларга да керәсем бар. Кызылсуда кап сугучылар байтак, үзең беләсең...

Ш ә р и ф ә. Кирәк бит, Мәүлә абзый. Утынга урманын булса да бирәләр...

М ә ү л ә. Шулай... Малайлар үсеп беткәннәрдер инде?

Ш ә р и ф ә. Өчесе дә мәктәптә... Шулар суга инде ул капны... Нәрәт бирәм үзләренә, нурмы эшләмичә, уйнарга чыгармыйм, шулай чиратлап сугалар... Кая китәсең, үзең генә өлгереп җитеп булмый... Безнекеләр ничек соң анда?

М ә ү л ә. Әкрен генә... Картлар картаялар... Исмәгыйльләр Үзбәкстанга китәргә җыенып йөриләр. Килен һаман шулай тынгылык бирми аңа... Кәриманең саулыгы бөтенләй бернәрсәгә ярарлык түгел... Сиздермәскә тырышса да, күренә. Торфта йөргәннәре чыга балакайның... Минем Әнсәр калага китте, шунда кайнаша... Минсабирның каберен карап, чистартып торабыз...

Ш ә р и ф ә *(яшьләрен сөртә)*. Бу соң, Монголмы?

М ә ү л ә. Шул...

Ш ә р и ф ә. Йа Аллам... *(Чабып кереп китә.)*

М о н г о л . Кем ул? Әллә Шәрифә киленме? Тавышы бигрәк җитдиләнгән, тәмам ныгып җиткән кызый...

Ш ә р и ф ә *(ипи катысы алып чыгып, Монголга каптыра.)* Мәле, җанашым! Танымыйча да торам бит үзеңне!

М о н г о л . И-и! Рәхмәт, киленкәй!

Ш ә р и ф ә. Мәүлә абзый, без дә шул чаклы картайдык микәнни? Гомер бигрәк тиз үтә икән?

М о н г о л . Әйтмә дә инде, әле кайчан гына үзеңне Думага җилләтеп алып кайткан идем шикелле...

М ә ү л ә. Сез яшьләргә гомер узу турында уйлау иртә әле, иң өлгергән чагыгыз. Әле сезнең күрәселәр... Китик без. Әле кайчан кайтып җитәбез, хәзер титаклап кына йөрибез бит...

Ш ә р и ф ә. Чәйләр эчеп чыгасы иде...

М ә ү л ә. Рәхмәт, сеңлем, башка юлы...

Ш ә р и ф ә. Ярый алайса... Күргән-белгәннәргә сәламнәр әйтегез...

М о н г о л . Ярый, хуш, киленкәй...

*Арба тәгәрмәче сыкрап кына кузгалып китә. Шәрифә алар артыннан күзәтеп кала. Ә м и н ә килеп керә.*

Ә м и н ә. Кем ул китеп бара?

Ш ә р и ф ә. Мәүлә абзый, кап сугарга мунчалалар китерде...

Ә м и н ә. Ә-ә. Безгә дә керер инде. Карале, малай, кичә Мамыктан кайтышлый сугылган идем, өйдә очратмадым үзеңне. Мамык кибетенә кызыл костюм-чалбар кайткан, синең Мөдәррисеңә таман гына була инде. Бар әле, малай, соңламыйча гына барып кайт әле...

Ш ә р и ф ә. И Аллам, палучка да алмаган бит, акчам җитеп бетмәс шул. Кемнән генә сорап торыйм икән?..

Ә м и н ә. Фуат абзыйларга кереп кара, алар акчасыз тормый. Ярый, малай, анысын чамала инде. Мәүлә абзый безнең урамга борылды, кайтыйм мин. Бар, бар, басып торма, кереп чык... *(Китә.)*

Ш ә р и ф ә. Чиләкләремне дә ала барыйм әле, суга да төшеп менәрмен... *(Кереп китә.)*

## XXI

*Фуат абзыйларның өе. Мич кадәрле М ә л и к ә апа кызыл сандык өстендә тирләп-пешеп, авыр сулап, шикәр шакмагын чәенә манып, аны шапырдатып суырып, тәмам интегеп чәй эчеп утыра. Ишеккә шакыйлар. Мәликә апа тончыга.*

М ә л и к ә *(ямьсез авазлар чыгарып)*. Кем бар?

Ш ә р и ф ә *(кереп)*. Исәннәрдәмесез!..

М ә л и к ә. Һәрвакыттагыча инде, ярый, кер... Менә тәмам җәфаланып беттем, Фуат әнә шул нәрсәне алып кайтып элде дә. *(Стенадагы сәгатькә күрсәтә.)* Көннәр буена келт тә келт... Үзәкләремә генә үтә дә инде... Бер тынычлык юк...

Ш ә р и ф ә. Шулайдыр инде. Фуат абзыйның хәлләре ничек соң?

М ә л и к ә. Аңа нәрсә, ат кебек таза, йөри дөнья җимертеп. Менә минем бер сызламаган җирем юк. Буынnарым сулык-сулык итеп тора.

Ш ә р и ф ә. Мунчада бал белән уып, чабарга кирәк...

М ә л и к ә. Кирәк тә бит, кем уа соң аны...

Ш ә р и ф ә. Мәликә апа, мин бер йомыш белән кергән идем...

М ә л и к ә *(ишетмәгән булып)*. Аннары эссе мунчада чыдый алмыйм бит хәзер. Зиһенем тарала, аңым җуя башлыйм. Абзаң саклап кына тора...

Ш ә р и ф ә. Шулайдыр... Мәликә апа, кызлар Мамык кибетендә кызыл костюм-чалбар күреп кайтканнар, минем Мөдәррисемнең мәктәпкә керергә өстенә начар иде... Палучка шул көннәрдә булырга тиеш...

М ә л и к ә. Палучкаңнан ал, кызым, балаларны кеше арасында кимхур итәргә ярамый. Бүген син аларны карыйсың, иртәгә алар сине... Олылар киңәшен тыңла, балам! Палучкаңнан ал!

Ш ә р и ф ә. Үзем дә шул фикердә дә. Палучканы көтеп торсаң, костюмны сатып җибәрерләр шул, өлгермәм дип куркам. Менә сездән бурычка сорап торырмын дигән идем...

М ә л и к ә *(коты алына, сандыкка җәелебрәк утырган кебек була)*. И, бәбекәем, каян килсен, ди, безгә? Мин чирле, абзаң чирле, сыкранып кына йөри. Кайчак чәйгә шикәр алырга да бер тиен юк... Абзаңны сүгәм инде, үлә нитә калсам, Аллам сакласын, өйдә бер тиен запасың юк, дим... Адәм хурлыгы бит инде...

Ш ә р и ф ә. Юк инде алайса... Җитмәсә, Мөдәррискә әйтеп, күңелен кузгатып куйган идем...

М ә л и к ә. Булса икән, җәлмени? Юк шул, балам, заманасы ул түгел бит...

Ш ә р и ф ә. Ярый, рәхмәт, Мәликә апа... *(Чыга.)*

М ә л и к ә *(артыннан сөйләнеп кала).* Исән-сау йөр, балам!.. Булса икән... Юк бит, нишләтәсең... Капкаңны яхшылап ябып чык, тавык-чебеш урамга тарала... *(Ниһаять, тынычланып, тирән сулап куя.)* Аллага шөкер...

*Мәликә чәен яңартып, алъяпкыч кесәсеннән шакмак шикәр чыгарып, авыр сулап, әле генә булып үткән коточкыч хәлне тагы бер кат җентекләп исенә төшереп, эчәргә керешә.*

## XXII

*Кызылсу елгасы ярындагы басма. Яшь кенә, нәзек кенә камыш кебек төз, шәһәрдән килгән укытучы кыз Л у и з а инде унбиш минутлап елгадан су алалмый җәфалана. Ул басма уртасында нишләргә белми аптырап тора, як-ягына карана – ярдәм итәргә кеше юк. Аннары бер чиләк белән аз-азлап чумырып, башка чиләкне тутыра. Инде хәзер монысын ничек тутырырга белми, бөтенләе белән чумырып алса, чиләк белән бергә төшеп китәрмен дип курка. Бер чиләктәге суны ике чиләккә бүлеп карый: аз кебек. Ш ә р и ф ә килеп чыга.*

Ш ә р и ф ә. Исәнмесез... *(Ул кызның хәлен күрүгә аңлый, тиз генә аның чиләкләрен дә, үзенекен дә чумырып, су ала.)*

Л у и з а. Исәнмесез! Бик зур рәхмәт сезгә. Ялгышмасам, сез Ибраһимова Шәрифә апа буласыз.

Ш ә р и ф ә. Әйе, мин...

Л у и з а. Ә мин әле сезгә барырмын дип тора идем... Гафу итегез инде, сезнең малайларыгыз турында әйтмәкче идем. Ничек дип башларга да белмим. Менә кечкенәгез, Мөдәррис, бигрәк усал инде... Дәресен әйбәт белә, тик менә шул усаллыгы... Ул абыйсы Марсның классына кереп, үзеннән өлкән малайлар белән сугышып йөри. *(Яшьләренә буыла.)* Мин нишләргә дә белмим, ул мине бөтенләй тыңламый. Такта янына чыгарып, икеле куеп, тынычландырыр идең, ләкин нәрсә сорасаң да, җавабын таба... Алар бит шундый күбәү, мин аларны җиңә алмыйм... Олырак классларда малайлар дәрестән тәмәке тартырга чыгып китәләр... Мин нәрсә әйтергә дә аптырап калам... *(Шәрифәнең елап торганын күреп.)* Сез нәрсә? Гафу итегез инде мине... Берәр нәрсә булмагандыр бит? Сез нигә елыйсыз, мин

елаттыммы? Зинһар, гафу итегез... *(Үзе дә елап җибәрә.)*

Ш ә р и ф ә. Юк, юк, сез түгел... Борчылмагыз...

Л у и з а. Мин тагын дөрес эшләмәдем инде... Әйе, ана кешегә шулай кисәк... Йа Ходаем, китәм мин моннан, китәм...

Ш ә р и ф ә. Сез түгел... Мамык кибетенә кызыл костюм-чалбар кайткан, Мөдәррисемә шуны алырмын дигән идем. Җитмәсә, үзенә дә әйтеп ташладым. Палучкага кадәр бурычка сорап торырга дип, ничә йортка кердем, сәбәп тапкан булып... Берәр кайчан кайтармый калганым булса иде, озаклап тотканым булса икән... Мөдәррис көтеп утыра инде, хәзер ничек кайтып, улым, акча тапмадым, дияргә? Сабый бит әле ул.

Л у и з а. Шул гынамыни? Мин, мин үзем биреп торам сезгә! Без бүген акча алдык, әйдәгез. Әйе...

Ш ә р и ф ә. Аннан үзегезгә авыр булыр бит. Болай да кеше өстендә торасыз...

Л у и з а. Булмый, җитә. Әйдәгез безгә!..

Ш ә р и ф ә. Ходайның рәхмәте... Шул көннәрдә палучкам була, Алла теләсә... Шундук кайтарам...

Л у и з а. Җаегыз белән кайтарырсыз әле.

*Шәрифәнең чиләкләре буш диярсең, ул аларны очыртып кына йөртә. Луиза үзенекеләрен күтәреп карагач, сыгылып төшә. Бераз баргач, туктап, ике чиләктән дә бераз суын түгеп, Шәрифәне куа китә.*

**XXIII**

*Урман. Коры-сары төялгән тарантаска К е ч к е н ә җигелгән. Ул инде тәмам олыгаеп җиткән.*

К е ч к е н ә . Мескенкәем әни гомере буена алданып яшәгән икән... Бичаракай, минем өчен шатланып калган иде. Шатланырлык нәрсә күрдем инде? Иртән көтүгә чыгып китәсең, кич кайтасың, савалар да шул тарантаска җигеп, алып чыгып китәләр. Сыер да бул, ат та бул... Шулмы инде көтеп алган киләчәк?.. Ә бәлки, ул киләчәк бөтенләй юктыр? Ә әнием ышана иде бит, төннәр буена хыялларын сөйләп чыга иде. Мин йоклап китәм, уянсам, ул һаман сөйли. Мине түгел, үзен-үзе ышандырган икән бичаракай... Дөрестән дә, андый матур тормыш, бәлки, җирдә юк тадыр, булырга да тиеш түгелдер?.. Без аны һәрберебез үзебезгә үзебез хыялда төзергә тиешбездер? Шатлыкның иң югарысы – шул дөньяны уйлап чыгарып, аңа чын күңелдән ышанып, аның турындагы хыялларда назланып яшәүдер?.. Ул чагында, әни чыннан да бәхетле булган килеп чыга түгелме соң? Әйе, нәкъ шулай булып чыга. Иң бәхетсезе, димәк, без... бернигә дә ышанмаучы, хыяллана белмәүчеләр... Шулай булып чыгамы инде?

*Урман эченнән зур бәйләм коры-сары күтәргән Шәрифә чыга. Бәйләмен тарантас янына төшерә.*

К е ч к е н ә. И җаным, кыл кебек билкәйләреңне бигрәкләр дә кызганмыйсың...

Ш ә р и ф ә. Хәзер... Әстәгъфирулла... Хәзер кайтабыз, Аллаһы боерган булса... Хәзер, җаным, син түз генә инде... *(Коры-сарыларны тарантаска урнаштыра башлый. Туктый.)* Нишләптер, вакыт-вакыт күз алларым караңгыланып китә... Әй, бер йотым су эчәсе иде. Җаным көйде-көйде дә... *(Кечкенә каршындагы чокырчыкта Ай төшеп чумган җыентык суны шәйләп ала.)* Менә бит, Ходайның рәхмәте... *(Кечкенәгә.)* Син эчтеңме, җанашым, буең җиттеме?

К е ч к е н ә . Җитте...

Ш ә р и ф ә. Ярар... Менә шулай, яулык чите куеп булса да... *(Яулык аркылы сөзеп, җыентык суны эчә. Күтәрелә. Аның күз алдына төп өстендә утырган М и н с а б и р күренә.)* Елмаясың? Миннән көләсеңдер инде! Әйе, менә шулай яшибез шул хәзер, сыер җигеп йөрибез!.. Савым сыерларын интектергәнебез өчен Ходай Тәгалә каршында ничек җавап тотып бетерербез инде?.. Һаман тынычлана алмыйсың?.. Борчылма... Барысы да тәртиптә... Ашар-эчәребезгә бар, Аллага шөкер... Елмаясың?! Әйе, бүген иртән чәйгә шикәр юк иде шул, ләкин анысы куркыныч түгел... Әйе, ялгыз хатын булгач, төрле сүзләр дә ишетергә туры килә, явыз телләр ни әйтмәс... Куркыныч түгел... Арслан да җитәрлек җәфалады инде. Монда бит ничек, ирләр бөтен печәнлек җирләрне бүлеп алалар да чабалар, без эштә, өлгермибез. Кукуруз арасыннан, юл буеннан эт эчәгесе, алабутадыр җыябыз инде. Аның өчен дә, Арслан килеп чыкса, сүгә, чалгыларны сындырып ата, капчыкларны пәке белән ярып җибәрә, атлаган саен терлекләрне ябып куя. Беркөн Газинурның вилсәпитенең нипелләрен салдырып киткән. Газинур да, бәбекәем, аптырап калмаган, көтү каршыларга баргач, Арсланның малаен туктатып: «Минекен атаңнан сорарсың», – дип, аның нипелләрен салдырып алган! Газинур инде зур... Абыйлар үзен эшкә дә алгалыйлар... Әнә, нинди тарантас ясады. Елый-елый ясады, балам. Ничегрәк итеп ясарга белмәгән җирләрен, барып, берәрсенекеннән карап кайта. Шулай да ясады, әнә, унөч яшьлек малай ясаган, димәссең, мужикларның да һәммәсе булдыралмый андыйны... Марс йомшак табигатьле, сабыр. Гел уку өстендә инде. Укытучылары да мактый. Нечкә күңелле дә инде. Кечерәк вакытында бер кайтып кердем, Марс балакаем тәрәзә төбендә елап утыра. Нәрсә булды, улым, дим? Бөтен малайларның әтиләре тайлы атлар белән кайтып беттеләр, безнең әти һаман юк, ди. Күрәсең мин, әтиең ат белән кайтыр, дип әйткәнмендер инде, сине сорагач... Ә бер юлысы мәктәпкә йөри башлагач, яныма гәҗит тотып килгән. Сорый миннән: «Әни, менә монда: «Дөньядагы иң ямьсез сүз – тол хатын» – дип язган. Тол – нәрсә дигән сүз ул?» – ди. Улым, менә безнең әтиебез юк бит инде, мин ялгыз, тол хатын мин булам инде ул, дигән идем, үкереп елап җибәрмәсенме сабыем. «Ничек инде син иң ямьсез буласың?» – дип, елапмы елый!.. Мөдәррис үҗәт. Ул үзен үпкәләтергә ирек бирми. Күптән түгел, Мамыкка барып, кызыл костюм алдык үзенә. Әй шатланды инде. Сталавайга кергән идек, мин юк арада, башкаларның нишләгәнен карап торган да, шулар кебек кыланып, зур кашык белән тутырып, горщисы капкан, нәнием... Бал дип уйлаган, сабый! Үҗәт инде...

Син борчылма... Тынычлан... Малайлар да, үзем дә башкалардан кимхур түгел. Азмыни безнең кебекләр... Син борчылма... Яшибез, Алла теләсә...

*Урманнан коры-сары бәйләме күтәргән Ә м и н ә чыга. Бәйләмен тарантас янына төшерә.*

Ә м и н ә. Әй, малай, абынып егылдым тегендә, торалмыйм гына бит!.. Сине чакырам, ишетмисең. Каты кычкырырга куркыта...

Ш ә р и ф ә. Ә мин монда килеп аудым, күз алларым караңгыланып китте...

Ә м и н ә. Карале, малай, әйдә, төяник тә кузгалыйк, яхшы чакта. Каравылчы фәлән килеп чыкса, бетте баш...

Ш ә р и ф ә. Әйдә... Исән-сау кайтып җитсәк, Алла теләсә, самовар куеп, туйганчы бер чәй эчәр идем...

Ә м и н ә. Әйдә, малай, әйдә. Селкеник. Аннан чәй дә эчәрбез. Әйдә...

*Шәрифә белән Әминә коры-сарыларны тарантаска төйиләр.*

**XXIV**

*Төн. Шәрифәнең өе. Алдагы бүлмәдә ниндидер тавышлар ишетелеп тора. Ш ә р и ф ә белән Л у и з а килеп керәләр.*

Л у и з а. Сез мине гафу итә күрегез инде... Бу вакытта килгәнем өчен...

Ш ә р и ф ә. Нәрсә, нәрсә булды соң?..

Л у и з а. Мин сезнең алда гафу үтенергә килдем...

Ш ә р и ф ә. Гафу?..

Л у и з а. Әйе... Мин аңламаганмын... Бүген уйлап яттым, йокыга китә алмадым... Мин сезнең алда гаепле... Теге юлысы мин сезнең малайларны сүгеп маташтым...

Ш ә р и ф ә. Әллә берәр нәрсә эшләгәннәрме, Ходаем?

Л у и з а. Юк, юк... Сез борчылмагыз. Бүген Мөдәррисне педсоветта тикшерделәр, спецшколага җибәрмәкчеләр иде...

Ш ә р и ф ә. Әстәгъфирулла...

Л у и з а. Сез борчылмагыз, барысы да тәртиптә. Аны усал, диләр... Аны бит без – усал ясаучылар. Ул бездән үзен саклар өчен шулай эшли. Марс абыйсын яклап, үзеннән олы малайларны кыйнап чыга. Чөнки Марс сабыр табигатьле. Ул аның үпкәсен чыгара... Без бит үзебез гаепле. Әнә, беркөн директор Шәрәф абыйның базыннан вареньеларын урлаганнар. Бер дә юкка, сәбәп табып, сезнең малайларны, Әминә апаның кызын линейка алдында җәберләделәр. Әгәр алар атасыз икән, димәк, усаллар, кулга туры түгелләр... Барысы да түзә, ә Мөдәррис андый түгел. Шәрәф абыйны исерек килеш күреп, аның аунап яткан партбилетын кабинетындагы Ленин томнарының берсе эченә яшереп куйган. Кая, дип сорагач, гомерегездә ачып та карамаган китабыгыз эчендә, дигән... Ул горур. Һәм хаклы да, чөнки аның моңа хокукы бар!.. Мин еладым, аңлаттым... Аны кызгандылар, сезне кызгандылар, спецшкола турында әлегә онытылды... Мин дә бит элек аңламаганмын, гафу итегез мине!..

Ш ә р и ф ә. Ходаем, ничекләр генә сезгә рәхмәтләр укыйм икән?.. Әйдәгез әле, чәй булса да эчик. И Аллам, шикәр дә беткән иде... *(Күз яшьләрен тыя алмый.)*

Л у и з а *(елый)*. Ярый, шикәрсез дә...

*Шәрифә өстәл өстен ачып җибәрә. Анда ап-ак булып өч литрлы банка тулы шикәр тора.*

Ш ә р и ф ә. Әстәгъфирулла... Нәрсә бу? *(Банка янында торган кәгазь төргәкне сүтеп карый.)* Ике сум утыз тиен?.. Ходаем, каян алганнар болар бу акчаны? *(Тәмам куркып кала.)*

Л у и з а *(кинәт акылына килеп)*. Ә! Соң... Газинур алып кайткан... Курыкмагыз... Бүген өлкән классларга бәрәңгедә эшләгән өчен бишәр сум акча бирделәр... Шул акчалар ул! Шикләнмәгез... Эшләп алган акчалары!

*Шәрифә урындыкка утыра. Луиза да аның янәшәсенә утыра. Шунда гына алар баядан бирле күрше бүлмәдән яңгырап торган гармун тавышын ишетеп алалар.*

Л у и з а. Нинди көй ул?..

Ш ә р и ф ә. Малайлар... Аталарының гармунында уйныйлар...

*Уйнаучының әле өйрәнеп кенә килүе, кайбер җирләрдә ялгышкалаганы сизелеп тора. Шул көйгә өч малай тавышы кушылып, аталарының яраткан җырын җырларга тырышалар. Шәрифәнең иреннәре селкенүеннән җыр сүзләрен эченнән кабатлап баруы күренеп тора. Арткы планда Монгол арба артында аякларын салындырып утырган Минсабирны күзләрне камаштыра торган яктылыкка алып китеп бара.*

**Пәрдә.**



Рөстәм
Сүлти

# КОМ КҮЧӘ, БАРХАН КҮЧӘ...

## Телем калсын

*Әюп пәйгамбәрнең догасына ияреп*

Беркем түгел, үземә мин
Үзем залим... Үзем залим.

Хатам өчен, гөнаһ өчен
Җәзам алыйм, җәзаланыйм.

Чир-авыру, мең җәрәхәт,
Яра булсын – миңа рәхәт.

Түзәр бу җан, түзәр бу тән,
Мәхрүм итмә бу милләттән!

Биргән дә Син, алган да Син,
Саулык, байлык – ал барысын.

Булсын тәнем телем-телем,
Тик үтенәм – калсын телем!

Сиңа шөкер итү өчен,
Сине зекер итү өчен,

Телем калсын!
Телем калсын!
Телем калсын
Телем калсын!

---

Рөстәм СҮЛТИ (1969) – *шагыйрь, галим; «Мин – шигырьдән» исемле китап авторы. Лондонда яши.*

## Мин – шигырьдән

Мин шигырьдән. Мосафирмын –
Килгән идем – китәмен,
Тәрәз чиртер кебек күңел кылларына чиртәмен,
Әле Хозыр-Ильясмын мин, әле Читекче Вәли
Тәңре мосафирының мәгълүмме хәл-әхвәле?

Һәр кичәне Кадер дип бел, һәрбер кешене – Хозыр,
Бәлки Читекче Вәли ул чын Вәли-әүлиядер?
«Асрамага бала бирәм, кемнәр ала? Әманәт...»
Бул Сәгъди абзый!
Булмасын әманәткә хыянәт!

Уйлама кабык арбада бары Апуш – бер ятим,
Бер түгел, мең Апуш бардыр – ятим минем милләтем.
Вәли түгел, Хозыр түгел, гап-гади мосафир мин,
Вәгъдә итмим, биреп китмим ни алтын, ни сапфир мин.

Алтын-сапфирлардан битәр, асрамага Сүз бирәм,
Телсез калма, әйтсәң җитәр: «Асрамага сүз бирәм!»
Мин – шигырьдән. Мосафирмын.
Килгән идем – китәрмен,
Тәрәз чирткән кебек күңел кылларыңа чиртермен.

## Дөнья бу

Дөнья бу – бар да күчә:
ком күчә,
        бархан күчә.
Шул комнарның, барханнарның
өстеннән барган күчә.
Кош күчә,
     кәрван күчә,
             кол күчә,
                бәй, хан күчә
Әбелхәят-мәңгесу дип, белгәнен эчә-эчә...

Кем калган? Күчте ике җиһанның әфәндесе,
Биш вакытлы дөньяның бу инде икендесе...
Буеңнан озын шәүләң – үлчә дә карыш-карыш,
Кемнеке озынрак – ярыш, лилипут, ярыш!
Кәрван арган,
       хан арган,
           бархан арган,
                    ком арган,
Шул бархан-ком өсләреннән барган арган, кол арган.

Раббым, барысы арган...
Самимигә дәрман бир,
Йә төрдер дәфтәрләрне, кәрваныңа фәрман бир!
Көттерүче көттереп, көтүче көтеп арган,
Инкарьче инкарь итеп, әйтүче әйтеп арган.

Үзгәрә тора залим, бетми тик золым гына,
Дәвер, дәверан күчә, кан-яшьле колың гына.
Мазлум арган,
                    ком арган,
                                        кол арыган, алҗыган,
Шул ук бер сәмум жиле, шул рәшә, шул аҗаган,
«Раббым, туктат жир шарын, инде башлар әйләнә», –
Дияр булам – үзгәреш килсен дөнья чүленә…

Юл, юлчы,
        юлдаш сәрхуш,
                    юлбашчысы исерек,
Кәрван сәрхуш,
      ком сәрхуш,
            кәрван башы исерек...
«Үзгәрталмас беркемнең үгете-нәсыйхәте»
Дигәндәй, тора агып арыган ком сәгате.

## Кәрван

Моңсу бер көндә, ахшамга таба
Мине Ватанга китерер кәрван.
Бер ял көнендә һич көтмәгәндә,
Йөз-мең мәшәкать иттерер кәрван.

Дөнья чүлендә сусаган җанга
Шифа суларын эчерер кәрван,
Былбыллар сыман сайрар җанымны
Дөнья-читлектән очырыр кәрван.

Җанымны яккан сагыш утларын
Шәм-чыра кебек сүндерер кәрван,
Дусларым ләм-мим тынып торганда,
Урам этләрен өрдерер кәрван.

Гыйбрәт иттереп фани дөньяга,
Гамәл дәфтәрен төрдерер кәрван.
Фани дөньядан аралап алып,
Бакый дөньяны сөйдерер кәрван.

Гомерем буе килгән һиҗрәтне –
Хәсрәтне шулай бетерер кәрван,
Үз Ватаныма кара табутта
Ак кәфен белән китерер кәрван...

## Урман яна

Тау-тау утын, ә Ибраһим аста –
«Яндырырга!»
Залим әмере кыска,
Шулчак авызында бер тамчы су
Белән йөгерә икән бер кырмыска.

Сораганнар: «Кая болай?»
Әйткән:
«Күрмисеңме залим ул Намрутны?
Ибраһимны яндырасы икән –
Сүндерергә телим мин шул утны!»

И көлгәннәр:
«Ничек итеп тәмуг
Утын сүндералсын ул бер тамчы?!»
Әйткән:
«Сүндералмам бәлки, ләкин
Аңлашылыр: кем мин,
кемгә каршы!"

Урман яна...
Модерн Намрутларның
Кул уышып күзләр кысышканы…
Гәрчә бүген Ибраһимны түгел,
Яндырырга иткән Кырмысканы!

Урман яна... Урман белән бергә
Кош-корт яна, яна оя-өннәр,
Әй, Кырмыска! Өнең саласың да
Кем ишетер, кем коткарыр, кемнәр?

Ультра-модерн сәүдә үзәге һәм
Биш йолдызлы люкс «Намрут» отеле
Калкып чыгар урман урынында
Сүнәр-сүнмәс бу Намрут ут теле…

Быкыр-быкыр кальян тарткан көйгә
Лаф ор: «Табигать һәм Җир-Анабыз...»
Ишетелмәсме шулчак колакларга
Кырмысканың өне: «Без янабыз!»

Кырмыска бул! Сүндер,
Сүнми икән
Залим белән булмавыңны җиткер!
Ил төкерсә, бер күл – батар залим,
Авызыңда бер тамчы су – төкер!

Төкер!
Пакьләнмәсме кешелекнең
Икейөзле йөзендәге бу кер,
Чебен белән Намрутны хәл иткән
Янында ла, курыкма, Ул бар, шөкер!

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*



Айдар
Хәлим

# ИСКИТМӘЛЕ ИСМӘГЫЙЛЬ

ХИКӘЯ

*Социалистик Хезмәт Герое*
*Гомәр Гариф улы Теләшев рухына*

I

Авылга кайтып килгән идем. Менә ничә тәүлек уйланып йөрим: матур нигә гел матур, ямьсез нигә гел ямьсез түгел? Тормыш матурлык аша, әллә ямьсезлек аша да ачыламы? Алар кайда аерылыша да, кайда килеп кушыла? Әллә алар аралашып, берсен-берсе яктыртып, кыяфәт-сыйфатлары белән алмаша, адәм баласын тәрбияләү, аның зиһенен әвәләүдә тигез катнаша микән?

Әкчин станцасыннан Миякәгә төшкән автобустагы бер бик матур хатынкайның бик ямьсез итеп йоклаганы хәтеремнән китми. Гөбедән кымыз күбеге кебек ташып чыккан ак, көпшәк күкрәгенә ишелеп төшкән ияге буйлап бер нәселле чебен шуыша, ул аңа кымшанып та бирмичә, гырлавын дәвам итә...

Инде авылга кайтып егылганнан соң, менә бүгенге аяз иртәдә бертуган агам һәм җиңгәчәм белән чәй эчеп утырганда, әллә минем күз алдымда торган теге манзараны оныттырырга, әллә дөньяда ямьсезлек белән беррәттән икенче бер матурлык дигән нәрсә дә барлыгын исемә төшерергә теләп, ут-күршебез Исмәгыйль абзыйның сызгырганы ишетелде. Без үскәндә, ул урам аша каршыбыздагы өянке астындагы ут-күршебез иде. Аннан, яшь җиткереп, башлы-күзле булгач, урамның ике-өч өянке аша гына безнең рәттән йорт бетереп, башка чыккач, ул, ниһаять, инде үз ягыбыздагы ут-күршебезгә әйләнде.

Сызгырганы дип кенә әйтү дөрес тә түгелдер. Сайравын дию дөресрәктер. Бер караганда, үтә дә милли гамьле булган, җаны-тәне белән үз бәгыребездә кайнаган, икенче караганда, бөтенләй чит сулышта ят сагыш, ят мәкам белән сугарылган, безнең яклар өчен чит сөякне, ерак Европаларның алман-ярман ариэтталарын хәтерләткән бу көй тургай кебек күккә күтәрелә, бер нокта-нотада асылынып бөҗралана-бөҗралана да, Исмәгыйльнең иреннәрен бөреп, башкорт курае сыман өзли-өзлегә, таш кебек түбәнгә атылганыннан соң, сыерчык кебек оясы тупсасына куна, аннан талпынып-талпынып, күккә күтәрелә, яңадан

Айдар ХӘЛИМ (1942) – *шагыйрь, прозаик, публицист; «Өч аяклы ат», «Татар моңы», «Хунвейбин» һ.б. китаплар авторы. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге әдәби премия лауреаты. Чаллыда яши.*

диңгез киңлекләренә чыга, туйганчы сулыш ала, салмаклана, андагы тирән аһәң, андагы нәфислек, ирлек-хөрлек, үзәкләрне өздергән нечкә алкым – моны музыка гыйлемендә фальцет диләр бугай – мин ишеткән бер генә җыру, бер генә көй, бер генә музыкаль әсәрне дә кабатламыйча, адәм баласының сандугачлардан ким булмаган, ә бәлки, бу очракта күкләргә эленеп көмеш моңнар койган соры тургай, оясы баскычыннан тирадалар сузган кара сыерчык, өянкеләр түрендә гаммалар түккән сары сандугачлардан да артык моңлана алганлыгын раслый иде. Сәхнәдән яңгыратмасалар да, көндәлек тормышта яңгыраган мондый сәнгати сыктау-чеңләү төрен «нәфис сызгыру» диләр шикелле. Нинди көй бу? Таныш та, түгел дә. Милли дә, түгел дә. Гаҗәбетдин!.. Шул гына, мин сезгә әйтим!..

Аерым кешенең сызгырып та барлык кешелекне әнә шул моң дәрьясына сала, аңарда, кайвакыт барысы да бетте, һәммәсе дә җимерелде дип күңеле төшүчән җан иясендә бу кадәр көч-гайрәт ташкынын хасил итә алганлыгына бүген ышанмаган, иртәгә дә ышанмыйча яши алганлыгына ышанмаган булыр идем мин, әгәр бу могҗизаны үзем кичермәгән булсам, валлаһи!..

– Ходай аңа моң дигәнне чамасыз биргән. Яшь чагында җырлаган гына, диләр. Әллә моң дигәнен җыр аша гына чыгарып бетерә алмаганмы... хәзер нишләптер җырламый, сызгыра гына! – диде күзләре дымлана төшкән агам, чынаягын үзеннән этәреп. – Бар, шулайрак итеп сызгырып кара син!.. Ә ул, әйтәсе уй-фикерен шулай сызгырып кына ирештерә, менә бит!.. Әгәр җырлаган гына булса, бәлки, бу кадәр моңлана алмас иде. Кем белгән?.. Үзе сызгыра гына, ә үзе торган белән эскрипкә!..

Сызгыру кинәт тынып калды. Соңгы елларда ике колагы да катылана башлаган агам сагаеп, колагын шомрайтты:

– Әллә туктады инде? Ул сызгырганда, гадәттә, мин ишетә башлаган кебек булам. Хәзер ишетмим, шуңа әйтәм, кем. Безгә керергә җыенмый микән?

Моннан берничә көн элек Исмәгыйль абзый чынлап та безгә керергә һәм миңа «беркемгә дә сөйләмәгән сер»ен сөйләргә вәгъдә иткән иде. Әмма кермәде дә кермәде. Әллә кичә кибеттәге вакыйгадан соң тартынамы? Мәгънәсен тапмыймы? Гомере буе чокырыннан чыкмыйча яшәп, сөекле Гөлзәйнәбенә өйләнеп, өч бала үстерсә дә, ягъни шактый билгеле, ихтирамлы кеше булса да, ул авылдашлары белән артык аралашып, колачын җәеп бармый, һаман да шул эчтән ябык, серле зат булып кала килә. Колхоз эше, җәмгыяви гамәлләрдә дә бик күренмәс ул. Бригадирлар аңа эшкә әйтеп тә тормыйлар бугай. Гомере буе колхозга кермичә яшәгән намаз әһеле Чоных картка да, яшь кенә башы белән «колхоз булмый калган» Исмәгыйльгә дә бер караш. Колхоз печәнгә төшкәч, яше-карты катнаша торган өмәләргә катнаша ул катнашуын, әмма күзләре мөмкинлек бирсә. Чалгысын чүки, хатын-кызга янап та бирә.Чоных картның дөнья көтәргә дигәндә, аты бар, ә Исмәгыйльнең аты да юк. Минем аның хәтта сыер асраганы да хәтердә калмаган. Ул ниндидер үзенә хас бер авыл пралетары иде: иреннәрен бөреп сызгыра торган авызы һәм һаман да шул күз кабагы кара кан белән тулышмаган көннәрендә авыр күтәрергә ярый торган тактадай аркасы гына бар.

Онытып торам икән, мин бит әле сезгә аның сул күзе турында сөйләмәгәнмен. Халык Исмәгыйльнең ул күзен ике халәттә күрергә күнеккән: шешенгән һәм шешеннән кайткан гамәлләрендә. Беренчесендә күз кабагы йодрык кадәр булып караеп шешә. Ул куркыныч: кара кан белән тулыша, сыер җилененең имчәге кебек асылынып төшеп, өртелә. Ул мондый чагында күзен кара күзелдерек белән бәйләп йөртә. Шеше кайткач, күзелдерекне ала. Ул чагында артык текәлеп карамасаң, аның бераз гына юешләнеп, пычкылдап торуына игътибар

итмәсәң, күз тек күз инде. Авылда Исмәгыйльнең бу хафасы хакында төрле сүз йөри, берәүләр аны йөзендәге эре күзәнәкле шадрасына сылтап, чәчәк чиреннән, икенчеләр кемдер җибәргән бозымнан калган, диләр. Өченчеләр әллә булганны, әллә булмаганны сөйләп, бераз арттырып та җибәрәләр бугай. Имеш, сугыштан соң, 1947 елдагы ачлыкта атасыз ятим гаиләсенең ипи сорап тилерүләренә чыдый алмаган Исмәгыйль сул тарафтан нибары ике йорт аша ут-күршесе Бүре Садретдиннең келәтен басканы өчен утырган һәм бозымын шунда – өтермәндә эләктергән. Дүртенчеләр, имеш, ул өтермәннән кайткач, авылларында нефть эзләп азапланган буравайда эшләгәндә, бер азгын хатын көнләшеп, аның күзләренә ниндидер химикат сипкән. И-и-и, ни генә сөйләмәс халык! Булганмы бу хәлләр? Кемгә нәрсә кирәк: иң мөһиме – гомер үтә; Исмәгыйль исән – авыл исән, авыл исән – Исмәгыйль исән. Шунысы кызык: кичә кибеттә үзем шаһит булган гаугада ачыклана барган бу тарихларның кайсы чын дөрес икән дә, Исмәгыйль шуларның кайсын миңа тәфсилләп сөйләргә җыенган иде икән? Әллә шуның белән тарихлар чикләнә микән?

Ничек кенә булмасын, бригадир халкыннан «Исмәгыйльне нигә авыр эшкә чыгармыйсыз? » дип сорасаң, алар иңнәрен сикертеп, «Нишлисең инде аның белән? – диләр. – Ул бит Искитмәле Исмәгыйль. Нәкъ җырдагы кебек:

«Кулымдагы йөзегемнең
Исемнәре Исмәгыйль,
Бик сагынган чакларымда
Сайрама, кош, исмә, җил...»

Һәрхәлдә, Исмәгыйльдәге мондый җисми үзгәрешләр аның кешелек гадәтләренә, кальбе-холкына тәэсир итми, ул һәрвакыттагыча артык сөйләшеп, чишелеп бармаган Исмәгыйль булып кала бирә. Элеккечә өздереп сызгыра да сызгыра. Сызгырганда, аның шадрасы тагын да куера, тирәнәя, әлифба хәрефләрен хәтерләтеп ачыклана, халык телендә икенче исемдәге «Шадра Исмәгыйль»гә әйләнә.

### II

Әйе, кичә мин аның белән көтмәгәндә кибеттә очрашкан һәм бик тә гыйбрәтле аңлашуның шаһиты булган идем. Шунда баягы сорауларыма шактый күләмдә җаваплар да таба биреп куйдым, дисәм, ялган тартмас. Абзамның күзе бәйләнгән иде. Кибеттә Исмәгыйль күршем, миннән һәм көлдә пешкән ак көлчә кебек сатучы кыздан башка беркем юк. Анысы күрше чуваш авылы Өязебаштан икән. Кибетне тоткан кеше дә чуваш булганга, күрәсең, сатучы итеп сеңлесен куйгандыр, дигән фикер килде миңа. Татарчасын яхшы гына белә белүен, ә менә Исмәгыйльнең дөньяда барлыгын белми булып чыкты. Бу аңлашыла да. Күптән түгел генә кибет кабул иткән чуваш кызы нигә Исмәгыйльне белергә тиеш әле? Мине белүе-белмәве турында инде әйтеп тә торасы юк. Хәер, боларның кирәге дә үзләре кадәр генә иде. Эт иснәшеп, кеше сөйләшеп таныша, дигәндәй, без Исмәгыйль абзый белән сәламләшеп торган арада кибеткә ярчакланып беткән тупса аша тулган арыш капчыгыдай Хафизәттәй ишелеп килеп керде.

Ул миңа игътибар да итмәде.

– Исәнме, үскәнем, – диде ул, Исмәгыйль абзый ягына сирпелеп кенә.

– Исәнме, Матур Апа, – диде Исмәгыйль, апасына күз дә ташламыйча.

Аякларына ак җеп оекбашлар, өр-яңа, ялтырап торган калош, өстенә буявы уңа төшкән эре чәчкәле зәңгәр халат, аның өстеннән яшькелт бәйләм кигән,

кайчандыр тышка бәреп чыккан бик тә камил, коеп куйган буй-сынлы булып, яшьлегендә ир-ат кавемен ифрат та ымсындырган, аларның энәсенең үткен күзе аша нәзек җеп булып сапланып, давыллы мәхәббәтләр кичереп, инде сүнүгә, картаюга юл алган көннәрендә, йөзен өлкәнлек рәшәсе биләсә дә, әле бүген дә күзе-башы уйнап, иске казнасында сакланып, җанда эркелгән матурлыкның кычкырып торган өлешен тоемларга мөмкин иде. Мут, наян карашлы, күз читләрендә туймас-төкәнмәс сөю чаткылары әлегә кадәр сүрелмәгән, яшьлегендә сөт өстедәй татлы булып, хәзерге тел белән әйткәндә, топ-модель дигән исем яуларга лаек Хафизәттәй, икенче караганда, жалу кенәгәсе сыман бөкләнеп, сынып, кайтарылып таушалган ханым иде. Әллә нигә бер күргән, тормышта бигүк аралашып яшәмәгән, очраганда язучы авылдашы белән тартынып-авырсынып кына күрешкән түтки минем белән бу юлы да баш кагып кына исәнләшкәндәй итте, аннан колак йомшакларында атынган айлы-йолдызлы алкаларын тирбәлдереп, инде шактый шиңеп өлгерсә дә, бәйләм кием аша төртелеп тырпайган ачык күкрәкләрен яктыртып, сатучы каршына килде:

– Анавы кәнфитеңне үлчә әле, Пүләнә, – диде, төрле төстә бүлек-бүлек булып яткан татлы затларның берсенә төртеп күрсәтеп. – Бабаевский, әйем? Ярты кила. Төргән кәгазе дә авыр тартмый...

– Пула ул, Каписәттәй, – диде Полина, төссез пакетына кәнфитләр коя башлап. – Дөрес әйтәсен. Папаевскийлар пик тәмле алар. Упаковкалары та авыр дегел...

Мин Хафизәттәйнең куе итеп кызарткан ireннәренә һәм уң кашы өстенә кара каләм белән төрткән ясалма миңенә игътибар иттем. Һәрвакыт матур булырга тырышкан хатын сыер саварга чыкканда да бизәнеп, иннек-кершән ягарга онытмый шул ул.

– Пыртманитың калыннан булмагач, кәнфит кәгазенең калынлыгын да исәпкә алырга туры килә, Пүләнә сеңлем, – диде сатучыны куәтләп Хафизәттәй, аннан Исмәгыйль алдында борылыштагы чана сыман канаты белән чалулап, сатучы каршына килде, моңа кадәр мине күрмәмешкә салышса да, инде, ниһаять, гүя минем – язучы өчен махсус мәгълүмат биреп алды. – Исмәгыйль үскәнем Садретдин карт йортын басканы өчен зонада утырганда, мин «Кызыл Маяк» колхозының алдынгы трахтырисы гына түгел, алдынгы уракчысы да ием. Көненә икешәр йөз көлтә бәйли ием... Әмма минем пинсәм... – Ул итәкләрен күбәләк кебек җилфердәтә биреп, Исмәгыйльнең алдына диярлек барып, нәзек җил кузгатты. – Синекеннән ике тапкыр накысрак!..

– Зарланма, Матур Апа... Бер дә кешедән ким яшәмәдең әле, – диде Исмәгыйль тыныч кына, юктан тавыш чыгарырга теләп, үз бакчасына ыргытылган ташны күтәреп. – Колхозыбыз көлтәңдәге буш башакларны онытмаган, димәк. Тарсынма, киң бул, күкрәгеңә тиң бул!

– Миңа бит пинсәне синең кебек сызгырган өчен генә түләмиләр, үскәнем!..

Мин уңайсызланып куйдым. Исмәгыйльнең күз читләре тартышкандай итте. Моннан кырык ел элек авылдан чыгып китеп, авылдашларым арасында балачагымнан кальбемә сеңеп калган итагать, үзара ихтирамнан башка бернинди күңелне кыя торган, ямьсез мөнәсәбәтләрне күрмәгән генә түгел, аларның була алуын да күз алдына китермәгән каләм әһеленә, җирдәшләремнең болай ерткалаша башлавы минем өчен битабигый нәрсә иде.

– Ә мин, үскәнем, дөрес әйтәсең, не прападам!.. Җир бите бетмәсә, ир бите бетмәс!..

Исмәгыйль абзый тешләрен кысып яныма килде, Хафизәттәйгә кыек караш ташлап:

– Син, Мирас туган, авылда туып, авылыңны белеп бетермисеңдер әле. Ул Матур апаңның әле ул сатып алырга җыенган кәнфитнең елтыр кәгазе генә түгел... – диде дә, кулларын минем иңемә салып, Хафизәттәйнең каршына ук алып килде. – Син язучымын, дисәң, әнә шул күзләрне укы. Анда нинәмәрсә күрәсең? Күз тирәләрен сарган күкшел рәшәне күрәсеңме? Рәшә түгел, зәһәр, дөньяга үч, ачу ул!.. Берәүгә кара сөрмә, икенчегә кара өтермә!..

– Тучны, Исмәкыйль апси! – дип көлде Пүләнә, аңлап та өлгермәстән. – Күзе төпләре кукшыл захар!..

– Син, сеңлем, кеше өстеннән көлмә, этеү авызыңны анавы үлчәвеңнең тәлинкәсе белән капларга да күп сорамам!.. – дип кисәтте Хафизәттәй блатной тел белән.

Мин инде теләсәм дә, чыгып китә алмый идем. Өч тарафтан камалышта калып, берьюлы Матур Апага, Исмәгыйльгә һәм Пүләнәгә әсир төшкән идем.

– Мондый зәһәр күкшеллек хатын-кыз күзендә акланмаган өметтән, көчсезлектән килә, Мирас туган. Ул сине кисеп кенә ыргыта. Моннан илле ел элек ул мине дә плингә төшереп, кисеп кенә ыргыткан иде... Әмма!.. Аһ!.. Бу зәһәрнең угы!..

– Уты диген, үскәнем!..

– Утың бар иде, яктыртмадың. Сүндердең, Матур Апам!.. Нәтиҗәдә, минем, ир кешенең, күзләре – бер фаралы йөк машинасы сыман, ә син – буш бишек!.. – Исмәгыйль абзый дулкынланудан нәрсә әйтергә дә белмичә туктап калды. – Сүзне үзең башлагач, чарасыздан, еландай телемне чыгарып әйтәм: яшьлектәге азгынлык җавап сорый, Матур апакаем!..

– Кемнең азгын икәнлеген ачыкларга кирәк әле, үскәнем. Сине миннән тартып алган Гөлзәйнәбең түгелме?

– Син Гөлзәйнәпкә кагылма!

Бу яратып өйләнгән хатынын, шушы кечкенә авылда аның белән матур гомер кичереп, бер түшәктә менә дигән өч бала табып үстергән ананы яладан яклау иде. Ул тирән итеп тын алды, башын югары чөйде, сабырлык сорагандай, бер мизгелгә күзләрен йомып хәрәкәтсез торды.

– Такын нәстә алапсыз, Кафисәттәй? – дип кысылды арага кәнфитен үлчәп беткән Пүләнә. – Жевательни сакыз кирәкмиме?

– Көләсең ышту ли? Сагызың үзеңә булсын! Чәйнәп чәйнәләсе көннәрең алда әле, сеңелкәем! – Ана каз кебек ысылдап, Хафизәттәй кайчандыр теге гасырда крәчин, тозлы балыктан дегетле ат камытлары, дилбегә-йөгән, арба тәгәрмәчләренә кадәр асаба тауар асрап, инде ике меңенче еллар башында алардан кирәкмәс малдан котылган кебек котылып, вакланган, твикс-микслар, елтыр шешәләр белән тулган авыл кибетен рентген күзеннән кичерде, аннан гасаби көчсезлектән көнчелеккә әйләнгән «Сам знам!»ының тотып тыйгысыз тантанасын раслап, өстәп куйды. – Без заманында аның каен тузыннан кайнатылган настояшниен чәйнәдек...

Ул артына борылды һәм Исмәгыйльне тупка тота башлады. Үзе гел миңа карап, гүя «Улым, сиңа әйтәм, киленем, син тыңла!» дигәндәй, башкаларга күптән билгелене минем өчен генә сөйли иде.

– Угым бар, тик мин Бүре Садретдин куенынннан качкан елан түгел. Мин тере, үскәнем! Кышын печән өмәсендә яланнан кайтып, сәнәк очына сигезле булып эләккән туң еланны онытмагансыңдыр, шәт? Садретдин аны бәлки терелер, дип мич арасына ыргыткач, икенче каравына юкка чыккан иде? Ә менә мин юкка чыкмадым. Синең белән бер авылда – бер давылда барысыннан

да бәйсез булып, берьялгызым гөрләп яшәп ятам, үскәнем! Шулай да, мин актин-акмын дип масайма, сак бул. Син шома көпшәдән чыккан өзләү курае, ә мин сөттән туган кара җир!.. Сөрүчесе генә табылмады!..

Һәм үткен итеп кеткелдәде.

– Җизниләрдән пәкесез калдырдың шул, – диде Исмәгыйль тыныч кына. – Гафу дә үтенмисең.

Хафизәттәйнең үткен, бай, җор теле мине таң калдырды. Ул сайланып кына чыккан сүзләр чалгысы белән урып кына калмый, кырып чаба, кисә, астан шыя иде...

– Үләсе күркә төрткәннән дә үлә, ди. Ә мин сау!.. Яшәгән саен аш кими, эш арта...

Менә шулай, халкы берсен-берсе белмәгән ниндидер миллионлы шәһәрдә түгел, ә бәлки, әйткәнемчә, җитмеш-сиксән генә йортлык авылда, мин барысын, бар серләрен беләм дип исәпләгән, алай гынамы, ифрат та дус, яхшы, бердәм дип ышанып йөргән, әмма хәзер генә ишетүем-күрүемчә, күп нәрсәне белмәгән булып чыккан чокырда, җитмәсә, аның кысан кибетендә, берсе икенчесен «Матур Апа» белән «Үскәнем» дип кенә зурлап вә чеметеп сөйләшкән ике газиз авылдашым арасындагы катлаулы, мин башыма да китерә алмаган мөнәсәбәтләрнең тетрәткеч тарихлары аша очраклы «халаек»тан «публика» ясап, шәхесләрен ачыклау, әгәр шулай әйтергә яраса, тиешле урынга утырту, төрткәләү, тәпәләү манзаралары башланып кына торганда, ошбу кызып кына барган сөйләшүне бүлеп, кибеткә яшел күлмәге өстеннән тагын да ачыграк яшел алъяпкычын бәйләгән Мәфтуха җиңги килеп керде. Ул үзенең тегеннән-моннан буылган буынтыклы гәүдәсе белән борчагы өлгергән яшел кузакка охшаган иде. Ул томандагы күбәләк кебек беркемгә күз салмыйча, тупсадан түргә үк очып барып, сатучы катына килде:

– Пүләнә сеңлем, оным беткән – бер, борычым беткән – ике! Ун кап шырпы, ярты кила берәнник, ярты кила анауы кызыл манпачиыңны үлчәрсең, яме! – Шулай санап китте дә мине абайлап алды: –Һи-и-и, күрми дә торам икән! Язучыбыз кайткан бит!.. Исәнме-саумы, Мирас энем!

Чуваш кызының башы яулыксыз булган кебек, татар хатыннары башыннан да яулыклары сикереп төшкән, йөзләре ачылган, алар инде борынгы мөэмин-мөселман нисалары кебек авыз тирәләрен яулык чите белән каплап сөйләшү гадәтен тәмам онытканнар иде.

Мәфтуха җиңги ике кулымны өзәрдәй булып, куш куллап күреште. Уң кулының барысы да көмеш йөзеккә тиенгән бармаклары ялтлап куйды.

– Барыгыз да исәнмесез әле! – дип урынында таптанды да янә сатучы каршына килде.

– Язучы?! Безнең турыда язмый торган язучы ул, – диде Хафизәттәй. – Нифтәникләр, акчалы халык хакында гына яза бит ул...

– Әйе, дөрес әйтәсез. Кайчандыр яшь чагымда дөнья җимерердәй булып яза идем, – дип кысылып киттем мин дә сөйләшүгә. – Кешелекне алга илтәм дип, көне-төне кәгазь кимереп, алтмышлап китап чыгарып, аны бер генә миллиметр да алга җибәрә алмагач, мин хәзер язмый торган язучы. Мин алга чакырган саен ул артка күтенли...

Бу барысына да ошады. Бердәм көлештеләр.

– Кысык әйткән! – диде Пүләнә сагыз чәйнәп агарткан тешләре белән яктырып. – Мин пу күтенли тигән сүсне пелмәгән!..

– Син язган саен кешелек артка киткәч, димәк, начар язгансың, иркәм!.. –

дип каплады авызымны Хафизәттәй. – Бер китабыңны укый башлап, верандада калдырган идем, юкка чыкты. Минем крысалар синең китабыңның келәен бик яратты, күрәсең...

Хафизәттәй янә дә авыз күтәреп көлгәннәрен көткән иде, әмма бу юлы авылдашларым ашыкмадылар. Киресенчә, уңайсызланып куйдылар.

– Юк, безнең Мирас – чын язучы, – дип каршы төште Исмәгыйль абзый.

– Каян беләсең? Аны мин генә түгел, син дә укымыйсың бит, үскәнем! – диде Хафизәттәй һәм сүзен такмак белән сипләп куйды:

– Без үзебез аючы,
Түгел урлап баючы,
Әтиебез төлкече,
Булмыйк адәм көлкесе!

Такмак урынсыз иде кебек, әмма Хафизәттәй моның белән «урынсызга»да урын табып, һаман да шул Исмәгыйль бакчасына таш ыргытып, аның кайчандыр, моннан күп еллар элек, тормыш юлын «бурлык» белән башлап, Ярыяхмәт картның келәтен басканлыгын һәм төрмәдән кайткач, буровойда эшләгән кыска гына вакыт эчендә шул буровой борысларыннан алты почмаклы йорт бетереп керүенә, авылда беренче «Иж» матаен алуына ишарәләде бугай. Абзый Хафизәттәйнең май сыланган кармакка охшаган такмагын сиздермичә йотып җибәрде. Кем белә, бәлки, такмакны ул миңа юнәлткән булгандыр?

– Барысын да укып барам, дип әйтмим, әмма мин укыганнары бер дә адәм көлкесе түгел, Матур Апа. Ярыйсы. Хәтта шәп. Бик әйбәтләре дә бар. Аннан ул тышкы кыяфәте белән дә чын язучы... – Үзе дә сизмәстән такмактагы яшерен фикерне осталык белән әләктереп алган Исмәгыйль абзый язучыларның килеш-килбәте хакында тоташ бер лекцион укып алды. – Безнең Мирас лесорубка... минем кебек, өтерманнән чыккан зэккә охшаган. Төсе-буе ышандырамы? Ышандыра. Чалбары үтексезме? Үтексез. Язучы чырае белән матур, купшы түгел... тупас булырга тиеш. Аллаһы Тәгалә даһиларга матурлыкны бик тә үлчәп бирә. Йөзләре почмаклы, йөрешләре шатыр-ботыр булган саен аларның язганнары гүзәл килеп чыга. Ә болар... бүгенгеләр... телевизор каршында утырыр өчен генә тугандай коеп куйган чибәрләр. Үзләре төзек, язганнары җимерек. Җөмлә дә төзи белмиләр. Матурлык еш кына ямьсез юл белән йөри!.. Әтеү китте шагыйрь-шагыйрәләр... язучылар, понимаешь, шома йөзлеләр, туры, күккә сикергән курныс танаулылар, буянып, сәхнәгә чыккан циркачлар, диярсең. Нәрсә, Шекспир матур булганмы? Виктор Гюго, Александр Пушкин, Анна түтеки Ахматова, Габдулла Тукай, Такташ, кәнсә дә кәнис! Аларның барысының борыннары үркәчле. Безнең Мирасның бор-рыны да нәкъ шундый, ат борынына охшаган, җәмәгать!..

Башта мин үзем көлеп куйдым. Бу фәлсәфә миңа нәрсәсе беләндер кызык, хәтта яңа тоелды. Миңа ияреп, кулларын чәбәкәйли-чәбәкәйли Пүләнә көлде:

– И правда, кыс-сык! ! Күсләре дә кыс-сык! Ничек күргән?! Ничек ашаган!..

Фикерне соңлабрак тотып алган Мәфтуха җиңги исәнгерәгән жиреннән уянды, хәлиткеч адымнар белән яныма ук килеп янтайды һәм мине кояш ягына борып, борынымның үркәчен чамалады һәм кеткелдәп куйды:

– Чынлап та! Биргәч тә биргән Аллаһы Тәгалә!..

Арабыздан Хафизәттәй генә көлмәде. Тышта эсселек егерме градустан да ашып барганда, авыл кибетенең салкынча күләгәсендә, без, дүрт авылдаш һәм күрше Өязебаштан чуваш кызы Пүләнә, фәлсәфи коллоквиум ачып җибәргән идек.

– Матурларның йөзенә сагыш ятмый, – диде Исмәгыйль. – Матурлык сагышны үтерә...

– Сезнең сызгыруыгыздагы сагышны кем үлчи ала икән? – дип куйдым мин. – Каян килә бу кадәр моңлы сагыш, Исмәгыйль абзый?

– Исмәгыйльме моңлы?! – Хафизәттәй, кузгалган теңкәсенә түзә алмыйча, прилавкада яткан тукымаларны капшагандай итте. – Таптыгыз моңлы кешене! Моңлы булганга сызгырамыни ул? Моңсыз булганга сызгыра. Алай итеп һәркем сызгыра ала! Сызгырта белергә генә кирәк. Хәтерлисезме, әлеге дә баягы, Зифа карчык таягы дигәндәй, һаман да шул Садретдин карт турындагы мәзәкне? «Бабай, сызгыра беләсеңме?» «Юк, балам, үтерсәң дә белмим». «Кызыңны урлаганнар бит!» Карт шулчак «фью!» дип сызгырып җибәргән, диме? Бар кеше дә Шадра Исмәгыйль кебек сызгыра башласа, асылынырга гына кала!

Соңгы сүзләрдән соң Исмәгыйль усал итеп карап куйды.

– Нәрсә беләсез сез?!

– Бер дә асылынмыйсың әле, Хафизә. Көне-төне Исмәгыйль моңнары астында йон теттереп яшәп ятасың... – диде Мәфтухаттәй. – Нихәлләр генә түзәсең?

– Ятам ди тагын! Ике ятып, бер төшемә керде!.. Җырласа, тагын бер хәл. Югыйсә, күпләрне сызгыртты инде ул гомере буе авыл җилкәсендә. Моңлы кеше ярлы була, акчасыз була. Ә ул әнә нинди йортларда яши! Кыр тавыгыдай чуар хатыны белән балда-майда йөзәләр! Чегән баруны диярсең!..

Һава кыза башлады. Сизендем: Хафизәттәй алдына үзе белән Исмәгыйль арасындагы безгә билгесез тарихлар хакына тавыш чыгару, мөмкин булса, шуның үчен кайтару һәм бу бурычны, мөкаммәл, минем, ягъни язучы алдында башкарып чыгу бурычын куйган иде...

– Син нәрсәгә бәйләндең әле Исмәгыйльгә? – Мәфтуха җиңги чын-чынлап ачуланган кыяфәттә алга калкынып куйды. – Кыр тавыгы, дисең. Гөлзәйнәпне дә беләбез. Сезләрнең икегезне мин дә бит куначамдагы тавыкларым кебек беләм, җаныкайларым!.. Кем ничектер, мин Исмәгыйль энемнең сызгыруын үтә дә яратам! Мин хәтта җылап та алам... – Күңеле йомшарган Мәфтуха күз төпләрен сөртеп алгандай итте. – Ул елларны искә төшерсәңме? Исмәгыйль кебек булырга кирәк әле!..

– Мактама-а-а... – диде сузып Исмәгыйль абзый.

– Мактыйм, нигә мактамыйм, ди? Нәрсә, Хафизә, Исмәгыйль гаиләсе белән синнән бурычка яшимени? Аның Идел-Уралда бер дигән дөядәй зур сараен син күтәрдеңме? Синең хыянәтең аркасында төрмәләрдән башы чыкмаячак Исмәгыйльне коткарып калган, шул патша сараедай йортлар эчендә берсеннән-берсе асыл балалар үстергән, халыкка асалы паласлар тукыган Гөлзәйнәптән көнләшәсеңмени? Онытма, борынгылар «Атың начар булса – сатып, этең котырса, атып котылырсың, хатының котырса, ничек котылырсың?» дигәннәр...

Мин уйга калдым: нинди төрмәләр, нинди коткарулар? Елгадагы кечкенә кораб эченнән бик тә зур кораб тишеп чыкты: монда ихластан да ниндидер тетрәткеч тарих яшеренгән иде...

Исмәгыйль абзый соңлап өйләнгән. Монысын беләм. Шулчак минем күз алдына аның өлкән улы – ике яшьлек Сабирҗан килде. Теле бик мәрәкә итеп ачылган иде.

– Әтиең нишли? – дип сорадым мин аңардан бер тапкыр авылга кайткач, урамда очратып.

– Титак тукый. (Китап укый, димәк.)
– Әниең нишли?
– Амын саба. (Камыр баса, димәк.)
– Песиегез нишли?
– Пыртлый. (Йоклый, димәк.)
Кемдер кибет тупсасына килде. Таптанды да мыгырданып китеп тә барды. Кермәве яхшы. Кем белә, кем ул? Шул уңайдан кибет эчендә урнашкан тынлыкны тагын да Мәфтуха җиңги бозды.
– Син мине кыздырма, Хафизә. Әтеү сүләтәсең. Сезнең гыйшкыгыз минем күз алдымда кабынып сүнде бит!
– Мәхәббәт! Кая, нинди гыйшык? – дип читкә борылып төкергәндәй итте Хафизәттәй. – Сөеште, ди тагын...
– Сөештегез шул. Ничек кенә әле! Бүгенгедәй эт белән песи кебек булмадыгыз...
– Мин аңа эт тә, песи дә түгел, таныш авылдашы гына, шулай бит, Матур Апа? – диде Исмәгыйль абзый, үзе дә бераз үчекләнә төшеп.
– Ир-атка каты нәфрәт ялгыз хатын-кызның салкын түшәгендә туа. Синең бит, Исмәгыйль туганым, сызгырганда әйтәсе сүзең сандугач булып сайрала һәм кайрала. Ә син, Хафизә сеңлем, үпкәләмә, шул сандугач сайрауларына итәгең белән кереп йөздең!..
– Йөзде, ди!
– Баттың!..
– Батты, ди!
– Баттың. Чыга да алмадың.
– Чыга алмады, ди.
– Бу тарихны Андрей Малаховка язып җибәрик мәллә? – дип, җиңелчә көлеп куйды Мәфтүхә җиңги. – «Пущай говорят!» Сөйләсеннәр!.. Нигә син гөнаһны кеше алдында кылып, кешедән читтә тәүбә итәсең?
– Сөйләсеннәр! Итмим мин тәүбә! Ник итим, ди? Берәр гөнаһым булса тагын?! Авылда элеккеге сепаратор гайбәте урынына телевизор гайбәте генә калды инде хәзер... – диде Хафизәттәй. – Мәхәббәт! Бу сүзне телгә алганда... телегезгә телчә чыккыры!..
– Алабыз. Син аны, кузгалып кына килгән сөюегезне, яшерен-батырын түгел, буравай Иваннары белән себерелеп, үзең салып таптадың!
– Күрдеңме? Мине итәгең белән каплап тордыңмы? Хәзер мин сине... Хәзер мин сине!.. – Һәм Хафизә Пүләнә кулындагы соскыны тартып алып, Мәфтухаттәйгә таба томырылды.
– Туктагыз! Сез нәрсә, тилерештегез мәллә? – дип, Исмәгыйль абзый аларның арасына керде.
Куркуыннан агарынган Пүләнә соскысы артыннан сикереп чыкканын сизми дә калды:
– Ярамай! Соскам перәү кенә!..
Без бу минутта чынлап та Андрей Малаховның «Беренче канал»дан талаш-гайбәтләргә корылган атаклы тапшыруының инде чокырдагы татар авылына килеп кергән сериясен карый идек. Бередә ярамаган яраган, яраган исә ярамаган белән тигезләшкән исәптә патшалык итә иде. Егерме беренче гасыр башында газлы, телефонлы булып, туган телендә радиосыз, телевидениесез, мәктәпсез, хәтта клубсыз калган авыл кешеләренең борынгы бергәлек, кешелек-күршелек, аш-су мәҗлесләрен юксынудан туган сагышын шушы тел чарлау белән булса

да алыштырырга тырышуы иде. Бу бик тә кызганыч күренеш, авылда сакланып кала алган әхлак, бу соңгы елларда бушап, әдәп-әдәбияттан ычкынган, буыннар бәйләнешен, йола-юллама, гореф-гадәтләрне оныткан, намазыннан ваз кичеп, кире мәҗүсилеккә кайткан татар-мөселманның сиздермичә генә иске совет тормышын сагынып чеңләве иде!.. Үзенә генә бикләнеп яшәгән, хәтта урманга җиләккә дә йөрүдән, мал асрап, печән чабудан да туктаган, кечкенә вакыйгаларны да зурайтып, тарих ясаган, шуның белән картаюга, юкка чыгуга барган авылның утырып еларлык бер дәһшәте иде. Без чынлап та, үзебез бер җыен булып оешкан һәм һәр очраклы кеше катнаша алган бу җыеннан нибары дүрт авылдаш – инде картаеп барган ике хатын, алардан яшьрәк Исмәгыйль, Исмәгыйльдән яшьрәк булган мин, бишенчебез – миннән яшьрәк булган сатучы Пүләнә – вакыйгадан вакыйгага сикерә, мизгеленә карап, гаепләүче прокурор, мизгеленә карап, хөкемдар, мизгеленә карап, шаһит, мизгеленә карап, яклаучы-адвокатка әйләнеп, бер-беребезне гаепли, һөҗүм итә, яклана, аклана, аннан рольләрне алмашып, тагын гаепли, янә дә һөҗүм итә, чигенә һәм аннан кемнең гаепләүче, кемнең гаепләнүче икәнлеген дә онытып, буталып кала идек. Шунысы кызык: безнең арада гаепләнүче булып та, без аны нишләптер гаепләмибез, күрмибез, ә бәлки, гаеп эчендә үзебез дә эреп, гүя юктан фаразлап кына, кыскасы, Горбачев әйтмешли, «процессны башлап», аңа башыбыз-тоягыбыз белән кереп баткан идек.

– Сүлә инде, Кафисәттәй! – дип өзгәләнде үз урынына кереп өлгергән Пүләнә. – Пескә, яшьләргә кысык тарих пит!..

– Сиңа кызыктыр ла ул, безгә кысык бит... Әмма аны ачыклар урын авыл лафкасы түгел...– Хафизәттәй тирә-ягын сөзеп, күзеннән үткәрде, ул үзенә теләктәшлек көтеп, берничә секунд торды, әмма аны тапмагач, җим эзләгән үрдәк баласы кебек, җай гына капшангандай итеп, Исмәгыйль абзый каршына барды һәм ярды да салды:

– Шул заманнардан кансыраган яраларны актарасыз... Азагы хәерле булсын. Яшьлек дәрте гөнаһ булалмый! – Ул Исмәгыйль каршында боҗра ясап, янә дә борылыштагы чанадай чалулап үз урынына килде дә һөҗүмгә күчте. – Яшьлек маҗарасы өчен картлыкта түләнергә тиеш түгел!.. Йә, әйт әле үскәнем, минме сиңа тугры булмадым? Син бурлыкта тотылып утыртылгач, кем азык-төлек күтәреп, Бәләбәй өтерманенең юлларына тузан төшермәде? Мин түгелме?!

Исмәгыйль абзыйның йөзе җил кунган су өсте кебек җыерылды, чырае буйлап чаткылы яшеннәр шуышты, шадралары исә тагын да куерып тирәнәйде. Баскыч өстендәге ике тәкә шикелле мөгезләрне чәкәштереп, бу көтелмәгән сөйләшүне дәвам итәргәме-юкмы икәнлеген шулай газапланып хәл итә иде ул хәзер. Ниһаять, ахры, бер фикергә килеп, Хафизәттәй түгел, Пуләнә каршына барды.

– Синең хакыңа гына чишеләм, сеңлем... Чибәрлегеңне сакла!.. Масайма!.. – диде, сүзләрен санап кына чыгарып. – Кайберәүләр кебек, хаталана күрмә...

Аннан кинәт кенә Хафизәттәйгә борылды:

– Дөрес. Булды ул хәл. Әмма син шунысын... шунысын онытма, Матур Апа... Мине төрмәдән шулай сызгырырга өйрәтеп чыгаручы да син үзең түгелме? Синең хыянәтеңнән соң... Минем шундый бар кешелеккә ишетелерлек итеп чеңлисем, «Кара урман»нарны җырлыйсым, шундый итеп моңланасым килде... Әмма төрмәдә җыр тыелган булгач, мин гражданин нәчәнниктән, яхшы урман кисүче... балтачы булганым өчен сызгырырга рөхсәт алдым. Орден урынына!.. Көн саен ярты сәгать сызгырттылар. Ырадиу итеп!.. Мин сызгырганда уянып, урманнар да моңлана иде!.. – Ул тамагына торган ыргаклы төерне йотып

җибәрә алмыйча газапланып, Хафизәттәй каршына килде, күзләренә укталып, аңа иң төп соравын бирде.

– Үзеңнең бүләгеңне кайтарып биримме? Сызгырып күрсәтимме? Телисеңме?!

– Сыскыр, Исмәкил апсый!.. – дип җанланып куйды Пүләнә. – Сыскыр да куй!..

– Кирәкми! – күчәрдән ычкынган чәкүшкә кебек, Хафизәттәй уртага сикереп чыкканын сизми дә калды. – Мин аны ишетеп болай да туйган!.. Һәр иртә, һәр кичтә!.. Газап!..

Минем алдымда кечкенә бер авылның бик зур тарихы – без белмәгән фаҗига күренешләре ачыла бара иде.

Әмма Исмәгыйль абзый шаярмаган икән. Ул кузгалган иде.

– Мин – ир, син –хатын-кыз, Матур Апа. Һәр җан иясе... үз җенесенә... намусына тугры калып... үз бурычын үтәргә... – Ул бердәнбер сүзне эзләп беразга туктап торды. – ... дастуин булырга тиеш!.. Без, тоткыннар колоннасы, Дәүләкән яланнарында авыр бомбардировщиклар өчен аэродром төзегәндә... Караиделдә йөзьяшәр урманнарны екканда... синең авылыбызга килгән буравай җегетләре белән типтерә башлаганыңны ишеткәч, мин шундаен да... шундаен да бәгырем белән өшедем, сызгырганнан соң да җылына алмагач, агач кәүсәләрен кочам һәм алар мине, биш кила он өчен биш елга утырып, вакытында өйләнә алмый калган җегетне, анам кочагыдай җылыталар иде!.. Әйе, кәүсәләр туң түгел, күңелләр генә туң!... Кәүсәләрдә җирдән күтәрелгән сут ялкыны яна, ышанасызмы?.. Син бит боларны беләсең, Мәфтуха җиңги!..

– Белмиме соң! – Мәфтуха үксеп куйгандай итте. – Ничек белмим, ди!.. Берегезне мактап, икенчегезне хурлыйсым, яманлыйсым килми, әмма әйтмичә дә калалмыйм. Сезнең табышуыгыз без – трахтырис кызлар алдында булды бит. Әле селәгәе кипмәгән, биш яшькә кече яшүсмер егетне үзеңә караттың да аннан буравай бүреләренә ерткаларга ыргыттың бит, Хафизә! Шулай түгел диген? Ир-егетләребез фронтта кырылгач, шушы ундүрт яшьлек Исмәгыйль безнең эзвинода бердәнбер трахтырис үсмер иде. Без – сугыш аркасында җегетләрсез калган, күкрәкләрендә җенес җене котырткан дүрт кыз, дүрт ана бурзай!.. Һәм син – балалыгыңнан чыкмаган бердәнбер ир заты!.. Безнең арада өлкәнрәк булсак та, сине үзебезгә карату, соңгы чиктә, шушы иреннәреннән бал тамып торган бердәнбер җегетебездән үзебезне яраттыру өчен яшерен ярыш бара иде. Син моны сизенеп тә карамый идең, Исмәгыйль туганым!.. Җегет өчен ярышта син җиңдең, Хафизә, әмма син аны тиз расхутка чыгардың... Без, кызлар, мәхәббәт мендәренә ятар урында, беребез эрүльдә, беребез сабан артыннан плугар булып ышырыла, беребез төннәрдә алдан Исмәгыйльнең кан сауган күзе сыман кызарып, крәчин фонаре белән алдан төшеп, сөреләчәк җирне яктыртып килә... Их, ул көннәр!..

– Минем күзгә кагылма, түтки, – диде Исмәгыйль кырыс кына. – Үз буразнаңнан чыкма, яме. Без, авыл җегетләре, яшьләребезне буравай шакалларыннан талаттырмас өчен ут йота идек. Без көчле, әмма... тыйнак, әдәпле идек шул!. Кызларыбызны бозган килмешәкләрне каезлар өчен без көннәр буе күзләрдә яшен яшьнәтеп, эрзин ышланкылардан шомпол шомартабыз, әмма кич җитсә, төннәрен, аларны билгә асып чыгарга, тегеләргә каршы күтәрергә кыенсынабыз... Сукмас зур күтәрер, дигәннәре хак икән. Их, бу татарның куркаклыкка тиң тыйнак сабырлыгы!..

– Әйт әле, Хафизә ахирәтем, Исмәгыйльне салам күбәсенә төртеп егып,

аны котырган дәртең белән оят җирләрен капшаганың, кочаклап үпкәнең, «Их, Исмәгыйль үскәнем, нигә бераз зуррак булмадың, без синең белән өзелеп яратышкан, өйләнешкән булыр идек, әйдә, хет башыңдагы бетләреңне карап юаныйм!» дип инәлгәннәрең хәтереңдәме? Шулай бер тапкыр аның башын караганда, син: «Һи-и-и, үскәнем, мондагы җанварның очы-кырые юк, әйдә, башыңны крәчингә тыгып кырдырыйк», дигәнеңне онытмадыңмы? Исмәгыйль үзе алдыбызда басып тора, ялганларга бирмәс. Син трахтырга дигән крәчин белән бидрәне тутырдың... «Шушы крәчинне минем мәхәббәтем хакыма эчәргә әзерсеңме?» «Әзер!» – ди Исмәгыйль. «Башыңны да тыгарга әзерсеңме? «Әзер!» – ди Исмәгыйль.

– Дүррәк! – дип кыстырып куйды Исмәгыйль абзый. – Мин дә инде!..

– «Бәй, алай булгач, башыңны тык, бетләреңне кыздырыйк!» – ди бу. Кызлар каршыңда каушап калмаска, үсәргә, тизрәк ир корына кереп, егетлек күрсәтергә тырышкан Исмәгыйлебез, аны-моны уйлап тормыйча, имән бармакларын колак тишекләренә тыга да башы-күзе белән крәчингә чума... Без тартып чыгармасак, ул, бәлки, бүгенгә кадәр чыкмаган булыр иде. Көлсәң, көл, еласаң, ела!.. Хакмы, Исмәгыйль?

Пүләнәгә һәм миңа ияреп, Исмәгыйль абзый да елмайды.

– Ул чакта баштан бет карау сәвит дәүләтенең бишьеллык планнарында иде бит... – диде Исмәгыйль тыныч кына. – Шунысы хак: мин крәчин бидрәсеннән чыкканда, күзсез идем инде... Крәчин утында янган башым белән Аккош күленә дә сикердем сикерүен, әмма ул да коткармады...

– Ялганлама, үскәнем, — дип каршы төште Хафизәттәй. – Син күзеңне өтермәндә калдырып кайттың!..

– Юк, Исмәгыйль өтермәннән кайтканда күзле иде!.. Ул буравайга урнашкач, синең чит ирләр белән шухыр-мухырларыңнан туктый алмаганыңа үзе күреп ышангач, синнән ваз кичте һәм син... һәм син, явызбикә, аның Гөлзәйнәбеннән көнләшеп...

– Юк, бу чеп-чи ялган!.. – Хафизәттәй Мәфтуха җиңгигә әйтеп бетерергә бирмәде. – Йоласы шундый: тора-тора күл сазга, ир тазга әйләнә!..

– Бер дә әйләнми, әгәр үзең әйләндермәсәң! – диде аңа, кискен каршы төшеп Мәфтухаттәй. – Синең ул чакта авылга килгән рабучий класстан тишегең тегермән ташы кебек кызган иде шул, ахирәткәем. Һәм син Исмәгыйльнең башын әйләндереп, сыртына салдың да куйдың...

– Минем яманатны сатып, шулай дискридит итәсегез киләме? Бирермен мин сезгә дискридит!.. Сезне хөкемгә бирәм, билләһи!..

Һәм Хафизәттәй чыгарга дип ишеккә юнәлде.

– Ә мин сине чыгармыйм! – Мәфтухаттәй ишек катына барып, аркылы агач булып аркаланды. – Мин бу сөйләшүне илле ел көткән идем!.. Язучыга шаһит булырга насыйп иткән икән!..

– Тавыш күтәрмәкес! – Пүләнә инде икенче кат урыныннан кубарылып чыкты. – Перүк!..

Миңа бу манзара куркыныч булып китте. Туктатырга кулымнан килмәгәнгә, бу нәрсә белән бетәр икән дип борчыла да башладым. Әмма кәртләр ачылган, очколарны санайсы гына калган иде.

– Мин авылга да кайтмаган, буравайга эшкә дә урнашмаган булыр идем... Әгәр дә... – Исмәгыйль сүзен нидән башларга икән дип туктап калды. Аннан исән күзен бер ноктагы төбәп, акрын гына сөйли башлады. – Әйе, яшьлек гакылсызлыгым белән мин аны үземнән өлкән булса да, чынлап та яраткан

кебек идем. Ә ул – матур, шундый матур иде! Каян туа андый матур хатыннар? Начар хатыннар шулардан яратыламы? Булмас!.. Иркәләгән чакларында... ул аеруча чәчкә ата, нурлана иде. Мин бит аны шуннан соң Матур Апам дип йөртә башладым...

– Хак! – дип раслады бу сүзләрне Мәфтуха җиңги. – Безнең шул сүзне ишеткән саен эчебез көя иде!..

– Гыйшыкның күзе сукыр, колагы чукрак аның. Мин дә үземнән өлкәнрәк дип тормадым, Матур Апага өйрәнеп киттем. Башкага өйрәнү, кешесенә карап, яратудан көчлерәк икән. Ярату дигәне соңлап килә. Келтемпие килеп җитсә. Җитмәсә, бөтенләй дә килми куя... – Исмәгыйль абзый да гүя теле чишелеп, боларны яшьләр өчен сөйли иде. – Безнең араны мәхәббәт дип булмагандыр да. Әмма яралгысы бар иде... тик шул келтемпие җитмәгәч, туктап, чигенде, күрәсең... Башка сәбәпләре дә булгандыр. Төп сәбәбе: сугыштан соңгы ачлыктыр аның!.. – Ул авыр, озын итеп тын алды. – «Әгәр мине яраткан ир-җегет булсаң, анавы Бүре Садретдин келәтен басып, андагы түшкә-түшкә итне безгә алып чыгар идең, ичмасам!» – дидең син көннәрдән бер көнне. – Колхоз өчен кыл да кыймылдатмыйча, палнамучларны эчереп, хатын-кыз белән өегештереп ята!»

– Ялганлама! Алай дигәнем булмады!

– Ничек кенә дидең әле. Әүвәлдә мин моңа әллә ни игътибар бирмәдем. Бу коткы минем күңелгә бер кара корт булып оялаган иде. Төнгә каршы эсминәдән кайтсам, өемдә минем газизә әнкәм, өч кыз туганым, ашарга сорап, ач карыннарын тырнап, елап утыралар!.. Теге үзәгемдәге син салган корт бу минутта кара ыргакка әйләнеп, эчкәйләремне актарып чыгарды. Нишләп берәүләр, калхузга төкереп, балда-майда йөзә, калхуз дип изелгән икенчеләр ач карыннарын тырнап җылый?! Мин нәфрәттән урын табалмый котырдым. Эчемдә кайнаган ләгънәтемнән мин шул төндә кулыма дилбегә алып, Садретдин келәтенә төшеп асылынырга һәм аның башын өтермәнгә тыкмакчы булдым. «Минем үлемемдә колхоз коллыгы, Садретдин шикелле колхоз буржуйлары гаепле» дип язу язып, кесәмә салдым һәм... к-келәтнең салам түбәсен чокып к-кереп... кулымдагы элмәккә башымны тыгып аска сикердем... – Исмәгыйль абзый ары таба сөйли алмас дәрәҗәдә тотлыкты. – Ч-черек а-аркан күтәрә алмыйча өзелеп, муенымдагы элмәгем-нием белән он лары эченә төшеп чумдым... Көлсәң – көл, еласаң – ела, мине, ач-ялангачны, үлемнән монда да ипекәй – он коткарды!.. Асылына алмаган гарьлегемнән... шул онны урлап котылырга тиеш булганмын икән мин! Һәм мин, капчыксыз-нисез, караңгыда, киндер күлмәгемне салып, җиңнәренә кадәр төеп-төеп... төеп-төеп он тутырдым!.. Чыкканда, эте сизенеп, дау күтәрде. Мине, тегермән тартмыйча да онга баткан каракны, шундук эләктереп алдылар. Күлмәгем белән биш килога тарткан он өчен миңа биш ел чәпәделәр. «Җырчы Исмәгыйль»дән «бур Исмәгыйльгә» әйләндем дә куйдым. Биш елымны от збанка до збанка утырып бетерәм дигәндә, миннән, яхшы эшләгәнем өчен түгел... яхшы сызгырганым өчен үрнәк тоткын ясап, ярты елга иртәрәк чыгардылар. Әмма аның иң кызыгы икенчедә... Иң кызыгы менә кайда. Көтмәгәндә иреккә тиенгәч, мин аның белән нишләргә дә белмичә, авылга кайтырга теләмәдем. Чөнки анда мине синең... буравай идәнендә убший сөяркәгә әйләнеп, минем алдымда кылган хыянәтеңне күтәрү хурлыгы көтә иде...

– Сөйләмә, үскәнем! Ышанмагыз! Дөрес түгел!.. – дип чәбәләнде ишек катыннан тышка чыгарга теләгән Хафизә. Әмма аны Мәфтуха җиңги тышка үткәрми иде. – Мине бикләп алып, хөкем ясыйсыз! Ни хакыгыз бар?!

– Нишләргә? Барыр урыным юк... – дип дәвам итте тыныч кына Исмәгыйль абзый. – Авылга кайткан хәлдә... синең янындагы иректә тормыш... минем өчен иң әшәке төрмәләрдән дә әшәкерәк төрмә иде, билләһи!.. Чөнки мин сиңа, биш яшькә зуррак булсаң да, өйрәнгән, тәҗрибәсезлегем аркасында... никахсыз зина белән бәйләнгән идем. Мин аны ярату дип кабул иткән булганмын, беләсезме?.. Һәм мин, ышансагыз ышаныгыз, ышанмасагыз, ышанмагыз, кәтильщикләр белән килешеп, ике ай чамасы төрмә кәтильниендә качып яшәдем. Кәтильщикләргә бу бик файдалы иде. Алар төннәрен гыр да гыр йоклый, мин алар өчен пар куам. Алар мине апкилеп ашата, әлбәттә. Мине монда да эләктереп алдылар һәм милиция белән авыл сәвитенә кайтарып тапшырдылар. Менә мин ничек килеп таптым сезләрне! Ә сезләр ул чакта буравай халкы белән... Матур Апам!.. Сезгә бит, хатын-кызга, авылга да токмач урынына шома талун-макарун, крәстиян урынына рабучи подавай!.. Мин дә буровойга рабучи булып киттем. Синең мине җибәрәсең килмәде. Яңадан кол итәргә иттең. Беренче көннәремдә сине күрмәс... күземә күрсәтмәс... абайламас... онытыр өчен кесәмнән самагун шешәсе төшмәде. Аллага шөкер, соңрак эчкемнән дә котылдым. Күрше Гайнәдән Гөлзәйнәбемне төшергәч, үзеңнең бер чираттагы исерек хухелеңнән күзләремә агу сиптерттең!.. Мин бит кайчандыр синең хакыңа шул хлорны да эчәргә әзер идем, ә син аны күзләремә генә сиптертеп котылдың. Нигә кирәк булды сиңа мондый миһербансызлык? Фараларымның берсе яна, икенчесе сүнгән!.. Кире кайтар!..

– Себерке! – дип куйды Мәфтуха җиңги. – Аяклы прәблимә! Үзеңнекен чит итсәң, үзәгең дә читләргә калып җәзаланасың шул ул. Авылны эчкечегә сабыштырган бур-равайлар өчен җавап бирмичә булмый, сеңлем...

– Болай килеп чыгачагын белсәм... – дип уфылдады Исмәгыйль. – Ике аягымның берсен атламаган булыр идем...

– Дөрес әйтмисең, энем! Атларга кирәк иде! – дип аваз салды әле һаман Хафизәгә юл бирмәгән Мәфтуха җиңги. – Бу – яшьләргә сабак бит!.. Үтеп барышлый гына булса да!.. Онытмагыз, Аллаһы Тәгалә алдында җавап тотасыбыз бар. Моннан зиратка ерак түгел. Без бүген... бу кибеттә... шул зиратка үтеп барышлый гына очраштык. Барыбер аңлашасыгыз бар иде. Илле ел үтсә дә!.. Әйтергә генә җиңел...

– Кәнишне, Исмәкил апсый. Пескә кызык полар!.. – диде сары йөзе алсулана төшкән Пуләнә. – Шылай вит, Хафиза апа?.. Пер килеп аннашырга кирәк вит...

Әмма Исмәгыйль абзый әле һаман да суынып өлгермәгән иде.

– Кем уйлаган? – дип дәвам итте ул сүзен. – Синең хыянәтеңне ишетеп, бәгъре туңган мин, Павловка урманнарында агач кәүсәләрен кочаклап җылынган зэк, илле ел буе синең белән бер авылда бер-беребезнең бәгырен суытып, күрше яшәрбез дип кем уйлаган?! Әмма мин җылынып, җылыда яшәдем! Тик синең җылың белән түгел. Урманнарда агачларым, тормышымда Гөлзәйнәбем, балаларым – җимешләрем җылысы белән. Ә синең җимешләрең кая, ялгыз күке?!.

Шулчак Хафизәгә нидер булды. Ул күкрәгеннән «Аһ!» дигән аваз чыгарып алга, Исмәгыйльгә атылды һәм бар көченә Исмәгыйльнең яңагына сугып җибәрде.

– Мылтыктан калган куян! Хәзер икенче күзеңне агызам!..

Мылтыктан калып акайган куян! Сүзләрен ничек таба, диген. Хатын-кыз тарафыннан мондый гамәлне көтмәгәнгә, мин дә, Пүләнә дә, Мәфтуха җиңги дә Исмәгыйль белән Хафизә арасына кереп өлгерә алмадык. Хафизә шундый

көчле итеп сукты ки, Исмәгыйль абзый чирле күзе урынындамы, аннан шарылдап кан китә күрмәсен, исән күзе исән микән дигән куркудан ике кулы белән ике як битен сыпырып төште.

– Ә сез үз җимешләрегез белән бәхетлеме соң? Җимешләрегез черек түгелме? – дип тузынды ишек катында Хафизәттәй. – Уйлап карасаң, мин бит сездән күпкә бәхетлерәк! Ялгыз башым, тыныч колагым!.. Балаларың кем булды, Исмәгыйль үскәнем? Берсенең башы хатыны белән бергә бәлнистән чыкмый. Икенчесенең тырым-тырагайдан кайтып та күренгәне юк. Өченчесе үзеннән өлкән хатынга йортка кереп маташа түгелме? Биш бала үстереп, син бәхетлеме соң, Мәфтуха? Кайда синең газиз чебешләрең? Берсе дә куначаңда кукылдамый. Нигә син берьялгызың?! Мин яшь чагымнан ук кешенең гаиләдә бәхетле була алуына ышанмадым һәм бүген дә ышанмыйм!..

– Рәхмәт, Матур Апа. Мин балаларым өчен Аллаһ каршында үзем җавап бирәм, – диде Исмәгыйль, шешкән яңагын тагын капшап. – Рәхмәт, яме.

Башка бер сүз дә эндәшмәде.

– Исмәгыйльдән гафу үтен!.. – диде Мәфтуха җиңги. – Ярлыкау сора!.. Алдына тезлән, дәҗҗал!..

– Теслән инде, Каписә апа, – дип ялынды Пүләнә, ачыргаланып. – Шундый матур мәкәббәт какына. – Тесләнүнең нәстәсе пар? Мин пулсам, тесләнер идем...

Хафизәттәй, мин белгән, аның хакында төрлесен ишетеп үскән Хафизәттәй, әле балачагымда исеме ир-аттан аерылгысыз яңгыраган ап-ак тәнле хатын, аяк астын карышлап кына санап килеп, сатучыга елышты:

– Яшең баш әле. Телеңә салынып торма. Миңа шул ярты кила бабаевскийны... Бер кила макарун... Бер кила маргарин үлчә дә...

Без Исмәгыйль абзый белән кибеттән чыктык.

### III

Икенче көнне, кичләтеп, ул килде. Чирле күзеннән күзелдереген алган, күз чокырының тирәләре ничектер суклыгып, тартылып калган иде.

Абзый, үз шәфәгате белән бал коярга оста кеше, аңа ачы бал тәкъдим итте. Әмма Исмәгыйль абзый эчү түгел, бу юлы ут-күршесе кулыннан да алмады.

Җиләк өлгереп килгән мәл иде. Без җиләк әчкелтеме борыннарга кергән һаваны ерып, урыны белән чәчкә аткан, урыны белән атарга йомарланган бәрәңгы ызаннары буйлап, Кәркәле тавының Зөбәер абзыйлар тапкырындагы уйсулыгына таба юнәлдек. Исмәгыйль абзыйның бүген иртәнге якта сызгырганы ишетелмәде. Бу минем өчен бик сәер иде. Моңыннан язмаганмы?! Ул үзгәргән, хәтта тартылып, ябыгып та калган кебек. Исән күзенең гадәттәге куе коңгырты ничектер төссезләнә төшкән. Битендәге шадралары тирәнәйгән, маңгаендагы җыерчыклары да буразна-буразна булып телгәләнгән. Хафизәттәй, Мәфтуха җиңги, бу ачыктан-ачык, кызганусыз, хәтта кансыз сөйләшүнең очраклы шаһиты булган Пүләнә үзләрен ничегрәк хис итәләр икән, дип уйлап куйдым. Бераз гына өлкәнәя, үсә төштеләр, әллә, киресенчә, бераз яшәрделәр дә микән? Минемчә, бу сөйләшү безнең, йөз елның егерме бишәр елдан дүрт буыны вәкилләре өчен ифрат та мәгънәле булды кебек. Менә без мүк үләне кебек тыгызланып үскән су кынасы, кояш нурында көеп, көрән төскә керә башлаган кондырак, бадьян үләннәре келәмендә тирбәлә-тирбәлә, уйсулыкка җиттек һәм аның текә иңсәсендә пешмәгән җиләкләрне чүпләп азапланган чыпчыклар өерен пырылдатып, үзебезгә урын алдык. «Әгәр Хафизәттәй белән

яшь чагында никах укытып, балалар үстергән, берсе икенчесенә ничек кенә пар килмәсәләр дә, түзеп яшәп, килешкән булсалар, аларга карап, кайбер кеше «Кара, нинди бәхетле пар! » – дип сокланган булыр иде, дигән фикер килде миңа. – Кичәге бәхәс менә бит ничек итеп мөнәсәбәтләрне ачып салды. Әле алар арасында әллә нинди серле тарихлар бардыр. Сөйләтеп булырмы?»

– Малайлыктан бабайлыкка чыгу бер адым икән, – диде ул, миннән сорау көткән кебек көлемсерәп һәм мут егетләрчә исән күзен кыскалап. – Кичә малай гына идем, бүген бабай булдым, Мирас энекәш!..

Мондый очракларда кесәмдә теркәштереп барыр өчен куен дәфтәрем булса да, аны күрсәтеп, әңгәмәдәшне борчымаска, өркетмәскә, кирәкле детальләрне хәтердә калдырырга ният иттем. Сүзне ничек башлап китәргә? Беренче итеп нинди сорау бирергә? Күз алдыма тәрәзә яңаклары сандугачлы, пыялалары сиксән сигез өлгеле сарай кебек киң, инде оныклары чыр-чу килгән йортта, стан артында безнең якларда гына сакланып калган паласлар асалаучы Гөлзәйнәп җиңги килде.

– Гөлзәйнәп җиңги белән ничегрәк табыштыгыз, Исмәгыйль абзый? Шул хакта сөйләмәссеңме?

– Монысын инде үземә калдыр, – диде ул кырыс кына. – Тапкансың ир-егеттән сорар нәрсә. Кичә ишеттең бит. Язучыга шулары бик җиткән.

Бу хак иде. Язучыга чынлап та шулары артыгы белән җиткәндер. Урынсыз соравым өчен үземне битәрләп, икенчерәк сорау бирергә карар иттем...

– Син авылда өтермәнгә утырган беренче кешедер бит?

Ул миңа усал караш ыргытты.

– Патша заманнары өчен җавап бирмим. Авылыбызга каторжаннар нигез салганын беләсең. Өтермәндә утыручылардан совет заманында миңа билгелеләрдән мин – бишенче. Беренчебез – ат карагы Гобәйдулла, икенчебез – гаиләсе белән кулакка озатылган Сәхап, калган икебез – трахтырисларга өчәр кила он биргәннәре өчен өч ел утырган кладаушик Әмирҗан абзый һәм хисапчы Әүдәгый һәм мин – «Бур Исмәгыйль»... Күрәсең, барыбыз да диярлек, анавы чыпчыклар кебек, корсак коллары...

– Хөкем ничегрәк барды соң? Халык якладымы?

– Нинди яклау ул тагын? Яклау бездә – вак мәсьәлә.

– Нинди мәсьәлә эре була? – дидем мин, аптырап.

– Әнә тегеләр эрерәк... – диде ул, бездән бераз үрдәрәк үзара сугыша-сугыша, чөкер-чөкер килеп туң җиләк чүпләгән чыпчыкларга ымлап. – Мигрантлар. Әфганстаннан килгән «чегәннәр» алар. Кара син ул килмешәкләрне, Кафтау, Һиндекыш таулары артыннан килгәннәр, ә үзләрен шушы Кәркәле тауларының хуҗасы итеп тоялар. Титульный натсия, диләр мәле? Шундый әрсезләр. Менә кем безнең һише җебегәннәргә үрнәк!.. Җирле чыпчык халкы алардан курка, якын да бармый. Сугыш аларны бирегә китерде. Килгән мәлләрендә атыш тавышыннан саңгырау иде, мәхлуклар. Биредә, тынычта, колак барабаннары яңадан ачылды. Брежнев үз заманында безнекеләрне әфганнан табутта гына кайтартса, Горбач андагы армияләребезне уптым-илаһым сөреп кайтарды, рәхмәт төшкере. Ә безгә килгән мигрант чыпчыклар үз илләренә кире китмәделәр. Бирөдә яңа ватан таптылар. Яшәсеннәр. Безнең татарның исеме генә «тар»дан тора, җисеме чиксез океан аның. Чыпчык та белә: монда, Идел-Уралда, азык очсызгарак төшә... Ватан сугышы чорында да шулай булган иде. Шартлауга кеше түзде, җанвар түзә алмады. Гуртлары белән безгә бүреләр күчеп килде. Туп тавышларыннан башта җанвар, аннан гына кеше кача,

малайгынам. Украинадан Владивостокка кадәр урман-яланнарыбыз бүре белән тулды. Бүре тиз үрчи. Алар урамнарыбызда бишәр-алтышарлап гүләйт итеп йөри иде. Сугыштан соң самолёттан кырып бетерделәр. Өязебашта Волков дигән атаклы бүре атучы бар иде. 500 бүре сугып алган өчен аңа Ленин орденын бирделәр. Ул бүрене атмаган, холкын белеп «буйсындырган». Ана бүрене, бугазына очлы казык тыгып туктаткан да, биш-алты баласын күз алдында иялтеп кайткан да киткән. Волков бүредән курыкмаган, чөнки бүре баласын яклап кешегә ташланмый, ди. Тагын бала тудыра. Төлке дә шулай. Синең берәр тапкыр «фәлән-фәләнне бүре ашаган» дигән сафсатаны ишеткәнең бармы? Булмас. Шуңа күрә, без – төркиләр, аңа инде кыргыз-казахы да, чуваш-башкорты да төрекмән-үзбәге дә керә... борынгыдан үзебезнең анабыз итеп Ак Бүрене таныганбыз. Без бүре нәселеннән. Әнә нинди күмәк без – Ак Бүре балалары!.. Бүреләр колхоз фермаларына кереп, иллешәр-алтмышар баш сарыкны буып ташлый, кешеләрнең абзар түбәсеннән төшеп, кәҗә-сарык, хәтта ат-сыер малын да бугазлый иде, каһәрең. Ә менә эт дигәнең кешегә ташлана. Күмәк булсалар, кешене умырып ташларга да күп сорамыйлар...

Исмәгыйль абзый, истәлекләренә чумып, беразга гына тынып торды да яңадан сүзен дәвам итте:

– Ач авылны уратып алган бүреләрнең ничек улаганнарын ишетсәң! Кышкы төндә тышка чыгып, кәкәй иткәндә дә, бүре тавышын тыңлап утыра торганыек. Гүя ач балалар елый!.. Бүре эт кебек өрә белә. Әмма нәзек тавыш белән. Этләргә охшатып өрәләр дә, алдатып, этләрне күтәреп алып китәләр. Алар безнең Кашка дигән этебезне дә йоттылар. Эчләренә кергәнче чинады. Шул үксегән тавышы гына калды бахырның. Бүредән качкан этләр кайчак кешеләрдән ярдәм сорап, ишекләрне дөбердәтә иде, мин сиңа әйтим!.. Бүре Сәйфетдин келәтенә төшкән төндә дә бүреләр шулай улаганнарые... Әфган чыпчыклары да бүре кебек акыллы, тапкыр сугыш чукмарлары. Әнә, җиләк әле таштай каты, алар, пешмәгән дими, корытып бара. Сугыш аларны сугышырга өйрәткән, үз илләрен чит, чит илләрне үзенеке иттергән, Мирас энем. Кызык бит: син әнә теге җан иясен соры сандугач дип уйлыйсың, ә ул – чыпчык!.. Сандугач кебек матур сайрый да. Эскрипкәсе тел очында. Аерма шунда: безнең сандугачлар, рәхмәт әйтеп, ашый-ашый сайрый. Болар ашаганда сайрап вакланмый. Корсак хакына сыер мөгезенә генә түгел, кеше иңенә, коймаклы чәй өстәленә дә кунып сайрый!.. Тегеләр пошмасрак булса, хәтта песиләрне дә буалар. Мөгаллиме табылса, кешечә сөйләшә башлаячаклар, күр дә тор. Кичә кибеттән соң зиратка барып ураган идем. Капка каршында үлән кырган үгезнең сыртын чукый, имансыз!..

Исмәгыйль абзый миңа сугыштан качып, көнбатыштан безгә килгән бүреләр, әфган якларыннан килгән чегән чыпчыклар турында тулы бер гыйльми хезмәт язарлык мәгълүмат биреп өлгерде. Мин аңардан миңа сөйләргә теләгән тарихны көттем, ә ул һаман йозаклы калып, чишелеп бармады. Пошаманга төштем. Тегесе вак, монысы вак мәсьәлә. Әңгәмәбез ябышмый иде.

– Син шулай кинәт кенә... ничек сызгыра башладың соң, Исмәгыйль абзый?

– Менә бу сорау, ичмасам! – дип утырган җирендә сикереп куйды ул. – Әллә кайчан бирәләр аны... Мин сиңа шул хакта сөйләргә теләп килгән идем дә!.. Әтеү, әллә ниткән төче хатын-кыз сораулары биреп утырасың...

Ул тагын да бер мизгелгә тын калды. Фикерен туплап булса кирәк, кулындагы нәзек кенә чыбык очы белән алдында яткан каз мамыгын кузгаткалаштырды, тирән итеп сулыш алды һәм сөйли башлады:

– Кинәт кенә дип, дөрес әйтәсең. Кинәт булды шул. Ә бит мин элек болай итеп

сызгыра белми идем. Юк, тегеләй... малай-шалай, шпанача сызгырам, әлбәттә. Болай сызгыру... э-э-э, туган, ул икенче – икенче нәрсә. Анда өзелеп-өзелеп өзләргә кирәк. Әмма өтермәндә моңланырга, башкаларны моңландырырга ярамый!.. Анда гел куанып кына торырга кирәк. Ә миннән, куанычтан түгел, сагыштан күкрәк читлеген җимереп, моң чыга!.. Кая куярга?! Җырлый беләм – ярамый, шпанача сызгыруны әйткән дә юк, ярамый тек ярамый. Моңнан кибәм, корыйм. Нишләргә? Өзелеп-өзелеп өзлисем, өзеләсем килә, өзелә алмыйм!.. Шул чакта Ходай миңа ярдәм кулын сузды. Уралда, урманнар аударганда, тынлы музыка кораллары прафисыры Самуил Симанович дигән Житомир ябрәе белән танышкан идем. Җинаяте нәрсә, дисеңме? Сугыштан соң күршесе – икенче бер ябрәй контрабанд алтын белән сату иткән. Үзе ач булган Самуил абзый, имеш, моны белә торып, алтын саткан милләттәшен башкаларга сатмаган. Син кешене башкаларны сатмаган өчен утыртып кара әле!.. Сугыш чорында оккупациягә дә эләгә. Ябрәй немецның кан дошманы булса да, аны үлемнән немец солдаты коткара. «Уходь проч. Неметц отступай, – дигән ул аңа. – Неметц плохой, неметц отшень злой». Дуслашып киттек. Мин аның колагына пышылдап кына җырлыйм. «Татарин – лучшая гармонь», – диде ул миңа. Ябрәйнең аның акылы хәйләсенә тиң. Бөек халык. «Әйдә, мин сине сызгырырга өйрәтәм, – ди бу. – Сызгыру – сәнгатьнең шундый төре, анда җандагы моң, тетрәнеп, тын алышына күчә. Синдә фортедан пианого кадәр барлык штрихлар да көчле чыгачак!» Нәрсәсе штрих, нәрсәсе форте, нәрсәсе пиано икәнен кем белгән инде! Һәм ул мине өйрәтте. Башта үзебезнең «Кара урман»ны, «Уел»ны, «Хафизалам иркәм»не тыңлады, үзе өйрәнде, аннан мине сызгырырга өйрәтте. Бераз соңрак Иоганн Штрауснның «Вена урманы экиятләре»н...

Мин аһ итеп чак урынымнан сикереп тормадым. Авылдашым Исмәгыйль абзыймы, әллә икенче кешеме бу?! Төшемме, өнемме?

– Син Штраусны беләсең?! – Исмәгыйль абзый алтын тапкандай куанып куйды да, аннан үзенә-үзе җавап та бирде. – Шундый да бөек композитор... Композиторлар гаиләсе бар! Атасы да, үзе дә, Иоганның ике бертуганы Йозеф белән Эдуард та композитор булганнар...

– Беләм. Әмма кызыксынганым юк, – дидем мин ялганга кермичә.

– Кызыксын! Үзең вуз бетергәнсеңдер әле...

– Икене.

– Аһ, хәтта икене. Ә Штраусның биографиясен белмисең... Минем үземнең коридорлары белән өч класс. – Ул чынлап та мине ачуланып алды. – Әвстрәкләр алар. Венадан. Ерак бабасы нимескә күчкән ябрәй. Адәм баласы Штраус вальсын белмәсә, ул үлгән, димәк. Мин аның үткәнен яттан беләм, диярлек. Лесоповалдан кайткач, Симанович миңа төрмә китапханәсеннән Штрауслар нәселе турында китап табып бирде...

Исмәгыйль абзый күзләрен челт-челт йомгалап, Штраус «Әкиятләре»нең кечкенә бер өлешен сызгырып та куйды. Мин бу гүзәл вальсны, бу гүзәл серенаданы, әгәр шулай атарга яраса, бу гүзәл опереттаны үз янымда, иңемә кунган сандугачтан ишеткән кебек ишетеп, таң калдым. Бәй, теге көнне чәй артында ишетеп таң калган көем менә нинди көй булган икән! Мин бу үлемсез моңны көннәр-төннәр буе тыңларга әзер һәм һич кенә дә туктамавын тели идем. Әмма ул шып туктады.

– Алай гына, дисеңме? Җаен табып, Симанович башта мине гражданин начальникларга тыңлатты. Наган кобурасы кебек майланып беткән төрмә

сакчылары да телсез калды, малайгынам. Йөрәк аларда да бар!.. Менә нишләтә сызгыру, сызгыра белеп сызгырсаң... Һәм алар миңа һәр көнне, кичке аштан соң көненә ярты сәгать башка зэклар өчен дә сызгырырга рөхсәт иттеләр. Мин шундаен да сызгыра башладым, җырның барлыгын да оныттым. Җырга бик күп көч кирәк. Ул моң белән җир сөрү. Сызгыру – моңны тында кайрап ял итү... Ул җиңелрәк. Мин күкрәк җырыннан ваз кичеп, җилгә күчтем дә өзли башладым. Минем моңымнан төрмә халкының кайберләре, моңа кадәр башлары карцердән чыкмаган башкисәрләр дә, ачу-явызлыкларын эчкә йотып, юашлана, нечкәрә, кешеләнә бара иделәр...

Ул, күрәсең, шул көннәрне алдыннан үткәреп, азга гына тынып калды.

Каршыбызда – икедән үрелгән бау кебек сузылып яткан туган авыл урамы, әле кузгалырга гына ниятләп торган печән өсте һәм башка бихисап мәшәкатьләр белән хуҗалары урман-болыннан кайтып кермәгән ихаталарда шылт иткән тавыш та чыкмаган, әле кич булып өлгермәгән, әмма тузан тузгытып, кайтасы мал көтүеннән үзен узып килгән мал исенең танауны кытыклаган бер сихри мизгелендә мин кичәге зэк Исмәгыйль абзый авызыннан Штрауслар гаиләсе турында хикмәтле хикәят тыңлый идем... Шаклар катарсың!..

– Әкәмәт аларның тарихы!.. Гаилә башлыгы Давид Штраус, Австрия патшасының скрипкачысы һәм дирижёры була. Үз гомерендә ике йөз илле вальс, безнеңчә әйткәндә, парлы бию көйләре язган. Әтисе даһи, әмма баласы аңардан күпкә даһирак булып чыга: бөтен дөньяга танылган иң атаклы «Вена урманнары»н Давид абзый түгел, ә менә шушы улы Иоганн язган, малайгынам!.. Ата улыннан гомер буе көнләшеп яши. Мин укыган теге китапта үз баласыннан шулкадәр көнләшкән, баласы белән шулкадәр ярышкан ата кешелек тарихында булмаган, дип язылган иде. Бу кадәр көнчел күбәләк хәтта безнең кебек вак көнчел татарда да очрамый. Штраусларның гаилә кәмитенең барлык сере менә шунда күмелгән дә инде!.. Австриянең иң бөек композиторы, вальслар атасы данына ирешү хакына хыялланып җиңеләйгән ата улының дистәләгән вальслары, «Гүзәл Дунай буенда», «Ярканат», «Чегән бароны» сымак атаклы оперетталарын инкяр итеп, һәр әсәренә таяк тыгарга тырыша. Шундый тамашаны күз алдыңа китерә аласыңмы: тумышыннан аксөяк булмаса да, аксөякләр оркестрында дирижёр булган музыкант улына карата тыеп торалмаслык көнчелеген сарай аксөякләренә хас нечкәлек – башына калфаклар, бәби итәкле күлмәкләр киеп, ләззәт белән, җиренә җиткереп, тормышка ашырган!

Әтисе балачагында аңардан сәүдәгәр ясарга теләп, сәүдә мәктәбенә бирә, кичләрен таяк белән кыйный-кыйный, гел берүк күләмдәге акчаны саната, ә ул башбаштакланып, әнисе ярдәме белән музыкага тартыла. Атасы ихтыярына каршы барып, әнисе кул астында музыкаль белем алганнан соң, дирижёрлыкка гариза биргәч, өлкән Штраус бу гаризаны ертып ташлый...

Имәнлек, Сәнкә урманнары өстендә кичке шәфәкъ ялкыны тирбәлә, һәр нәрсә яктылыктан чыгып күләгәгә, күләгәдән чыгып, яктылыкка керә, шулай сиздермичә генә урыннарын алмаша башлаган гаҗәеп мәл иде. Тирәбездә өерелгән әфган чыпчыкларына ымлап:

– Әнә, күрдеңме? Боларга боламыкны өеңдә бутап, үзең белән йөртергә кирәк. Югыйсә, өстеңнән дә төшмиләр. Көш-көш-шү! – диде ул кулындагы чыбыгы белән тирә-ягына кизәнде. – Сөйләргә бирми, биглыйлар... Кайда туктаганием әле?

– Гаризасын ертып ташлый...

– Әйе. Давид Штрауcның ярлы, ачлык-ялангачлыктан чыга алмаган гаиләсе ел

саен фатир алыштыра. Хатыны иренә яңа фатирга күчкән саен бер малай бүләк итә. Алар һич тә ярлыбыз дип тормыйлар, юкны-барны уйламыйлар, туйганчы уйныйлар: ун фатир алмашканчы балаларның саны унга тула да куя. Яңа бала туу белән Вена «Штраусларда тагын малай!» дип барабан кага торган булган. Безнең бүгенге бер иркәби бала үстерүдән ары узмаган яшь ата-аналарыбызга нинди матур үрнәк, әйеме? Музыкадан башка бернәрсә белән кызыксынмаган өлкән Штраус гаилә эшенә кысылмый, бала тәрбияләүнең нәрсә икәнен дә белми. Ул гынамы? Давид абзый бик тә хатын-кызга хирыс була. Берсен дә чираттан үткәрми. Шуңа күрә нәүбәттәге яңа фатирга күчкәч, ул аның хуҗабикәсе белән мавыга һәм, теге хатынын аерып, яңа хатынга өйләнеп, монысыннан да җиде малай ясауга ирешә! Ышанасыңмы, җиде!.. Кая бездә хәзер шундый текә холыклы җегетләр?! Тәрбияләрендә катнашып, үрнәк ата булмаса да, ул үзенең ике хатыннан туган унҗиде ир бала атасы булганлыгын яшерми, киресенчә, моның белән горурланып, масаеп яши. Ха-ха-ха! – Исмәгыйль абзый беренче тапкыр шулай дөньясын онытып көлде. – Болар гына дисеңме? Беренче, икенче хатынын, аңардан туган унҗиде баланы мәхрүм итеп, ул үзенең барлык тапкан малын, мөлкәтен Эмилия Трампуш дигән сөяркәсенә калдыра. Менә шушы шартларда әнисенә һәм үзенә күпме газаплар күрсәткән этисенә үч итеп, Иоганн Аллаһ каршында этисеннән дә яхшырак композитор, вальслар, оперетталар остасы, этисеннән дә нечкәрәк дирижёр булырга ант итә. Балаларыннан аерылмаган атасы исә, аны яраткан һөнәреннән тыеп, эрзин шомполлар белән кыйный, оркестрдан китәргә мәҗбүр булгач, үз урынына улын алдыртмас өчен ул ниләр генә эшләми!

Иоганн кыска гына вакытта патша оркестрының иң атаклы музыкантына әверелә. Әмма аны баш дирижёрлыкка якын да җибәрмиләр. Этисенә охшап, ниятен ике уйлап тормастан тормышка ашырган Иоганн, үзенә карата мондый битарафлыкка чыдый алмыйча, үпкәләп, Питырбурга дип юлга чыга. Аны Рәсәй императоры бик зур акча түгеп оркестр җитәкчесе итеп яллаган була. Питырбурда Ольга дигән аксөяк кызга гашыйк була, аның кулын сорый, әмма ата-аналары Иоганның кара нәселдән булуын искә алып, кызларының нәфис кулларын аңа тоттырып та карамыйлар. Урыс императорының ихтирамыннан файдаланып, туганнарын Питырбурга чакырта. Алар да бик тырышып музыка язсалар да, «Вена урманнары әкиятләре»н, «Чегән барун»нарын язган агалары бөек композитор Иоганн Штраусны уздыра алмыйлар. Холкы белән ата баласы булган Иоганн ундүрт Питырбур аксөягенең ундүрт булачак кәләшенә күз кыса, әмма уңышка ирешә алмый. Яна-яна йөрәге көлгә калган Иоганн Венасына кайта. Аптырагач, ул үзеннән җиде яшькә зур, җиде сөяркәсеннән җиде баласы булган Гертрудасына килеп каба. Һәм – үз бәхетенә!.. Гертруда җиде баласын җәһәт кенә җиде атасына таратып, Иоганнга кияүгә чыга. Ха-ха-ха! Нигә көлмисең, Мирас энем? Көл! Кызык бит! – Ул минем касыкка төртеп алгач, без икәүләп көлеп куйдык. – Син Хафизә, дисең. Штраус ундүрт кәләш белән идарә иткәндә, мин бер Хафизә белән идарә итә алмадым! Бәлки, миңа башта Штраус кебек падишаһ оркестры белән идарә итәргә кирәк булгандыр, ә? Ничек кенә булмасын, биш яшькә зур Хафизәне үземә өйләндерергә насыйп итмәде!.. Аһ, чибәр, аһ, акылсыз наян иде ул!..

Гертруда аны бик ярата һәм Иоганны сигезенче баласы кебек тәрбияли, чын-чынлап анасы, илһамчысы, концертларын оештыручы да була. Ялгышмасам, 1887 елда Гертруда инде үсеп җиткән бер баласыннан хат ала, шул хатны укыганда, йөрәге ярылып үлә. Аның ни сәбәпле үлгәнен әлегә кадәр белмиләр...

Авыл очыннан Өязе үзәннәренә кичке салкынлык вәгъдә итеп, тузан күтәрелде. Тирә-якны мал мөгрәгән, тамакларына кайнар тузан капланып төчкергән мал тавышлары басты. Әлегә энә сапларлык дәрәҗәдә якты, әмма күзләрне бәйли башлап, көтү төшә иде...

– Бу үлем Иоганны зур кайгыга сала. Ул, Венаның иң атаклы композиторы һәм иң бай кешесе, кайгысыннан нишләргә белмичә, ашык-пошык Анжелика дигән карт кызга өйләнә. Әмма Анжелика инде бу чорларда ирлеген югалта башлаган композитор белән ястык уртаклап азапланмый, аны ташлап китә һәм икенче ир белән яши башлый. Озак та үтми, Иоганн үзе кебек Штраус фамилиясен йөрткән тол хатын белән кушыла. Ул аңардан бик тә уңа һәм 1899 елда аның кулында җан бирә. Беләсеңме, үз гомерендә күпме әсәр язган ул? Мин боларны да яттан беләм: 170 вальс, 117 полька, 73 кадриль, 43 марш, 31 мазурка, 16 оперетта! Менә кем ул мин сызгырырга яраткан «Вена урманнары»ның иҗатчысы Иоганн Штраус!.. Композиторны барлык Вена җирли. Җеназада аягында басып тора һәм йөри алган һәр кеше катнаша...

Исмәгыйль абзый бик дулкынланган иде. Ул Өязе елгасы буйлап якыная килгән мал тавышына колагын салып, тын калды. Гүя ул Штраус биеклегеннән чынбарлыкка кайта алмыйча газаплана иде. Аның тавышы утырды. Мизгел үттеме-юкмы, ул бөтенләй икенче аһәң, икенче, ничектер карлыккан тавыш белән сөйли башлады.

– Мин үзем, кеше буларак, Иоганн Штраусның тәрбиялелеге, кешелеклелегенә таңнар калам. Бер караганда, ул үзләренә күпме зыян китергән әтисен гомерлек дошман итеп күрергә тиеш иде бит ул. Әмма – юк! Шау-гөрле тормышта иркен тәгәрәп яшәгән атасы нибары кырык биш яшендә үлеп киткәч, Иоганн, өлкән бала буларак, әтисен зурлап күмүне оештыра, аның кабере... барлык Вена халкы алдында эскрипкәдә Моцартның «Реквием»ын уйный. Ата хакы!.. Тәңре хакы!.. Аның барлык әсәрләрен туплап, китап итеп чыгара. Атасы истәлегенә... тарихта кабатланышы булмаган мең кешелек оркестрның дирижёры сыйфатында шул ук «Реквием»не башкара! Күз алдыңа китерәсеңме – мең кешелек оркестр! – Ул сулкылдап, үксегәндәй итте. – Мин, менә син, Мирас туган, хәерчелеккә төшерелгән ятимнәр, Иоганн кебек шулкадәр атаклы, шулкадәр бай булган булсак, күкләрдән төшеп, үзебезне рәнҗеткән атабыз алдында Иоганн шикелле шушындый киң күңеллелекне, батырлыкны кыла алган булыр идек микән, ә?.. Белмим!.. – Аның күңеле йомшарды. Ул читкә карап куйды. Исмәгыйль абзый Зөбәер уйсулыгында Штраус рәвешенә кереп, яшен эчкә йотып елый, аны күрсәтмәскә тырышып сыктый иде. – Минем әткәй сугышның азагында... нәкъ әнә шул Вена өчен сугышларда һәлак булды. Әгәр мин Веналарга барып, аның каберен таба алсам, бу изге тупрак өеме алдында нишләр идем икән?! Юк, мин, Өязенең... эскрипкәсез-гармунсыз, мандолинасыз калган татар авылының баласы, барлык көчемне туплап, миңа гомер бүләк иткән атам кабере каршында Иоганн Штраусның «Вена урманы экиятләре»н, татарның «Кара урман», «Уел»ларын сызгырган булыр идем!.. Ишетсен әткәем-бәгърем, аның ятим улы исән!.. Туган моңы исән!..

– Германиягә Гитлер килгәч, барлык немесләрнең кан чисталыгын тикшерәләр, – дип дәвам итте хикәятенең азагын Исмәгыйль абзый. – Кабахәтлек, әлбәттә. Милләтне милләттән өстен кую чирен әйтәм. Үзең беләсең, тиле бәрән орлыгы ашап котырып, татардан башкорт ясарга омтылу күренешләре безнең илләрдә дә булып алды бит... – дип уфтанды ул. – Әмма барып чыкмады. Эрәзве мөмкин? Мин берүзем – берьюлы татар да, башкорт та! Ябрәйлеге аркасында

бөек Мендельсон тыелган илдә гитлерчылар бабалары Венгриядән Австриягә качкан ябрәй Штрауслар белән нишләргә белмиләр. Байтак баш ватканнан соң, нимес халкын Штрауссыз да калдырмас өчен, милләтен вакытлыча «нимес» дип язып торалар. Йә, әйт, бүген Штраусның кайсы милләттән булуын берәр адәм заты таләп итәме? Юк, итми. Ул Штраусның музыкасын сорый!.. Безнең кебек!..

Һәм без моңа кадәр «Шадра Исмәгыйль», «Бур Исмәгыйль», «Өтөрмә Исмәгыйль» дип кенә белгән Исмәгыйль абзый, туган авылының тау битләвендәге уйсулыкта җир йөзенең иң атаклы музыканты турында озын хикәятен тәмамлап, талгын җилдә җыерылган су өсте сымак итеп, иреннәрен бөрештерде һәм Штраусның «Вена урманы әкиятләре»н сызгырып җибәрде. Ул берьюлы тальян да, аккордеон да, баян да, эскрипкә дә, флейта да, мандолина да иде. Кичке һава тетрәнгәндәй итте. Сөт белән тулышудан җәядәй киерелгән имчәкләреннән юл читендәге үләннәргә сөт чәптереп килгән малдан аңкыган җылы сөт тәме, җылы мал исе шушы моң белән кушылып, тирә-якка мәңге үлемсез яшәү чынбарлыгын бүләк итә иде. Штраус үлемсез, аның «Әкиятләр»е үлемсез, хәтта андагы гүзәллек, андагы дәһшәт, андагы серне гади авылдашларыма тирән итеп ачып сала алган Исмәгыйль абзый үзе дә үлемсез иде. Йөрәкләргә үтеп, ераkларга китеп, ул нәкъ безнеңчә, татарча моңлана, чәчкәләнә, сибелә, эркелә, куана, сагышлана. Үтә дә милли гамьле, бәгыребездә кайнап, жаны-тәне белән кан-карындаш булган, икенче караганда, бөтенләй чит сагыш, чит мәкам, ят сөяк, алман-ярман гаммаларын искә төшергән бу көй тургай кебек күктә асылынып әйләнә-әйләнә дә, таш сыман түбәнгә атылып, югалып тора, сүлпәнәеп-көчәеп ала, аннан тагын килеп чыгып, талпына-талпына күккә күтәрелә. Аның «пиано» дигәннәре кайда башлана да, «форте» дигәннәре кайда тәмамлана икән? Биредә нинди «штрих»лар минеке дә, нинди крещендо, стакатолар, легатолар читнеке икән? Юк, алар барысы да минеке иде! Мин аларны беркайчан да беркемгә бирмәдем, бирми һәм беркайчан да бирмәячәк идем. Әнә ул шагыйрәнә Өязе-Дим буйлары, миннән кул сузымында булган Ырымбур далаларыннан яңадан диңгез киңлекләренә чыга, туйганчы сулыш ала, салмаклана, андагы тирән аһәң, андагы нәфислек, ирлек-хөрлек, үзәкләрне сыздырып төшкән нечкә мәкам – фальцетка калып, адәм баласына иң кирәк булган шифага әверелә...

Мин Исмәгыйль абзыйга карадым. Һәм танымадым. Ул канатланып яшәргән, йөзендә караеп ноктаaланган шадралары, тирән сызыклары югалган, чырае күкләрдән төшкән илһам белән яктырган. Ул кичәге Исмәгыйль түгел, бүген туган, моңа кадәр була алмаган, башкалар ярдәме белән аңлау-фикердәшлек табып, үткәндәге сагыш-борчылуларыннан арынган-бушанган искитмәле Исмәгыйль иде...

Мин горур һәм чиксез шат идем. Мин ишеткән бу көй, башка бер генә әсәрне дә кабатламастан, адәм баласының берьюлы тал-тирәк түрендәге сары сандугач, күкләргә эленеп, көмеш моңнар койган соры тургай, оясының ак баскычыннан энҗеләр койган кара сыерчык булып сайрый алуын раслаган илаһи бер манзара иде.

Ә Исмәгыйль җир йөзендә иң матур кеше иде.

Ул туктады. Без икебез дә моңнан хәлсез идек.

Сәнкә урманнары өстендәге ялкынлы кояш инде батып бара икән.

Без Суфиян тыкрыгы буйлап кайтырга юнәлдек.



Рәсимә
Гарифуллина

# ТУРЫ СҮЗ ДӘ КАЙЧАК ЯРАЛЫЙ

## Рәхмәт фәрештәсе

ШИГЪРИ ХИКӘЯТ

Үпкәләде әтисенә-әнисенә:
– Үлгәндә дә гафу итмәм сезне, – диде.

Шул чагында киңәш бирде бер фәрештә:
– Кичералсаң, җиңелрәк булыр иде...
Барыбыз да бер түлибез гамәл өчен.
Ходай сине гафу итсен, аңла, кешем.
Нишләтерсең бу кадәрле ачуыңны,
Әллә шулай аңлашудан качуыңмы?
Кайда сакларсың соң аны – кичермичә,
Шундый сандыгың барын да сиздермичә.

– Йөрәгемдә! – диде катып киресенә,
Ышанды ул үз уеның дөресенә.

Еллар үтте: кичермәде әтисен дә,
Бакыйлыкка күчеп китте әнисе дә.
Гаилә корды, бала бакты, акча тапты...
Ә ачуы тирәнгәрәк – төпкә ятты.

Тагын шул ук фәрештәсе киңәш бирде:
– Ачу җаныңны көйдерер, кичер! – диде.

Ачу ташка әйләнде дә төпкә төште,
Ә беркөнне яман шештәй башка күчте.

Рәсимә ГАРИФУЛЛИНА (1958) – *шагыйрә; «Минем куллар – синең кулда», «Йолдызлар юл күрсәтер», «Зәңгәр дуга» һ.б. китаплар авторы.Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре. Балык Бистәсендә яши.*

Бертуктаусыз баш авырта, сызлый йөрәк,
Сырхауларны дәваларга табиб кирәк.
Инде шунда йөгерде ул ярдәм сорап,
Юллар үтте, акча түкте дәва юллап.

Тикшерделәр, нәтиҗәсе бик куркыныч:
Башында – шеш, йөрәк беткән... Ни аяныч!..

Ярдәм сорап күккә бакты: «Раббым!» – диде.
Аңа тагын таныш тавыш җавап бирде:
– Әтиеңне, әниеңне кичер инде,
Шулчагында терелерсең, кешем, – диде.

Бу җавапка көлде генә:
– Булмаганны...
Мөмкинме соң?.. Гомер буе чыдаганны?..

– Сиңа башка котылу юк, кичермичә,
Йөрәгеңә шәфкать нуры күчермичә.

...Үзе өчен кирәк өметне күрде ул,
Әтисен дә, әнисен дә кичерде ул.

Аңа карап чир китмәде, хәл кермәде.
Ул кичерде... ә Раббысы кичермәде.

Һәм фәрештә тагын килде, акыл бирде:
– Инде хәзер чын күңелдән гафу сора,
Гомер буе үкенерсең юкса, – диде.

– Мин гаепсез, нигә миңа үкенергә?
Алар тиеш миннән гафу үтенергә.
Һәм фәрештә:
– Тезләнсәң дә таман, – диде –
Сине гафу итмәсәләр – яман, – диде.

Аңлады ул үз хатасын, акты яше.
Йөрәгендә бушлык тойды фәрештәсе.
Җанны баскан таш эреде кинәт кенә,
Бу халәткә түзсен инде йөрәк кенә!

Раббысына рәхмәт әйтеп дога кылды:
– Ник элегрәк белмәдем, дип, ул аһ орды.
Йөрәгенә шифа инде... рәхәт иде.
Аны саклаган фәрештә – «Рәхмәт» иде.

## Хәтер дәфтәре

Хәтер дәфтәремне җилләр ача,
Ни укырга аннан телидер?
Бер-бер артлы хатирәләр купты,
Ничек туктатырга белмимдер.

Җилгә рәхәт – кузгатты да китте,
Гарасаты калды җанымда.
Давылларын басып туктатырга
Син дә юк шул, бәгырь, янымда.

Күңел дәфтәремне җилләр ача,
Битен-биткә күпме хатирә.
Үсмер еллар күз алдына килә,
Тәүге сөю төшә хәтергә.

Салам чәчле, ялан тәпиле ул –
Югары оч урам малае.
Билсәпиттә бергә печән ташып,
Шаярышкан еллар, җәй ае...

Ул чагында аңламаган әле
Мәхәббәтнең нәрсә икәнен.
Хәтер дәфтәреннән яшьлек дәшә:
– Кал әйдә, – ди, – китмә, үскәнем!

Әмма анда калып буламы соң?
Алда әле җитди еллар бар.
Ымсындырган тормыш сукмаклары,
Мин узасы каудар юллар бар.

Һаман барам, тукталуны белмим,
Кемдер дәшә, нидер чакыра.
Әллә нинди маҗаралар мине
Көтеп тора тормыш чатында.

Мин яратып яшим бу җиһанны,
Һәр мизгелен тоеп, сөенеп.
Бу гомерне җирдәшләрем белән
Бергә кичәм, сөеп-сөелеп.

Хәтер дәфтәремне җилләр ача,
Хатирәләр бик күп – актарсаң.
Кылган эшләр, менгән үрләр байтак,
Сөйләр нәрсәләр бар – мактансаң.

Нигә масаерга? Ходай аның
Сынауларын үзе бирә бит.
Шатлыгы да, борчуы да анык,
Адәм башы барын күрә бит.

Бу гомердә хәтер дәфтәремнең
Язылачы күпме бите бар?
Бер киләбез җиргә, бер китәрбез –
Килгәннәрнең китәр юлы бар.

Хәтер дәфтәремне барладым бер,
Укып карар өчен гыйбрәт бар.
Яратканнар өчен мәхәббәт бар,
Ачы телләр өчен гайбәт бар.

Тормыш бит ул адым саен сыный,
Тигез генә түгел, сикәлтә.
Хәтер дәфтәремне җилләр ачып,
Яшәү мәгънәләрен искәртә.

## Күк түбәсе

Зәңгәр болытлары ак тауларны
Юрган итеп япкан шикелле.
Ул болытлар күк түбәсен бизи,
Аклык бизи безнең күңелне.

Таң атканда, күк түбәсе алсу –
Кояш нурларына коена.
Көнозынга җирне ямьгә күмеп
Кичке шәфәкъ керә куенга.

Ә төннәрен күк түбәсе айлы –
Меңәрләгән йолдыз яктыра.
Инсаннарны, хәерле төн теләп,
Бишек җыры көйләп яткыра.

Күк түбәсен бизәп йолдызлар да
Бәхет теләп кенә яналар.
Акыл төзек булса, төзек булыр
Җирдә безнең авыл, калалар.

Ходай үзе биргән бәрәкәтне
Кеше кулы пыран туздырса,
Кан-яшь белән тулыр тормышыбыз,
Яхшылыктан яман уздырса.

Күкләр түбәсендә кояш янсын,
Таңнар алсу булсын һәрдаим.
Адәмнәрдә шәфкать нурын сакла,
Иман нурын сакла, Ходаем!

## Көзге каеннар

Каеннарның сары ефәк шәлен
Алтын көзләр бүләк иткәннәр.
Сагынудан шулай саргаялар
Гомере буе кавышу көткәннәр.

Сары сагышларга әйләнгәнме
Өмет өзми көтү хәлләре?
...Тугрылыкның асыл билгеседер –
Каеннарның сары шәлләре.



Шикалёв
Максим

# МУЛЛА КЫЗЫ

хикәя

Алма җиңел турала. Тураган саен тәлинкәдә өелә генә бара. Кайбер кисәкләре зур өстәл өстендәге өрәңге яфраклары төшкән ашъяулыкта ята. «Грушевка» сорты аеруча тәмле. Казан тирәсендә күпләр утырта аны. Камырым да әзер, җиде яшьлек оныгым Гадел ярата торган алма бәлеше исе тиздән бөтен тирә-юньне әсир итәчәк. Менә үзе дә килеп җитте.

– Дәү әни, менә, кара, нәрсә таптым мин!

Кулларымны сөртеп, күзлегемне төзәтә-төзәтә кулыма аклы-каралы фото алам. Анда дүрт бала сурәтләнгән.

– Кайдан таптың моны, улым?

Күз яшьләремне көчкә тыеп калам.

– Китап арасыннан таптым, ә нәрсә? Елыйсыңмы әллә?

– Юк, юк...

Шулай дисәм дә, яңагымнан яшьләр агып төшә.

– Ә бу кем?

– Бу мин, туганнарым белән.

– Алар минем бабайларыммы?

Гадел тезләремә менеп утыра.

– Юк, бу минем абыйларым: Мөхәммәт, Сафа һәм Нурияздан.

Бала игътибар белән фотога карый.

– Дәү әни, син шундый кечкенә. Ничә яшь соң сиңа монда?

Сурәтнең артында төсе уңган штампта: «Фотограф А.В.Соловьев, Большая Проломная, 15, Казань» дип язылган.

Ә тагын да астарак – «1926 ел» тора.

– Миңа монда ун яшь.

– Ә нишләп сез монда үзегез генә? Әтиегез-әниегез кайда?

– Әни... юк инде, ә эти...

– Дәү әни, әйт инде тизрәк?

Гадел түземсезлек белән минем кулымны селкетә. Җавапны көтеп тормыйча, идәнгә сикереп төшә дә коридорга чыгып йөгерә.

Мин фотодагы балаларның моңсу күзләренә кабат күз салам. Һәркайсының

---

Максим ШИКАЛЁВ (1970) – *язучы; әсәрләре «Российский колокол» (Мәскәү), «Невский альманах» (Санкт-Петербург), «Казань» (Казан) журналларында басылган. Мәскәүдә яши.*

карашы олыларча. Минем башымда – җәймәдән тегелгән яулык. Сафа өстендә – мөгаллимебез пинжәге. Катлаулы чорлар иде шул. Бу – туганнарым белән төшкән бердәнбер фото. Ничек табылды әле ул? Карточканың бөкләнгән почмагын турайтырга маташам.

Күптән булган хәл бу. Моннан соң тулы бер гомер узган.

Күземне йомып, балалар йортындагы мәктәпне искә төшерәм. Аннары медучилище һәм беренче эш урыны. Шау-шусыз гына туй, олы кызыбызның дөньяга килүе. Без офицер киеме кигән ирем белән Казан үзәгендә, яр буенда йөрибез. Сугыш. Мин госпитальдә. Авыртудан өзгәләнгән яралының ыңгырашкан тавышы ишетелеп торган авыр носилканы көчкә өстерәп барам.

Нури белән Сафа яңа солдат шинеле кигәннәр дә сугышка китә торган фронт составы янында басып торалар. Күптән көткән май ае һәм иремнең сугыштан кайтуы...

Ә моңа кадәр – балачак. Менә әни йон эрләп утыра. Мөхәммәт белән без ишегалдында тавык куып чабабыз... Көзге моңсу кичтә коедан су алган әти артыннан йөгерәбез... Ул мине кулымнан тоткан да тизрәк бар дигән сыман алга этә. Бу нәкъ шул кич иде. Без шуннан соң киттек, шуннан соң барысы да үзгәрде...

***

Таң ата. Арба көпчәге шыгыр-шыгыр килә, кыр буйлап сузылган юл очсыз-кырыйсыз булып тоела. Көзге яңгыр юган юл шактый сикәлтәле. Миңа рәхәт, уңайлы гына ятып, ат тояклары тавышын тыңлап барам. Якты кояш нурлары акрынлап төшә башлаган кырауны да җиңә. Мин барысыннан да иртәрәк уяндым. Абыйларым бер-берсенә елышып йоклыйлар әле. Нури, Мөхәммәт һәм Сафа. Яннарында аягын салындырып әтием утыра. Әтием өстемә япты, күрәсең, ул черем дә итмәгәндер. Мин аның борчулы йөзенә карыйм: күзләре еракка төбәлгән һәм алар, әйтерсең, тонык пыяла белән капланган. Уянганымны аңа әйтәсем килми. Бәлки, ул бик мөһим әйберләр турында уйлыйдыр. Өйдә намаз укырга җыенса, һәрвакыт битемнән үбә дә тавышланмаска куша. Әтием һәрвакыт Ходай белән үзе генә сөйләшергә ярата иде. Безгә: «Ул бар һәм бер, бөтен җирдән дә күрә һәм ишетә», дип әйтә иде. Аллаһы Тәгалә бик кешелекле һәм әниемне күреп тора. Әнием бит аның янында... Әтиебез әни киткән көнне елаганда, безнең барыбызны да шулай дип юатты. Һәм әниемнең күңеле булсын өчен мин һәрвакыт сүзне тыңларга тиеш.

Нәкъ шулай итәм дә, әтием кушканны һәрвакыт үтим. Минемчә, авылда һәркем әтиемне хөрмәт итә. Күбесе киңәш-табыш сорап яки болай гына сөйләшергә дип килә. Әле ул тагын авылдагы балаларны укырга, язарга өйрәтә. Теләге булганнарны, әлбәттә.

Авыр көпчәк иртәнге юка бозны ватып, пычракка батты. Арба никадәр селкенсә дә, абыйлар уянмады. Кичә бик авыр көн булды. Арыдык. Аеруча Сафа арыды. Чөнки Ибраһим абый яши торган күрше авылга барып җиткәнче, төнгә кадәр мин аның кулында булдым. Хәзер абый да безнең белән, дилбегә аның кулында. Кичә әти кайтып керде дә тиз генә кышкы киемнәрегезне киегез дип, җыенырга кушты. Куркып калдым. Нишләптер ул тиздән кыш җитә, шуңа күрә тиз генә Ибраһим абыйларга китәргә кирәк, диде. Аннары сандыктан ипи чыгарды, ниндидер әйберләрне алып сәкегә тезеп куйды. Барысын бергә эскәтергә төрде дә капчык итеп аркасына асты. Без тыныч кына башлыкларыбызны, толыпларыбызны кидек. Әти кабаланып, өй буенча йөргән арада мин әниемнең яулыгын һәм читекләрен киеп, аның яраткан җәймәсен

кочаклап, почмакта басып көтеп тордым. Караңгы төшкәнне күргәнем юк иде. Урамга чыккач, без өй артыннан борылдык та корылыктан кипкән басу аша алга таба йөгердек. Узган ел бер тамчы да яңгыр яумады, шунлыктан җир ярылып беткән һәм атлаган саен абындыра иде. Әти шауламаска һәм артта калмаска кушты. Бу миңа бер уен кебек тоелды. Сер булса да, соңрак Мөхәммәт абыйдан сорашып белермен дип уйладым. Ул миңа барысын да сөйли. Иң арттан Сафа йөгерә, шуңа күрә курыкмыйм. Йөгерергә читенрәк, әниемнең читеге зур булгач, камылга эләгә дә кала, эләгә дә кала. Арытты. Әти безгә борылып, калкулыкка җиткәч, ял итеп алырбыз, хәзергә түзегез, диде.

Тауга күтәрелгәч кенә артыма борылып карадым. Барыбыз да тыныбыз кысылып, җиргә утырыштык. Каршыбызда үзебезнең Әсән авылы иде.

Ай яктысы. Барлык йортлардан да мәһабәтрәк булып, мәчет манарасы күренә. Нишләптер аның өстәге тәрәзәсеннән яктылык сирпелә. Кинәт кенә бөтен дөньяны яктыртып, түбәдән көчле ялкын күтәрелде. Мин әтигә борылдым, ул исә, йөзен читкә борып, тавышсыз гына елый иде. Безнең йорт та мәчеттән ерак түгел. Кулымны сузып, түбәләрне саныйм. Бер, ике, өч... Безнең йортыбыз да яна!

Бер сүз әйтергә дә өлгерми калдым. Әти кинәт кенә торып басты да кулымнан кысып: «Кузгалыйк, балалар!» – диде. Аның артыннан шактый йөгереп бардым, абынып егылгач, Сафа мине кулына күтәрде. Без каядыр җитеп тукталдык.

Ибраһим абыйның нык курыкканы сизелә. Әти белән шыпырт кына нәрсә хакындадыр сөйләшәләр, еш кына тәрәзәгә күз салгалыйлар. Чыра яктысы бүлмәне яктыртмый диярлек. Без киң сәкегә дүртебез бергә яттык. Минем бөтенләй йокым килми иде, абыйга карап яттым. Ул йокы аралаш ыңгыраша. Абый миңа безнең монда ник килүебез һәм ни өчен өебез януы хакында барыбер сөйләмәде. Мин берничә тапкыр әтинең иртүк шәһәргә китеп өлгерергә кирәклеге турында әйткәнен ишеттем. Югыйсә... Ул Ибраһим абыйның колагына нәрсәдер пышылдады. Абый исә, әтинең аркасыннан сөеп, баш какты.

Әнием киткәннән соң, мин бик тәртипле кыз булырга тырыштым. Укырга, язарга өйрәндем. Миңа язу ошый иде. Хәрефләрем матур гына кебек. Аларның кайберләре нокта белән, ә кайберләре дулкынлы итеп языла. Ә әти укый башласа, җырлаган кебек килеп чыга. Әлиф, ләм, мим – мин өйрәнгән беренче хәрефләр. Әтием шәһәрдә белемле кешеләрнең башкача язуын әйтте. Уңнан сулга. Мин исә озакламый шуларны үз күзем белән күрәчәгемне уйлап яттым. Тизрәк таң атсын иде. Әтием күптән түгел генә шәһәрдә булды, кая барасыбызны беләдер, мөгаен. Ул абыйга хәзер иң мөһиме – безне коткарып калу, диде.

Коткарырга? Ә нәрсәдән коткарырга соң?

Көн туды. Мин һаман да арбада, үзем әтигә карыйм. Аның безне коткарачагын төгәл беләм, нәрсәдән коткаруын гына аңламыйм. Әлегә...

Кузгалып киткәнебезне бөтенләй хәтерләмим. Мине монда кемдер иртүк алып килде. Барасы юл ерак, алда тулы бер көн. Әти бераздан абыйларны уятыр да, без арбадан төшәрбез. Атыбыз ял итеп алсын һәм тагын безне алып барсын өчен азрак җәяү атларбыз.

Кич җитте. Ат башын чайкый. Ибраһим абый аңа капчык белән тарттырылган үлән әзерли һәм безнең белән саубуллаша. Аның әйтүе буенча без шәһәр читеннән узачакбыз, һәм ул шунда безне төшереп калдырачак. Без берәм-берәм аның белән кочаклашып чыктык. Ул бигрәк тә әти белән озаклап хушлашты.

Әти безне үзенә чакырды. Барыбыз да аңа елыштык, ул да безне муеннарыбыздан кочаклап алды. Нindидер бер мөһим нәрсәне истә

калдырырга кирәклеге турында әйтте. Хәзер безнең исемнәр башка булачак, үзебезнең исемнәрне онытырга кирәк икән. Вафа, әтинең исеме шундый. Димәк, без – Вафиннар, ә әти-әниебез – крестьяннар. Без моны гомер буена истә тотарга тиеш. Моның ялган икәнен бик нык әйтәсем килсә дә, дәшмәдем. Әти имән бармагын ирененә китереп, шулай кирәк, диде.

Без елга буендагы биек йортлар аша юан баганалы тимер койма буйлап барабыз, аларның һәркайсы кечкенә шарлар белән бизәлгән. Мин янә читекләремне шапылдата-шапылдата, төрелгән җәймәмне кочаклап, Нури артыннан йөгерәм. Алда әти бара, аның кулында әле өйдән үк алган капчыгы. Монда урамнар авылдагы кебек караңгы түгел. Биек баганаларда юлны яктыртып, тонык кына пыяла шешәләр янып тора. Җил аларны селкетә, яктылык тагын да кими төшә, шул чакта күңелсез булып китә. Тагын әниемне сагынып елыйсым килә. Ул да, мөгаен, безнең белән барыр иде һәм минем белән янәшә атлар иде.

– Без кая барабыз?

Мөхәммәт миңа борылып, иңбашын сикертеп куйды. Әмма мин тыныч, абыйларым беркайчан да ташламаячагын бик яхшы беләм.

Урамда бездән башка беркем дә юк. Таш коймаларга күп төрле кәгазьләр ябыштырылган, алар җилдә селкенеп тора. Кызык, нәрсә язылган икән аларга? Әти кинәт кенә түбәле тимер болдыр каршында туктап калды да капчыгын Нурига тоттырды. Бинаһая зур агач ишектә бер кәгазь бите эленгән. Зур хәрефләр белән нидер язылган, саннар да бар: бер, тугыз, ике, ике. Әти ишек шакый. Эчтә нидер дөбердәгәч, ишек биге шалтырый башлады. Авыр ишек ачылып китте, һәм караңгыда эти русчалап нидер әйтте. Әтием безгә көтеп торырга кушып, эчкә үтте. Мин Сафага сыендым, ул минем кулымнан нык итеп тоткан. Ишек янәдән ачылып китте, һәм без бер-бер артлы тезелешеп, баскычлар буйлап менеп, өйгә кердек. Монда бик җылы. Алгы бүлмә идәне шома ак таштан түшәлгән һәм бик якты иде. Мөгаен, шәһәрдә бөтен җирдә шулайдыр. Безнең каршыбызда яулыклы, озын буйлы бер апа басып тора. Ул безнең арттан ишекне бикли һәм ым кагып кына үзе артыннан барырга куша. Әти башын селкеп куя, һәм без озын коридор буйлап, ачык ишекле бүлмәгә узабыз. Әти, сәкегә утырып, тыныч кына көтеп торсак, безне ашатачаклар, ди. Бик яхшы булыр иде дә соң... Мин беренче булып, ишеккә якынрак килеп утырдым. Ниһаять, теге авыр җәймәдән арынырга да була. Ул җәймә мине урамда җылытты, әмма күтәреп йөрергә бик авыр иде. Әтинең мине чакырганын ишетеп, сәкедән сикереп төштем дә аның янына килдем. Бүлмәдә тагын шул апа. Ул яулыгын салган, зур өстәл янында солдат киеменнән утыра һәм җитди йөз белән безгә төбәлгән. Солдат хатын русча нидер әйтә, әмма мин аңламыйм һәм әтигә карыйм. Әти минем өчен нидер әйтергә тели, әмма ул аны туктата һәм янә миннән сорый:

– Син... кем... кызым, исем?

Дөрес әйтмәсә дә, мин аны аңлыйм һәм җавап бирәм:

– Мөнирә, әтинең исеме Вафа.

– Ничә яшь сиңа, кызым?

– Алты, – мин алты бармагымны күрсәтәм.

Теге хатын әтигә борыла, эти килешмичә, башын селки. Алар тагын да кычкырыбрак сөйләшә башлыйлар. Бәхәсләшәләр һәм кычкырышалар. Ниһаять, тыналар. Әтием башлыгын сала да, аны ике кулы белән күкрәгенә кысып, ялварып, теге усал хатынга күз ташлый. Миңа карап алганнан соң, хатын авыр сулап, кулын селки. Аннары эти миңа чыгарга куша.

Абыйлар миннән нәрсә булганын сорыйлар, әмма җавап бирергә өлгерми калам. Хуҗа хатын коридорга чыга да безне яңадан үз янына чакыра. Без бергәләшеп башка бүлмәгә керәбез. Монысы зур зал. Сафа миңа мәчеттә дә шундый зал икәнлеген әйтә. Чыннан да шулай иркен микәнни? Диварга ак халаттан һәм башлыктан ниндидер абый сурәтләнгән картина эленгән. Ул зур кашык тотып, елмаеп тора. Мөгаен, безне хәзер сыйлыйлардыр. Менә бит чәйнек, дүрт калай кружка һәм кашык китерделәр. Монда сәке юк, барыбыз да киң өстәл янына утырыштык. Безгә карап, теге хатын авыр көрсенеп куйды да этигә тиз-тиз генә нәрсәдер әйтеп, ишектән чыгып китте.

Без һәрвакыттагыча барыбыз бергә. Әни генә юк. Эти калай кружкаларга кайнар су агыза. Капчыгын ачып, ипи чыгара һәм берәр телем сындырып бирә. Ипине кайнар суга салсаң, бик тәмле шулпа килеп чыга. Кап-кайнар! Хәзер әзрәк суына һәм...

Без кружка белән кашыкларны өстәлгә куябыз. Эти калган ипине төреп, Сафага суза.

Ул шыпырт кына аңа нидер әйтә, ә абый игътибар белән тыңлап, баш кагып тора.

Аннары... аннары эти һәрберебезне кочаклап, үбеп чыкты да аңа китәргә кирәклеген әйтте. Заманалар авыр, диде, шуңа әлегә безгә шушында яшәп торырга туры киләчәк икән.

Әтием китешли кабат яныма килеп чүгәләде һәм, башымнан сыйпап, сабыр булырга, абыйларны, бигрәк тә Сафаны тыңларга кушты. Әгәр дә без бергә, бердәм булсак, тормыш яхшы якка китәчәк, чөнки гаилә – иң мөһиме, диде. Әтинең бөтен нәрсәне дә дөрес эшләгәнен беләм, шуңа күрә дә аның кая китәсен дә сорамадым.

Карашым белән этине озатканда, мин аның ачык ишектән йөзен учлары белән каплый-каплый китеп барганын күреп калдым. Аны солдат хатын көтеп тора иде, һәм алар бергәләшеп күздән югалды. Каты итеп ишек ябылды, шомлы итеп келә шалтырады.

Сафа минем колагыма пышылдады шулчак:

– Син эти әйткәннәрне хәтерлисеңме?

– Әйе, – дим мин, шулай ук пышылдап кына.

– Беркайчан да, беркемгә дә эти турында сөйләмә, үзеңнең кем кызы икәнеңне дә әйтмә.

– Яхшы, ә без кайчан да булса өйгә, авылга кайтачакбызмы?

– Беркайчан да! – диде Сафа.

– Нигә? – дип кычкырып җибәрдем мин күз яшьләренә буылып.

– Чөнки, сеңлем, син – мулла кызы...

***

Гадел кулымнан җилтерәтә. Аның әйләнеп килгәнен сизми дә калганмын.

– Дәү әни, син бит этиегезнең кая киткәнен әйтмәдең.

– Кайчандыр безне коткарып калды да китте.

– Кая китте?

– Белмим, Гадел. Без аны башка күрмәдек.

– Ә ни өчен коткарды?

Мин оныгымны кочагыма алдым.

– Синең өчен, улым.

*Русчадан* **Нурия ХӘЙРУЛЛИНА** *тәрҗемәсе.*



*Надия Вәлиева 1954 елда Әтнә районының Мокшы авылында туа.*

*1978 елда Казан дәүләт педагогия институтын тәмамлап, татар һәм рус телләре, әдәбияты укытучысы белгечлеге ала. Удмуртиянең Можга шәһәре балалар иҗат йортында, 1нче мәктәптә татар теле укыта, социаль педагог, унике ел шәһәр хакимиятендә балигълык яшенә җитмәгәннәр белән эшләү комиссиясендә секретарь була.*

*2010 елдан Казан шәһәре Совет районының 162 нче балалар бакчасында татар теле буенча тәрбияче.*

*Россия Федерациясенең гомуми белем бирү өлкәсендә мактаулы хезмәткәре.*

*«Күңел дәрьям дулкын-дулкын», «Без – Можга татарлары» һ.б. җыентыклар авторы.*

Надия
Вәлиева

# ЯШӘҮДӘН ТУЙМАГЫЗ!

## Сүз

...Йоклыйм күк бик озак,
Сәбәпсез көенеп.
Шатлык юк күңелдә
Яшәүдән, сөенеп.
Ә бүген... йа Ходам! –
Кәгазьгә сүз тама,
Шул сүздән бар Җиһан
Ямьләнә, яңара.
И сүзләр, сүзкәйләр,
Сезләргә мәдхия!
Сез – Аллаһ бүләге,
Илаһи көчкә ия!
Сезләрдән кальбемә
Тамчылап моң тула.
Нәзберек җаныма
Урала-урала,
Очыра күкләрнең
Җиденче катына.
Әйдәкләп утырта
Ләззәтнең атына.
Атым, и, очына,
Уйнаклап атыла.

Ләззәтме пышылдый:
– Ябыш, – дип ялына!

...Мин әле күкләрнең
Җиденче катында.
Тоташтан моңнан мин –
Кагылма, кагылма!

## Безнең халык

Баш биргәнсең,
Утырыплар уйланырга.
Кул биргәнсең,
Шул уйларны кулланырга.
Баш эшләми,
Кулың гына эшләгәндә,
Бөтен халык аптыраштa,
Аптыраштa...

Тел биргәнсең,
Тел ул үзе бер хикмәттер.
Сүзләр сөйләү
Могҗизалы бер сәләттер.
Әмма сүзең
Төпле түгел, төпсез булса,
Бу кешенең бер тиенлек
Юк хаҗәте...

Җан биргәнсең,
Кемгә – олы, кемгә – кече,
Кемдер – кансыз,
Ә кемнәрең кешелекле.
«Җан биргәнгә җүн биргән», ди
Безнең халык,
Җүнне эзли ничә еллар,
Тапмый әле...

## Биләрдә

Кайчан да бер без китәрбез,
Таулар калыр, Биләр торыр.
Кырык кызның батырлыгын
Күргән тау бу – шуңа горур!

Күңел күзең күпне күрә,
Илгә чыгып йөргән чакта.
Искән җилләр тарих сөйли,
Хәтер төпкелен актара.

Газиз халкым! Синең язмыш
Моңлы һәрчак, үтә кырыс.
Ничә гасыр түгелгән яшь,
Таулар горур, анысы дөрес...

Бу киңлекләр, иңкүлекләр,
Урлар, валлар...
Йоклый тарих.
Аның битләрен язарга
Соңга калмыйк, вакыт табыйк!

Баскычлардан, дога укып,
Төшеп килә абыстайлар.
Ак яулыклы, ак күңелле,
Ниләр уйлый икән алар?

– Сөбханалла, – диләр булыр,
Бу көнне дә күрдек, шөкер...
Тагын бер гасыр узгачтын
Безнең татар ни кичерер?

Телен җуйган кавем күреп,
Биләр таулары селкенер...

## Көз мәллә?..

Әллә соң минем дә
Күзләрем җитәме?
Күңелем ник елый,
Ютәлли-ютәлли?

Туңдыра бер мәлне,
Өшетә ни сәбәп?
Җәй генә бит әле,
Ул килә, кул изәп...

Кояш та шул, үзе,
Ае да шул чама.
Тик халык үзгәрде,
Үзгәрде замана!

«Исәнме» дию юк,
Кая ул хәл белү...
Күчтәнәч кыстырып,
Кунакка кич керү.

Рәхмәтләр әйтешү...
Үттеләр, беттеләр.
Байлыкка корылган
Заманнар җиттеләр.

Күп кеше, ни гаҗәп,
Бернигә карамый,
Көнен дә, төнен дә
Баерга чамалый.

Йөгерә, күр, әнә,
Урлаша, хәйләли,
Бию, җырлавы –
Гел байлык тирәли.

Үзгәрде замана.
Мин өшим. Өшетә...
Җәй ае булса да,
Күңелдә көз ята.
...Елата! Елата.



*Гүзәлә (Гүзәл Закирова) Балтач районының Куныр авылында туган. Мәктәптән соң, Казан (Идел буе) федераль университетында татар филологиясен өйрәнә. Шигырьләре вакытлы матбугат чараларында басылганы бар, шулай ук интернет аша киң таралган. Гүзәлә хәзерге вакытта КФУның Л.Толстой исемендәге филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында магистратурада укый, «Ялкын» журналында эшли.*

Гүзәлә

# МИН ЧИКСЕЗЛЕК КАДӘР СИНДӘ

***

Табан астын – Казан комы,
ә күңелне хис кытыклый.
Шундый рәхәт,
күпереннән шундый сикерәсе килә!
Ә чынбарлык үтә сәер:
ярга бәрелә буш шешәләр –
үзләренчә тансык бер моң
бу калага насыйп көйдә.
Тик үзләре белгән серне
саклап йөзә пар үрдәкләр.
Алар хәтта үземә дә
эндәшмәде.
Ахыр чиктә
бу сукмаклар илтә булыр
чиксезлекнең үзенә үк.
Шуңа әле күрешербез
йә суларда, йә күкләрдә.
Йә икесен бер итәрбез
(үтә ансат кичке якта).
аерамы соң бу күңел
чынбарлыкны уйдырмадан.
Сибелеп ята берсен-берсе
аңышмыйча таш тартмалар.
Чыга алмасымны тойдым
инде мәңге уй урманын.
Кояш китә,
авырттырып
дулкынланган күкрәк турын,
истәлеге ягылып кала
кайнар булып йөзебезгә.
Ул сулыштан җаным тетрәп,
кызылында күмелә барам.
Карашыңа җылы үрли –
син кайтасың үз-үзеңә.

Син эзлисең бик мөһимне,
тик үзеңә тиешлесен.
Шуңа аякларың һаман
тынгы белми кала таптый.
Казан комын кытыклыйм дип,
бармакларым сүз тудыра.
Ул сүз – караш.
яңа сер бу.
Пар үрдәкләр аны ятлый.

***

Аякларны җиргә тарта
әйтелмәгән сүз әрнүе,
еланмаган яшь диңгезе
күзләремне күккә төртә.
(Һәрбер сүзең – миңа дога).

Һәрбер караш канга бара,
кысып куя чигә турын,
тынып кала кара гавам –
хәрәмләшми уйнау кала.
(Дөнья – тоташ сынау бугай).

Казан – тоташ сайлау бугай
үз-үзеңне мең сурәттә.
Хисем аякларга күчә –
миңа шулай яшәү кулай.
(Син бирешмә шикләреңә).

Син карышма өметеңә,
мин чиксезлек кадәр синдә,
(син чиксезлек кадәр миндә).
Белмәм, бары әйтә генә.
Аякларга күчә хисем,
аякларны тарта җиргә.

***

Кала йөзе – тоташ кершән,
бураннары җанга үтә.
Чәчләремне җилгә сибеп,
һава ертып җырлап киләм.
Ярты сүзем эленеп кала
чәүкә сырган тупылларда.
Көйләремнән чәүкә халкы
бер оялмый чыңлап көлә.

Аякларым – кыргый учак,
адым саен асфальт шыта.
Ташкын булып кар эретә
жанны өткән кайнар тыным.

Болыт сына тавышымнан,
тавышымнан туар яңгыр.
Алтмыш көннән кунакка кил –
агачларны сафлык сарыр.

Күңел утын басам, димә,
синнән өстен көчләр шактый.
Кайтып-кайтып гашыйк булам
бу дөньялык туган көнгә.
Чәчләремнән коелып кала
җанга тансык юкә исе.
Инанып көт: буран аша
яз ияртеп кайтып киләм.

***

Сүнеп барган соңгы яфракларның
(кочагына җирнең атылганда)
май чыгында янган кояш белән
серләшүе тора күз алдында.

Колакларын ярып, ярсып чыңлый
җәй төнендә шаулап үткән яңгыр.
...
«анда аста, юк-юк, туфрак түгел,
үлем түгел. Анда язгы таңдыр!»

***

*Тарысаң*
*Үлемгә,*
*Арканa*
*салып чык*
*Һәм коткар*
*Үзеннән.*
Миләүшә Гафурова

Күкләргә ярәшкән
болытлар өерен
ул буйый җиләкле кайнатма төсенә.
Канынмы сыеклый,
әллә бу
адашып чорналган төш кенә?

Кечкенә чагымны яңартып,
сусыл ут табанны кытыклый.
җан сорый чынбарлык упкыны –
керфекләр дымланган,
сак атлыйм.

Юатып туфракны
тез чүгәм:
«Көт мине,
син диеп кар сибәм чәчемә.

Кулыңа егылыр көч тапсам –
җилгә бит сүз түгел,
мин үзем чәчеләм.»

Сүз диеп лаф орам
асылда,
сыеклыйм хакыйкать карасын.
Үкенми китәсем
каныма буясам
(һичьюгы!)
бер кичкә бер болыт баласын.

Бу тормыш тоташтан
төш, ахры.
Һәм беркөн, сүгенеп кайтканда,
ул мине очратыр,
уятыр
һәм сөяр, күтәреп кулына.

***

Караңгы сүрелә, күкләрдән хәбәр бар:
синең дә җаныңда кар-бозлар кузгалган.
Болытлар таралып кояшны көтә күк,
мин монда һаман да. Кулыңны суз гына.
Бу ярда һаман да җылымны саклыймын,
адашсаң, җитсен дип, сиңа да, миңа да.
Һәм айның сагышын җанымда кадерлим:
ул миңа иш булыр, югалсаң яңадан.
Күзләрең яктысы күкләргә үрмәли,
гыйсъянчы яз шавын кабатлый тавышың:
«Минсезлек язларын яңартып санама».
Чамалыйм: бу әле чиксезнең тик башы.
Тоясың: юлларың мәңгегә тоташкан,
чиксез күп бу җирдә түлисе ясаклар.
Онытма: аяктан егардай җилләрдә,
тынычлык югалткан сагышлы бу җирдә
җаныңны өзелмәс өметем ышыклар.

# ГҮЗӘЛӘ ШИГЫРЬЛӘРЕ

Татар шигъриятенең, шигыренең зур үзгәрешләр кичерүе барыннан да бигрәк яшьләр иҗатында күзгә ташлана. Бүгенге яшьләр иҗатын XX йөз башы яки уртасы гына түгел, XX-XXI гасырлар чигендә мәйдан тоткан шагыйрьләр әсәрләре белән дә янәшә куеп булмый. Хәтта шигырь теориясе белән таныш булмаган кеше өчен дә шигырь техникасының үзгәргәне, яшьләрнең бөтенләй үзгә текстлар тудыруга омтылуы аермачык.

Бәлки, моның сәбәпләре хәзер бик еш телгә алына торган «клип мәдәнияте» – замана яшьләренең образлар җемелдәве рәвешендә фикерләвенә тоташа торгандыр. Бәлки, идеологик чикләүләрдән арыну әдәбиятта шәхси башлангычны калкуландыргандыр. Ничек кенә булмасын, яшьләр иҗатында модернизм һәм постмодернизмга өстенлек бирелү, тормышны катлаулы сурәт итеп тергезү, дөньяга үзенчәлекле, күпмедер сәеррәк карашлы лирик герой булу, синтетизм, ягъни төрле, бер-берсеннән ерак алымнарны бергә куллану кебек күренешләр күзәтелә.

Әмма яңача язу рәвешенә, яңа «техникага» өстенлек биргәндә дә, сәнгатьнең төп законнары саклану шарт. Әйтик, әлеге шарт үтәлмәүне Җир шарындагы төп физика законнарын исәпкә алмыйча, мәңгелек двигатель уйлап табу белән тиңләргә мөмкин. Әдәбияттагы законнар да Җир шарындагы физика законнары кебек үк беренчел әһәмияткә ия. Аларны саклау мәҗбүри. Бүген укучыга тәкъдим ителә торган Гүзәлә шигырьләре турында сөйләшкәндә, әлеге законнарның кайберләренә игътибар итәрбез. Ритм-көй тудыра белү, лирик субъекттагы сәерлек, тормышны аңларга омтылу сыйфатлары белән бу әсәрләр Гүзәләнең шигърияттә үз юлын-сукмагын эзләве хакында сөйли.

Беренче текст – «...Аякларны җиргә тарта...», асылда, иҗат турында. Каләмгә үрелгән һәр кеше иҗатында әдәбият-сәнгать турында шигырьләр бар. Гүзәлә иҗат эшен ике пар оппозиция тирәсенә туплап күзаллый: сүз – хис һәм җир – күк. Сүз – җирнеке, хис – күккә тарта; шуларны тоташтырганда, иҗат хасил була дигән фикер кабатлаулар ярдәмендә укыла *(«Аякларны җиргә тарта / әйтелмәгән сүз әрнүе, / еланмаган яшь диңгезе / күзләремне күккә төртә»;* аннары *«Хисем аякларга күчә –/ миңа шулай яшәү кулай».* Һәм соңгы тезмәләр: *«Аякларга күчә хисем, / аякларны тарта җиргә»)*. Әлеге 3 кабатлау төп фикерне билгеләргә ярдәм итә.

Гүзәлә теманы шулкадәр үзенчәлекле формага төргән ки, текстның иҗатка багышланган булуын аерып алу да җиңел түгел. Шигырьдә (башка текстларда да) заман әдәбияты яратып куллана торган алым – «аң агышы» кулланылган. «Аң агышы» – субъектның фикере артыннан күзәтеп бару, эчке монолог, үз-үзең белән сөйләшү; әдәбиятта ихласлылык, психологизмның көчле булуы дигән сүз. Ул модернизмның төп алымнарыннан санала, татар постмодернистик поэзиясендә дә үзәктә. Әмма теләсә нинди алым кулланылып язылган текстта, шул исәптән «аң агышы»на мөрәҗәгать иткәндә дә, төп фикер аныклыгы булу мәҗбүри. Бу да – әдәбиятның төп законнарыннан. Шул фикер аныклыгы белән янәшә сурәтләнә торган тормышка гаҗәпләндерерлек караш-образ булып, аның шигърилеге дә күзәтелсә, болар инде «аң агышы»на, кеше психологиясенә төрелгән энҗе бөртекләренә әйләнәләр.

Тагын бер үзенчәлек – лирик әсәрнең субъекты. Текстта характеры, тормыш тарихы күренеп торса, лирик герой, болар ачык булмаганда, «лирик мин» табыла, дибез. Әмма нинди генә амплуада бирелмәсен, лирик субъект, аның сурәте аңлаешлы булырга тиеш. Чөнки лирик әсәр укучыны лирик субъект хис-кичерешен үзенеке кебек күңел аша уздырырга мәҗбүр итә. Димәк, тексттагы лирик герой, хәтта «мин» образы да ачык күзаллану шарт. «Аң агышы» кебек психологик алым кулланылганда да, лирик субъектның асылын күрсәтү мөһим. Бу очракта, Гүзәлә тексты «мин» исеменнән

башланып китә. Беренче строфада илһам – күккә өндәгән, каләм – җиргә тарткан, ягъни иҗатка һәвәс лирик субъект сурәте хасил була башлый. Беренче строфага бишенче юл итеп урнаштырылган тезмә: *«Һәрбер сүзең – миңа дога»* – эндәшү объектын Илаһи көч, каләм, илһам ... итеп аңлауга юл күрсәтә. Әмма өченче строфа кабул итү горизонтын үзгәртә: «миңа шулай яшәү кулай» дигән фраза икеләнү уята: илһам белән яшәүнең кулай булуы бердәм логикага буйсынмый башлый. Аннан соң килгән «Син бирешмә шикләреңә» тезмәсе инде эндәшү объектын үзгәртә: ул укучы булып аңлашыла башлый. Аннан соң килгән соңгы тезмәдә кабат буталчыклык чыгара, ул сөйгән кеше түгел микән дигән фараз уяна: *«мин чиксезлек кадәр синдә, / (син чиксезлек кадәр миндә)»*. Мондый күчешләр текстны аңлауны авырайта.

Инде тагын бер мәсьәләгә килик: шигырь эстетикасы. Шигърият сүзләр сайлауда, куллануда, проза яки драматургия белән чагыштырганда, үзгә таләпләр куя. Биредә һәр сүз яки фраза һәм мәгънәсе, һәм яңгырашы ягыннан эчтәлеккә тәңгәл сайланырга тиеш. Шушы таләптән чыгып караганда, күп кенә образ-детальләр, сүзләр уңышлы сайланганмы дигән сорау туа. Иң беренче күзгә бәрелә торган образ – «хисем аякларга күчә» шактый каршылыклы кабул ителә.

Текстлардагы самимилек үзенә җәлеп итә. «...Табан астын – Казан комы...» шигырендә беренче дүрт тезмәнең ихласлыгы, сурәтләнә торган тормышны детальләрдә тергезә белү текстка тарта. Тик тормышның матурлыгы һәм сәерлеге турындагы текстта шулай ук фикер аныклыгы җитенкерәми. Моңа аерым фразаларның нindидер вазифа башкарырлык итеп файдаланылып та, аны укырга юл күрсәтелмәү дә китереп чыгара. Мәсәлән, *«Алар хәтта үземә дә / эндәшмәде»* дигәндәге «үземә дә» сүзләре лирик героиняның сәерлеген ассызыкларга мөмкинлек бирә алыр иде. Текстның соңгы строфасы – «аң агышының» йомгаклану өлеше, ачыклык кертү урынына, фикри буталчык тудыра: *«Казан комын кытыклыйм, дип / бармакларым сүз тудыра./ Ул сүз – караш. / яңа сер бу. / Пар үрдәкләр аны ятлый»*.

Өченче, кышның матурлыгын раслап, әмма кешенең барыбер язга омтылып яшәвен күрсәтеп язылган «...Кала йөзе – тоташ кершән...» дигән шигырь дә хисләрнең самимилеге, сәер, экспрессив лирик геройның дөньяга карашы, үзәк фикернең үзенчәлеге белән җәлеп итә. Әмма биредә дә сүзләрнең уңышсыз кулланылуын әйтми булмый. Әйтик, алтмыш көннән «син» кунакка чакырыла, аннан соң килгән строфада «синнән өстен көчләр шактый» дигәндә, «син» урынына «мин»не куллану дөресрәк түгелме?

«...Сүнеп барган соңгы яфракларның...» дигән кыска, ике строфалык шигырь бу кимчелекләрнең ритм һәм рифма өчен сүз сайлау белән бәйле булуы хакындагы нәтиҗәне ныгыта. Чөнки кыска шигырь – һәр теренең өмет белән яшәве хакындагы текст мондый кимчелекләрдән азат. Ул Гүзәләнең үз стиле, тормышка үз карашы булуны аңларга ярдәм итә.

«...Күкләргә ярәшкән болытлар өерен...» шигыренә эпиграфның уңышсыз булуын әйтергә кирәк. Әдәби әсәрдә көчле позиция булган эпиграф аерым бер вазифа башкарырга тиеш. Шулай булмаганда, аны куллану кирәкмәс.

Мәхәббәт шигыре булган «...Караңгы сүрелә, күкләрдән хәбәр бар...» тексты да үзенчәлекле фикерләре белән игътибарны җәлеп итә. Анда сөю белән иҗатны бер үремтәгә бәйләп, һәр шигырьнең – шагыйрь яшәгән мизгелне үтереп тууы, икенчесендә – мәхәббәтнең өмет ярдәмендә башкага яшәү көче бирүе әйтелә. Шулай итеп, шигъриятә үз стилен булдырырга омтылган Гүзәләнең игътибарын шигырь техникасы өлкәсенә юнәлтәсе килә. Дөньяны хаос халәтендә сурәтләсәләр дә, заманча юнәлеш-агымнар барыбер төзек кануннарга буйсына, шул хаос-тәртипсезлек арасында ялтыраган энҗеләре белән укучыны җәлеп итә.

**Дания ЗАҺИДУЛЛИНА,**
*академик, филология фәннәре докторы*



Зәбир
Гыймаев

# КЕНДЕК БАБАЙ

ХИКӘЯ

**1**

Төньяк Кореяның «Хёндай» заводында җыелган автобус чираттагы түмгәктә янә бер сикертеп алды. Автобусның рессорлары каты, утыргычлары уңайсыз, ике арада үтеп йөрү юлы тар, ачыла-ябыла торган тәрәзәләрнең чит-читләре кереш белән каймаланмаган, пыяла тимергә бәрелеп чыкылдаган тавышка түзеп кайту өчен нервыларыңның таушалмаган булуы кирәк. Кыскасы, «Хёндай» заводында дөньяга килгән автобус Рәсәй дигән илдә, аннан бигрәк Татарстан Республикасының бу төбәгендә яшәүче халык өчен уңайлы транспорт чарасы, дисәк, чынбарлыктан шактый ерак торуыбыз ачыкланыр. Татарстан Республикасының бу төбәгендә эрерәк сөякле, кызурак табигатьле халык яши шул. Төньяк Кореяда кеше тынычрак та, ваграк та...

Хәер, гел автобусның гына кимчелеген эзләмик, бөтен гаепне аның өстенә өймик әле.

Рәсәй... Юллар... Әйе. Һәркемгә мәгълүм хакыйкатьне искә төшермәсәк тә буладыр.

Кешелек Галәмне айкый.

Адәм баласы Марска аяк басу турында хыяллана.

Ә Суыксу белән Көйдергән авылы арасында асфальт юл юк.

Дөньяны интернет чолгап алды.

Сабый бала төнге чүлмәгенә кесә телефонын тотып утыра.

Көйдергәнгә асфальт юл һаман юк.

Япон галимнәре ирнең һәр теләген үтәргә әзер: ир салып кайтса да, кочагына алып назлап йоклата; иртәгесен Сафура бураннары уйнатмый, киресенчә, ягымлы елмаеп, баш төзәтергә салып бирә торган робот хатын-кыз уйлап табу белән мәшгуль.

Ике авыл арасында асфальт юл барыбер юк.

Аяк киемең кыса икән, дөньяның киң булуыннан ни мәгънә?!

Тагын бер сикереп алдылар.

– Бәрәңге төямәгәнсеңдер бит, сиңайтәм?!

Автобус чаба торсын, әйдәгез, калган эшкә кар яудырмый гына хикәябезнең геройлары белән танышып үтик.

Юлчылар күп түгел, бары – дүртәү. Хәзер кеше тормыштан зарлана-зарлана

байый – һәркемнең үз машинасы, җәмәгать транспорты пассажир ташуда зур кыенлыклар кичерә.

Иң алда, ике кешегә исәпләнгән утыргычны ялгызы биләп, үзенә кай тарафтан күз ташласаң да, «сөбханалла!» дип артыңа чүгеп куярлык, гомеренең август аен узып, сагышлы сентябренә аяк басса да, картаерга әле һич тә ашыкмаган мәһабәт гәүдәле ханым утыра. Шофёрга кисәтүне ул ясады. Зур кара күзләрендә усал чаткылар да кабынып алды. Күзләр... Әйе. Күзләр – кеше күңеленең көзгесе, диләр. Ул кара күзләрдә усаллык та бар; сабырлык, күндәмлек, мәхәббәт, әйтеп-сөйләп бетерә алмаслык моң-сагыш – барысы да бар. Бу асыл һәм бигүк асыл булмаган сыйфатларның кайсы күбрәк, кайсы азрактыр – анысын бер Ходай белә. Хатын-кызның ачылмаган серле сандык икәне күпләребезгә мәгълүм бит.

Ханымның кулында үтә күренмәле пакет. Пакетта яшькелт җирлеккә болын чәчәкләре төшкән тәрәзә пәрдәләре һәм үзенә халат. Нәкъ менә шундый тәрәзә пәрдәләрен ул озак эзләде. Бу аның хыялына әйләнде, дисәк тә, чамадан тыш арттыру булмас. Ниһаять, тапты.

Кайтуга ук пәрдәләр, әлбәттә, тәрәзәләргә эленер. Аның өе кояш нурларында җәйрәп яткан җәйге болынга охшап калыр. Ул өр-яңа халатын кияр. Үзе дә шул болындагы бер чәчәк төсле булыр. Ә менә ире шул матурлыкны күрә белерме? Мәнсезлегенә барып, бөтенләй игътибар итмәсме?! Ханымның бай фантазиясе сөекле иренең мәңге йокымсыраулы-пошмас чыраен күз алдына китереп бастырды, иреннәре нык кысылып, зур кара күзләрендә янә дә усал очкыннар биешеп алды. Менә игътибар итми генә карасын! Кайнар аш та юк, җылы кочак та юк аннан соң! Вчу!..

Икенче юлчыбыз – ир-ат. Яше иллегә җитеп килә, дисәк, күпкә ялгышмабыз. Башта кыңгыр салып киелгән киндер кәпәч; шакмаклы аксыл күлмәге күкрәк-җилкәләрдә таман булса да, бил тирәсендә кысан: шул сәбәпле ике төймәсе ычкынып киткән. Нишлисең, җан ял итә, корсак ирек даулый торган заманда яшибез. Хәер, ир-ат дөньяның бу вак-төягенә игътибар итми дә, болай җайлырак та әле: шул «форточка»дан бик тәмләп кенә бүксәне кашып алып була. Кулында – пакет. Пакетта биш-алты банан, дүрт-биш әфлисун, өч лимон. Әлбәттә, үзен дә онытмаган (мөмкинме соң?): көньяк җимешләре арасында «казан малае» да шәйләнә. Сүз дә юк, яртыны авыл кибетеннән дә алып булыр иде. Әмма хатын белгән акчага. Бусын хатын белми. Аерма бик зур. Моны аңлаган кеше генә аңлый.

Ир-ат баҗасына спиннинг алды. Аны авыл кибетендә табып булмый. Шәһәргә баруы да шуның өчен. Хатын спиннингның күпме торганын белми, чегын тикшерү башына килмәячәк. Бер яртылык янга калды. Шулай бит ул дөнья! Тирәнгәрәк чумып уйлап карасаң, гел сөенеп кенә яшәрлек!

Җомга көн баҗай кайтачак! Татар халкында «кәҗә мал түгел, баҗай туган түгел» дигән әйтем бар. Уйламыйчарак, ашыгыбрак әйткәннәр! Ярый, кәҗәсе бәхәсле мәсьәлә булып калсын, әмма баҗай! Баҗай – мировой!

Баҗай – мәгариф һәм фән министрлыгында җаваплы хезмәткәр. Җитмәсә, шагыйрь! Илле яшьлек юбилеен уздырырга авылга кайта. Илле яшь! Илле яшь кай яктан карасаң да, түгәрәк дата. Дөрес, юбилейның төп өлеше Казанда узгандыр. Узсын! Казан дигәч тә, бер дә егылып китәрлек түгел. Шөкер «ТНВ-Планета» каналын карый, ничә тапкыр игътибар иткәне булды: арада җырлап алып, сәхнәгә чыгалар да юбилярны котлыйлар. Чыгалар да сүз сөйлиләр... Кәефне кырганы шул: «хөрмәтле юбилярыбызга озын гомер телисе килә», «иҗат чишмәгезнең саекмавын телисе килә» дип авыз суын корыталар. Соң телисең килә икән – телә син! «Телим» диген! «Озын гомер телим» диген!

«Иҗат чишмәңнең саекмавын телим» диген! Авызыңны тутырып, кычкырып әйт! Хөрмәтле юбиляр моңа лаек. Мең тапкыр лаек! Юк, «телисе килә» дип җанны кыйный. Әмма теләми. Ни өчен? Чөнки хөсет! Кешенең ничек сөйләшүенә карап, аның кем икәнен бик тиз чамалап була.

Авылда алай булмас! Сүз дә юк, кадерле кунаклар кайтып төшкәч, хәл-әхвәл сорашып, чәй эчеп, ыгы-зыгы килеп алырлар. Кунаклар чакырылган; хатын-кыз, зурдан кубып, табын әзерли башлар. Әмма болар барысы да – вак мәсьәлә.

Ул баҗасына менә шушы спиннингны бүләк итәр, һәм алар Ыкка балык тотарга китәрләр. Ык балыклары юбиляр хөрмәтенә чиертеп кенә торырлар, рәхмәт төшкерләре! Тотылган балыкны тиз генә чистартып, кыздырып алыр. Өстенә мул итеп яшел суган, укроп сибеп җибәрер. Табынга ямь өстәп, «казан малае» чыгар. «Әйдәле, баҗай, илле яшең тулу хөрмәтенә тотып куйыйк, «эһ» тә итмичә әле тагын иллене яшәргә насыйп булсын!» – дияр. Тост менә шулай кыска гына, әмма тирән эчтәлекле булырга тиеш. Тотып куйгач, искитмәле тәмле кызган балыктан җитешерләр. Алдан кат-кат сөйләшенгән: вакытын белеп кенә радиоалгычын кабызыр. Бәй, «Болгар» радиосы котлаулар тапшырып ята түгелме?! Әйе шул, «Җырлы сәлам»! Алып баручы кыз җанга сары май булып ята торган ягымлы тавышы белән аның баҗасын котлый. Һәм җыр! Вадим Захаров! «Юбиляр»! Керәшен малае шушы җырны бигрәк тә җиренә җиткереп, үтә дә матур итеп җырлый! Баҗай, әлбәттә, бик каты дулкынланыр. Шагыйрь кешегә күп кирәкмени?! Әмма бу әле чәчәге генә! Җимеше алда булыр. Бәрәч, очраклы рәвештә генә юл капчыгында гармуны килгән икән! Кулына гармунын алыр. Бармаклары гармун телләреннән йөгереп узар.

«Базарларга барсаң, кара җимеш алсаң,
Акчаларын үзем түләрмен;
Әҗәлләрең житсә, әйт үземә,
Синең өчен үзем үләрмен»,

– дип җыр сузар.

Булды. Артыгы кирәк түгел. Йөрәгең таш булмаса, түз, баҗай! Баҗай түзмәс. Баҗай егылыр. Без менә шулай, сукмыйча да аяктан ега беләбез!

Алар, ике баҗай, Ык ярында утырырлар. Әрәмәдә кошлар чутылдашыр, Ыкта балык уйнар, күктә йолдызлар җемелдәр, Чияле тау артыннан Ай күренер... Сүз дә юк, хатыннар, апалы-сеңелле, ирләрдән уңдылар. Дөрес, бу хакта үзенә әйтсәң, хатын пыр-пыр килә: «Кем кемнән уңгандыр әле!» – ди. Ул бәхәсләшми. Бу мәсьәләдә хатын-кызның сай йөзүе, тирәнгә чумып, фикер йөртә белмәве күпләргә мәгълүм бит.

Тиздән булачак шушы куанычлы мизгелләрне күз алдына китергәч, иратның өч көн кырынмаган чыраенда бәхетле елмаю пәйда булды, күзләре рәхәт кысылып, кулы «форточка»дан үтә дә тәмләп: кетер-кетер итеп кенә, бүксәсен кашып алды.

Өченче юлчыбыз – егет кеше. Яше егермедән чак артык булыр. Быел Түбән Кама медицина көллиятен тәмамлады. Автобуска зур биштәр күтәреп керде. Биштәрендә – алмашка кием-салым, китаплар, студент чакта язган конспектлар. Егеткә карап тагын нәрсә әйтим? Яшьлек! Матурлык! Тазалык! Көч! Алда – зур планнар! Якты хыяллар!

И яшьлек! Бер мизгелгә тукта! Чак кына сабыр ит! Язмышның сикәлтәле юлларыннан кая ашкынасың?!

Бу юлларны яшьлегемне искә төшереп, йөрәгемнең татлы сыкравына

түзә алмыйча язам... Юк, читкә китмик, керфекләргә эленгән яшь тамчысын сыпырып ташлыйк та хикәябезгә әйләнеп кайтыйк.

Ни өчен бу юлны сайлады ул? Мөгаен, бабасы сәбәпче булгандыр. Гарифҗан бабасы – сугыш ветераны, Берлин өчен барган яуда каты яраланган; табиблар солдатны, үз сүзләре белән әйтсәк, кара гүргә кереп яткан җиреннән якты дөньяга тартып чыгарып аякка бастырганнар. Бабасы табибларны Алла урынына күреп яшәде. Күңел түрендә йөрткән ихтирам хисен оныгына да сеңдерде.

Бердәм дәүләт имтиханнарының баллары югары: егетебез медицина университетының ишеген ачып та керә алыр иде. Әмма медицина университетында уку өчен кесәңнең шактый калын булуы кирәк икән. Дөрес, берничә студентны бюджет төркемендә укыталар, тик анда эләгү өчен йә бик каты кода-кодагыйлык, йә булмаса, түрә малае булуың кирәк. Тегесе дә бусы да юк икән: «Әй, Алла бирсә, без дә бер баербыз әле!» – дип, университетка кул селтәде дә юрганына карап аягын сузды.

Студент еллар артта калды, бүген егетебез Көйдергән авылына эшкә бара.

Көйдергән авылы турында берничә сүз... Көйдергән халкы хакимият белән көрәштә ике тапкыр җиңү яулады. Егерменче гасырның утызынчы елларында мәчетен саклап кала алды. Егерме беренче гасыр башында – медпунктын. Дөрес, медпункт ел ярым ябылып торды, әмма көйдергәнлеләр дә үҗәт халык булып чыкты. Ачтылар бит! Югыйсә «оптимизация» дигән булып, авылны медпунктсыз калдырмакчылар иде. «Оптимист» белән «оптимизация» сүзе бер тамырдан микән? Охшаганнар бит. Юктыр, капма-каршы мәгънәдәге сүзләрдер. Оптимист – рухын бер дә төшермичә киләчәккә өмет һәм ышаныч белән караучы кеше. Оптимизация татар авылының тамырына балта чаба. Капма-каршы мәгънәдәге сүзләр. Монда бәхәскә урын юк.

Бүген бу хакта уйлыйсы килми, егетебезнең уйлары еракка: бер төркемдә укыган, бүгенге көндә Олыяз авылына эшкә киткән Гөлмәрьям исемле кыз янына очты. Гөлмәрьям!.. Хакыйкатьнең күзенә карап дөресен әйтик: егетебез үлеп-бетеп Гөлмәрьям исемле кызга гашыйк. Аның турында уйлый башласа, ул үзенең кызарып киткәнен сизә. Кыз янында исә бөтенләй югалып кала. Шул кимчелеген бетерү өчен дөнья кадәр махсус әдәбият укыды – файдасы гына тимәде. Гөлмәрьямгә нәрсә? Көләргә булсын! «Фәргатьчик, битеңдә белен пешерерлек булган, камырым әзер, тиз генә чыжлатып алыймчы, соңыннан икәү утырып чәй эчәрбез!» – дип мыскыллый. Теленә шайтан төкергән кыз! Үртәшүе белән тәмам җелегенә төшкәч: «Җитте!», «Гарык булдым!», «Чыраен күрәсем килми!» – дип, бар дөньясына каш җыерып йөри башлый. Ике көннән кыз үзе килә: «Фәргатьчик, сагындым үзеңне!» – ди. Менә нишләмәк кирәк шундый кыз белән?! Дөрес, төркемдә заманына күрә оялчан, басынкырак табигатьле кызлар да бар. Йөрәгеңне пәрәвез сармаган булса, бер сизелә бит ул: үзенә күз атып йөрүчеләр дә юк түгел. Әмма акылны йөрәккә баш итеп куеп буламы?! Такташ та, әнә, тырышып караган. Акылын йөрәгенә баш итеп куя, имеш!.. Шагыйрь башы белән! Куярсың, бар! Алай җиңел генә!..

Дүртенче юлчыбыз – ять-яшь хатын. Яше егермесе тулыр-тулмас булыр. Бөдрәләнеп торган алтынсу чәчләре иңбашына таралып төшкән, сипкелләре битен сөйкемле иткән, кемгәдер үпкәләгән сыман чак турсайган иреннәрендә иркә балачагы сыенып калган, ә менә зәңгәр күзләрендә курку... Яшь хатын авырлы. Дөнья күргән өлкән яшьтәге кеше: «Әй, бала, бу хәлеңдә ничек юлга чыгасы иттең?» – дип сорар иде. Чыкты шул инде!.. Ире иртән-иртүк эшенә китте. Дөрес, күршеләре Фәрдәнә апага күз-колак булып торырга әйтте. Ире артыннан ишек ябылгач, ул курыкты. Ярты көне куркуда узды. Бөтен

дөньясында ялгызы гына калган кебек тоелды. Әнкәй!.. Бу дөньяда аның әнисе бар ич! Әнисе янында ул курыкмас! Әнисе янында шундый ышанычлы. Ике сәгать ярымлык юл... Күпмени ул? Әнисенең яраткан тортын алды да юлга кузгалды. Күчтәнәче белән эчен каплап автобуска керде, иң арткы рәткә барып утырды. Алай-болай бала тудыру йортына китә калса дип, бөтен кирәк-ярагы тутырылган сумкасы ишек төбендә онытылып калды.

Эче авырта башлаганга күпме вакыт үтте икән? Ул вакыт төшенчәсен югалтты. Һәр авырту өянәгеннән соң хатын «бусы соңгысы булыр» дип өметләнә. Әмма авырту яңадан кабатлана... Хатын ояла, кыенсына, бу халәтен бүтәннәргә күрсәтмәскә тырышып иреннәрен тешли...

Бу дөньяда бөтенесе көтмәгәндә килә икән. Әле гашыйк булырмын дип уйламый иде – гашыйк булды. Егет кочагына алып бер үпте – дөньясын онытты. Авырга узганын белгәч, югалып калды. Егетенә әйтте. Үзе күзләрен күтәреп аңа карарга курыкты. Шулай бик озак басып торадыр кебек тоелды. Әллә кайда, бик биектә, сүнәм-сүнәм дип өмет йолдызы янды... Башы әйләнеп китеп, инде егылам дигәндә, аны көчле куллар тотып калды. Кайнар иреннәр битеннән, күзләреннән үбә-үбә пышылдады: «Зөһрә, эш тәртибе болай: син үзеңнекеләргә хәбәр ит, мин – үземнекеләргә. Туйга әзерләнә башласыннар. Без балдаклар алу хәстәрен күрик, язылышу көнен билгелик».

Яңалык ата-аналарга барып иреште. Кыз ягы хәсрәт дәрьясына чумды: «Кызыбыз бик тәүфыйклы, инсафлы бала булып үсте. Ходаем, кешегә ышана торган гадәте барые. Алдангандыр... алдангандыр...»

Егет ягы ут йотты: «Улыбыз бик тәртипле, олыны – олы, кечене кече итә белде. Хәзер җүнле кызлары бармыни аның: эчәләр, тарталар, сүгенәләр! Башын әйләндергәндер... әйләндергәндер...»

Әмма башны ташка орып булмый – туйга әзерләнделәр. Туйдан соң яшьләргә торыр урын да кирәк булачак. Монысыннан да ата-ана читтә кала алмый. «Сөйгән яр белән шалашта да җәннәт», диләр дә бит... Әмма ул җәннәтнең өч кенә көн дәвам итәчәген дә онытырга ярамый.

Төньяк Кореяның «Хёндай» заводында җыелган автобус каты рессорлары, каймаланмаган тәрәзәләре белән янә бер сикертеп алды.

Авырлы хатын бу юлы озаграк, авыртыныбрак ыңгырашты. Йөрәк бәгыреннән өзелеп төшкән бу авазга, иң алда утырса да, беренче булып ханым игътибар итте. Игътибар итте дә, урыныннан җәһәт кенә кубып, тар арада кысыла-кысыла, егет янына килде. Өстенә иелеп, тыны кысылып пышылдады: «Бәбәйләргә җыена түгелме соң бу? – Күзләре белән авырлы хатынга йотылды. – Икмәктер әгәр!.. Килеп терәлгәнгә охшаган... Өч бала таптым мин. Өчесе дә малай. Беләм!» – дип, шик-шөбһәләргә чик куйды.

– Сез «скорый»га шалтыратыгыз. Мин янына барыйм, – диде егет, шулай ук пышылдап. Ханымның сүзләре аны каушатып җибәрде. Гөлмәрьяме турында уйлап, ул, чыннан да, дөньясын онытып кайта иде. Әйе, ул – фельдшер. Һич югы барып, хәлен сорарга кирәк.

– Тукта! Кая чабасың син?! – дип кычкырды ханым, шофёрга борылып.

Автобус юл читенә чыгып туктады. Басу өстендә тургай сайравы ишетелде. Ханым кабаланып, кесә телефонын алды.

– Хәлегез ничек? Мин – фельдшер, – диде егет, елмаерга тырышып. Авырлы хатын курку, ятсыну, чарасызлык, өмет тулы күзләрен күтәреп, аңа карады. «Тулгак кына булса ярар иде»... Башында гел шул уй бөтерелде. Тулгак кына булса, бер-ике сәгать вакыт бар. Ашыгыч ярдәм машинасы кызуласа, бер сәгатьтән килеп җитәргә тиеш. Аңарчы янында булыр. «Түзегез!» – дияр... Шулай да үзен куркыткан сорауны бирде: «Эчегез генә авыртамы? Әллә

йомышыгызны да йомышлыйсы килгән кебекме?» Авырлы хатын «әйе» дигәнне белгертеп, тиз-тиз башын какты. Димәк, шулай... Апа хаклы...

– Урын-җир чиста булырга тиеш. Сезнең пакетыгызда нинди чүпрәк ул? – диде егет, ханымның сораулы карашына җавап итеп.

– Нинди чүпрәк булсын ул?! Тәрәзә пәрдәләрем! Үземә халат! – дип чәчрәп җавап кайтарды ханым. «Чүпрәк», имеш!.. И бу ир-атның мәнсезлеге! И мәнсезлеге!..

– Җәегез!

– Әһе! – ханымның керфекләренә ике бөртек яшь тамчысы эленде. Шуннан чыгып та тәрәзә пәрдәләренең ханым өчен никадәр кадерле икәнен чамаларга була иде.

Авырлы хатынны чиста урын-җир өстенә яткырдылар. Хәзер ул нишләргә тиеш соң? Ашыгыч ярдәм машинасы килеп җитмәсә?.. Килеп җитмәсә... җитмәсә... Ул нишләргә тиеш? Нишләргә... нишләргә... Баш уйлау сәләтен югалтты. Ми күзәнәкләрен, әйтерсең, йөз градус салкында туңдырдылар да дөрләп янган утка тондырдылар. Шулай да фикерләү сәләтен югалтмаган берничә күзәнәк кыймылдашып алды: синең юл капчыгыңда китаплар... конспектлар... Кара... Исеңә төшер... Яшел тышлы дәфтәр... Конспект: «Роды в экстремальных ситуациях». Анда бөтенесе язылган. Үзе кулын тартып алырга кыймады: авырлы хатын нәзек бармаклары белән беләгенә чытырдатып ябышкан иде, ханымнан үтенде:

– Юл капчыгында... Яшел тышлы дәфтәр...

– Әһе!..

Ханым юл капчыгыннан алмашка дигән киемне, китап-дәфтәрләрне чәчеп ташлады. Берничә секундтан аның тантаналы тавышы ишетелде:

– Таптым!

– Укыгыз.

– Постелить под роженицу чистую простыню. Тәрәзә пәрдәләремне җәйдек бит инде! – ханымның тавышы өзлекте, керфекләренә янә ике бөртек яшь эленде.

– Дәвам итегез.

– «Вымыть руки с мылом, а затем протереть спиртом, йодом или другим дезинфицирующим раствором». Җәяләр эчендә «можно и водкой» дип язылган. – ханым укуын тәмамлады һәм ни өчендер ир-атка карап алды. – Аптечкаң бармы? – соравы шофёрга иде.

– Бар бугай, – диде тегесе сүрән тавыш белән. Ул авырлы хатынны утыртуына үкенә башлаган иде. Юл бит ул... Ул-бу була калса: «Алар – яшьләр, син, карт җүләр, кая карадың? – дип бәйләнәчәкләр. Бәйләнүләре бер хәл, үзеңне гаепле сизеп яшәү тагын да авыррак. Ходай күрсәтмәсен... «Хастаханә» тукталышында төшереп кенә калдырасы калган үзен. Татар акылы төштән соң шул.

– «Бугай»мы, бармы? – дип янә бер сорады ханым, тавышын күтәрә төшеп.

– Бар, бар! – диде шофёр, җанланып.

– Нәрсәләр бар?

– Бинт, мамык, йод, перекись водорода, ниндидер таблеткалар, мазь...

– Бинт! Мамык! Йод! Бөтенесен бир! Тиз бул! – әмер катгый, сүзләр кылыч белән уеп алгандай кискен яңгырады – шофёр, урыныннан сикереп торып, аптечкасын ханымга бирергә ашыкты. Ә менә су һәм сабын юк иде. Су! Гап-гади су! Кайнамаганы да ярый. Сабын! Хуҗалык сабыны! Бер чеметем! Кул юарга! Юк!

– Син ишетмәдеңмени? Ә мин кычкырып укыдым бит, Габделәхәт, – диде

ханым, ир-атның исемен тутырып әйтеп һәм бөтен мәһабәт гәүдәсе белән аңа борылды.

– Юк, ишетмәдем, – диде ир-ат бәхетле чыраена гаҗәпләнү билгесе чыгарып. – Тыңламадым да мин сине. Нәрсә укыган булдың соң син?

Ханым эндәшмәде. Ханым зур кара күзләрен тутырып, чак кына гаҗәпләнә төшеп, ир-атка карады. Аһ, ул хатын-кызның күз карашы! Йә плинтустан да түбән төшерә ул сине, йә биек тау башына күтәреп куя. Түз! Түзә алсаң!..

– Теге җәяләр эчендә язылганын күз алдында тотып әйтәсеңме? – дип сорады ир-ат, кыбырсый башлап.

– Җәяләр эчендә язылганын күз алдында тотып әйтәм, Габделәхәт, – диде ханым.

– Бәй, нигә әллә кайчан шулай димисең аны? – диде ир-ат, тагын да ныграк гаҗәпләнеп һәм «казан малаен» ханымга сузды. – Илле грамм. Күп сарыф итмәгез.

– Күпме кирәк, шулкадәр сарыф итәрбез, Габделәхәт, – диде ханым, ике уйларга урын калдырмаслык итеп.

Шофёр «салонга исе сеңеп калмасын» дипме, чиләк китереп куйды. Ханым салып торды, егет кулын юды.

– Әйбәтләп ю! Терсәкләреңә кадәр ю! Бер генә микроб та калмасын! – диде ханым, таләпчәнлек күрсәтеп.

– Син үзең микроб, – диде ир-ат, шешәдәге сыеклыкның котылгысыз рәвештә кими баруына эче янып. Шытырдатып, корсагын кашып алгач, фикеренә ачыклык кертте: – Микробтан да хужерак син!

– Сөйләнеп тор тагын, – диде ханым ачусыз гына.

– Пәке йә кайчы кирәк булыр, – диде егет. Пәке баланың кендеген кисү өчен кирәк иде. Шофёрда пәке табылды. Пәкенең йөзен ут кабызгычта кыздырып алды, аракы белән юды, йод сөртте. Йодны, тырнак асларын җентекләп чистартып, кулына да сөртте: көрән төстәге перчаткалар киеп куйган кебек булды. Авырлы хатын янына килде. Тирән итеп сулыш алды да:

– Укыгыз, апа! – диде.

– «Обработать наружные половые органы, промежность и внутренние поверхности бёдер женщины дезинфицирующим раствором...»

Укыды – егетне үлем җәзасына хөкем итте. Маңгаена салкын, хыянәтчел тир бәреп чыкты. Тез буыннары, дерелдәвеккә әйләнеп, тыелгысыз калтырарга тотынды. Баш миендә әле моңарчы фикерләү сәләтен югалтмаган соңгы күзәнәк соңгы тапкыр талпынып алды да сүнде... Бетте... Ул берни эшли алмый... Ул беркем түгел... Ул эшафотка менә... Хөкемдар – тормыш үзе. Баш очында – тәкъдир балтасы. Башыңны түмәргә куй. Чапсыннар!.. Соңгы сүз... Әйе, ул соңгы сүзен әйтергә тиеш.

И газиз әни! Бу баламнан да кеше чыкмасмы дип өметләнеп үстергәнсеңдер... Кичер, әни! Хуш, Гөлмәрьям! Мин синең мәхәббәтеңә лаек түгел... Мин синең кисеп ташлаган тырнагыңа да тормыйм!.. Син, әлбәттә, үзеңә лаек ир-егетне табарсың.

Гөлмәрьям... Соңгы очрашуыбыз...

Ул кичне алар, төркемдәшләреннән аерылып, икәү генә калдылар. Имтиханнар уңышлы тапшырылган, кесәдә – диплом! Алмагачлар алмага бөреләнә, юкә чәчәк ата, шәһәр юкә чәчәге исе белән тулган. Шулай булса да, икесенә дә чак кына моңсу да кебек иде. Гөлмәрьям дә элеккечә үртәшмәде.

Әйтәм! Менә хәзер әйтәм! Ир-егетме син, түгелме?! «Гөлмәрьям, мин сине яратам!» – дияр! Кызны күкрәгенә кысып, башны әйләндерерлек дәрәҗәдә ымсындыргыч иреннәреннән үбеп алыр! Әйтәм!.. Каһәр генә төшкән кыюсызлык!

Соңыннан... Соңыннан аларга өч егет бәйләнде. Урам хулиганнары белән беркайчан да бәйләнешеп китәргә ярамый. Чөнки үзеңне кыйнасалар да – начар, үзең кыйнасаң да – яхшы түгел. Сугышканда, аны-моны уйлап торасыңмыни, Аллам сакласын, хулиганга ул-бу була калса, «за превышение самообороны» дип бәйләнәчәкләр. Иң дөресе: качып китү. Аякларың җитез булсын – куып тота алмаячаклар. Әмма кыз бар. Кыз ул кадәр тиз йөгерә алмаячак. Ул конфликтны тыныч юл белән җайга салырга тырышты. Тегеләр аның саен оятсызландылар. Өчесе дә кызмача... Көтмәгәндә, берсе сугып та җибәрде. Икенчесенең йодрыгыннан ул читкә тайпылып өлгерде, кискен хәрәкәт белән тегенең күкрәк сөяге астына үзе сукты, тынсыз калып сыгылып төшкән уңайга тезе белән өстәде; өченчесен, яман сүгенеп, өстенә ыргылганда, кисәк бил каешыннан кысып күтәреп алды да авыр гәүдәне, әйләндереп торып, аркасына салды. Тәпи йөри башлаганнан бирле көрәшеп үсүе сәбәпче булдымы, татарчарак килеп чыкты бугай – уйлап торырга вакыты бармыни аның! Башлап сукканы «очрашырбыз әле!» дигән булып, үзен юата-юата, качып китү ягын карады. Икенчесе дә әкренләп аякланды. Сыртына төшкәне азмы-күпме «ял итмичә» торырлык хәлдә түгел иде. Таш тротуар Сабан туе мәйданының яшел чирәме түгел шул. Нишләмәк кирәк, таш джунглиларның үз кануны.

Кыз коты очып, аңа карап торды да, биек үкчәле туфлиләрен текелдәтеп, тулай торагына йөгерде.

Нигә исенә төште соң әле бу вакыйга? Вакыты ул түгел... Урыны ул түгел... Ул тәпәләшүнең ничек бетүе мөһим түгел... Туктале... Теге хулиган сугып җибәргәннән соң, ул үзен бик тиз кулга алды лабаса! Менә нәрсә мөһим!

– Җә! – диде ханым түземсезләнеп. – Озак басып торырга уйлыйсыңмы әле? Мәрткә китмәгәнсеңдер бит?

– Мин югалып калдым. Минем шундый кимчелегем бар. Миңа бу халәттән чыгарга кирәк. Чыгу юлы бер генә: әрләгез мине! Мыскыл итегез! Сугып җибәрегез!

Ханым күзләрен челт-мелт йомгалап, сүзсез калды. Маңгаена нечкә сыр ятты. Күрәсең, ханымның баш мие бу сәер мәгълүматны үзләштерә алмый интегә иде. Үзләштерде.

– Синең кай җиреңне мыскыл итәсең?! Ходай болай да кыерсыткан бит инде сине! Алланың үги малае булып басып торасың монда, чөгендердәй кызарып! И ата-анаңның яшьлек хатасы! Куркып калдыңмыни?! Бер дә күргән нәмәң түгелмени соң?!

Артыкка китте. Бу кадәр кирәкмәс иде. Мыскыл итәм, дигәч тә!.. Уйлаганын ханымның йөзенә бәреп әйтергә дип, егетебез башын күтәрде һәм яңагына төшкән авыр кулдан чак егылып китмәде. Шул мизгелдә күңел төпкеленнән кайнап чыккан ачулы тавыштан чит-читләре кереш белән каймаланмаган тәрәзә пыялалары зыңлап куйды:

– Ир-атмы син, боламыкмы?!

Бәрәч, башы эшли башлады түгелме?! Әйе шул, гөжләтеп эшли! Әллә апаның саллы кулыннан соң колагы шаулый?.. Ни генә дисәң дә, баш эшли! Кызыл дипломлы белгеч була торып, нишләп югалып калды соң әле ул?! Оят, валлаһи!

Ханым исә куркудан аһылдап куйды. Ир-атка кул күтәрде ләбаса! Ир-ат бит ул – ир-ат! Юаш дисәң дә, ир заты! Ходаем икән!..

– Чыгыгыз, – диде егет.

– Нәрсә күзләрегезне тасрайтып карап торасыз? Чыгыгыз! – дип боерды ханым. Ир-атлар автобустан төшеп, тәмәке кабыздылар.

– Сезгә дә кагыла, апа, – диде егет.

– Мин булышам, – диде ханым, батыраеп.

Бала табучы хатын бик көчле стресс кичерә. Чит-ят күзләр булмаска тиеш. Бары тик бәбәйләргә ярдәм итүче генә. Боларны аңлатып торырга вакыт тар: шуңа күрә кыска, аңлаешлы итеп:

– Микроб таратып йөрмәгез монда! – диде.

– Тоталар да «микроб», диләр. Тоталар да «микроб», диләр! Кичә генә мунча чабынып чыккан кешедә нинди микроб булсын?! – диде ханым, үпкәләп. Чыгып киткәндә, барыбер үз сүзен әйтте:

– Харап икән! Элгәре заманда кырда урак урганда да бала тапканнар әле! Бер дә «микроб» дип тормаганнар!

– Кирәгегез чыкса, чакырырмын, – диде егет, әйткән сүзенә үкенә төшеп.

Ул, чыннан да, үзен кулга алды. «Хатын-кыз сиңа кадәр дә бала тапкан, синнән соң да табачак. Монда куркырлык берни дә юк», – диде. Авырлы хатын елмайгандай итте. Күзләрендә курку кимегәндәй булды. Ике арада күзгә күренмәс ышаныч җепләре сузылды.

Иң әүвәл ул хатынга дөрес суларга кушты, «Менә шулай кирәк!» – дип, үзе сулап күрсәтте. Кирәк чакта көчәнергә боерды. «Әйдә, тагын бер тырышып карыйк!» – диде. Ул бөтенесен хәтерләде. «Көллияттә безне нинди яхшы укытучылар укыткан икән!» – дип, күңеленнән аларга рәхмәт укыды.

Ул бөтенесен дөрес эшләде. Бер генә тәҗрибәле акушер да аның эшеннән гаеп таба алмас иде. Гомерендә беренче тапкыр, ашык-пошыграк булса да, әбисе өйрәткән доганы да укып алды. Ихластан ышанып, Ходайга ялварды. «И сабый, бу якты дөньяга артың белән генә килә күрмә!» – дип, туачак балага эндәште. (Алай булган очракта хәлләр кискен катлауланып китәчәк иде.) Ходай да, туачак сабый да аның гозеренә колак салдылар булса кирәк, бераздан тынычлана төште.

Ниһаять, үзе юеш, үзе җып-җылы тере йомгакны, үпкәләвен инде онытып, таза беләкләренә чәчәкле халатын салып, яннарына ашыккан ханымга бирде.

– Бәхетең-тәүфыйгың белән, балакай! Төкле аягың белән! Аллаһы Тәгалә үзеңә исәнлек-саулык, сәламәтлек, озын гомерләр насыйп итсен! Ата-анаңны куандырып яшәргә язсын! – Артык дулкынланудан ханымның зур кара күзләренә мул булып яшь бәреп чыкты, иреннәре дога сүзләре пышылдады...

– Үә-ә! – дип аваз салды сабый анасының җылы тәненнән аерганга дәгъва белдереп. – Үә-ә!

– Сөбханалла-машалла! Тавышы нинди көр! «Кемнәр сез ?» дип, гаҗәпкә калдыңмы? Зөлхәбирә апаң булырмын мин! Синең кендек әбиең! – дип гөрләде ханым, мәһабәт гәүдәсе белән егетне читкәрәк кысрыклап.

– Баланы анасы янына салыгыз. Өсләренә ябыгыз. Мин хәзер керәм, – диде егет һәм тотрыксыз адымнар белән ишеккә юнәлде.

Ә басу өстендә тургайлар һаман сайрыйлар икән! Бөтен җиһан җырлап тора!

– Төсең качкан, – диде ир-ат, егетнең хәленә кереп. Шешәсенә ымлады: Монда илле грамм калган. Тотып куясыңмы?

– Юк.

– Рөхсәт итсәң, мин йомгаклап куйыйм. Бик каты дулкынландым, парин. Ничек дулкынланмыйсың?! Дөньяга өр-яңа кеше килде! Вакыйга ич бу! Сиңа дип саклап торган идем дә. Алайса, тотып куям.

– Үзеңә кара, абзый.

Йөгән күрмәгән ярсу тайдай дулап бер чабасы, кычкырып җырлыйсы, утырып елыйсы килә иде егетнең. Кыскасы, егетебезнең күңел халәте сүз белән сөйләп, тел белән аңлатып бирерлек түгел иде. Без аны тынычлыкта калдырыйк.

Хәер, ул үзен тиз кулга алды. Шофёрга: «Борыл! Кичекмәстән шәһәргә, роддомга!» – диде. Шофёр берсүзсез буйсынды. Юлчыларның берсе дә каршы сүз әйтмәде.

Ярты сәгатьтән автобус асфальт юлга чыкты. Борылышта, утларын җемелдәтеп, каршыга килүче ашыгыч ярдәм машинасы күренде.

**2**

Бәян ителгән шушы вакыйгадан соң җиде көн үтте микән, Көйдергән авылының медпункты каршына зәңгәр «Жигули» килеп туктады. Машинадан егерме дүрт-егерме биш яшьләрендәге ир-ат чыгып, пассажир утырган якта ишекне ачты.

Йа Хода! Шул мизгелдә җиңел юрганга төреп, бала күтәргән, бәхетле елмаюы, зәңгәр күзләре, көләч сипкелләре, ак күлмәге белән болай да кояшлы иртәне тагын да нурландырып, Җир йөзенә фәрештә иңде.

– Кендек бабасы безне каршы алырга чыккан икән, ийе бит, улым? Кендек бабасы безне сагынып көткәндер, ийе бит, улым? – дип апрель күгәрченедәй гөрләргә тотынды фәрештә. Ю-у-к, фәрештәләр бала тапмый ич. Бу илаһи зат аның беренче пациенткасы лабаса!

Ире исә сүзне кыска тотты. Егетнең кулын кысып: «Рәхмәт, брат. Малайның тәпиен обязательно юачакбыз. Бүген түгел. Бүген мин рульдә, – диде дә машинасының капотын ачты. Аның каравы хатын кинәнде: һәр җөмләсен «ийе бит, улым» дип йомгаклап куеп, һәр сүзен якты нурга, җылы назга төреп, авызыннан энҗе-мәрҗәннәр сипте; әйтерсең лә, салкын асылташларга җан иңдерде, ул асылташлар терелеп, иң газиз, иң мөкатдәс сүзләргә әверелделәр. Берничә җөмләне язып үтик:

– Кендек бабамны исем кушу мәҗлесенә чакырам, дип килде ич ул, ийе бит, улым? Кендек бабамны чакырмасагыз, бик каты үпкәлим, диде ич ул, ийе бит, улым? Бүген сәгать биштә безгә рәхим итсен, ди ич ул, ийе бит, улым? Зөлхәбирә апабыз да чакырулы. Якын киләчәктә Галимнур атлы егет булабыз инде без! Зур үскәч, нур чәчеп торучы галим кеше булырбыз, боерган булса!

Бәхетле ананың әле туктар исәбе юк иде, кыска бер паузаны тотып сорый алды:

– Ниме соң?

– Балагыз сау-сәламәт, диделәр! Авырлыгы өч кило да җиде йөз грамм, ийе бит, улым? Менә шундый баһадир без!

– Ниме соң?

– Имә! Имә! Күкрәкләремә сөт төште, Аллага шөкер. Башта бик курыккан идем. Иммәгән кая ул! Үсәргә кирәк бит безгә, ийе бит, улым? Зу-у-р булып үсәргә кирәк!

Тагын «ниме соң?» дип сорамакчы иде, туктап калды. Карасана, сорау да бирә белми икән. Оят, билләһи! Алайса, бу яшь әни аның нәрсә сорарга теләгәнен каян белә? Менә сиңа табышмак!

Бала тудыру йортыннан кайтып килүләре икән. Берара авылда яшәргә уйлаганнар. Әбисе белән бабасы: «Сездән булмас, беренче мунчаны үзебез кертәбез!» – дип атлыгып торалар. Авыл авыл инде: саф һавасы, сөте-катыгы дигәндәй – әни янында барыбер ышанычлырак. Кендек бабасының монда булуы бигрәк тә әйбәт! Менә ире нишләр инде? Ашарына пешереп ашый алырмы? Җыенып, заводына китә белерме? Оекбашын эзләп, эшенә соңга калмасмы? Әгәр дә хатын өйдә юк дип, чит хатын-кызга күз кырые белән генә карап алсамы?! Ул чагында грандиоз скандал булачак икән! (Соңгы җөмлә ире дә ишетерлек итеп, кычкырып әйтелде).

Ул арада бала тавыш бирде. Әнисенең бөтен игътибары сабыена күчте. Бәхетле ананың баласына әйткән иркә сүзләрен түкми-чәчми яза башласак, хикәябез күләме ягыннан саллы гына романга тартыр иде, вакытында туктый белик.

Ниһаять, мәҗлескә килергә вәгъдәсен алып саубуллаштылар. «Сезнең кулларыгыз шифалы», – диде хатын машинага кереп утыргач, янә балкып-елмаеп. Ул ирексездән кулларына күз төшерде. Сул кулында урта бармагының тырнак төбе кара янып чыккан.

Медпункт бинасының түбәсеннән су үтә иде. Түбәгә үзе менде. Чүкеч белән бармакка сугылды. Тырнагы төшәр микән, юк микән? Кулларыгыз шифалы, имеш. Кеше арттырып, матур итеп сөйләргә ярата инде.

«Жигули» ике тапкыр зәңгәр төтен төчкерде дә җай гына кузгалып китеп барды. Киттеләр... Күңелендә өермә кузгатып киттеләр. Бәхетлеләр! Берберсен тапканнар! Пар килүләрен әйт: хатыны – тел бистәсе, ире сүзгә саранга охшаган. Икесе дә тел бистәсе булса, нишләр идең? Йә булмаса, икесе дә сүзгә саран булсалар?

Гөлмәрьям!.. Без кайчан аңлашырбыз, Гөлмәрьям?! Ике ара күп тә түгел, аз да түгел – җитмеш чакрым. Җитмеш чакрым ерак арамы?! Туктале, уйлыйк. Әтисенең «Иж-Юпитер»ы йөреп тора бит! Утырдың – киттең! Сөйләшү җитди булачак. «Гөлмәрьям туташ, сезгә булган мәхәббәтем чиксез һәм гаять дәрәҗәдә тирән. Мин сездән җавап көтәм!» – дияр. Булсын! Китап сүзләре булсын! Гадәти көндәлек сүзләр белән мәхәббәттә аңлашырга малай-шалай түгел. Шөкер, авылның зыялы кешеләре исәбендә йөри. Бу хакта үзе белмәс тә иде, ярты гасыр гомерен балалар укытуга багышлаган Искәндәр бабай әйтте: «В нашем полку прибыло!» – диде. Авылның иң өлкән, зыялы кешесе шулай дип торгач! Монда бәхәскә урын юк.

Гөлмәрьям, әлбәттә, көлә башлар. «Фәргатьчик, башыңа эссе капмагандыр бит, кая әле дару бирим үзеңә!» – дияр. Ул сабыр гына көтәр. Кыз чагында көлеп калсын, хатын булып яши башлагач, әллә вакыты кала, әллә юк. Көлеп бетергәч, кызның нечкә биленнән эләктереп алыр да мотоциклының бишегенә ташлар. «Иж-Юпитер» бер тибүдә кабыныр «и по газам»! Җитмеш чакрымны без аны җитмеш минутта узабыз! «Иж-Юпитер»ның бишеген кыр чәчәкләре белән бизәргә кирәктер. Печән чабып салыр. Йомшакта утырып кайтсын. Сүз дә юк, болар – вак-төяк нәрсәләр. Әмма әһәмиятле вак-төяк!

Туган нигезнең капка төбенә кайтып туктагач, кызны кулына күтәреп кенә өйгә алып керер, идәннең кыл уртасында йомшак мендәргә бастырыр һәм әйтер: «Әти-әни, менә сезгә килен. «Прошу любить и жаловать!» – дияр. Менә шулай! Кыска. Ачык. Аңлаешлы. Озын-озак сөйләп тормас. Заманасы ул түгел. Әтисе башта бик каты гаҗәпләнер. Соңыннан килеп кулын кысар: «Көтмәгән идем, улым. Афәрин! Кызның кәттәсен эләктергәнсең. Безне киленле иттең. Рәхмәт!» – дияр. Әнисе, мөгаен, күз-керфекләрен чылатып алыр. Хатын-кызга елап алса да, гаеп ителми.

Әйе, шулай булачак! Инде бу хәлләрдән соң да кыз янында каушап калсамы?! Артка юл юк! Күперләр яндырылган! Ач күзеңне, егет, дөнья бу! Дөнья бит ул киләчәккә якты хыяллар белән яшәгәндә генә ямьле. Йөрәгеңдә мәхәббәт йөрткәндә генә матур. Ә шуның өстенә кешеләргә игелек тә кылып яшәсәң, мең кат ямьлерәк! Мең кат матуррак! Без шулай яшәрбез! Әйе, без шулай яшәрбез! Алла бирсә!




*Сабада «Яшь ленинчы»ның 50 еллыгына багышланган бәйрәм. Мөнбәрдә – газетаның баш мөхәррире Венера Ихсанова. Уңда – Роберт Миңнуллин, Нургали Булатов. 1974 ел.*




*«Пионерстан урамы»нда бәйрәм. «Яшь ленинчы» газетасы редакциясе. Утырганнар (сулдан уңга): Саимә Ибраһимова, Фоат Хәмидуллин, Роза Туфитуллова, Камил Кәримов, Илгизәр Сәмигуллина, Илгизә Садриева, Николай Седов. Басканнар: Рәйсә Яхина, Зөлфәт,Фәридә Вәгыйзова, Госман Садә, Нияз Акмал, Вакыйф Нуриев. 1981 ел.*



*Язучылар – «Яшь ленинчы» бәйрәменең кадерле кунаклары. Узган гасырның 90 нчы еллар башы.*




*Шагыйрьләр Илдар Юзеев (сулда), Шәүкәт Галиев әдәби әсәрләрнең геройлары белән. 2000 ел.*



*«Сабантуй»ның баш мөхәррире Илназ Фазуллин Арча районыннан килгән яшь хәбәрчеләр белән. 2017 ел.*

# КҮҢЕЛ КУШКАННЫ ТЫҢЛАП...

Күңел түреннән чыккан эчке тавышны һәркемнең дә ишеткәне бардыр. Кайчакта ул бер генә мизгелгә дә тынычлыкта калдырмый, бимазалап тора башлый. Яшьлек язының иркен һавасын күкрәк тутырып сулаган бер мәлдә Әлки якларында туып-үскән Рәшит белән дә шундыйрак хәл килеп чыга. Егет бар көчен, тәвәккәллеген җыеп, шул эчке тавышына буйсынып, инде ияләшергә дә өлгергән Зәй якларын калдырып, кабаттан юлларга чыга. Киң офыклар, якты хыяллар аны кайсы якларга дәшкәнен үзе дә аңлыймы ул, юкмы? Иң мөһиме – зуррак эшкә алыну һәм күләмле хезмәтнең нәтиҗәсен күрү ниятен тормышка ашыру. Тәвәккәллек кеше өчен кирәкле сыйфат шул. Хыяллар артыннан ияру дә кирәк гамәлдер. Рәшит Хәмәтшинның эшләнәсе эшләре башта хыял гына булып тоелса да, гомер барышында аларның барысы да тормышка аша. Кошчылык фабрикасында башкарылган илкүләм проектларны ул соңрак яңалык һәм бай тәҗрибә чоры итеп искә ала. «Шундый киң колачлы эшләрдә катнашу йөрәкне дә җилкетә, офыкларны да киңәйтә иде», – ди ул үзенең яшьлек еллары хакында сөйләгәндә.


*Корыч сынавын узган хезмәттәшләр Рөстәм Гайнетдинов һәм Рәшит Хәмәтшин*

1976 елда авыл хуҗалыгы институтын тәмамлаган егетнең Зәй районына юллама белән эшкә җибәрелеп, аннан соң, 1982 елда Лаеш районындагы зур проектлар тормышка ашырылган кошчылык тармагына чыгып китүе үкенерлек гамәл булмый. Бу якларда мәхәббәтен очратып, гаилә дә кора. Гөлсинә ханым белән ике бала тәрбияләп үстерәләр. Мәхәббәт хакында күп кешеләр, гомумән, сөйләшергә яратмый. Аны башкалар өчен сер итеп саклыйлар. Бу очракта да шулайдыр, мөгаен. Рәшит абый гаиләдә иң мөһиме – бер-береңне хөрмәт итү дип саный. Мәхәббәттән башка да сөйләшер сүзләр күп бит, дип тә өсти. Яшьлектә мәхәббәт дип типкән йөрәкләр, яши-яши, чыннан да, бер-берсе өчен терәк, таяныч һәм ышаныч хисләре белән ныгырга тиештер инде ул. Гомер буе янәшә, иңне-иңгә куеп яшәгән парлар шушы ышанычны күрсәтеп тә тора бит. Лаеш яклары да, аның гүзәл табигате дә бу гаиләне үзенә бәйли.

Әмма әнә теге эчке тавыш дигәнең бер мәлдә тагын үзен сиздерә. Бер карасаң, инде тормыш көйләнгән. Шактый гына эшләр дә эшләнеп өлгергән. Булганына шөкер итеп яшә дә яшә генә. Тик узган гасырның туксанынчы елларында илдә-көндә башланган үзгәртеп кору галәмәтләре, күпләрнең язмышына тәэсир итә. Кошчылык тармагында да зур, масштаблы эшләрнең туктатылуы күңелен бимазалый Рәшит Галләм улының. Ләкин лаеклы хезмәте белән телгә кергән һөнәр ияләре югалмый. Үзен тагын зуррак эшләрдә сынап карыйсы килгән бер мәлдә, аны 2000 елда Казан корыч эшләнмәләр заводына инженер итеп эшкә чакыралар.

Төзеләчәк заводның директоры Илдар Гыйльфан улы Ногманов кабинетының ишекләрен ачып кергәндә, мең төрле уй бөтерелә аның башында. Тагын юлларга чыгасы, инде күпме көч куеп эшләгән оешмадан китәсе булачак бит. Тик торгынлыкка тарган тармакта да калып булмый. Андагы эшләрне җанландыру өчен үз ниятләрен даими җиткергән эшчеләр сүзенә дә колак салмыйлар югарыда. Монда килүенең төп сәбәбе дә – әлеге каршылык бит. Бер караганда, яшь чак түгел, бер селтәнүдән күнегелгән урынны калдырып чыгып та китә

алмыйсың. Эчке тавыш кына һаман үзен сиздерә. Тукталып калырга ярамый, мин кушканча эшлә, ди. Шулчакта үзен-үзе тыңламаган булса, бәлки соңыннан үкенер, ник форсатны кулдан ычкындырдым икән, дияр иде. Бәхетенә, ул озак уйламый, чакырылган эшкә килергә ризалаша һәм җиң сызганып, заводның яңа корпусларын төзи дә башлыйлар. Завод директоры Илдар Гыйльфан улы зур масштаблы эшләрне башкарганда, кадрлар мәсьәләсенә бик җитди карый. Рәшит абыйның үзе кебекләр җыела яңа заводны төзегәндә. Шуңа да эшләре гел уңа. Көн үсәсен ай үсә, ел үсәсен ай үсә дигәндәй, күп көч куеп тырышуларның нәтиҗәсе үзенең күләме һәм сыйфаты белән дә сөендерә.

Әлки районы Түбән Әлки авылында туып үскән Рәшит Галләм улының инде күңеле күтәрелеп, эшләгән эшләре, яшәлгән гомере өчен сөенеп йөргән чагы. Илдә барган үзгәртеп кору елларында гигант җитештерү тармаклары тузгытылганны да күрә, нигездән башлап төзелгән заводларның барлыкка килүенә дә өлеше керә аның. Бер кеше гомерендә күпме үзгәреш, күпме яңадан корып төзү дә туры килә шул. Ләкин совет илендә үсеп чыныгу алган кешеләр бу авырлыкларга бирешми.

Оештыру эшенә, инженерлык хезмәтенә сәләт аңа әнисеннән күчкән икән. Әйе, ялгыш язмадым. Рәшит абыйның әнисе Әминә апа унтугыз яшендә тракторга утыра, бригадир була. Бөек Ватан сугышы елларында иген кырларында югары нәтиҗәләр күрсәтеп, япь-яшь кыз бала Бөек Җиңүгә үзеннән дә өлеш кертә. Дүртенче дәрәҗә Хезмәт даны ордены белән бүләкләнә. 89 яшенә кадәр гомер иткән Әминә апа дүрт баласы өчен үрнәк була. Рәшит абыйның әтисе Галләм абый бүгенге көндә дә исән-сау. Даулы сугышта илебезне яклаган ветеран киләчәк буынга тыныч көннәр теләп гомер итә.

**Айсылу ЗӨФӘРОВА**

---

*Кайтаваз*

## ЯЗМЫШТАН УЗМЫШ ЮК...

Соңгы вакытта «Казан утлары» кулымнан төшми, ябышып, яратып укыйм, чөнки укырлык яхшы әсәрләр бар. Әйтик, апрель-май саннарында Роза Туфитуллованың «Язмыш җиле», май-июнь саннарында Ринат Мөхәммәдиевнең «Ак кәгазь нидән саргая...» романнары, 6 нчы санда Ркаил Зәйдулланың «Кол Шәриф» романыннан өзек басылды. Шулай ук Рафис Корбанның «Ватан» романына карата «Кайтаваз» сәхифәсендә басылган Фоат Галимуллин һәм Фәрит Батталов фикерләре дә уйга салды. Рүзәл Мөхәммәтша исә үз Такташын үзенчә ачкан. Казан университетында мине дә укыткан хөрмәтле остазым, академик Дания Заһидуллина алып бара торган «Җәһәт тәнкыйть» сәхифәсенең практик киңәшләре башлап язучылар өчен бик тә мөһим. Грузин классигы Нодар Думбадзене («Кан авазы» хикәясе, Рәшит Бәшәр тәрҗемәсендә) татарча яңгырату да кирәк, чөнки дөнья халыклары әдәбиятына якынаюның бер юлы бу.

Р.Туфитуллованың «Язмыш җиле» романында («Казан утлары», 2019, 4-5 нче саннар) Курамша улы Тимербулат, аның уллары Хәсән, Абдулла Акчуриннар, Абдулланың җәмәгате Гөлсем турында гаҗәеп күп мәгълүмат тупланган. Мондагы бай фактик материалга исең китәрлек!

Акчуриннар нәселе мисалында без бөек татар ул-кызларының ачы язмышын аңлыйбыз. Беренче гильдия сәүдәгәре Тимербулат Акчурин 1880-1881 еллардагы һәм 1891 елгы ачлыктан интеккән якташлары өчен Иске Тимошкинода бушлай ашханә ачтырган, көн саен көндезен һәм кичен 300 кеше ашаткан, барысы 41 000 кеше тукланган. Гражданнар сугышы елларында хәрби госпиталь оештырган, янгыннан зыян күргән 240 йортка матди яктан нык ярдәм иткән ул. Аның кылган хәйрия гамәлләрен санап бетергесез... Ләкин совет хакимияте Акчуриннарның бөтен шәхси милкен, барлык мал-мөлкәтен, шул исәптән Гурьевкадагы данлыклы сукно фабрикасын да талап алган. Тоталитар режим Акчуриннарга гаять зур зыян салган, балаларын, оныкларын эзәрлекләгән һәм репрессияләгән.

Роза ханым Туфитуллованың бу романын Акчуриннар истәлеген мәңгеләштерү юлында сүздән салынган һәйкәл буларак кабул иттем.

**Илһам ФӘТТАХОВ,**
*КФУ доценты, филология фәннәре кандидаты*



Илсөяр
Иксанова

# СӘПИТ

ХИКӘЯ

Кайткан!

Ул!

Аныкы кебек өй кадәр кара джип булмас башка бу тирәдә. Юк, бу юлы да әйтми калырга ярамый! Кистереп әйтергә кирәк: «Синең хәзер акчаң күп, алып бир миңа бер сәпит. Син бит миңа тиеш!» Тиеш...

Сабантуй мәйданын уратып алган машиналар арасыннан кара джипка турылап атлаганда, Шәүкәт ул тирәдә күрергә өметләнгән ыгы-зыгыны күз алдыннан кичерде: ачып куелган багажник эчендә кечкенә табын корылган, берничә ир-ат баскан җирдән генә Сабантуйны хөрмәтлиләр, канәгать чырайлы Рәмис пластмасс стаканнарга эчемлек агызып, сыйлап тора... Шулай булырга тиеш иде. Гадәттә шулай була торган иде. Юк! Машина тирәсендә беркем юк. Җыелып өлгермәгәннәр, димәк. Мәйданны әйләнеп килергә кирәк. Казан артистлары бармы соң тагын?! Музыканы колакны ярырлык итеп көйләгәннәр.

Сабантуй мәйданында кызык тапмады Шәүкәт. Чабыштан кайткан атларны инде бүләкләп өлгергәннәр, ә мәйдан әле чын-чынлап кызып җитмәгән иде. Әлегә монда бала-чага хуҗа: күз бәйләп, җепкә элеп куелган уенчыкларны кисәләр, читтәрәк йөгереш бара, ике үсмер баганага атланып, капчык сугышып маташа. Сәхнәдә тучны чакырылган артистлар! Җырлыйсы урында, сикергәләп биеп йөриләр. Фанера акыртып! Юк икән инде, болар булгач, тагын авыл җырчылары чыкмый инде.

Сабан туенда авыл апаларының җырлаганын ярата иде ул. Әнисе белән бергә фермада эшләп йөргән гап-гади апалар, мәйдан уртасына чыгып җырлый башлагач, бөтенләй башка кешегә әвереләләр: сыннары тураеп китә, башлары югарырак күтәрелә. Чын артистлар диярсең! Шәүкәт эченнән генә алар белән таныш булуына горурланып тора. Чынлап та, туры килгәндә, Шәүкәтнең сары башын ферма исе сеңгән зәңгәр халатларына кысып сөйгән апалармы соң инде бу?! Шәүкәтнең әнисе җырламый. Ә әтисенең тавышы матур. Тик ул да мәйдан уртасына чыкмый, аның Сабан туена чыкканын да хәтерләми Шәүкәт. Көтү көткәндә, болында үзалдына җырлап йөргәнен ишеткәннән генә белә тавышының моңлы икәнен.

Сабан туеның тагын аерым биючеләре була торган иде. «Фәизкәбир кайткан, ну биеп күрсәтәчәк инде!», «Гөлнәзирәләрнең биегәнен карарга гына төштем» диләр сөйләшә иде авыл халкы.

Ә көрәш! Андый көрәшләр юк хәзер. Бил алышулары үзе бер тамаша булса, көрәш тирәсендәге ыгы-зыгы аннан болайрак тамаша! Көрәшчеләр комиссия өстәле тирәсендә җиргә чүгәләп утыра башлаганда, мәйдан дулкынланып-дулкынланып ала: кемнәр көрәшә? Чит авылларны кертәләрме? Фәлән көрәшче күренәме?

---

Илсөяр ИКСАНОВА (1966) – *шагыйрә; «Ышанасы килә», «Кышкы канәферләр», «Кырык кыл» һ.б. китаплар авторы. С.Сөләйманова һәм Һ.Такташ исемендәге әдәби премияләр лауреаты. Казанда яши.*

– Иии, бу амбал тагын килгән икән, тагын имгәтеп бетерәчәк бахырларны.
– Үткән елны да хәрәмләште Барый кияве.
– Узган атнада Көектә батыр калган егет түгелме соң тегесе?
– Монда да калыр.
– Сала бу боларны...

Көрәшчеләрнең танылганнары, мәйдан өстенә эре генә караш ташлап, үз дәрәҗәләрен белеп кенә кыймылдыйлар. Кайсы тартылып-сузылып ала, кайберсе, яннарында торган чиләктән үрелеп кенә, чи кукәй эчеп куя. Беләкләренә кызыл яулык бәйләгән комиссия әгъзалары алар янына килеп, иелеп, сөйләшеп-сөйләшеп китә...

Инде бил алышулар башлангач, бөтен мәйдан күнеле белән көрәш эченә кереп китеп, үзе көрәшкәндәй була. Көрәшчеләрнең астында дырык-дырык итеп, җир селкенеп-селкенеп ала. Мәйдан гөжли:

– Булды!
– Кая булсын, җилкәсенә салмады бит!
– Бер очко!
– Очко инде... Очколап көрәшү көрәшмени ул?! Чиста итеп салсыннар!
– Билләрен бәйлиләр...
– Ууу...
– Салды!

Ул арада көрәшүчеләрнең туганнары мәйдан уртасына ыргыла:

– Юууuук! Дөрес түгел!
– Аяк чалды!
– Нишләп дөрес булмасын, җирдән аерды, җилкәсенә салды!

Комиссия әгъзалары мәйдан уртасына йөгереп-йөгереп чыккан туган-тумачаны көчкә тоткарлап тора...

Үткәндәге Сабантуйларының ямьнәрен исенә төшергәндә, бу матур бәйрәмнең бүгенгәчә күңелен тырнап торган күренешен дә хәтереннән куа алмады Шәүкәт. Инде әллә кайчан күксел офыклар артында калырга тиеш хатирәләр бөтен җетелеге белән күз алдына килде дә басты. Хәтта, мәйдан читендә күз яшьләрен кешегә күрсәтмәскә тырышып, тиз-тиз сулышы белән эченә йота барган сап-сары сипкелле чандыр үсмерне – үзенең малай чагын – күргәндәй булып, кочагына алып юатасы килде...

Сабантуй бит иң элек игенчеләрне хөрмәтләү, бүләкләү белән башлана иде. Язгы чәчүдә җиңүчеләрне генә түгел, узган җәйдә урып-җыюда беренчелекне алган игенчеләрне дә бүләклиләр. Игенчеләр белән бергә, комбайнчы ярдәмчесе булып эшләгән үсмер малайлар да мәйдан уртасына чыгып баса. Менә шунда Шәүкәтнең бергә уйнап йөргән дуслары аннан бер башка, юк, бер генә түгел, ун башка үсеп киткәндәй була. Шәүкәтнең дә алар янына чыгып басасы, бүләкләнәсе, кыр батыры буласы килә! Килә... тик... ярдәмче итеп комбайнчылар үз яннарына йә улларын, йә туганнарын гына ала шул. Ә Шәүкәтнең әтисе көтүче. Ул да улын үз янына ала...

– Шәүти!

Җилкәсенә килеп төшкән саллы кул аны авыр хатирәләреннән бүлде.

– ... чыкмагансың дип торам. Әйдә, Рәмис сыйлый анда...

Кара джип тирәсенә шактый кеше җыелган иде. Күбесе Рәмиснең классташлары. Җылынып алгач, дөньялары бөтенләй түгәрәкләнеп киткән ир-егетләрнең очкалак сүзләренә кушылып китә алмады Шәүкәт. Башында бер генә уй бөтерелде: ничек итеп җаен китереп әйтергә Рәмискә? Берсен-берсе уздырырга тырышып кычкырып-кычкырып сөйләшкән, дәррәү көлешкән егетләрнең сүзен өзәр әмәл дә тапмады. Ул арада, көрәш башлана, ахрысы, мәйданга барырга кирәк, дип кабалана башладылар. Йә менә хәзер әйтә, йә тагын бер ел күңелендә йөртергә туры киләчәк иде әйтәсе сүзен. Быел кем батыр калыр дип гөманлап, бәхәскә әверелеп барган әңгәмә эчендә Шәүкәтнең:

– Рәмис! Синең акчаң күп хәзер, алып бир миңа сәпит! Син бит миңа тиеш! – дигән сүзләре ат дагалаганда, бака ботын кыстырган кебек булып чыкты.

Шау иткән өер бер мәлгә сүзсез калды. Аннан дәррәү көлеп җибәрделәр.

– Нәрсә?

– Нинди сәпит?

– Нәрсә сөйли бу?

– Үзе беләә! Ул миңа тиеш! – диде Шәүкәт, өстенә ябырылган сүз һөҗүмен кире кагып.

– Ха! Ха-ха! Ха-ха-ха! – Рәмис тыела алмый көлә башлады. – Сәпит! – Аннан күңелле хатирәләргә бирелгәндәй, көр тавыш белән әйтеп куйды: – Дааа, бар иде яшь чаклар, кесә тулы борчаклар! Каян исеңә төшердең, ә?!

Исеңә төшердең!.. Шәүкәтнең аны онытканы да юк. Рәмис исә аның сүзләрен чынга да алмый, шаярып сөйләшә дип уйлый, күрәсең. Сәпит алып бирергә җыенмый да.

– Алып бирәсеңме сәпит? Син бит миңа тиеш! – диде Шәүкәт, тагын үҗәтләнеп.

Кәефләнеп алган Чырый Хәмите Шәүкәтнең каршына төште:

– Ул сиңа бернәрсә тиеш түгел! Авызыңны белеп ач! Син аңа бурычлы менә. Кое казытып бирдеме үзеңә?.. Бирде! Ә син, оятсыз...

Шәүкәтнең тамагына төер тыгылды. Авыз ачып сүз әйтсә, елак тавыш чыгачагын аңлап, кулын гына селтәде дә эре-эре атлап, читкә китте.

Белмиме ул Рәмиснең яхшылыкларын?! Белә! Тик... Тик сәпит бөтенләй башка бит ул!

Шәүкәт инде мәйданга барып, күңел ачып, көрәш караудан ваз кичте. Өенә юнәлде.

Кырык бер яшьлек ир уртасы түгел, хыялы җимерелгән унике яшьлек малай елый иде аның җанында.

Ул хыялга ирешүнең аның өчен никадәр авыр булганын беркем, беркем белми шул!

...Кыр батырлары булып, масаеп, мәйдан уртасында басып торган иптәшләреннән көнләшеп, Сабан туеннан кайткач, әтисенә әйтте ул:

– Күрше Мидхәт абыйдан сора, алсын мине үзе янына, ә! Улы барыбер быел аңа булыша алмый, Казанга ушилищега керәм, ди...

– Ә миңа кем булышыр?

– Мин көтү көтмим бүтән! Кырда эшлисем килә!

– Эшләрмен мин сиңа! Малай актыгы! Бүген дә берүзем азапландым әнә...

Куба башлаган давылны сүндереп өлгерергә дип, әниләре почмактан чыкты. Мич каршында кайнашкан әнисенең ике бите алланып яна иде.

– Нәрсә инде син, улым? Таптың карышыр вакыт. Күрәсең бит, әтиең арып кайткан. Бөтен авыл бәйрәм иткәндә, бер әтиең эшен ташламады. Син тагын торасың...

– Ул да, бер көн көтүгә чыкмаса, дөнья җимерелмәс иде! Сабантуй көнне бер авылда да көтү чыкмый. Бездә генә...

– Бездә шул! Әтиең чын көтүче ул...

Белә инде Шәүкәт әтисенең нинди көтүче икәнлеген! Шул маллар янында йөрсә, аңа дөньясында башка берни кирәк түгел!

...Күпме генә карулашса да, әнисе җайлый-майлый, Шәүкәтне җәй ахырынача әтисе белән көтү көтәргә күндерде. Тик бу юлы Шәүкәтнең дә теләгенә каршы килмәделәр: эшләгән акчасына сәпит алырга вәгъдә бирделәр.

Сәпит! Шәүкәт өчен хыялларның иң-иңе иде шул ул! Сәпит алсалармы? Сәпит алсалар, Шәүкәт дөньяның иң бәхетле кешесе булачак! Дүртенче класстан соң, күрше авылга йөреп укый башлаганнан бирле, сәпит аның төп хыялына әверелде. Класстагы бөтен малайлар диярлек сәпиткә утырды инде. Сәпитлеләр артыннан һәр иртәдә мыш-мыш дүрт чакрымдагы мәктәпкә йөгергәндә, күңелендә туган тойгыларны ул сүзгә күчереп әйтә дә алмас иде. Кызыгу, көнләшү, гарьләнү... тагын әллә нинди йөрәкне әрнеткеч хисләр укмаша җанда. Сәпите булса... Фәридәне дә, Чырый Хәмите түгел, бәлки, ул утыртып йөрер иде... Фәридә, сары бөдрәләрен җилдә җилфердәтеп, Шәүкәт янәшәсендә җилдерер иде! Сәпит хакына көтү көтәргә дә була!

Сәпит хакына... әйе, сәпит хакына түзде ул! Күзне ертып таң тишегеннән йокыдан торуларга да, азгын сыерларның көтүдән качып җәфалауларына да, бөтен көтүне берүзенә калдырып, этисенең күрше авылга тамак чылатырга китеп, озак-озак югалып торуларына да... түзәргә туры килде. Көтүне Җәнәй ягына алып чыксалар, этисе шундагы дуслары янына кыякларга гына тора. Шәүкәтнең: «Китмә, эти, мин куркам, мин бит бәләкәй...» – дип елый-елый артыннан баруына да карап тормый. Чынлап та курка Шәүкәт. Таулы-елгалы аулак урында ялгызы калудан бер курыкса, авыл көтүенә кушып җибәрелгән ферманың мир үгезеннән икенче коты алына. Шуның өстенә яңгырлы көннәрдә көтү таралып теңкәгә тия. Җитмәсә, елганың аръягында иген кыры, уҗым тәмен татып калган азгын сыерлар шунда элдертергә генә тора...

Бөтенесенә кул селтәп, көтүне ташлап китүдән хыялындагы сәпит кенә саклап калган чаклары күп булды аның.

Һәм... Һәм җитте ул көн! Җәй ахырында Шәүкәткә сәпит алып кайттылар. Рамнары ялтырап торган куе яшел төстә. Аңа алтын хәрефләр белән «Урал» дип язылган җитмәсә. Утыргычы күннән. Артында күн сумкасы да бар! Сәпит түгел, хыял иде бу! Чоланга кертеп куйган сәпитне төнлә торып та берничә кат карап чыкты ул. Икенче көнне сәпитен бизи башлады: рульнең ике ягына кечкенә көзгеләр урнаштырды, рамның алгы ягына инде әллә кайчан әзерләп куйган наклейканы ябыштырып куйды. Елмаеп торган сары чәчле матур кыз сурәте төшерелгән бу наклейканы армиядән кайткан күрше абыйсыннан алган иде, шуның өчен ничә арба тирес түгәргә туры килде аңа!

– Ооо, сәпит! Тәки алганнар, ә! Өр-яңа?.. – Шәүкәтнең абыйсы янына кергән күрше малае Рәмис, кызыксынып, сәпитне әйләнеп-әйләнеп карап чыкты.

– Әйттем бит, алалар дип! – Шәүкәтнең күңел тантанасы тавышына бәреп чыккан иде.

– Тормозы шәп монең! Әйдә, таудан төшеп карыйбыз.

Шәүкәтнең коты очты.

– Җүләр мәллә! Таудан төшеп җимерергә...

– Тормозы шәп дим ич!

– Синең сәпитең бар бит, үзеңнеке белән төш!

– Төшәм дә! Синекен сынап карыйсы иде...

– Сынамый гына тор әле!

Өйдән чыгып килүче абыйсы, гадәтенчә, Рәмис ягына басты:

– Сынап карарга кирәк, диләр бит сиңа.

– Үзең эшләп ал да сына!

– Миңа сәпит кирәкми...

– Эләкмәгәч, кирәкми инде!

– Саран бакаланма инде, бер генә төшәбез!

– Теләсә нәрсә диегез, барыбер бирмим...

Ул арада абыйсы сәпитне җәһәт кенә эләктерде дә атланып, йөреп тә китте. Рәмисе кай арада багажникка кунаклап өлгерде диген... Урам буйлап җилдергән сәпит артыннан елый-елый йөгерде Шәүкәт. Тик... тик ул куып җиткәнче сәпит инде текә таудан аска тәгәрәде...

...Рамы кәкрәеп, алгы көпчәге сул якка борылып каткан сәпитен күргәч, Шәүкәтнең йөрәге өзелеп төшкәндәй булды. Күпме генә рәтләсәләр дә сәпит җилдереп йөрергә яраксыз иде, гел сул якка салулап җәфалады.

Шәүкәтнең башка сәпите булмады. Бары тик төшләрендә генә яшел сәпиткә атланып биек-биек тауларга менә иде ул. Гаҗәп! Сәпиттә үргә менү шундый җиңел, гүя аяклар педальне түгел, ә педальләр аякны әйләндерә. Менә ул сәпитенә атлана да... оча! Оча! Ә яшел рамнан аңа карап сары чәчле кыз елмая... Елмая-елмая ул аны тагын да, тагын да биеккәрәк менәргә өнди.

...Тик мондый төшләр еллар үткән саен сирәгрәк керә бара.

# КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘРЕМ...

Төп-төгәл әйтә алам: Мостай ага Кәрим белән беренче тапкыр якыннан күзгә-күз очрашуым 1970 елны Казан университетында булды. Ул кунак булып Казанга килгән иде: студентлар белән дә очрашты. Киләсен алдан ук белгәнгә, үзем белән шагыйрьнең 1966 елда дөнья күргән сайланма әсәрләренең беренче томын да алдым. Кем белә, бәлки, яраткан шагыйремнең, ул чакта ук инде дан-шөһрәт тавының түбәсенә менеп җиткән Мостайның култамгасын да эләктерермен әле, дип тә уйлаганмын, күрәсең. Җитмәсә, кечкенәдән укып үскән, шигырьләрен яттан белгән якташым да бит әле ул. Иманым камил, Татарстанда туып үскән шагыйрь егетләрнең моңа кадәр Мостайның үзен күрү түгел, китапларын да тотып караганнары булмагандыр... Әдәби кичәнең буеннан-буена шундый горурлык хисләре белән дулкынлана-дулкынлана олпат шагыйрьнең акыллы сүзләрен, затлы шигырьләрен тыңлаганнан соң, ахырдан истәлеккә култамгасын алу бер дә авыр булмады. Чөнки кичәдән соң өлкән әдипләр, яшьләр сырып алса да, аның янына китап тотып килүче чыннан да бер мин генә идем. Китабын сузуга, ул аны әйләндереп-әйләндереп карады, Казан университетында үзенең башкортча китабын укуларына бераз гаҗәпләнде дә булса кирәк, минем исемемне, кайдан килүемне сораштырды. Илештән икәнемне белгәч кенә, барысын да аңлады шикелле: елмаю балкыган йөзе тагын да яктырып киткәндәй булды. Мостай Кәримнең автографы минеке иде инде. Минем өчен бик тә кадерле булган бу вакыйгага ике дәлилем бар. Әлеге **«Робертка истәлек. М.Кәрим. 14.I.70»** дип акка кара белән язылган автографлы китапны мин әле дә кадерләп саклыйм. Аннары бик күп еллар узганнан соң, язучы Гариф ага Ахунов үзенең архивыннан бер фотосурәт бүләк итте. Анда нәкъ әнә шул очрашу сурәтләнгән: Мостай ага миңа автограф яза. Безнең белән янәшә яшь шагыйрь Рәшит Бәшәр белән азәрбайҗан шагыйре Эйваз Борчалы да басып тора. Мин ул тарихи фотоны «Уфа-Казан юллары» исемле китабыма да керттем...



*Сулдан уңга: Мостай Кәрим, Рәшит Бәшәр, Эйваз Борчалы, Роберт Миңнуллин. 1970 ел.*

Шушы очрашудан соң Мостай аганың иҗаты миңа тагын да ныграк якынайды. Аның әсәрләре дә, тормышы да һәрчак үрнәккә әйләнде. Яшьрәк чакларда алай бик еш аралашырга туры килмәсә дә, без аның белән вакыт-вакыт очрашып-күрешеп тордык. Ул Казанга еш килә иде. Сәбәпләре дә табылып кына торды: яңа чыккан китапларын тәкъдир итү уңаеннан Тукай клубында очрашу кичәләрен хәтерлим. Кичәләрдән соң җыелып фотосурәтләргә төшү гадәте бар иде. Шуларның берсен әле дә кадерләп саклыйм. 1977 елның июле. Кичәгә әдәбиятыбызның аксакаллары да җыелып килде: Рәйсә белән Риза Ишморатлар, Шәйхи Маннур, Фатих Хөсни, Мөхәммәт Садри, Мөхәммәт Гайнуллин, яшьрәкләрдән Батулла, Гаташ, Мәдинә Маликова, Госман Садә...

***

Ул еллардан соң бик күп сулар акты, бик күп җилләр исте. Мостай ага белән якынаерга, еш булмаса да, якыннан аралашып яшәргә туры килде. Бигрәк тә соңгы елларында безнең аралашуларыбыз ихлас дуслыкка әйләнде дияргә батырчылык итәм. Әлбәттә, гади тормышта да, әдәбият дөньясында да, югары даирәләрдә дә Мостай аганың якыннары, дус ишләре бихисап булгандыр. Мин инде монда Уфадагы әдәби мохитне әйтеп тә тормыйм. Ул башкорт әдәбиятында замандашларының ихлас каләмдәше, рухташы, яшьрәк әдипләрнең кайгыртучан остазы була белде. Ә менә Башкортстаннан читтәге дусларының күпчелеге, билгеле инде, үзе дәрәҗәсендәге язучы, шагыйрьләр булды шикелле. Без белгәннәре арасында Айтматов, Гамзатов, Кулиев, Көгелтинов... Бу аңлашыла да, чөнки совет чорында аларның аралашулары, очрашулары СССР һәм РСФСР язучылар союзларында, төрледән-төрле съездларда, пленумнарда, әдәбият атналыкларында... Барысы да депутатлар, лауреатлар, секретарьлар, президиум әгъзалары... Казанда да Мостай аганың дуслары, әлбәттә, күп иде. Бөек Ватан сугышы чорыннан ук килә торган дуслык. Ә инде әдәби мәдәни тормышта шактый еллар Гариф абый Ахунов белән дус булдылар, чөнки Гариф абый Татарстан Язучылар союзы рәисе булып эшләде, СССР Югары Советы депутаты булып, партия съезды делегаты булып та сайланды. Соңрак Ренат Харис белән дә якыннан аралаштылар. Ренат Мәгъсүм улының да югары титуллары җитәрлек иде. Әле дә хәтерлим, Башкортстанда уздырылган Татарстан әдәбияты һәм сәнгате көннәре вакытында Мостай ага бер төркем Татарстан кунакларын үзенә кунакка алган. Мин аны кайдан беләм, безнең чордаш бер шагыйребез шул кичне үзен чакырмаганга, бик өзгәләнеп, үпкә белдереп йөргән иде: «Карт ялгыша, карт ялгыша!» – дигән сүзләре бик истә калган. Баксаң, Переделкино иҗат йортына баргач, Мостай ага белән бергә кайчандыр берничә тапкыр бильярд уйнаганнары булган икән. Күрәсең, өлкән шагыйрь шул чакта аңа якты чырай күрсәткән булгандыр инде...

***

Мостай аганың миндә берничә хаты саклана. Бик кадерле хатлар! Ихлас хатлар! Алар минем җанымны әле булса җылытып торалар...

Менә монысы минем өчен аеруча кадерле. Татарстан китап нәшриятында «Талбишек» исемле күләмле китабым дөнья күргәч, мин аны олуг шагыйребезгә җибәрергә батырчылык иткән идем. Дөресен әйтим, җавап та өмет итмәгән идем. Әмма Мостай ага китапны җентекләп укыган булып чыкты, җавабы да озак көттермәде.

*15.X.95*
*Өфе*

*Хөрмәтле Роберт!*

*Әле шушы арада гына бүләгең кулыма килеп юлыкты. Бик зур рәхмәт сиңа!*

*Гадәттә, чәбек сәләтле шигырь чыгаручылар калын-калын китаплар бастыра торганнар иде. Мул талантлы шагыйрьнең тулы тәнле, эре сөякле, ягъни, мыкты китабын кулыма алып куандым. Һәм бүген кич буе диярлек шушы шат та, ямансу да, шаталак та, уйчан да, ярсу да, сабыр да «Талбишек»тә тирбәлдем. Үземне берчә гамьсез сабый, берчә хәстәрләргә чумган ир итеп тойдым.*

*Поэзиягә нинди генә вазифалар йөкләмәсеннәр, нинди генә бурычлар такмасыннар, асылда ул – җан азыгы, күңел бәйрәме. Бүген кич мин шушы ямьле бәйрәмдә булдым. Изгелек, матурлык, ихласлык бәйрәмендә, мәхәббәт бәйрәмендә булдым.*

*Алга йөгереп тә, артка чигенеп тә укыдым шигырьләреңне. Һәрберсе йөрәгем һәм гакылым күзәнәкләренә үзенчә үтеп керде.*

*Үзеңне кочаклап калам.*

*Мостай Кәрим*

*P.S. «Кайда сайраса да...» дигән шигыреңне элек тә укыган идем. Аның мәгънәсе минем өчен тагын да ачыклана төште. Соңгы елларда мине нинди куакта сайрарга өйрәтүчеләр ишәеп китте. Ә мин тап син әйткәнчә дөнья көтәм.*

*P.P.S. Шөкер, син «Миң» дә, «Миңнул» да, «Миңнулла» да булып китмәгәнсең, реформага бирешми, Роберт Миңнуллин көе калгансың. Чөнки шул исемле генә шагыйрь булды, бар, булыр! МК.*

***

Бер сөйләшкәндә: «Мостай ага, соңгы елларда Казанда китапларыгыз чыкмый, матбугатта да күренмисез. Җибәрегез әле шигырьләрегезне!» – дигән идем. Минем бу тәкъдимем аның күңеленә бик хуш килгәндер, күрәсең, күпмедер вакыттан соң ул өр-яңа шигырьләрен җибәрде. Һәрберсен үз кулы белән матур итеп, пөхтә итеп язып җибәргән иде ул аларны. Шигырьләренең бер өлеше «Татарстан» журналында басылып чыкты. Калганнары башка гәзитләрдә дә дөнья күрде. Хатларына караганда, Мостай аганың күңеле булган шикелле. Хатта «Сәфәр»не дә гомум шәлкемгә кушарга мөмкиндер» дигән җөмлә бар. Сүз биредә Мостай аганың миңа багышлап язган «Сәфәр» дигән шигыре турында бара.

*4.V.01*

*Роберт!*

*Менә байтак кына шигырь күчердем. Өр-яңалары да бар. Әгәр кирәк тапсаң, шуларны йә «Мәдәни җомга»га, йә «Казан утлары»на бир.*

*«Казанга» дигәнен, бәлки, «Шәһри Казан»га тәкъдим итәрсең. Икесенә бирсәң дә ярар. Ул шигырьне Казандагы дусларым, укучыларым, тамашачыларым күбрәк күрсен иде. Бу асылда Казаннан гафу үтенү бит.*

*«Сәфәр»не дә гомум шәлкемгә кушарга мөмкиндер, дим.*

*Яратып*

*Мостай Кәрим*

*P.S. Шигырьләрдә татарча имләм шәп түгелдер, имләсен җентекләбрәк карап чык инде. Сүзлекләргә дә караштыргаладым, «болара» дигән сүз сүзлекләрдә юк. Бик сутлы сүз ул. Татар теленә дә керсен иде.*

***

*18.IX.2001*

*Хөрмәтле Роберт!*

*Телефонда Клара белән сөйләшеп бетүгә почтальон пакет китереп җиткерде. Бик матур итеп биргәннәр. Сиңа да, కларага да зур рәхмәт!*

*Теләсәң, кирәк дип тапсаң, аларын (калганнарын) берәй җиргә бир. «Мәдәни җомга»га бигрәк әйбәт булыр.*

*Сезнең өйгә шалтыратуымның сәбәбе шул: мин өйдә юкта Казаннан кичә дә, бүген дә шалтыратканнар. Аны мин синең звоногың дип уйладым. Баксаң, ул Ренат Харис булып чыкты. Безнең өйдәге медсестра: «Казаннан шалтыраттылар. Исемен хәтерләмим, «Р» хәрефенә башлана бугай», – ди. «Р» булгач, синдер дип, башта эшеңә, аннан Кларага шалтыраттым. Бер-бер хәл булмагае дип, борчылдым. Харис шалтыраткач, звонокның иясен белдем. Ул да әле генә шалтыратты. Ул кунакка чакыра. Әгәр комачауларлык зур сәбәпләр булмаса (килеп чыкмаса), барырга теләгем бик зур – бер генә тәүлеккә булса да. Сагындым Казанны да, дусларны да.*

*«Бөркет – бөртек» шәп рифма. Бөркет, үзең әйткәнчә, зурлыкны, горурлыкны аңлата. Ә бөртек кадерле, газиз нәрсәне күз алдына китерә. Җимешнең дә иң асылын «бөртекләп кенә җыйдым» диләр. Үзең дә сизмәстән, бер-берсен тулыландырган ике сүзне янәшә куйгансың. Тагын шул: бөркетнең баласы йә берәү, йә икәү генә була. Өч бик бик сирәк очрый. Димәк, бөркет үзе дә бөртек кош. Бер бәләкәч кенә нәрсәне ничек аңлавымны сиңа җиткерер өчен күпме сүз яздым. Син шуны ике юлда әйткәнсең дә биргәнсең.*

*Ярый, хуш. Язган булса, тиз арада күрешербез дә әле.*

*Үзеңне кочаклап калам.*

*Мостай Кәрим.*

***

*18.XII.2001*

*Хөрмәтле Роберт!*

*«Мәдәни җомга»ны алдым. Бик куандым. Сиңа зур рәхмәт! Рәхмәт әйтеп Зиннур Мансуровка да хат яздым. Шушы ук санда Заһид Шәфигыйның мәкаләсен укыдым. Татар-башкорт дуслыгын ихлас яклый. Бердәмлеккә чакыра. Бу бик һәйбәт һәм вакытлы фикер. Тик татар-башкорт конфедерациясе турындагы уйлары мине сагайтты. Әйтик, бер бабайның башка чыккан ике улын хатыннары, бала-чагалары, оныклары белән бергә яңадан гомум йортка җыйдылар, ди. Моннанниләр килеп чыгачак? Ызгыш-талаш. Әйдә, алар әлегәчә дөнья көткән өйләрендә яшәсеннәр, бер-берсенә ярдәм итешсеннәр, кунакка йөрешсеннәр, мал бүлешеп, ара бозышмасыннар. Хәзерге заманда бәгъзе ата-ана бердәнбер улының гаиләсе белән сыеша алмый, башка торырга тырыша. Хәзер психология бүтән. Бу хакта сүзем тәмам...*

Хатның шушы урынында мин дә туктыйм. Ни өчен дигәндә, хатның алдагы өлешендә сүз башка проблемалар турында бара. Алары инде башка вакытта, башка мәкаләдә урын аласы мәсьәләләр... Миндә әле Мостай аганың тагын бер озын хаты бер. Шактый каршылыклы, четерекле фикерләр... Шуңа күрә мин аларны әлегә беркемгә дә күрсәтми торам. Шулай дөресрәк булыр... Иртәрәк әле... Чөнки анда сәясәт бар, әле дә исән билгеле шәхесләрнең исем-фамилияләре бар...

***

Куен дәфтәремә тагын бер очрашуыбыз турында язып куйганмын. Башкортстанның халык шагыйре Кадим Аралбаев үзенең кичәсенә Ренат Харис белән икебезне чакырган иде. Кичә бик матур узды. Мостай ага да килгән иде. Кичәдән соң Ренат Харис белән икебезне иңнәребездән кочаклап алды да: «Егетләр, мин банкетка бара алмам инде», – диде. Аннары бер хатирә сөйләп алды: «Бер юбилеема Рәсүл Гамзатовны да чакырган идем. Башта ук әйтеп куйдым: «Рәсүл, – дидем, – бәйрәмемне бозмаска тырыш инде, эчмә инде, соңыннан иркенләп икебез бергә утырып эчәрбез, – дидем. Әйбәт кенә йөрде. Бик күңелем булды! Аэропортка озата баргач, әйттем үзенә: «Рәсүл, рәхмәт инде сиңа, түздең, эчмәдең!» – дидем. Рәсүл миңа карап торды да: «Ялгышасың, Мостай, мин туйганчы, исергәнче эчтем, үзеңә рәхмәт! Мин айнык булып юри притворяться итеп кенә йөрдем!» – диде. Рәхәтләнеп көлештек! Шуның кебек, миңа ачуланмагыз инде, үзем елмаям, үзем көләм, сөйләшкән булам, Рәсүл кебек притворяться гына итәм. Үз хәлләремне үзем генә беләм!» – диде дә безнең белән хушлашып кайтып китте. Аның хәлен без дә белә идек, чөнки аның җәмәгате Рауза апа озак еллар авырды, аны ташлап, мәҗлесләрдә утыру бик авыр булгандыр шагыйрьгә.

Минем 50 яшемне Уфада олылап билгеләп үткәндә дә шулай булды. Башкортстан матбугатына багышланган бәйрәмдә Мостай ага белән бергә булдык, Салават һәйкәле янында бик озак сөйләшеп йөрдек. Хушлашканда: «Роберт! Кич белән бәйрәмеңдә була алмыйм инде, Рауза апаңны ташлап китә алмыйм!» – дигән иде ул моңсу гына… Һәм күзләремә карап, иңнәремнән кочып, кат-кат юбилеем белән котлаган иде, иҗат уңышлары теләгән иде…

***

Тагын бер язма килеп чыкты.

Август, 1999. Уфага Кадим Аралбайга шалтыратам. Җылы гына итеп сәламнәр бирешәбез, сәламнәр алышабыз. Бераз гына тынып торгач, әйтә бу:

– Роберт, синмени бу? Бәй, мин бит сине Мостай агай дип торам. Тавышларыгыз шулкадәр охшаган! Беркөнне ул Йоматаудан шалтыраткан иде. Бүген тагын шалтыратырга тиеш...

– Әйтәм аны бу юлы шулкадәр җылы итеп сөйләштең! – дип шаяртам. – Рәхмәт. Мостай Кәрим белән бутаганнары юк иде әле!

– Менә шулай, дустым, Мостай Кәрим белән дә бутый башладылар үзеңне. Күзгә күренеп үсәсең! – дип, Аралбай мине тагын да үсендереп җибәрә.

***

2004 елның 31 декабрендә, төп-төгәл кичке алтыда телефон шалтырады.

– Мостай абыең әле бу! Яңа еллар котлы булсын!

Бик җылы итеп котлаштык. Хәл-әхвәлләр сораштык.

– Язып булдымы соң быел?

– Бераз тырыштым инде. Менә китабым чыкты! Уфадан сезнең өчтомлыкны да алып кайттым әле!

– Ну, анда яңа әйберләр күп түгел инде.

– Яңа булмасалар да, Мостай Кәримнекеләр бит алар.

– Мин аларны Минтимер Шәриповичка да җибәргән идем. Бик матур җавабы килде: «Сәкинә белән икәүләп укыдык!» – дигән. Бу аны тагын да олайтып җибәрде!

– Үзеңнең кәефләрең ничек соң, Мостай абый, нишләптер тавышың үзгәргән?

– Менә өч-дүрт көн инде кәефсезрәк йөрим әле. Тамак авырта, маңкалап торам. Ничава, мәхәббәткә маңка мешать итми, ди бит урыслар… Әйдә, бергә-бергә яшәргә язсын!..

Аннары Клара белән дә сөйләшеп алдылар…

***

Миндә Мостай аганың тагын берничә автографлы китабы саклана. Берсенә Түбән Камада «Җидегән чишмә» оештырган кичәсеннән соң кул куйдырткан идем. Ул кичә турында мин бәйнә-бәйнә язган идем инде. Ул истәлекләр матбугат битләрендә дә басылып чыкты, минем китапларымда да бар. Шуңа күрә әлеге автограф турында гына берничә сүз әйтмәкчемен. Без ул көнне кунакханәдә Мостай ага белән кич буе, төн буе сөйләшеп чыктык. Без дигәнем, Илдар абый Юзеев, Мөдәррис Әгъләмов, Рөстәм Галиев… Үзем төшереп алган фотолары әле дә саклана. Хәзер инде төгәл генә хәтерләмим, бүлмәдәге тумбочка өстендә Мостай Кәримнең Татарстан китап нәшриятында чыккан «Гомер мизгелләре» исемле китабы күземә чалынды. «Библиотека издательства ТАТ. ОБКОМА КПСС» дигән мөһере дә бар. Каян килеп эләккән ул бирегә, тәки аңламадым. Аннары гына Мөдәррис үзе белән кыстырып килмәде микән, дип уйлап куйдым. Ни генә булса да, китапка, башкалар күрмәгәндә генә, Мостай агадан кул куйдырып алдым. *«Кадерле минем туганым Роберт, эчкән көе дә сине яратам! Мостай Кәрим. 1.XII.2000»*. Шәп автограф бит! Ихлас! Гап-гади! Үзебезчә!



*Сулдан уңга: Илдар Юзеев, Роберт Миңнуллин, Мостай Кәрим, Мөдәррис Әгъләмов. 2000 ел.*

***

Икенче автограф та шагыйрьнең «Гомер мизгелләре» исемле китабына куелган. Тик монысы «Китап» нәшриятында башкорт телендә чыкканы… 2002 елда миңа Башкортстан татарлары съездында катнашу өчен Татарстаннан рәсми делегация җитәкчесе булып барырга туры килде. (Ул чакта Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары булып эшли идем). Минем белән бергә Премьер-министр урынбасары Зилә Вәлиева, журналист Римзил Вәлиев, тагын берничә кеше бар иде. Съезд бик югары кимәлдә узды. Башкортстан Президенты М.Г. Рәхимов үзе катнашты. Соңыннан

кунак бүлмәсендә чәйләп алдык. Фойеда китаплар сатуны да оештырганнар иде. Мостай аганың яңа китабы да чыккан икән. Автограф куйдыртырга җай чыкты дип, сатып алдым да табында бик кәефләнеп утырган Мостай агага суздым. «Сездән бер истәлек булсын! Уфа истәлеге дә булыр!» – дидем. Ул башта аптырабрак китте, аннары канәгать елмаеп, бер миңа, бер китапка, бер янында утырган Зилә ханыма карап алды. Һәм, мут кына елмаеп, китапка автограф яза башлады. Язып бетерде дә китабын миңа түгел, Зилә ханыма сузды. Икесе дә бик мәэмнүн булдылар. Кул кысыштылар! Кочаклашып та алдылар бугай әле! Шуннан соң гына Мостай ага миңа таба борылып: «Ә сиңа үзем җибәрермен, китап өчен рәхмәт!» – диде. Шулай итеп, минем аркада Зилә Рәхимҗан кызы уйламаганда гына Мостай Кәримнең автографлы китабына ия булды. Минем моңа, билгеле инде, бер дә кәефем китмәде. Ни дисәң дә, берьюлы ике кешене бәхетле иттем бит! Мостай агага да хатын-кызлар алдында үзенең егетлеген күрсәтергә матур бер форсат булды! Шулай да, автографсыз калгач, китап сата торган җиргә яңадан да барып карадым, тик Мостай аганың ул китабы сатылып беткән иде инде…

Казанга кайткач, күп тә үтмәде, Уфадан бандероль килеп төште. Мостай Кәримнән! Эчендә – теге китап! Кечкенә хаты да бар. *«4.VIII.02. Роберт! Кичә китапны кызмача баштан тартып алды, дип уйлама. Ап-аек булсам да шулай эшләр идем… Һәм ап-аек булсам да, сиңа әйткән бер-ике теләгемне әйтер идем. Үзеңне сагынырга да өлгердем инде. Кларага сәлам. Мостай Кәрим.»*

Мостай аганың хатындагы «бер-ике теләгем» дигән сүзләргә аз гына аңлатма бирү кирәктер. Съездда мин, делегация җитәкчесе буларак, чыгыш ясадым. Анда шактый гына усал урыннар да бар иде. Мәсәлән, «безне стенага китереп терәделәр, курокка басасылары гына калды» дигән сүзләр. Биредә сүз, билгеле инде, федераль хакимият турында бара. Залдагылар аны бик аңлап кабул иттеләр һәм бик озак кул чаптылар! Көтелмәгәнрәк булды бугай… Чәйләп утырганда, Мостай ага мине читкәрәк алып китеп: «Чыгышың бик һәйбәт булды… Ләкин курок мәсьәләсендә арттырыбрак җибәрдең. Синең статусыңа туры килми ул! Андый әйберләрдә саграк булырга кирәк!» – дип, аксакалларча аркамнан кагып куйды. Мин аны бик аңладым. Нишлисең, аларның буынын әлеге мәсьәләләрдә сак булырга өйрәткәннәр иде шул…

Ә китапка минем өчен бик тә кадерле булган түбәндәге сүзләр язылган иде: *«Туфракташым, каләмдәшем, сердәшем Роберт Миңнуллинга – әдәпле* талант иясенә – сыналган ярату белән Мостай Кәрим. 4.VII.02.*

**Моны – үзе дә, таланты да әдәпле дип аңларга кирәк. МК».*

Мин инде бу язмамда бөек Мостай Кәримнең күпкырлы олы иҗатына, әдәбияттагы биек урынына тукталып тормадым. Соңгы вакытта гына, шагыйрьнең 100 еллыгы уңаеннан, «Мәйдан» журналында Ландыш Әбүдәрова белән күләмле әңгәмәбез басылып чыкты. «Казанские ведомости» гәзитендә дә Венера Якупова белән әңгәмә дөнья күрде. Аңа кадәр дә матбугат битләрендә, китапларымда Мостай агага багышланган мәкаләләрем, шигырьләрем басылып торды. Ул чактагы Мостай Кәрим турындагы фикерләрем, аның шәхесе, иҗаты турындагы уйлануларым еллар узу белән тамчы да үзгәрмәде. Киресенчә, бөек замандашыбызның образы торган саен тулылана, зурая һәм ачыклана гына бара. Мин аны, Уфага барып, соңгы юлга да озатыштым. Вафатына бер ел тулуга багышланган чараларда да катнаштым. Аның Уфада куелган һәйкәлен ачу тантанасында чыгыш та ясадым... Китаплары – киштәләрдә, иҗаты – күңелләрдә, хәтирәләремнең бер өлеше – шушы истәлекләремдә… Якташымның, өлкән каләмдәшемнең, остазымның һәм дустымның бер гасырлык бәйрәмен каршылаган көннәрдә аның белән бәйле кайбер истәлекләремне кабат яңарттым. Якты да, моңсу да, кадерле дә истәлекләр…

**Роберт МИҢНУЛЛИН,**
*Татарстанның халык шагыйре*

# «ЯЗУ – АКЫЛ ҺӘМ ЙӨРӘК ЭШЕ...»*



2019 елның 1 октябрендә талантлы галим һәм педагог, Татарстан Фәннәр академиясе академигы (2011), филология фәннәре докторы, профессор, ТФА вице-президенты Дания Заһидуллинаның юбилее.

Д.Заһидуллинаның галим – әдәбият тарихчысы һәм теоретигы, фәнни традицияләргә нигез салучы, аларны үстерүче, яхшы оештыручы, югары мәктәп укытучысы буларак танылуы Казан университеты белән бәйле. Биредә ул филология факультеты студентыннан кафедра мөдиренә һәм яңа фәнни юнәлеш җитәкчесенә кадәр юл уза. Бүген республикада фән сәясәтен формалаштыручыларның берсе, Халыкара конференцияләрдә һәм форумнарда Татарстан вәкиле, гуманитар фәннәр өлкәсендә күренекле галим буларак, ул татар халкының гамьнәре белән яши, XX гасыр башы зыялылары кебек үк, «милләткә хезмәтне» беренче урынга куя. XX гасырның күренекле татар язучылары иҗатын өйрәнү белән бергә, ул тормышта да алар билгеләгән әхлак нормаларына – гаделлек һәм яхшылык идеалына хезмәт итә, кешеләргә хөрмәт, үзенә һәм башкаларга таләпчәнлек сыйфатлары белән аерылып тора. Намуслы, зыялы, югары профессионализмга ия, шул ук вакытта йомшак һәм яхшы күңелле галимә, тыйнак кеше, катлаулы мәсьәләләрдә принципиаль, үз фикерен яклый һәм үткәрә белә. Бу сыйфатлар фән дөньясында традицияләрнең кыйммәтле тәҗрибәсен сакларга ярдәм итә.

Дания Заһидуллина – 300 дән артык фәнни хезмәт авторы, аларның 18е – монографияләр, дәреслекләр, уку-укыту ярдәмлекләре. Аның әдәбият белеме фәненә, аның методологиясен булдыруга, теориясен формалаштыруга һәм үсешен андагы методлар байлыгына, милли үзенчәлекләргә таянып аңлатуга, татар классик әдәбияты тарихын, хәзерге әдәби барышны өйрәнүгә керткән өлеше зур.

Нәкъ менә Дания Фатих кызы кебек хезмәт сөючән, эзләнүчән галимнәр бигрәк тә филология кебек әдәби текстка сизгерлек һәм сүзгә, андагы мәгънәләр байлыгына игътибар таләп ителгән фәнне үстерәләр. Аның каләменә татар әдәбияты тарихы һәм теориясе өчен иң мөһим фактларны аерып ала белү, күзәтүчәнлек, эрудиция, философия, эстетика, мәдәни семиотика, тарих һәм әдәбият фәне өлкәләрендә тирән белемле булу, әдәби тоем, зәвык, өйрәнә торган материалга аналитик якын килү хас.

Дания Заһидуллинаның фән юлы илдә филология фәннәре узган юл белән тыгыз бәйләнгән. Әдәбият үсешенең тулы сурәтен тергезү өчен шартлар туган, укучыга «яшерелгән» әдәбият, тыелган әсәрләр кайткан бер вакытта ул титаник текстология

* Ә.Еники «Соңгы китап» (1986).

эшен башкара. Аның тарафыннан фәнни әйләнешкә әдәбият теориясенә караган һәм моңа кадәр өйрәнелмәгән, аз билгеле хезмәтләр – Г.Сәгъдинең «Мохтасар кавагыйде әдәбия», «Мохтасар кавагыйде әдәбиягә гыйлавә», «Әдәбият ысуллары», «Әдәбият мөгаллиме», Г.Батталның «Нәзарияте әдәбия», Г.Ибраһимовның «Әдәбият дәресләре», «Әдәбият кануннары», Гата Исхакыйның «Әдәбият юллары» һ.б. кертелә. Болар аңа татар әдәби-теоретик фикеренең бөтенлекле формалашу һәм үсеш сурәтен тергезергә, борынгы заманнардан алып, XIX гасыр ахырына кадәр төп үсеш юнәлешләрен һәм этапларын билгеләргә мөмкинлек бирә. Бу эзләнүләрнең мөһим нәтиҗәсе булып, «татар әдәбияты теориясе» төшенчәсе, аның Европа һәм рус әдәбияты теориясеннән үзгә эчтәлеккә ия икәнлеге ачыклана. Әдәби әсәр, әдәби иҗатның үзенчәлекләре хакындагы законнар һәм күзаллаулар тупланмасының – милли яшәеш фәлсәфәсенә һәм шуңа бәйле милли иҗади аңга бәйле булуы билгеләнә *(Заһидуллина Д.Ф. Әдәбият кануннары һәм заман / Татар әдәбияты нәзариясе барлыкка килү һәм үсеш этаплары: монография. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2000. – 271 б.).*

Бер үк вакытта Д.Ф.Заһидуллина мәдәниятнең тирән диахрон үзгәрешләре яссылыгында XX гасыр башы әдәби-тарихи барышның һәм аның милли үзбилгеләнүен тәэмин иткән үзенчәлекләрне тикшерә. Аның тырышлыгы белән бер төркем язучылар мирасы халыкка «кайта»: Гали Рәхим, Газиз Гобәйдуллин, Мөхәммәтхәнәфи Кайбышев, Фәйзи Вәлиев, Әхнәф Тангатаров, Шаһит Әхмәдиев, Нәкыя һ.б. Алар иҗатының бер кыйпылчыгы «Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы» (2003; 255 б.) монографиясенә кушымта итеп урнаштырыла. Моннан тыш, Д.Заһидуллина тарафыннан 2004 елда Гали Рәхимнең иҗаты, XX йөз башы проза әсәрләре тупланмасы *(Рәхим Г. Сайланма әсәрләр. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2004. – 287 б.; Татар хикәяләре: XX гасыр башы. – Казан: Мәгариф, 2007. – 399 б.)* нәшер ителә. Бу тикшеренүләр гасыр башы татар әдәбияты, аерым авторлар иҗаты хакындагы күзаллауларны үзгәртә: XX гасыр башы татар әдәбияты эстетик төрле һәм күпкатламлы, төрле әдәби юнәлешләр һәм агымнар янәшә яшәгән барыш буларак күренә.

XXI гасыр башында әдәбият белеме социологик басымнан, тенденциоз һәм идеологик шәрехләүләрдән арына бара, әдәбиятны әдәби-эстетик яссылыкта өйрәнү кирәклеге ассызыклана. Гуманитар фикернең дөнья мәдәниятен Гареб моделе тирәсендә «үзәкләштерүдән» баш тартуы Шәрык мәдәнияте кыйммәтләрен, нигез сыйфатларын барлауга этәрә. Бу шартларда милли тарихи-әдәби барышны тикшерү, XX гасыр башы татар әдәбиятының тулы картинасын тергезү, аның тарихының төп принципларын ачыклау ихтыяҗы туа. Шул ихтыяҗга Д.Заһидуллина Н.Йосыпова белән язган ике китаптан гыйбарәт әдәбият тарихы дәреслеге җавап бирә *(Заһидуллина Д.Ф. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек / Д.Ф.Заһидуллина, Н.М.Йосыпова 1 нче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. – Казан: Казан университеты, 2011. – 229 б.; 2 нче китап: XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты. – Казан : Казан университеты, 2011. – 196 б.).*

Галимнең татар әдәбиятындагы яңа күренешләр хакындагы тикшеренүләре аеруча кыйммәтле. Бу – галимәнең яраткан темасы. Ул татар модернизмы һәм авангардының уникаль поэтикасын үзенә генә хас тирәнлек белән аңлата, аның әдәби-эстетик закончалыкларын ача, аларны өйрәнү өчен махсус инструментарий булдыра. Татар әдәбият белеме өчен катлаулы булган төшенчәләр («мәдәниятнең классик булмаган тибы», «сызлану әдәбияты», иҗади аңдагы экзистенциаль компонент, дөнья сурәте трансформацияләнү, әдәбияттагы эчке синтетизм һ.б.) аның каләме белән ачыклык һәм фәнни дәлилләнү таба.

Татар әдәбиятында модернизм күренешенә багышланган ике монографиядә *(Заһидуллина Д.Ф. Модернизм һәм XX йөз башы татар прозасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2003. – 255 б.; Загидуллина Д.Ф. Модернизм в татарской литературе первой трети XX века. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2013. – 207 с.)* XX гасырның

беренче чиреге милли әдәби барышында классик булмаган мәдәният тибының феноменологиясе һәм поэтикасы аңлатыла. Татар әдәбият белеме өчен бу хезмәтләр концептуаль әһәмияткә ия: алар XX гасыр башында милләтнең үсеш юлларын эзләүнең, яңа тормыш кору һәм милли мәдәниятне камилләштерү мөмкинлекләрен барлауның – әдәби барышта үзенчәлекле үсеш баскычы булган модернизмның яңа агымнарында чагылыш табуын дәлилли. Фәнни әйләнешкә кертелгән материал, аның гыйльми дәлилләнүе һәм адекват эстетик бәяләнүе татар әдәбиятында модернизмның «соңармавын»: бу чор язучылар иҗатында әдәби аңның экзистенциаль тибы күзәтелгәнлекне; яшь авторларның максат итеп яңа, якындагы традиция чикләреннән чыгып киткән, тәҗрибәләргә йөз тоткан «стиль» булдыруын, әдәби сурәтләүдә символизмга һәм импрессионизмга, ә 1920 елларда футуризмга һәм имажинизмга хас принципларны һәм алымнарны үзләштерүен күрсәтә. XX гасыр башы татар модернизм әдәбиятында Д.Заһидуллина үзенчәлекле агым – «сызлану әдәбияты»н аерып чыгара, анда әдәби аңның экзистенциаль тибы һәм традицион, һәм яңа иҗат принциплары һәм алымнары системасы аша гамәлгә куелганлыкны исбат итә: XX гасыр башы татар прозаиклары үзләренең геройларын «чиктәш халәттә», экзистенциаль шомлану, чарасызлык, читләшү, курку, борчылу кебек кичерешләр өермәсендә сурәтлиләр, бу вакытта тормышның мәгънәсенә төшенү, яшәүнең чиклелеген аңлау, милли-мәдәни үзбилгеләнү күзәтелә. Гаять киң текстлар корпусын эчке, имманент анализлап, «сызлану әдәбияты»на хас булган әдәби форма үзенчәлекләре табыла: «аң агышы» алымына мөрәҗәгать итү, кыйссага тартым жанрлык бөтенлекләре хасил булу, лиризмның, автор-хикәяләүче сөйләмендә риторик-публицистик башлангычның активлашуы, сурәтләнә торган күренешләрне символлаштыру вакытында гомумиләштерү принципларының кулланылуы һ.б.

Әлеге материалны анализлау һәм гомумиләштерү галимәне «Кеше – Алла» оппозициясе тәртипләгән традицион дөнья сурәтенең үзгәрүе хакындагы киң колачлы нәтиҗәгә китерә: аңа алмашка XX йөз башы татар әдәбиятында мәгърифәт һәм белемсезлек каршылыгына корылган реалистик дөнья моделе килә. Д.Заһидуллина фикеренчә, бу чорның башлангычында татар әдәбияты эстетик күптөрлелеккә ия булу белән бергә, фәлсәфи концепцияләрнең төрлелеге белән дә аерылып тора: традицион суфичыл фәлсәфәгә нигезләнгән әсәрләр языла, бер үк вакытта традицион образлар, мотивлар үзгәрә, алар үзгә эчтәлек ала. Күп кенә яшь авторлар (Г.Исхакый, Ш.Камал, М.Хәнәфи, М.Гафури) идеализм фәлсәфәсенә мөрәҗәгать итәләр, трансцендентализм һәм экзистенциализм белән кызыксыналар (Дәрдемәнд, Г.Тукай, М.Гафури, Н.Думави, Ә.Тангатаров). Дөньяны танып-белү мөмкинлеген шик астына куйган, агностицизм фәлсәфәсен белдерә торган (Ә.Тангатаров, «Хәят мәҗһүл»), субъектив идеализм, иллюзионизм тәгълиматы дулкынында (Г.Рәхим «Җәйге нәсер») әсәрләр языла. Дәрдемәнд, С.Рәмиев, Ш.Бабич шигырьләрендә, Ф.Борнаш, Н.Исәнбәт поэмаларында, фәлсәфи трактатларда (Г. Гобәйдуллин, «Юлдаш эзләгәндә») һ.б. күпсанлы әсәрләрдә эсхатологик тематика һәм проблематика чагылыш таба. Бу процесслар ярдәмендә галимә 1906-1908 еллар татар әдәбиятында мәдәниятнең классик булмаган тибына караган яңа дөнья моделе формалашуны исбат итә. Аның нигезендә түбәндәге оппозицияләр ятканлыкны ачыклый: реаль / трансценденталь; яшәү / үлем, үткән / бүгенге, макрокосмос / микрокосмос (әдәби сүз / кеше, әдәби сүз / милләт, кеше / тормыш, табигать / кеше һ.б.). Бу дөнья модельләренә тәңгәл поэтик принциплар булдырыла: көнбатыш Европа һәм рус әдәбиятыннан алынган алымнар традицион шәрык структуралары белән керешә; төрле язучылар иҗатындагы тотрыклы билгеләр шәхси вариантларда гамәлгә куела һәм һәр язучының метод һәм стиль үзенчәлеге хакында сөйли. Бу катлаулы һәм төрле материал бөтенлекле һәм системалы төстә галимәнең яңача язылган монографиясендә тәкъдим ителә. *(Дөнья сурәте үзгәрү: XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр: Монография. – Казан: Мәгариф, 2006. – 191 б.)*

Әлеге теманың дәвамы булып 1960-1980 еллар әдәби-тарихи барышын татар

әдәбияты тарихындагы үзенчәлекле дәвер – авангард эзләнүләр һәм тәҗрибәләр активлашкан чор буларак өйрәнү тора. «1960–1980 еллар татар әдәбияты: яңарыш мәйданнары һәм авангард эзләнүләр» (2015. 383б.) монографиясендә татар әдәбият фәнендә беренче булып «авангард», «яңачалык», «1960 еллар яңарышы», «алтмышынчы елгылар» төшенчәләре, «беренчел» һәм «икенчел» иҗат системаларын тикшерү ярдәмендә яңа күренешләр һәм процессларның әдәби-эстетик табигате ачыклана, мәдәниятнең классик булмаган һәм постклассик типлары нигезендә яткан иң мөһим багланышларның үзара мөнәсәбәтләре күзәтелә.

Татар гуманитар фәннәрендә иң катлаулылардан булган теманы сайлап, Д.Заһидуллина аны төрле аспектларда тикшерә: авангард эстетика һәм поэтика чикләрендә күп кенә күренекле шагыйрьләр (Г.Афзал, Ш.Анак, М.Әгъләмов, Р.Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Р. Харис, Р. Фәйзуллин, И.Юзеев) һәм прозаиклар (Г.Ахунов, Ә.Баян, Г.Бәширов, М.Галиев, А.Гыйләҗев, Ә.Еники, М.Мәһдиев, Х.Сарьян, Н.Фәттах, Ш.Хөсәенов, М.Юныс) иҗаты анализлана, авангардист-язучылар иҗатының нигезенә салынган әдәби-эстетик принциплар барлана, аларның XX йөз башындагы модернизмга нисбәтле дәвамчанлыгы билгеләнә, прозада һәм поэзиядә авангард эзләнүләрнең төп юнәлешләре ачыклана: экспрессионизм, символизм, сюрреализм, психологик абстракционизм шундыйлардан. Хезмәтнең үзенчәлеге булып 1960-1980 еллар әдәби барышындагы гына түгел, бәлки югарыда санап үтелгән язучыларның иҗатына хас эчке эстетик сыйфатлар һәм законнар, бу чор татар әдәбияты өчен мөһим текстлар билгеләнүне күрсәтергә кирәк.

Галимә әдәбиятта миллилек категориясенә: дөньяга милли-мәдәни караш формаларына, милли иҗат логикасына һәм традицияләргә, фәлсәфәгә, милли характер, менталитетка, этник кыйммәтләр һәм идеаллар системасына аеруча игътибар бирә. Тикшеренүләренең мөһим нәтиҗәсе булып, әлеге теманы һәм теоретик, һәм тарихи-әдәби яссылыкларда дәвам итү мөмкинлеге бирә торган гомумиләштерү ясала: «Татар әдәбиятында авангард тәҗрибәләр башка мәдәниятләрдәге мондый күренешләргә охшатып түгел, бәлки милли әдәбиятны халык җырына якынайту, аның образлар, алымнар һәм чаралар системасын киң файдалану, төрки-татар фольклорында шигырь төзелеше үзенчәлекләрен тергезү; поэзиядә – эзоп теле алымына мөрәҗәгать итү, яшерен эчтәлек һәм өстәмә мәгънәләр тудыру, татар прозасында исә – тәнкыйди башлангычның көчәюе, әдәби әсәрләрдә тыелган темалар һәм асылы белән милли проблемалар белән бергә, романтизм, психологизм, экзистенциальлек традицияләрен яңарту, шулай ук постромантизм, лирик проза, орнаментализм һ.б. яңа күренешләр барлыкка китерү аша башлана. Шулай итеп, XX гасыр уртасы татар әдәбиятында яңарыш аерым язучылар һәм шагыйрьләрнең милли әдәбиятның киләчәге хакындагы күзаллауларыннан чыгып башкарыла. Бу очракта без авангард сәнгать милли әдәбиятка алып кергән эстетик яңалыкларга гына түгел, авангардның «үзгә чынбарлык философиясенә» әйләнүенә дә игътибар итәбез» *(Д.Заһидуллина, 2015)*.

«Яңа дулкында (1980-2000 еллар татар прозасында традицияләр һәм яңачалык)» *(2006, 255 б.)* монографиясендә гасырлар чиге әдәби-тарихи барышының үсеш-үзгәреш теориясе элеккеге идеологик һәм мәдәни кыйблалар үзгәргән, иҗади тәҗрибәләр һәм яңа әдәби алымнарны үзләштерү башланган күчеш чорына бәйләнә. Гасыр чигенең төп билгесе итеп Д.Заһидуллина төрле әдәби системалар (реализм, романтизм, модернизм һәм постмодернизм) үзара бәйләнештә яшәгән татар прозасының синтезга омтылышын күрсәтә. Синтетизм милли иҗади фикерләүнең фундаменталь үзенчәлеге, тарихи-әдәби барышның универсаль закончалыкларын чагылдыра торган күренеш, бер үк вакытта әдәби системаларның милли-мәдәни үзбилгеләнүенә ярдәм итә торган процесс итеп карала. Галимә фикеренчә, 1980 елларга татар прозасының алга таба үзгәрешен тәэмин итәрлек стиль тенденцияләре формалашып җитә, болар – анда лирик-эмоциональ, тәнкыйди, публицистик башлангычларның көчәюе, психологизмның тирәнәюе.

«Татарская поэзия рубежа XX-XXI веков (1986-2015): эстетические ориентиры и

художественные поиски» (2017, 268 с.), «Современная татарская проза (1986-2016): основные тенденции историко-литературного процесса» (2017, 246 с.), «Татарская поэзия и проза рубежа XX-XXI веков: эстетические ориентиры и художественные поиски» (2018, 287 с.) монографияләрендә беренче тапкыр советтан соңгы дәвер татар әдәбиятының тулы һәм ачык картинасы тергезелә. Алдагы монографиядәге кебек үк, татар әдәбияты үсешендәге яңа этап төп әдәби юнәлешләр: «романтизм», «яңа романтизм» һәм «постромантизм», «реализм» һәм «яңа реализм», «модернизм» һәм «постмодернизм» хәрәкәте аша күзаллана, аларның татар әдәбиятында үзгәлеге, әйтик, рус әдәбиятындагы эчтәлеккә тәңгәл булмавы билгеләнә. Әдәби юнәлешләр һәм агымнар типологиясе һәм күренекле шагыйрьләр (Р.Аймәт, Ш.Гаделша, Л.Гыйбадуллина, Р.Зәйдулла, Б.Ибраһим, И.Иксанова, Й.Миңнуллина, М.Мирза, Р.Мөхәммәтшин, Г.Салим, Ф.Сафин, Сөләйман,) һәм прозаиклар (Ф.Бәйрәмова, Р.Бәшәр, М.Вәлиев, Р.Вәлиев, Р.Габделхакова, Р.Галиуллин, Г.Гыйльманов, Н.Гыйматдинова, В.Имамов, М.Кәбиров, Ф.Латыйфи, Т.Миңнулин, Ф.Садриев, Ф.Сафин, З.Хәким һ.б.) иҗат дөньясының модельләре, шуларның әдәби принципларда һәм сурәтләү алымнарында чагылышы анализлана.

Хәзерге әдәбият белеме фәненең методологик эзләнүләре контекстында «Татарская поэзия рубежа XX-XXI веков (1986-2015): эстетические ориентиры и художественные поиски» монографиясендә тәкъдим ителгән милли әдәби-тарихи барышның лирик субсистемасын өйрәнү принциплары да гаять перспективалы. Болар – индивидуаль поэтик сөйләмнәрне һәм әдәби системаны хәрәкәттәге шәхси эзләнүләр яссылыгында анализлау; иҗади новаторлык феноменының дөньяны модельләштерүгә, социомәдәни һәм шәхси поэтик контекстларга тәэсирен күзәтү; әдәбиятны синхрон һәм диахрон тикшерү.

«Современная татарская проза (1986-2016): основные тенденции историко-литературного процесса» монографиясе башкача язылган. Күптөрле әдәби-тарихи материал анда дүрт проблемалы-концептуаль циклга тәңгәлләштереп урнашкан: «Реализмның үзгәрүе», «Хәзерге татар прозасы: романтик һәм экзистенциаль фикерләү типлары», ««Күчеш» чорында интеллектуаль проза», «Классик булмаган парадигма – постмодернизмга таба». Китапның кереш өлешендә автор үзенең төп теоретик-методологик максатын, материалны ничек сайлавын болай аңлата: «Татар әдәбиятындагы теге яки бу әсәрне анализ өчен сайлау аларның иҗади кыйммәте белән генә түгел, бәлки эстетик концепцияләренең яңачалыгы белән билгеләнде. Без, гомуми әдәби барыштагы төп хәрәкәт юнәлешләрен күзәтү өчен, татар прозаикларының үзгәрешләр, милли сүз сәнгатенең үсеше яссылыгында актуаль булган текстларны сайладык» *(4 б.)*. «Яңачалык» төшенчәсе галимә өчен әдәби-эстетик үзгәрешләрне, аларның хәрәкәтен һәм эчке логикасын, мәгънәсен аңлауда иң мөһим кыйммәт булып санала. Шушы юнәлешне эзлекле үстерә барып, Д.Заһидуллина милли әдәбият тарихының системалы-динамик моделен эшли. Әлеге модель хәзерге чор әдәбияты үсешен – узган белән араны өзү һәм аңа әйләнеп кайту, традицияләр һәм яңачалык, «үз» һәм «чит», тотрыклылык һәм хәрәкәтчәнлек, универсальлек һәм уникальлек синтезы буларак шәрехләү өчен иң кулае булып тора.

Галимә тарафыннан әдәби анализ методологиясен һәм методикасын булдыру өлкәсендә зур эш башкарылган. Бу эзләнүләрнең фәнни кыйммәте, беренчедән, XIX–XX гасырларда булган әдәбият белеме концепцияләрен гомумиләштереп бөтенлекле һәм системалы шәрехләүдә; икенчедән, адекват тикшерү-анализлау инструментарие булдыруда; аның җитди сынау узуы исә гамәли куллану мөмкинлекләрен күрсәтә; өченчедән, хезмәтләр әдәбият белеменең үсеш процессын өйрәнүгә өлеш кертә.

Д.Заһидуллина катнашында һәм җитәкчелегендә әзерләнгән дәреслекләр, уку-укыту ярдәмлекләрендә милли әдәби системаларның уникальлеген, үзенчәлеген ачуга, милли әдәби традицияләрне аларга хас һәм еш кына башка телгә күчерелә алмый торган үзенчәлекле семантик һәм образлар тирәлегендә тикшерүгә; әдәбият

белемендәге билгеле методларны татар әдәбиятын анализлауда куллануга караган өлешләр аеруча кызыксыну уята. Материалның киң алынуы нәтиҗәләрне мөмкин кадәр тулы һәм барлык әһәмиятле чыганакларны файдаланып чыгаруда – иҗат психологиясен, текстның милли спецификасын тирәнтен аңлау, дәлилләрнең ышандырырлык булуы, теоретик һәм әдәби-тарихи материалның органик тоташуында чагылыш таба.

Д.Заһидуллинаның галим-тикшеренүче таланты укытучы һәм фәнни җитәкчелек сәләте белән аерылгысыз. Аның әдәбият теориясе һәм тарихы курсларында берничә буын филологлар тәрбияләнде. Үз фәнни өлкәсендә ул көчле рухны, югары идеалларны, гуманизмны, милләт язмышына кагылган гамьне аерып чыгара белә.

Казан университетында эшләү елларында Дания Фатих кызы студентларның хөрмәтле укытучысы, аларның яраткан курс һәм диплом эшләре җитәкчесе булды. Аның җитәкчелегендә 8 кандидатлык һәм 2 докторлык диссертацияләре якланган. Аспирантлар һәм докторантлар белән тема сайлаудан, максат-бурычлар билгеләүдән – документларны ВАКка җибәрүгә кадәр һәм аннан соң аларның язмышыннан ераклашмыйча яши белә ул.

Д.Заһидуллина – татар әдәбиятын популярлаштыруга, аның әдәби-эстетик тәҗрибәсен рус телле укучыга җиткерүче масштаблы проектларның инициаторы да. 2008 елдан Татарстан китап нәшриятында «Мир татарской литературы» дигән, урта һәм югары уку йорталары укучыларына, укытучыларга, шулай ук татар әдәбияты белән кызыксынган һәркемгә адресланган китаплар сериясе чыгып килә. Бу сериядәге китаплар XX гасыр татар әдәбияты классикларының әсәрләрен, авторларның тормышы, иҗаты хакында аналитик мәкаләләр, аерым әсәрләрнең анализын, мөстәкыйль эш өчен сораулар һәм биремнәрне үз эченә ала.

Дания Заһидуллина турында бик күп язарга мөмкин… Ул галим, педагог, җәмәгать эшлеклесенең үрнәге. Аның иҗат кредосын, минемчә, бөек татар язучысы Ә.Еники сүзләре белән формалаштырырга мөмкин: «Иҗат эше минем өчен башта ук шәхси эш, өзлексез уйлану белән бәйләнгән күңел һәм намус эше иде. Мин бары үзем белгәнне, үзем ышанганны гына язарга тиеш дип уйлый идем». Аннары Ә.Еники болай дип дәвам итә: «Язу – акыл һәм йөрәк эше – миңа калса, иң авыр эш. Таләпләр күп, җаваплылык бик зур. Менә шул җаваплылыктан курыкмас өчен, төрле таләпләр алдында югалып калмас өчен, язучы иң элек, ничек дим, үзенең төп максатын билгеләргә тиеш (кыйбласын дип әйтергә дә ярый). Ә максат ул – нәрсәгәдер ышану, нәрсәнедер бик нык теләү дигән сүз... Бары шул нигездә генә иҗат итәргә мөмкин».

«Дания Фатих кызы Заһидуллина» исеме инде күптән зыялылар арасында символик мәгънә алды, аның китаплары исә филологик мирасның алтын фондына керә.

Укучылары, коллегалары һәм дуслары галимәне юбилее белән ихлас күңелдән котлый, аңа ныклы сәламәтлек тели һәм яңа хезмәтләр көтә. Һәрвакыттагыча, алар татар әдәбиятын аңлауда яңа мөмкинлекләр ачар.

**Венера ӘМИНЕВА,**
*филология фәннәре докторы, профессор*

# АТАКЛЫ ТАТАР ӘДИБЕ ФАТИХ ӘМИРХАННЫҢ АВЫРУЫ, ҮЛҮЕ, КҮМЕЛҮ МӘРӘСИМЕ

*29 бит*

Фатих Әмирханның авырый башлаган көнендән (15 нче февральдән) 26 нчы февральгә чаклы хәлен белә килүчеләр арасында кардәшләрендән башка кешеләр юк[1]. Аның авырганлыгы бу вакыт дустларына, танышларына билгеле түгел. Фатихнең авырыб ятканлыгы үзенең дустларындан иң элек Кәрим Сәгыйд белән Ибраһим Бикколга мәгълүм булды. Бу 26 нчы февральдә иде. Шул көндән башлаб Фатихнең хәлен белә килүчеләрнең һәммәсенең дә диерлек исем-фамилияләре яздырыла барылды. (Югарыда шул исемлек күчерелеб куелды, ләкин монда кардәшләре кермиләр, алар язылудан тыш һәрвакыт шунда). Менә шул көндән башлаб үлгән көненә чаклы (ягъни 26 нчы февраль белән 9 нчы март арасында) 12 көн эчендә Фатихнең хәлен белә килүчеләрнең барысы бу язу буенча 76 кеше булды. Боларның 55се ир кешеләр, 21се кыз-хатынлар. Өчәүсе коммунистлар, калганлары партиясезләр. Килү исәбләре белән барлыгы 199 табкыр була. Шундан ирләр 152 табкыр, кыз хатынлар 47 табкыр килгәнләр. Исем-фамилияләре белән санаганда, болай була (хәреф тәртибе белән):

Ә[б]үбәкер Терегулов – 5 табкыр; Әфтәх Тәрҗемани – 1 табкыр; Әхмәдҗан Мостафа – 1 табкыр; Ильяс Әхмирев – 3 табкыр; Ибраһим Биккол – 12 көн рәтдән һәм һәркөн берничә табкыр. Төнлә дә саклады; Ибраһим Кули – 4 табкыр; Ибраһим Аит – 6 табкыр; Исхак Карташ – 5 табкыр. Берсендә төнен саклады; Исмәгыйль Кугушев – 1 табкыр;

30 бит

Бәдри Максудов – 2 табкыр. Берсендә ярты төн саклады; Борһан Шәрәф – 1 табкыр; Бениямин Әхтәмов – 1 табкыр; Танылмаган фамилияләр – 2 табкыр; Таһир Ильяс – 1 табкыр; Рабига Дивиева – 1 табкыр. Икенче табкыр төнен саклады; Разия Садыкова – 1 табкыр; Рауза Апакова – 1 табкыр; Рәхимә Мөхитова – 1 табкыр. 9 нчы мартка каршы төнен саклады; Рәхимә Шәрәф – 2 табкыр; Заһид Нуркин – 4 табкыр. Бер табкыр төнен саклаб кунды; Зәйнәб Хәсәни – 4 табкыр; Зыя Ваһапов – 5 табкыр. Бер табкыр төнен саклаб кунды; Җәмал Вәлиди – 1 табкыр; Халисә Сәгыйд – 5 табкыр; Хадичә Танач – 1 табкыр; Хәдичә Хуҗаханова – 6 табкыр; Хәдичә Карташ – 1 табкыр; Хәсән Исхаков – 4 табкыр. Бер табкыр төнен саклады. Хәмид Апаков – 2 табкыр; Хәмид Мөштәриев – 1 табкыр; Хәбибрахман Зәбири – 2 табкыр;

*31 бит*

Садри Җәлал – 3 табкыр. Бер табкыр төнен саклады. Садыйк Иманколый – 1 табкыр; Сара Касыймова – 1 табкыр. Ярты төн саклады. Сафа Хафиз – 3 табкыр. Бер табкыр төнен саклады. Сафа Рәйми – 1 табкыр; Сөләйман Яналиев – 1 табкыр; Суфия – 1 табкыр; Сибгать Ягуш – 1 табкыр; Шахмәмитов Рәуф – 2 табкыр. Берсендә ярты төн саклады. Шәриф Байчура – 1 табкыр; Шәһәр Шәрәф – 2 табкыр; Шәфика Аитова – 2 табкыр; Шәмсевәли Тимергали – 1 табкыр; Ш. Мостакай – 1 табкыр; Шиһаб Әхмирев

[1] Миңа мәгълүм булганлардан Галимҗан Шәрәф Бакудагы Тюркология съездына китәчәк төнне 18 нче февральдә кич белән кереб утырган. Шунда бераз кәефсезләнеб торуын сөйләгән. Ләкин ул вакытда әле ул бу авыруына әһәмият биреб карамаган. Күбрәк Бакуда булачак съездда һәм хәреф мәсьәләләре турында сөйләшкән. «Съездның күбчелеге башына ат тибкән халыкдан тормаса, латин кабул итү кебек җүләрлеккә бармас» дигән. Бакудан үзе өчен 15-20 сумларга кадәр яңа азәрбайҗан әдәбиятындагы һәм булса госманлы әдәбияты китабларын алыб кайтырга үтенгән. Соңындан каты авырыб яткан көнләрендә дә ул миндән съездның барышын сорашкалаб алгалый. «Галимҗан Шәрәф анда барыб үзенең докладын ясадымы әле, шул турыда «Коммунист» гәзитендә ниләр бар?» диб белергә кызыксына иде. *(Автор искәрмәсе)*.

*Ахыры. Башы узган санда.*

– 6 табкыр. Берсендә төнен саклады. Габдулла Агишев – 1 табкыр; Габдерахман Моратов – 9 табкыр. 3-4 мәртәбә төнен саклады. Газизә Баттал – 1 табкыр; Г. Кәрәм – 2 табкыр; Гыйльми Шәрәф – 3 табкыр; Гаяс Байки – 4 табкыр. Үлгәч, бер төн саклады. Фатих Мөхәммәдияров – 4 табкыр; Фатима Апакова – 4 табкыр; Фатима Бәхтиева – 4 табкыр; Фатиха Аитова – 1 табкыр;

*32 бит*

Фәтхи Борнаш – 1 табкыр; Фазыл Локманов – 1 табкыр; Касыйм Фәхретдинов – 1 табкыр; Касыйм хәзрәт – 2 табкыр; Кадир Хуҗаев – 4 табкыр; Каюм Мостакай – 4 табкыр. Берсендә төнен саклады. Кәрим Сәгыйд – 12 көн беррәтдән һәм һәркөн берничә табкыр. Төнлә дә саклады. Кәрим Тинчурин – 2 табкыр; Гәрәй Хәсәни – 8 табкыр; Мәхмүд Бөдәйли – 1 табкыр; Мәриям Мөштәри – 1 табкыр; Маһисәрвәр Мәрҗания – 1 табкыр; М. Гали – 3 табкыр. Берсендә төнен саклады. Мостафа Туминов – 1 табкыр; Вафа Бәхтияров – 2 табкыр. Һәр икәвендә төнләрен саклады. Вәлидхан Танач – 1 табкыр; Һади Максудов – 1 табкыр; Һарун Максудов – 2 табкыр; Йосыф Яушев – 3 табкыр; Юсупов – 1 табкыр; Гомәр Бикбулатов – 1 табкыр; 33, 34 битләр[2]

*35 бит*

*угълы Әмирханны дәвалату, карашу өчен һәм әгәр дә Ходаның әмере җитеб дөньядан кичә калса, тәкфин-тәҗһиз[3] эшләрен үтәшү, андан соң калдырган мирасларын, язуларын, кулъязмаларын, төрле документ һәм сәнәдләрен[4] барлаб акт языб алу өчен җәмәгать вәкилләре сыйфаты белән сезне ярдәмче итеб чакырабыз һәм ошбу дәгъвәтебезне[5] кабул иткән көндән кардәшебез әдиб Фатих Әмирханга гаид булган югарыдагы мәсьәләләрне башкаруда сезгә безнең белән бер хокукдан эш күрергә рөхсәт итәбез».* Имзалары: Габдулла Әмирхани, Гомәр Әмирхани, Разия Әмирхани, Газизә Яушева.

Күмү мәрәсименең[6] үзәк комиссиясе шушы чакырылган кешеләрдән гыйбарәт булды. Шул рәвешчә күмү мәрәсиме киңәшләренә керешдек. Безнең киңәшкә Заһид Нуркин белән Шиһаб Әхмиревләр дә катнашдылар. Мәҗлес актыгындарак янә берничә кеше килде. Күмү мәрәсименә хәзерләнү планы берничә көн элек хәзерләнгән проектка нигезләнеп, ошбу рәвешдә төзелде:

I. Фатих Әмирхан үзенең васыяте буенча ислам кагыйдәсе белән күмелер.

II. Коръән тутырту, тәһлил әйтдерү, дәүр[7] кылдыру, фидия[8] бирү кебек дин исемендән эшләнә торган бидгатьләр, җолалар, шулай ук табутына чәчәкләр, ленталар кую кебек горефләр һич берсе дә эшләнмәс. Чәчәк, лента китерүчеләр булса, өендә калдырылыр. Чәчәк, лента алырга теләгән кешеләргә шул акчаларын Фатих Әмирхан фондына бирергә мөмкин булуы гәзитдә чыгарылачак, тәгъзия игъланларында[9] әйтелер. Үзенең васыяте буенча һәүел намазы[10] укылырга тиешлек

*36 бит*

турында мәсҗедләргә хәбәр бирелер.

III. Җеназаны Казан мөхтәсибе Касыйм хәзрәт Салихи укыр.

IV. Күмү 12 нче февральдә[11] җомга көн булыр. Мәет шул көн көндез сәгать бердә өйдән чыгарылыр. Шул тугърыда гәзитләрдә игълан басдырылыр.

V. Күмү мәрәсимләрен башкару өчен өч төрле комиссия төзелә. Болар шушы сәгатьдән үк үзләренең эшләренә керешәләр.

**1. Информация һәм нотык сөйләүләр комиссиясе**

Бу комиссиянең вазифалары, эшләре:

1. Фатихнең чит шәһәр яки илләрдәге кардәшләренә, дустларына һәм мәтлуб[12] булган аерым кешеләргә Фатихнең үлүендән ашыгыч хәбәр тарату.

[2] Кулъязманың 34, 35 битләре сакланмаган.
[3] Тәкфин-тәҗһиз – кәфенләү-күмәргә хәзерләү.
[4] Сәнәд – документ.
[5] Дәгъвәтебезне – чакыруыбызны.
[6] Күмү мәрәсиме – күмү эшләре, процессы.
[7] Дәүр – үлгән кешенең гөнаһларын ярлыкауны сорап үткәрелгән дини йола.
[8] Фидия – үлгән кешенең гөнаһларын ярлыкауны сорап биргән мал, йолым.
[9] Тәгъзия игъланнарында – некрологларда
[10] Һәүел намазы – кеше үлгәнен ишеткәч, ахшамнан соң укыла торган ике рәкәгатьле намаз.
[11] Биредә хата киткән. Дөресе «мартта» булырга тиеш.
[12] Мәтлуб – эзләнгән.

2. Гәзитләргә игълан бирү. Рустага (?) хәбәр итү.

3. Фатихнең үлүенә багышланган бер номер газет чыгару.

4. Татар укучы һәм укытучыларын, студентларын, укымышлыларын күмү мәрәсименә катнашу өчен оешдыру.

5. Җеназа мәйданларында сөйләнәчәк нотыкларның мәүзугларын[13] һәм сөйләячәк кешеләрне алдан билгеләб кую.

Бу комиссиянең әгъзалары: Җәмал Вәлиди, Заһид Нуркин, Садри Җәлал, Бениямин Әхтәмов, Мостафа Туминов, Ф.Мөхәммәдияров һәм Гомәр Әмирхан.

*37 бит[14]*

*38 бит*

**2. Тәкфин-тәҗһиз[15] комиссиясе**

Әгъзалары: Габдулла Әмирхани, Кәрим Сәгыйд, Исхак Карташ, Зыя Ваһапов, Гыйльми Шәрәф, Шиһаб Әхмирев, Вафа Бәхтияров, Ибраһим Аитов.

Комиссиянең эшләре: юдырту, кәфенләү, мәетне саклау, атлар хәзерләтү, җеназа һәм кабер урынларын билгеләү, кабер казыту, өйдә һәм мәетне алыб барганда, тәртиб саклау, башкалар...

Бу комиссия үзенә аерым утырыш ясаб, хезмәтләрне түбәндәгечә бүлде:

1. Тәкфин-тәҗһиз өчен кирәкле булган материалларны, нәрсәләрне хәзерләү һәм күмү мәрәсимендә лязем[16] булачак барча мәсарифне[17] тәртибле рәвешдә алыб бару – хәзинәдарлык итү Исхак Карташевта йөкләнә.

2. Мәслихәт табылган кешеләрдән кизү белән мәетне саклату, саклау (почётлы сакчы кую), исләндермичә тоту Кәрим Сәгыйдкә табшырыла. Хезмәтләрен гарыз итеб[18] килүче студентлар иң беренче нәүбәтдә шушы эшдә Кәрим Сәгыйдкә ярдәм итәрләр.

3. Кабергә күмү өчен «Загс»дан рәсми язу алу Гомәр Әмирханга табшырыла.

4. Мәет булган өй янында мәсьәләгә гаид[19] йомышлар белән даими рәвешдә ат тоту (9-10 мартларда бер ат, 11 дә ике ат тоту), күмү көнесенә күб итдереб, җитәрлек кадәр атлар хәзерләү Зыя Ваһаповка йөкләнә.

5. Җеназа һәм кабер урынларын билгеләү, кабер казыту эшләре Габдулла мулла Әмирхани белән Шиһаб Әхмиревкә табшырыла.

6. Күмү көнендә өй янына җыелган халыкдан үзләре теләгән кешеләргә мәетне күрсәтү вакытында, мәетне җеназа урынына һәм кабергә алыб барганда һәм күмү вакытларында тәртиб саклау, башында Кәрим Сәгыйд торганы хәлдә

*39 бит*

Габдулла мулла Әмирхани, Ибраһим Биккол, Шиһаб Әхмирев, Каюм Мостакай һәм Зыя Ваһаповларга йөкләнә. Әгәр дә кирәк булса болар үзләренә ярдәмчеләр чакыралар.

7. Мәетне юу, Габдулла хәзрәт Әмирхани белән Фасих мөәззингә табшырыла. Юыб кую 11 нче март иртә беләндән дә соңга калдырылмас.

8. Мәетне өендә күтәреб табутына чыгарыб кую Габдулла хәзрәт Әмирхани, Гомәр Әмирхан, Ибраһим Биккол, Габдулла мулла углы Мәхмүд Әмирхани, Вафа Бәхтияр, Зыя Ваһапов һәм Гәрәй Хәсәниләргә табшырыла. Шулар өстенә башка кешеләр артдырылмый.

9. Мәетне табутка салгач, өй яныннан театр мәйданына кадәр күтәреб баручылар: Габдулла хәзрәт, Гомәр Әмирхан, Ибраһим Биккол, Кәрим Сәгыйд, Габдулла мулла углы Мәхмүд Әмирхани, Зәкәрия Әмирхани, Зәкәрия Садретдинев, Гәрәй Хәсәни, Вафа Бәхтияров, Заһид Нуркин, Кәрим Тинчурин, Ибраһим Аит, Фатих Мөхәммәдияров, Хәмид Апаков, Гомәр Бикбулатов, Һади Максудов, Гыйльми Шәрәф булырлар.

10. Театр мәйданындан каберенә чаклы күтәреб баручылар яңыз укучылар, студентлар, укытучылар, һәм укымышлылар гына булыр. Башка төрле сыйныф кешеләре катнашдырылмас.

[13] Мәүзугларын – темаларын, эчтәлекләрен.
[14] Кулъязмада 37 бит буш калдырылган.
[15] Тәкфин-тәҗһиз – кәфенләү-күмәргә хәзерләү.
[16] Лязем – кирәкле.
[17] Мәсарифне – тотылган чыгымнарны.
[18] Гарыз итеп – танып, олылап-хөрмәтләп.
[19] Гаид – бәйләнешле, мөнәсәбәтле.

11. Мәетне кабергә иңдерүчеләр: Җәмал Вәлиди, Фатих Мөхәммәдияров, Вафа Бәхтияров, Зәкәрия Садретдинев, Кәрим Сәгыйд, Зыя Ваһаповлар булырлар.

12. Каберенә алыб ләхедкә куючылар: Ибраһим Биккол, Габдулла хәзрәт Әмирхани һәм Гомәр Әмирханлар булырлар.

*40 бит*

**3. Рәсем алдыру комиссиясе**

Әгъзалары: Кәрим Тинчурин, Хәсән Исхаков, М.Гали, Кадир Хуҗаев, Каюм Мостакай, Г.Кәрәм.

Вазифалары: Фатихнең караватында яткан килеш рәсемен алдыру. Якын кардәшләре белән бергәләб рәсемен алдыру. Гипс белән маскасын алдыру һәм шуны балавызга эшләтү. Өендән каберенә илткәнче берничә урында җеназа мәрәсимләрен һәм каберенә төшерү вакытларын рәсемгә алдыру. Җеназа мәрәсимләрен киноматограф лентасына алдыру.

Бу өч төрле комиссиядән тыш янә Фатихне күмгәндән соң аны искә төшерү комиссиясе төзелергә тиешлеге дә сөйләнеб үтелде. Фатихнең каберенә таш куйдыру, аңарга багышланган кичәләр ясау, мәҗмугасын[20] чыгару, рәсемләрен эшләтдереб тарату, кайбер нәрсәләрен музейга бирү һәм, гомумән, аның исемен мәңгеләшдерү кебек эшләр шушы комиссиядә каралырга тиеш.

*41 бит*

**Комиссияләрдә**

Югарыда сөйләнгән комиссияләр һәм аның аерым-аерым әгъзалары һәммәсе дә бик ныклаб торыб үзләренең эшләренә керешделәр. 11 нче март кич һәммә эшләр башкарылыб бетде. Шушы ике арада, Фатихнең үлгән көнендән 11 нче март кичкә чаклы (өч көн эчендә) эш өстендә байтак сөйләшүләр, киңәшүләр булды. Ләкин шушы киңәшүләрдә татар коммунист укымышлылары, язучылары килеб һичберсе төбле рәвешдә катнашмадылар (бары тик үлгәнендән берничә сәгатьләр үткәч үк, Мәхмүд Бөдәйли ибдәш кенә зыярәт итеб, тәгъзия[21] кылыб чыкды).

Без үзебезнең Үзәк комиссия исемендән шушы вакытда дәвам итмәкдә булган Татарстан Советлары съездының президиумына Фатих Әмирханның үлүендән рәсми кәгазь җибәрдек. Күмелү көнен хәбәр итдек. Шуңар каршы һичбер җаваб булмады[22].

Фатих үлгәннең беренче көнендә үк яшь язучылардан кайберәүләре (Хәсән Исхаков, М.Гали, Садри Җәлаллар): «Әгәр дә гражданский күмү белән күмсәк, бәлки съезд да, хөкүмәт дә һәм коммунистлар да катнашырлар; күмү мәрәсиме тагын да зуррак булыр иде» дигән мәфһүмдәрәк[23] бер фикер сөйләделәр. Шул көнне кичен һәм иртәгесен Үзәк комиссия әгъзасы Фатих Мөхәммәдия[р]ов да шушы фикерне куәтләде. Ләкин боларның һичберсе Үзәк күмү комиссиясенә төбле бер тәклиф[24] рәвешендә түгел, бәлки хосусый рәвешдә генә әйтелделәр. Шулай да булса Үзәк комиссия бу фикерне игътибарга

*42 бит*

алыб, үз эчендә берничә кат сөйләшеб үтде һәм бу тугрыда Фатих Әмирханның кат-кат әйтеб калдырган васыяте булганга, аңарга ихтирам йөзендән һәм аның динле булуын күздә тотыб, үзе әйткәнчә, Ислам кагыйдәсе буенча җеназа укыб күмәргә карар бирде.

Шул көнне кич белән сәгать унларда Фәтхи Борнаш килде. Без әле бу вакыт аерым-аерым рәвешдә һаман да күмү мәрәсимләренә хәзерлек турында сөйләшеб утыра идек. Ул безгә янәдән ничек күмү мәсьәләсен кузгатды, безнең карарыбызга бәхәс итде: «Фатих Әмирхан сезнең карашда гына түгел, безнең карашда да зур язучы һәм

[20] Мәҗмугасын – әсәрләренең җыентыгын.

[21] Тәгъзыя – үлгән кеше якыннарының кайгысын уртаклашу, юату.

[22] Соңыннан ишетелгән хосусый хәбәрләрдән, съезд президиумының безнең бу кәгазебезне, гомумән, Фатихнең үлү хәбәрен съездда рәсми игълан итмәгәнлеге беленде. Руслардан берәү Фатихнең вафаты турында сөйләшкәндә «Фатихнең үлгәнен съездга хәбәр итеб җеназасын съезд утыра торган Комклуб бинасы алдына алыб барганлар имеш дә, съездлан берәү дә чыкмаган имеш, шул дөрестме?» диб сорады. Җавабда «Ул көн бәйрәм иде, бәлки съездның җыелышы булмагандыр» диб калдырырга гына туры килде.

[23] Мәфһүмдәрәк – эчтәлектәрәк.

[24] Тәклиф – көчләп кушу, боеру.

әдиб, ул җәмәгать кешесе. Аны сезнең кебек иске дустлары гына түгел, һәммәбез дә ихтирам итәбез, коммунистлар да ихтирам итәләр. Без аның Печән[25] һәм чалмалы халык кулы белән күмелүен теләмибез. Гражданларча күмелү белән күмелсен. Без партияле укымышлылар әле бу турыда съездда да сүз кузгатырга уйлаб йөрибез», – диб дау чыгарды. Безне орышды. Күңелендән ничек булгандыр, анысын белмим, ләкин тышындан үтә динсез киселергә маташды. «Фатих ул динсез иде. Аның бит җеназа укыб күмү турында шаһидләр алдында үз кулы белән язып калдырган васыяте юкдыр», диде.

Мөхәммәдияров үзенең әсасән[26] гражданларча күмү ягында икәнлеген сөйләб, әгәр дә васыяте буенча җеназа укырга теләүчеләр булса, анысын зыярәт янында гына эшләсенләр, диде.

Мин: «Без Фатихне зур ихтирам белән олуглаб күмәчәкбез. Бөтен партиясез укымышлылар бу күмү мәрәсименең уртасында булачаклар. Чалмалы халык белән Печән базары кулына бирергә уйлаганыбыз да юк. Фатихне татарның

*43 бит*

укымышлылары, укытучылары, укучылары, студентлары күмәчәк. Әгәр дә татар коммунист укымышлылары да Фатихне зур әдиб һәм җәмәгать кешесе диб танысалар, сез әйткәнчә ихтирам итсәләр, ни өчен исән чагында килмиләр иде? Ни өчен татар театрының 20 еллык юбилейсе вакытында аны игнорировать[27] итделәр, хәтта юбилей мәҗлесендә сүкделәр? Ни өчен ул авырган чагында хәлен белә килмәделәр? Ни өчен бөтен партиясез укымышлылар үзләренең барлык көчләре белән Фатихне үлемдән алыб калырга тырышыб йөргәндә, булышлык күрсәтмәделәр? «Фатих Әмирхан каты авырый» дигән хәбәргә һич бер төрле әһәмият дә бирмәделәр? «Кызыл Татарстан» идарәсендәге Толымбайскиләрегез «Фатих Әмирхан каты авырый» дигән хәбәрне гәзиткә басыб чыгарырга да каршы килделәр. «Фатих Әмирхан безнең өчен әллә кайчан үлгән инде, андый чепухаларны басыб ма[та]шмыйбыз» диб әйтергә дә нахаллыклары җитде! Инде хәзер инициативаны үзегезнең кулга алырга телисез! Монда аңлашылмый торган бер мантыйк бар», – дидем. Шуның өстенә «Әгәр дә чындан да аңар ихтирам күрсәтеб күмү мәрәсимләрендә катнашырга телисез икән, сезнең катнашуга җеназа уку бер дә комачаулык итми. Без җеназа укудан дүнмибез[28]. Ләкин мин үзем җеназа уку фактына чаклы гражданларча мәрәсим ясарга да каршы түгел», дидем.

Ибраһим Биккол: «Без Фатихне үзенең васыятенә бинаән[29], Ислам кагыйдәсе буенча җеназа укыб күмәчәкбез. Әгәр дә сез аны ихтирам итсәгез, аның васыятенә каршы килмәскә тиешсез. Мәсьәлә бик җиңел, бары тик җеназа гына укымыйсыз, без укыган чагында читкәрәк китеб кенә торасыз. Без бит җеназадан башка дини бидгатьләрнең берсен дә эшләмибез. Шуңар күрә җеназа укудан башка күмү мәрәсимләренә бик иркенләб катнаша аласыз. Әгәр дә без ихтирам иткән бер коммунист үлсә, аның

*44 бит*

җеназасыз күмелүенә һичбер каршы килмәс һәм күмелү мәрәсименә катнашыр идек. Шулай ук әгәр дә без ихтирам иткән бер урыс булса, аның поплар белән күмелүенә, чиркәүгә кертелүенә һичбер каршы килмәс идек. Урыслар белән чиркәүгә дә керер һәм чукынганларын да караб торыр идек; без үзебез андый игътикадда[30] булмаганга, бу безнең иманыбызга да зарар китермәс һәм аны ихтирам йөзендән күмү мәрәсименә катнашуыбызга да манигъ[31] булмас иде. Ни өчен сез дә бу мәсьәләгә шулай карый алмыйсыз?», – ди.

Фәтхи Борнаш янган шәһәр театры мәйданында гражданларча мәрәсим ясау фикерен куя. Җеназагызны зыярәт янында укырсыз, ди.

Ибраһим Биккол: «Без инде Фатихнең гәүдәсен коммунистлар да ихтирам итсенләр диб, мәйдандан мәйданга өстерәб йөрергә каршы киләбез. Әгәр дә ихтирам итсәгез, Фатихне үзегезгә китертмичә, үзегез Фатих янына килегез», – ди.

[25] Бирелә Печән базары халкы, сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр күз уңында тотыла.
[26] Әсасән – нигездә.
[27] Игнорировать – күрмәмешкә салышу, читкә тибәрү.
[28] Дүнмибез – кире чигенмибез, баш тартмыйбыз.
[29] Бинаән – нигезләп, таянып.
[30] Игътикад – инану, ышаныч.
[31] Манигъ – тыю, киртә.

Җәмал Вәлиди: «Гражданларча күмү мәрәсиме ясау намына[32] җеназасын яшереб укыб, Фатихне керәшенләрчә күмүгә һичбер разый булырга ярамый», – ди.

Моназарә[33] озынга китә. Башкалар да катнашалар. Комиссиянең карары бозылмый.

10 нчы март «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» гәзитләрендә Фатихнең үлүе турында түбәндәге игъланлар чыгарылды.

1. *9 нчы мартда сишәнбе көн иртә белән 10 сәгать 10 минутда атаклы олы татар язучысы Фатих Әмирханның дөньядан үткәнлеген якынларына, мөхибләренә тирән кайгы белән белдерәбез. Мәрхүмнең җәсаде җомга көн 12 нче мартда көндез сәгать бердә фатирыннан чыгарылыб, Мулланур Вахидов мәйданына китереләчәк. Мәрхүмнең васыяте буенча өстенә чәчәкләр һәм ленталар куелмаячак. (Ихтирам йөзендән чәчәк, лента куярга уйлаган оешма һәм кешеләргә, шул эшләргә тотачак акчаларын мәрхүмнең хатирәсе фондына табшырырга мөмкин).*

*Күмү мәрәсимен үткәрү комиссиясе*

*45 бит*

2. Шундый ук игълан. Фатихнең якын кардәшләре исемендән.

3. Гәзитнең Казан хәбәрләре арасында. Редакциядән.

10 март. Күмү комиссияләре үзләренең эшләрендә. Казандагы партиясез татар укымышлылары, Фатихнең дустлары, танышлары әледән-әле килеб булышлык күрсәтеб торалар. Коммунистлар да берәм-берәм килеб тәгъзия кылыб китәләр. Үзәк күмү комиссиясенә кичә Фәтхи Борнаш кузгаткан мәсьәлә турында бер рәсми тәклиф-фәлән юк.

11 март. «Кызыл Татарстан» һәм «Красная Татария» гәзитләрендә Фәтхи Борнашның Фатих Әмирханга багышланган мәкаләләре чыга. Ул үзенең бу мәкаләләрендә Фатих Әмирханга «Без аны инкыйлабчы мөхәррир, шагыйрьләр тезмәсенә кертергә тырышмыйбыз» диб бәя куя. Әйтерсең лә аңарга «зинһар, кертсәнә инде, Фәтхи ибдәш» диб ялынганлар, диярсең.

Андан соң шул ук көнге гәзитдә: 1) «Кызыл Татарстан» һәм «Крестьян» гәзитләре язучыларның, 2) Гужур һәм «Шәрык матбагасы» эшчеләренең, 3) матбугат эшчеләре оешмасы белән Гыйльми үзәк һәм Дәүләт нәшриятының тәгъзия игъланлары чыга.

«Татарстан» гәзите тирәсендәге яшь язучылар һәм партияле укымышлылар берәм-берәм килеб «Фатихне гражданнарча мәрәсим белән күмергә кирәк» диб сүз куертыб, комиссия әгъзаларын моназарага чакырыб йөриләр. Комиссия әгъзалары боларга каршы: «Әгәр дә гражданларча мәрәсим белән күмү ягында булучылар үзләренең күмү мәрәсименә катнашырга, Фатихне ихтирам итәргә теләгәнлекләрен комиссиягә килеб,

*46 бит*

төбле-җүнле рәвешдә әйтсәләр, бер тәклиф кертсәләр, без сөйләшүдән баш тартмыйбыз, сөйләшербез. Ләкин җеназа укудан дүнмәбез. Шунда да һәр ике як катнашырлык рәвешдә килешү ясаб, күмү мәрәсиме планнарын яңадан бер кат тикшереб караб чыгарбыз» диб җаваб бирәләр.

Көн урталарында Биккол белән мине телефондан обкомның агитпроп бүлегенә чакыралар. Барабыз. Анда утыручы Гыймранов «мин бернәрсә дә белмим», ди. Провакация булыб чыга.

Ниһаять, кич сәгать җиделәрдә (иртәгә Фатих күмеләчәк дигән кичдә) гражданларча күмү ягында булучылардан рәсми рәвешдә кешеләр киләләр. Безгә күмү мәрәсиме турында сөйләшер өчен катнаш утырыш ясарга гарыз итәләр[34]. Утырыш башлана. Ибраһим Биккол рәислек, Заһид Нуркин секретарьлек итә. Протоколы түбәндәгечә:

*Фатих Әмирханны күмү мәрәсиме турында мәҗлес протоколы*

1926 ел. 11 март.

Мәҗлесдә булучылар: Фатих Сәйфи, Исхак Рәхмәтуллин, Фәтхи Борнаш, Латыйф Гомәров, Мәхмүд Бөдәйли, Фатих Мөхәммәдияров, Ибраһим Биккол, Кәрим Сәгыйд, Бениямин Әхтәмов, Гомәр Әмирхан, Габдулла мулла Әмирхани, Заһид Нуркин, Гомәр Бикбулатов, Гыйльми Шәрәф, Шиһаб Әхмирев, Зыя Ваһапов, Гәрәй Хәсәни, Садри Җәлал, Фатих Әмирхан II, Х.Зәбири, Исмәгыйль Рәмиев.

[32] Намына – исеменә.
[33] Моназарә – бәхәс.
[34] Гарыз итәләр – тәкъдим итәләр.

Нәүбәтдә: ничек күмү мәсьәләсе.

Ибраһим Биккол: Күмү мәрәсиме үткәрү комиссияләренең карарларын игълан итде.

Латыйф Гомәр: Фатих абый барыбыз өчен дә кадерле. Ул үзенең гомерен искелек белән көрәшеб үткәрде. Яшь буынга тәэсире зур булды. Күмүне дә шундый итеб үткәрергә кирәк.

*47 бит*

Исхак Рәхмәтуллин: «Күмүгә без һәр хәлдә катнашачакбыз. Шулай да төб бер мәсьәләне чишәргә кирәк. Дини рәвешдә күмү буламы? Гражданскиймы? Безнең катнашуыбызның рәвеше шушы мәсьәлә белән чишеләчәк. Комиссия мәсьәләне «дини» диб кисеб куюы белән үзенең өстенә зур бер мәсьүлият[35] ала».

Габдулла мулла Әмирхани: «Фатихнең васыяте шулай», – ди.

Ф.Мөхәммәдияров: «Комиссиянең күб әгъзалары гражданский күмү ягында булса да, Фатихнең үз теләгенә ихтирам итеб, җеназа белән күмүгә разый булдылар[36]».

Фатих Сәйфи: «Ничек күмәргә дә мөмкин. Кеше үзенең якынын ничек күмсә дә ярый. Ләкин гәзитдә Фатихнең васыятен төртеб күрсәтүнең ни өчен эшләнгәнен белмибез[37]. Фатихнең языб калдырган әйбере юк икән. Мәрәсимне театр мәйданында үткәрү сезнең өчен дә кабул ителерлекдер».

Х.Зәбири: «Монда мәрәсимне үткәреб, тегендә җеназа укырга мөмкин».

Кәрим Сәгыйд: «Ни өчен Мулланур Вахидов мәйданында түгел дә, ни өчен бу мәйданда? Шуның төб сәбәбе нәрсә икән?»

Мәхмүд Бөдәйли: «Сәбәбләре: 1) Татарстан Советлар съездының шул мәйдан алдындагы Комклуб бинасында булуы. 2) Татар өчен эшләб торган Фатихнең җеназасы барыбер шушы мәйдандан үткәреләчәк. 3) Шулай булгач җеназачылар шунда туктаб бераз сабыр итә алалар».

Кәрим Сәгыйд: «Бу мәйдандагы митингда җыелган халык мондан соң да мәет белән барачаклармы?»

(Җаваб бирәләр: барачаклар).

Г.Әмирхани: «Мулланур Вахидов мәйданы алга китсен, шушындый тантаналы эшләр шунда эшләнсен иде».

*48 бит*

Фәтхи Борнаш: «Мәрәсимне тегендә ясаганда ихтирам булыб да, монда ясаганда ихтирам булмый диелсә, самимият булмас иде. Халык монда да килә алыр һәм килгән кешеләр озатырлар да».

Исхак Рәхмәтуллин: «Сез артык мәсьүлиятле эш алгансыз. Татар мәгариф эшчеләренең туксан проценты безнең якда. Безнең теләк бик катгый. Без ихтирамыбызны дини мәрасим белән бер урында җыя алмыйбыз. Сез уступка[38] ясасагыз, без дә ясарбыз».

Кәрим Сәгыйд: «Килешүгә якынлашу аңлашылды. Монда әледән-әле мәсьүлият алу белән куркытышырга урын юк. Без мәсьүлиятне бик ачык аңлаб, үз өстебезгә алабыз. Җавабын биргәндә, ярдәмгә сезгә барырга кирәк булмаса кирәк. Шулай да без мәслихәт булган эшкә каршы килмибез. Әгәр дә бу Театр мәйданында да мәрәсим ясаганда, халык икегә аерылыб таркалмаса, без Театр мәйданында ясаб үтәргә дә разый».

Шиһаб Әхмирев: «Габдулла хәзрәт ихтирам күрсәтергә манигъ[39] юк, – ди. – Театр мәйданында мәрәсим ясау тарафында кеше күб. Безнең аңарга каршы торырга хак юк».

Ф.Сәйфи: «Без Татарстан Советлары съездындан вәкил түгел. Андагы кешеләрне мәрәсимгә барырга көчләмибез. Митинганы теләсәк кайчан ясый алабыз. Җеназа артындан бармауда безне һичбер иҗтимагый совет (?) гаебләмәс».

Г.Әмирхани: «Низагъ юк. Уңайсызлык чыкмасмы? Монда да мәрәсим үткәрү озакка сузылмасмы?»

Латыйф Гомәров. Тәкъдимләр кертә: «1) Фатих абыйның васыятен безнеңчә аңларгамы? Комиссиячәме? 2) Мәрәсим театр мәйданында үткәреләме, әллә Вахидов

[35] Мәсьүлият – җаваплылык.
[36] Комиссиянең күбчелеге гражданский күмү ягында булмады. (Автор искәрмәсе).
[37] Тәгъзия игъланындагы чәчәкләр, ленталар турында әйтелгән сүзләргә күрсәтә. (Автор искәрмәсе).
[38] Уступка – юл кую.
[39] Манигъ – каршылык, киртә.

мәйданындамы? Әллә икесендә дәме? Шуларны чишәргә кирәк. Шундан соң гамәли чараларын төзәрбез, – ди.

Мәсьәлә бутала. Сөйләүчеләр күбәя.

Ф.Мөхәммәдияров: «Күмүне монда фиксировать[40] итеб калырга кирәк», – ди.

*49 бит*

Садри Җәлал: «Без партиясез зыялыны күмгәндә, һәммәбез бергә булырга тиешбез. Муллалар, пуркилар[41] катнашмасыннар иде», – ди.

Исхак Рәхмәтуллин: «Без мәгариф, мәдәният оешмалары вәкилләре Фатихне үзебез теләгәнчә хөрмәт итеб озатырга уйлыйбыз. Шуңарга разыймы?»

Ибраһим Биккол: «Без Театр мәйданында гражданларча мәрәсим үтәб үтәргә разый. Ләкин мин мәсьәләнең бу рәвешдә куелышына каршы булганга рәислекдән чыгам».

Фатих Мөхәммәдияров рәислек итә.

Ф. Сәйфи мәгариф, мәдәният оешмаларының белдермәсен игълан итә. Бу белдермә түбәндәге 4 маддәдән гыйбарәт:

1. Мәгариф һәм матбугат эшчеләренең оешмалары Фатих Әмирханны гражданларча күмү рәвеше белән үткәрергә (озатырга булса кирәк) тәкъдим итәләр.

2. Мәрхүмнең языб калдырган васыяте булмавын белсәк дә, ләкин васыйларының югарыда күрсәтелгән рәвешдә күмүгә риза булмавын искә алыб, Фатихне нинди мәрәсим белән күмүне васыйларның үзләренә табшырырга.

3. Бу карарның икенче маддәсе белән риза булмаган киңәш мәҗлесенең әгъзалары Фатихне озаткан чакда Театр мәйданында туктаб, хөрмәт итүне муафикъ диб таба.

4. Театр мәйданындагы җыелышның рәисе итеб Фәтхи Борнашны күрсәтә.

Бу белдермәне укыгандан соң мәсьәлә тагын бутала. Сөйләүчеләр артык күбәя. Фәтхи Борнаш урынына Фатих Мөхәммәдияровны тәкъдим итәләр. Партиялеләр моңарга разый булмыйлар. «Фәтхи Борнаш сезнең кеше ич» диб көләләр.

*50 бит*

Шуннан соң киселеб әйтелгән, сүз берекдерелгән булмаса да, түбәндәге карар язылыб куела (ләкин бу карарга бик күб кешеләр разый булмыйлар).

Карар: Театр мәйданындагы митинг Гыйльми Үзәк, матбугат эшчеләре оешмасы, Дәүләт нәшрияты һәм гражданларча мәрәсимдә хәзер булучылар исемендән Фәтхи Борнаш тарафындан ачылачак. (Аннары мәетне алыб бару йолалары).

Шуның белән гражданларча күмү тарафындагы кешеләр таралыб бетәләр. Аларча инде резолюция чыгарылгач, гүя һәммә нәрсә шуның белән тәмам булды.

Килгән халык таралыб беткәч, күмү мәрәсимен үткәрү комиссиясе шундук үзенең утырышын ясаб яңадан бер кат элекдәге карарларын тасдыйк[42] кылыб үтде. Шуның белән бергә Театр мәйданында ясалачак мәрәсимдә табутны туктатырга булды. Шунда Фатихнең тәрҗемәи хәлен һәм аның ничек авыруын сөйләр өчен комиссия әгъзаларыннан Ибраһим Биккол белән Фатих Мөхәммәдияровларны билгеләде. Театр мәйданында мәрәсим булачагын һәм табутның шунда туктатылачагын белдереб, гәзитдә игълан чыгарырга булды.

12 март. «Кызыл Татарстан»да информация комиссиясенең, кичә идарә белән ясаган килешүе буенча, гәзитнең уртасына салынган ярты табак кәгазьдә ике яклы булыб, Фатих Әмирханга багышланган мәкаләләр һәм игъланлар һәм читдән килгән тәгъзия телеграммларның кайберләре басылыб чыкды.

*51 бит*

Партиядәге укымышлы яки язучыларның, бигрәк дә сул канатда булганнарының Фатих Әмирханны үлгәндән соң «Без дә аны тәкъдир һәм хөрмәт итәбез» диб йөрүләрен, күмү мәрәсимләрендә катнашабыз диб митинг ясаб әтәчләнүләрен «якшы түгел, читдәге эмигрантлар – дошманлар шуны истифадә[43] итәрләр, Әмирханның әдиблеген игътираф[44] итмәгәнләр диб битебезгә бәрерләр» дигән тактикалардан чыкканлар диб юрадылар, шулай диб сөйләделәр.

[40] Фиксировать – теркәп.
[41] Пурки – ялкау, иҗтиһадсыз шәкерт, укучы.
[42] Тасдыйк – раслау.
[43] Истифадә – файдалану.
[44] Игътираф – тану.

Фатих Әмирхан үлгәндән соң күмү мәрасимен үткәрү комиссиясенә үзләренең кайгыларын белдереб, төрле оешма һәм аерым кешеләрдән түбәндәге телеграммлар килде:

*1. Мәскәү. 10 март. Бөек каләм остасы татар классигы Фатих Әмирханның үлү хәбәрен тирән кайгы белән каршы алдык. Бу югалтуга күңелебез сыкранганлыкны зур хәсрәт белән белдерәбез.*

*Эшче редакциясе.*

*2. Мәскәү. 10 март. Оста татар язучысы, татар матур әдәбиятын тудыручыларның берсе булган Фатих Әмирханның югалуына чын күңелдән кайгырабыз. Туган һәм дустларының хәсрәтләрен уртаклашабыз.*

*Үзәк нәшриятның татар-башкорд, казакъ, үзбәк, кыргыз, нугай, төркмән секцияләре.*

*3. Мәскәү. 10 март. Үзебезнең бөек классик, матур әдәбиятыбызның энҗесе Фатих Әмирханның үлүенә тирән һәм чын, ихласдан кайгырабыз. Үзебезнең халкыбыз, мәрхүмнең туган һәм дустларының кайгыларын уртаклашабыз.*

*Имзалар: Фатих Кәримев, Ф.Агиев, Суфия Агиева, Мәхмүд Мәрҗани, Нәҗиб Гасрый, Шакир Мостаев.*

*52 бит*

*4. Мәскәү. 10 март. Үзбәк әдәбияты, хәзерге художество ягындан үсү чорында Фатих Әмирханны татар әдәбиятының оста художнигы сыйфаты белән чын ихласдан һәм чиксез ярата. Мин Фатих Әмирханның талантын хөрмәт итүчеләрдән булыб, сезнең кайгыгызга кушылам.*

*Чулпан.*

*5. Мәскәү. 10 март. Бөек әдиб Фатих Әмирханның үлү хәбәре безне кайгыга төшерде. Аның исеме, үсеб килә торган яшьләрнең йөрәгендә мәңгегә калыр.*

*Үзәк наборщиклар мәктәбенең татар өйрәнүчеләр группасы.*

*6. Мәскәү. Классик Әмирханның вакытсыз үлеб китүенә кайгырганлыгыбызны белдерәбез.*

*Хиҗаз Гали, Бикбулат, Кушаев, Уразмөхәммитев.*

*7. Серпухов. 11 март. Тюркология съездының Татарстан вәкилләре татарның талантлы язучы һәм художникларыннан берсе булган Фатих Әмирханның үлгәнлеген юлда ишетеб тирән кайгыда калды. Чын күңелебездән ошбу гомуми кайгыга без дә кушылабыз.*

*Имзалар: Галимҗан Ибраһимов, Гаяз Максудов, Галимҗан Шәрәф, Гали Рәхим, Габдерахман Сәгъди, Нигъмәт Хәким, Мөхәммидева.*

*8. Ленинград. 10 март. Башкордстан студентлары оешмасы халык язучысы булган Фатих Әмирханның үлүе мөнәсәбәте белән үзенең тирән кайгырганлыгын белдерә.*

*Рәис: Төхфәтуллин.*

*9. Ленинград. 11 март. Кайгы аңлатыб бирелгән телеграм оешманың фикере түгел.*

*Төхфәтуллин.*

*10. Ленинград. 10 март. Ленинград яшьләре кыйммәтле язучы Фатих Әмирханның югалуына тирән кайгыра.*

*Имза: Яшьләр.*

*53 бит*

*11. Ленинград. 10 март. Сөекле язучыбыз Фатих Әмирханның үлүенә Ленинград мөселманларының кайгырганлыкларын белдерәбез.*

*Мәсҗиде Җамигъ комитеты*

*12. Әстерхан. 10 март. Чиксез хөрмәтле Фатих әфәнде Әмирханның үлү вакыйгасе белән гаять мөтәәссир*[45] *булганлыгымны белдерәм.*

*Мулла Ниязи.*

*13. Әстерхан. 9 март. Бәхил бул, кадерле дуст Фатих!*

*Әлмөхәммәдев, Габәши.*

*14. Әстерхан. 10 март. Безнең исемебездән Фатих Әмирханның табутына чәчәк куярсыз. 25 сум акча җибәрелде.*

*Имзалар: Борһан Бадамшин, Гали Шәмиунов, Фатих Шахмазов, Гата Баһаветдинов, Гани Ниязов, Гыйлаҗеддин Яһудин.*

[45] Мөтәәссир – кайгы-хәсрәткә төшкән.

*15. Әстерхан. 10 март. Татар күгенең йолдызларыннан берсенең сүнүе белән тирән хәсрәт эченә чумган хәлдә, кадерле дуст һәм алмашдырылмый торган ибдәшне югалткан дустларыбызның бөек кайгыларын уртаклашабыз.*

*Әлмөхәммәдев, Габәши, Һилалов.*

*16. Әстерхан. 10 март. Кадерле язучы Әмирханның вакытсыз үлеб китүенә Әстерханның партиясез укучы яшьләре исемендән чын ихласыбыздан сыкранганлыгыбызны аңлатабыз. Аның татар әдәбияты, татар иҗтимагыяте алдындагы хезмәтләрен таныганлыгыбызны әйтеб үтү белән бергә, үлем аның тәнен алыб китсә дә, татар яшьләренең аңарга һәм аның хезмәтләренә булган бөек ихтирамын алыб китә алмас, дибез.*

*Имзалар: Гомәрев, Шәмсетдинов, Камалетдинов, Хәсәнев һәм башкалар.*

*54 бит*

*17. Әстерхан. 11 март. Татарның бөек язучысы һәм татар кызларының хокукларын яклаучы әдибләрнең беренчеләрендән булган Фатих Әмирханның үлүенә без Әстерханның укучы кызлары үзебезнең тирән кайгы белән йөрәкдән кайгырганлыгыбызны белдерәбез.*

*Имзалар: Курамшина, Сайганова, Гомәрева һәм башкалар.*

*18. Әстерхан. 10 март. Йөзләгән татар халкының әхвале рухиясен һәм тормышын сурәтләндереб бирүче шагыйрь, рәссам, сатирик һәм әдиб мәрхүм Фатих Әмирханга үзебезнең мәңгелек соңгы сәламебезне күндерәбез. Уяну дәверен зур осталык белән матурлаб язган Фатихнең каләме киләчәкдәге татар әдәбиятына мәңге нур чәчеб торсын! Без аның бөек таланты, фикерләре, сүзләре һәм әдәби хезмәтләре алдында баш иябез.*

*Фатих Шахмазов, Яһудин, Галим Шакиров, Гата Баһаветдинов, Гани Ниязи, Борһан Бадамшин.*

*19. Әстерхан. Татар әдәбиятының ифтихары булган Фатих Әмирханның үлүенә тирән кайгырабыз. Аның үлүе турындагы бу зур кайгылы хәбәр аның хезмәтләренә булган безнең ихтирамыбызны тагын артдырачак һәм аның исеме безнең күңелләребездә мәңге сакланачак.*

*Урта мәктәб укучылары: Шакировлар, Гомәревләр, Әбүталиповлар һәм башкалар.*

*20. Сарытау. 10 март. Кадерле ибдәш һәм дуст Фатих Әмирханның вакытсыз үлүенә тирән кайгы белән кайгырам һәм үземнең күмү мәрәсименә хәзер була алмавыма чын күңелдән тәэссеф[46] итәм.*

*Зыя Янгаличев*

*55 бит*

*21. Симферополь. 10 март. Татарның зур язучыларындан Фатих Әмирханның үлү хәбәре аның талантын тәкъдир итүче яшь кырымлыларны тирән бер кайгыга салганлыгын белдерәбез.*

*Шакир Мөхәммәдияров, Озынбашлы, Чапчакчы, (Мөгыйнев) Җәлал, борадәран Адабаш һәм Бикинлар, Җәббар.*

*22. Симферополь. 10 март. Бөек мөхәррир Фатихның үлүе безне тирән кайгыга төшерде. Аның якынларының һәм аны тәкъдир итүчеләрнең кайгыларына уртаклашабыз.*

*Мөфти Хаҗи Мөслихеддин.*

*23. Уфа. 10 март. Тебя уже нет Фатих ибдяш*
*Прими привет последний наш[47] .*

*Сүнчәләй, Гафури, Исәнбәт.*

*24. Уфа. 11 март. Милләтнең талантлы мөхәррире Фатих Әмирханны югалтуга чын күңелемдән кайгыруымны белдерәм.*

*Мөфти Ризаэддин Фәхреддин.*

*25. Оренбург. 10 март. Губерна мәгариф шөгъбәсенең[48] вак милләтләр бүлегенә*

[46] Тәэссеф – кайгыга төшү, үкенү.
[47] Кирилл хәрефләре белән язылган.
[48] Шөгъбә – тармак, бүлек.

*караган Тәрбия-тәгълим техникумының татарлар һәйәте[49] , кыйммәтле классик язучы Әмирханның үлүен зур югалту диб карый һәм шуңарга үзенең тирән кайгы белән кайгырганлыгын белдерә.*

*Алиев, Шәркый.*

*26. Ташкенд. 10 март. Матур стиль тудыручы кыйммәтле дуст Фатих Әмирханның вакытсыз үлүенә чиксез хәсрәтләнәм. Фатих Әмирхан исеменә фонд өчен 200 сум җибәрәм.*

*Кәбир Бәкер.*

*56 бит*

*27. Ташкенд. 10 март. Октябрьгә чаклы булган татар әдәбиятына бик күб кыйммәтле әсәрләр биргән татар язучысы Әмирханның үлүенә кайгырабыз.*

*Урта Азия вак милләтләр Комуниверситетында эшләүче татар группасы исемедән: Абызов, Борһан Хәбиб.*

*28. Иске Бохара. 10 март. Без ерак Бохарада торучы татарлар, үзебезнең хезмәт иясе булган татар халкының кадерле язучысы Әмирханны югалту кайгыларына кушылабыз. Без Совет хезмәтендәге партияле татарлар кыйммәтле язучы ибдәш Әмирханның күмү мәрәсимендә була алмавыбызга бик үкенәбез. Бәхил бул бездән, безнең өчен багышланган татар әдәбиятының атасы – Әмирхан!*

*Имзалар: Әбүзәрев, Әлмәшев, Кәмалов, Каина, Зәетев, Гизаков, Хәсәнев, Фатих Сөләйманов, Гомәр Җанов, Мәрзыя Җанова, Даутов, Габбасов, Әбләзинләр, Бурлик, Ишмөхәмитов, Иблиев, Хәирев, Таһиров, Самад Кандани, Гайшә Сөләйманова, Сәгъдиев, Дибирдиев, Юсупов, Нагаев, Фәһимә Нагаева, Хөсәенев, Рабига, Кинукиев, Ситдыйков, Нугаев, Хаммадов, Ибраһимов, Якупов.*

*29. Иске Бохара. 11 март. Азад Бохара идарәсе татар халкы күбчелегенең бу көнге кайгысына кушыла. Без Фатих Әмирханны бары тик татар җәмәгатьче язучысы итдереб кенә түгел, бәлки бөтен Союздагы шәрык халыклары әдәбиятының пионеры итдереб хөрмәт итәбез.*

*30. Петропаул. 11 март. Әмирханның талантын тәкъдир итүчеләр исемендән аның вакытсыз үлеб китүенә кайгырганлыгыбызны белдерәбез. Исеме Татарстанның мәркәзендә*

*57 бит*

*мәнгеләшдерергә мөстәхикъ[50] булган бу талант иясенең бөтен әсәрләре мәҗмугәсенең тиздән басдырылыб чыгарылуын һәм киң халык күбчелеге арасына таратылуын телибез.*

*Габделҗәлилов (Галим Акчурин булса кирәк).*

*31. Омски. 10 март. Яшьләр арасында искелеккә каршы көрәшү фикерләре таратучы һәм татарның матур әдәбиятын тудыручылардан кыйммәтле Әмирханның үлүенә бик нык кайгырам.*

*Искәндәрев.*

*32. Омски. 10 март. Мәдрәсә реформасы өчен беренче булыб көрәшкә чыккан һәм мәктәбкә кыйммәтле әсәрләр биргән Әмирханның үлүенә кайгырабыз.*

*Омски мәктәбендә укучылар.*

Монда тәрҗемә итеб күчерелгәнләрдән тыш янә «Кызыл Татарстан» гәзите идарәсенә дә байтка тәгъзия телеграммлары килгән. Боларның кайберләре гәзитдә чыгарылсалар да, байтагысы ни өчендер басылмый калдылар. (Җеназа укыб күмгәнгә булса кирәк. Чөнки идарәнең шуңарга ачуы килгәнлеге күмү мәрәсименең ничек үткәнлеген язган номерында да ачык күренеб тора. 12 март). Бу гәзитдә басылмыйча һәм безгә күренмичә калган телеграммлар арасында Сәмәрканд, Ялта, Полторацки[51], Баку, Касыйм һәм башка шәһәрләрдән килгән телеграммлар бар иде диб риваять итделәр. Хәерле булсын.

*58 бит*

**Күмү мәрәсиме**

12 март. Бүген атаклы әдибләребезнең иң сөеклесе булган Фатих Әмирханның

[49] Һәйәт – төркеме.
[50] Мөстәхикъ – хаклы, лаеклы.
[51] Полтарацк – Ашхабад шәһәренең 1919-1927 еллар арасындагы рәсми атамасы.

гәүдәсен дөньядан озатдык. Бөтен Казан бөек җәмәгать хезмәтчесе булган Фатих Әмирханның үлүенә матәм тотды. Казанның бөтен татар җәмәгате аңарга үзенең ихтирамын күрсәтеб, җеназасы өстендә олуглау мәрәсимен ясады. Бүген бөтен каләм ияләребез, матбугат әһелләребез, изелгән татар халкының әхвале рухиясен[52], аның тормышын сурәтләндереб бирүче шагыйрь, рәссам, сатирик һәм татар әдәбиятында яңа матур стиль тудыручы әдиб Фатих Әмирхандан аерылыб, аңарга үзләренең мәңгелек соңгы сәламләрен әйтделәр. Татарның сәнәгате нәфисә[53] ияләре, артистлары, тормышның ямьсез якларын оста тәнкыйдь белән сәхнәгә кергән, сәхнәне яңа типлар белән баеткан драматург Фатих Әмирхандан аерылдылар. Бу көн бөтен татар хатын-кыз дөньясы, татар кызының иң каты изелгән бер вакытында аның хокукын яклаб чыккан көрәшче Фатих Әмирханны озатдылар. Татарның бөтен мәдрәсә җимешләре, шәкерддән җитешкән кешеләре үзләренең уяну, ислахәт[54] дәверендәге юлбашчысын югалтдылар, кордашларының алдынгысындан аерылдылар.

Бүген Русиядәге бөтен төрк-татар халыкларының аңлы сыйныфлары, Фатих Әмирханны олуглаб аның таланты, фикерләре, сүзләре һәм әдәби хезмәтләре алдында баш иделәр.

Менә шундый аң, шундый хиссият, шундый тәгъзияләр белән Фатих Әмирханның гәүдәсе дөньядан озатылды. Күмү мәрәсимендәге меңләрчә халыклар шушы нокталарны аңлаб, аның җеназасына җыелдылар. Гәүдәсен озатдылар.

*59 бит*

12 март иртә белән сәгать унларда Фатих Әмирханның фатиры тирәсенә халык җыела башлады. Өй эчендә үзенең кардәш-ыруглары, дустлары, якын танышлары тулыб калдылар. Сәгать 11ләрдә урамда төрле милләтләрдән, төрле сыйныфлардан, ирләрдән, кыз хатыннардан, картлардан-яшьләрдән, хәтта укучы балалардан җыелган халык меңләргә җитде. Дистәләрчә атлар җыелды.

Шундан соң төрле оешмаларның, мөәссәсәләрнең[55], сыйныфларның, милләтләрнең вәкилләре, мәктәб шәкердләре һәм аерым кешеләр Фатих яткан бүлмәгә кереб, үзләренең соңгы сәламләрен әйтеб саубуллаша башладылар. Ике сәгать тоташдан шушы халык бертуктаусыз кизү белән агылыб торды. Фатихне өендән алыб чыгар минут җиткәндә дә, бу агым бетмәде. Сәламләшүчеләрнең очы-кырые күренмәгәнгә туктатылды. Ишек төбләрендәге почётлы сакчылар авырлык белән тәртиб куя алдылар. Чөнки халык һаман да сәламләшергә сорады.

Мөхтәсиб Касыйм хәзрәт Коръән укыгандан соң, комиссия тарафындан билгеләнгән кешеләр Фатихнең гәүдәсен өендән алыб чыгыб табутка салдылар. Фатихнең дустлары, кардәшләре табутны күтәреб, Театр мәйданына юл тотдылар. Юлда мәктәб шәкертләрендән, укучылардан ике яклаб бау тартылды. Иң беренче рәсем Жуковский урам[ын]да алынды. Грузинский (Карл Маркс) урамына чыккач, трамбайлар тукталдылар. Театр мәйданында төрле мәгариф, мәдәният оешмаларындан килгән халыклар, төркем-төркем мәктәб шәкердләре каршы алдылар. Шулар өстенә һәр якдан аерым-аерым кешеләр агылыб килделәр. Мәйдан каршындагы Комклуб бинасындан, съездның оешкан хәлдә дә һәм аерым-аерым вәкилләренең дә[56] чыкканы күренмәде.

Алдан билгеләнеб куелган Фәтхи Борнаш, Татарстан матбугат эшчеләре

*60 бит*

оешмасы, Гыйльми үзәк, Гажур, Дәүләт нәшрияты һәм шундагы гражданларча күмү ягында булган кешеләр исемендән диб митингны ачды. Ләкин монда гражданларча күмүгә бөтенләй каршы булган кешеләр дә бик күб, бәлки, иң зур күбчелек алар ягында иде.

Барлык халык мең ярым – ике мең чамасында иде. Бу халык Фатихне фәлән яки төгән төрле күмү ягында булганлыгы өчен түгел, бәлки ничек булса да аны олуглаб

[52] Әһвале рухиясен – рухи дөньясын.
[53] Сәнәгате нәфисә – матур сәнгать.
[54] Ислахәт – реформалар.
[55] Мөәссәсәләрнең – оешмаларның.
[56] Текстның «һәм аерым-аерым вәкилләренең дә» дигән өлеше карандаш белән өстеннән сызылган.

ихтирам итеб озату өчен җыелганлар иде. Һәрхәлдә митинг ачылды. Фотографчылар, кинематографчылар төрле якдан рәсемләр алдылар. Төрле оешмаларның вәкилләре тарафыннан Фатих Әмирханны үзләренчә тәкъдир итеб, аның үлүенә кайгырыб сөйләүләр башланды:

1. Митингны ачучы Фәтхи Борнаш («Кызыл Татарстан»ның 14нче март номерында басылды).

2. Күмү комиссиясе әгъзасы Ибраһим Биккол (Фатихнең тәрҗемәи хәле).

3. Наркомпрос исемендән Фатих Мөхетдинев урысча телдә (14 нче март, «Кызыл Татарстан»).

4. Күмү комиссиясе әгъзасы Фатих Мөхәммәдияров. Авыруы турында.

5. Каләм эшчеләре исемендән Фатих Сәйфи (14 нче март, «Кызыл Татарстан»).

6. Гыйльми үзәк һәм укытучылар исемендән Мөхетдин Корбангалиев.

7. Гаскәри укучылар исемендән Булатов.

8. Урта мәктәбләрдә укучылардан Хуҗа Рәфыйков.

9. Татар артистларыннан Кәрим Тинчурин.

10. Башкорд яшьләрендән Нури Таһиров

сөйләделәр[57]. Митинг шуның белән ябылды. Артдан меңләрчә халык ияргән хәлдә, җеназаны Казанның партиясез татар укымышлылары күтәреб, Проломный урамга төшеб китделәр. Юлда ике якдан сузылган бау белән шул ук

*61 бит*

кешеләр тәртиб саклаб бардылар. Проломныйга җиткәч җеназа килгәнне каршылаб көтеб торган тагын бер зур төркем халык килеб кушылды. Ике яклаб тәртиб саклаб барыр өчен атлы милиционер килделәр. Күренеш зур бер манифестация рәвешен алды. Җеназаны күтәреб баручылар Кәрим Сәгыйд идарәсендә һаман да алмашына тордылар һәм ялңыз укучылар (студентлар), укытучылар, укымышлылардан гына күтәртелде. Мещан һәм рухани сыйныф кешеләренә бөтенләй бирелмәде.

Проломныйдан университет урамына борылыб, андан Печән базары урамы буенча Тукай урамына – Ак мәсҗед почмагына җиткәч, җеназаны исәбсез күб халык каршы алды. Мондагы халык мең генә түгел, ун меңләб бар иде. Тукай урамы белән Татарстан почмагыннан алыб, Юнусовлар мәйданын узыб киткәнчәгә чаклы бөтен юл халык белән шыгрым тулы иде. Алма ташласаң, җиргә төшмәслек дәрәҗәдә иде. Шуның өстенә урамның ике як йорт түбәләре чебен баскан кебек халык белән кабланган иде. Шул рәвешчә җеназаны атлы милиционерның ярдәме белән юл ачыб, Юнусовлар мәйданындагы җеназа намазы укыла торган урынга китереб куйдык. Алдан хәзерләнгән фотографчылар кат-кат рәсем алдылар.

Җеназа өстендә сөйләүләр башланды. Иң элек Фатихнең якын дустларындан: 1) Ибраһим Биккол, 2) Кәрим Сәгыйд, 3) Гыйльми Шәрәфләр; аннары татар укымышлыларыннан: 4) Мостафа Туминов, 5) Казан кустарларыннан[58] – Биккинин, 6) Әстерхан яшьләрендән – Кадир Хуҗаев, 7) матур сәнәгать эшчеләрендән – Кәрим Тинчурин, 8) руханилардан – Габдулла мулла Әмирхани, 9) фән эшчеләрендән – Салих Корбангалиев, 10) хатын-кызлардан – Зөһрә Салиховалар сөйләделәр[59].

*62 бит*

14 нче март «Кызыл Татарстан» гәзитендә Фатих Әмирханны күмү мәрәсиме турында язылган мәкаләдәге «Мулланур Вахидов мәйданында» һәм «Зыяратлыкда» дигән кисәкләр бөтенләй чеб-чи ялган.

Озату мәрәсименең иң зурысы, иң көчлесе Мулланур Вахидов (элекке Юнусовлар) мәйданында булды. Сөйләүләр беткәндән соң да очы-кырые күренмәгән шул халык бер таралмады. Иң аз дигәндә алты-җиде мең халык җеназа укыды. Шул вакыт коммунистлар җеназа укучы халык арасындан аерылыб чыга алмыйча буталыб калдылар. Чөнки андан һичбер ерыб чыгарга мөмкин дә түгел иде.

Җеназа укыгандан соң, табутны Казан университетының медицина факультетында

[57] Бу кешеләрнең сөйләгәнләрен үзләрендән яздырыб алыб мәҗмугага кертергә ярый.

[58] Кустарларыннан – һөнәрчеләреннән.

[59] Бу кешеләрнең сөйләгәнләрен языб бару М.Галигә табшырылган иде. Ул шуларны языб «Татарстан» гәзитенә биргән. Анда басмаганлар. Югалтканлар. Үзләрендән бер нәрсә оешдырганлар. Шуңар күрә мәҗмугага кертергә булганда, бу кешеләрнең үзләрендән яздырырга кирәк булачак.

укучы татар студентлары үз кулларына алдылар һәм, каберенә чаклы һичкемгә бирмичә, үзләре генә нәүбәтләб күтәреб бардылар. Вахидов мәйданындагы халыкның бер меңләбе (иң азында) җеназа артындан кабергә чаклы килде. Артда иң азында утыз-кырык ат бар иде. Яңа Бистәгә җиткәч, җеназаны тагын бер зур төркем халык каршы алды һәм алар да кабергә чаклы бардылар. Кабергә баручылар арасында Фәтхи Борнаш, Фатих Сәйфи, Рәфыйков кебек дистәләрчә җаваблы коммунистлар да һәм партиясез мәсьүл[60] совет эшчеләре дә бар иде.

Сәгать 4 нче яртыда Фатих Әмирханның гәүдәсе кабергә иңдерелеб, үзенең ләхеденә куелды. Кабергә иңдерүчеләр һәм ләхедкә куючылар комиссия тарафындан билгеләнгән кешеләр булдылар. Кабергә иңдергәндә, янәдән рәсем алдырылды. Ләхед такталарын Габдулла мулла Әмирхани тезде. Каберне үзенең дустлары, якынлары, кардәшләре күмделәр. Күмелгәндән соң 1) Кәрим Сәгыйд, 2) Шәһәр Шәрәф, 3) Ибраһим Бикколлар тарафыннан соңгы сәлам сүзләре сөйләнде. Фатихнең үзе

*63 бит*[61]

*64 бит*

**Фатих Әмирхан үлү уңае белән гәзит-журналларда чыккан мәкаләләр**

1. «Татарстан» гәзите. 11 март, 58 нче номер. Фәтхи Борнаш мәкаләсе.
2. «Красная Татария» гәзите. 11 март.
3. «Кызыл Татарстан». 12 март. 59 нчы номер. Җәмал Вәлиди һәм И.Биккол мәкаләләре.
4. «Кызыл Татарстан». 14 март. 60 нчы номер. Күмү мәрәсиме турында. Хәбәрче.
5. «Кызыл Татарстан». 18 март. 63 нче номер. «Васыятем». Гумер.
6. Мәскәү «Известия»се. 17 март. № 62. Мирсәид Солтангалиев мәкаләсе.
7. Саратов. «Ялкын» гәзите. 19 март. Номер 9.
8. «Башкордстан» гәзите. 12 март. 24 нче номер. Ризван Ибраһимов.
9. «Азад Бохара» гәзите. 14 март. 32 нче номер.
10. «Төрекмәнстан». 14 март. 51 нче номер. Зыя мәкаләсе.
11. «Зәрәфшан». 18 март. 345 нче номер.
12. «Яңа дөнья». 27 март. 70 нче номер. Г.Нури мәкаләсе.
13. «Белем» журналы. Уфа. Март. 2-3 нче номер. М.Гафури.
14. «Эшче» гәзите. Мәскәү.
15. «Азад Себер» гәзите. 27 март. 10 нчы номер. Сарим Фәхри мәкаләсе.
16. «Яңа авыл» гәзите. Уфа. 11 март. 29 нчы номер. Ризван Ибраһимов.
17. «Коммунист» гәзите. Баку. 12 март. 61 нче номер. Казандан телеграмма.

**Кәрим СӘГЫЙД**

[60] Мәсьүл – җаваплы.
[61] Кулъязманың 63нче бите юк.





*Бәләкәйләр*

# БӘЛӘКӘЙ ӘЛФӘТ

## Туган җирем

Табигатьтән шулай бирелгән, күрәсең, мин бала вакытымны аз хәтерлим. Мамадыш районы Югары Яке авылында гаиләдә җиденче бала булып дөньяга килгәнмен. Өч елдан соң энекәшем туган. Әтиемнең сеңлесе Миңнегөл апа кендек әбием булган. Ул еш кына әйтә торган иде: «Син йөзлек белән тудың, бәхетле бала булырсың». Әтием Мәгъсүмҗан Бөек Ватан сугышында катнашып, 1946 елда авылга кайтып төшә. Бер елдан соң районның иң зур авылларыннан берсе булган Үсәлидән булачак әнием Зәйтүнәне алып кайта. Тормышыбыз шактый авыр булган: берсеннән-берсе кечкенә сигез бала, аннан соң әтиемнең әбисе Рәхилә әби дә безнең белән кечкенә генә өйдә яшәгәнбез. Ул вакытларны хәтерләмим дияргә була, бары тик түрдәге сәкедә карт әбинең утыруын бераз төсмерлим. Тагын бер вакыйга хәтердә калган. Нииндидер сәбәп белән кунаклар чакырган көнне, мич алдында идәндә самовар булып, шул үзем биеклегендәге самоварга корсагымны пешердем. Каты елаудан мине күтәреп күршеләргә алып кергәннәрен хәтерлим. Каты пешкәнмен, күрәсең, эзе әле дә саклана.

## Кайгы адәм башыннан йөри

1966 елны мин беренче сыйныфка укырга бардым. Җиде яшем октябрьдә генә тулганга, башта исемлеккә кертмәгәннәр. Булачак укытучым Мәсгут абый йомыш белән безгә кергәч, танышып, укыйсың киләме дип сораган. Мин уңай җавап биргәч, чыбык очы гына туганлык та ярдәм иткәндер, ике көн кала гына укырга барачагым билгеле булды. Башка юньле кием булмагач, мин энекәшнең замоклы вельвет пиджагын киеп, «көтүче сумкасы» асып, мәктәпкә киттем. Беренче көннән үк мәктәпне бик яраттым. Укырга мин яратып йөрдем. Безне дәртләндерү, үсендерү өчендер инде, укытучыбыз «5» алган укучыларга кызыл белән «5» куелган дәфтәр бите бирә иде. Мәктәптән кайту юлында күршедә яшәүче бабай, әби, апалар турыннан үткәндә, шул зур «бишле»не күрсәтеп үтә идем.

Әмма тиздән гаиләбезгә зур кайгы килде. Ул елны без колхоздан ссуда алып, яңа йорт салып кергәнбез. Бурычны түләү өчен кышлаган үгезне сатарга дип, әти белән әни район үзәгенә барганнар. Әти акча бирүләрен көтеп кала, әни исә өй тулы балалары янына ашыккан. Машина кузовына утырып, 25 чакрымдагы авылга кайтырга чыга. Бу ноябрь башы: беренче кар явып үткән, бераз катырган чак була. Бозлавык юлда машина дамба астына тәгәри, әниебез, сигез баласын ятим калдырып, шунда вафат була. Әйтеп бетергесез зур хәсрәтне мин, билгеле, бөтен тулылыгында аңламаганмын. Бары әнинең гәүдәсен өйгә алып кайтуларын, барыбыз бергә җыелып, елашып

утыруыбыз гына күз алдында тора. Әниемне үзенең тырышлыгы, ярдәмчеллеге өчен олысы-кечесе бик хөрмәт иткән, соңгы юлга озатырга да бөтен авыл халкы, хәтта тирә-күрше авыллардан йөзләрчә кеше килгән. Әнине белүчеләр хәзер дә аны эшкә уңган, чиста-пөхтә, булган хатын иде дип искә алалар. Әниебезнең якты хатирәсенә күршебез Нуретдин абый «Зәйтүнә бәете» яза:

*Иртә сулган умырзая сыман,*
*Анның гомере иртә өзелде.*
*Ул көннәрдә авыр кайгылардан,*
*Дәрья булып яшьләр түгелде.*

Берничә айдан районндагы Баскан авылыннан Сабира әни килде. Зәйтүнә әни вафат булганда, олы апабыз Мөнәвәрә яңарак кына кияүгә чыккан була. Җиде баланы тәрбияләргә килгән яңа әниебезгә мин бик рәхмәтле. Бүгенге акыл белән аның бу адымын чын батырлык дип бәялим. Билгеле, төрле вакыт булгандыр, әмма Сабира әни дә какмады-сукмады, үги булсак да, безне үз әниебез кебек якын итте. Яңа әнидән сеңлебез Гөлнур туып, гаиләбез тагы да ишәйде.

## Бабай – мулла, әти – коммунист


Бабам Закирҗан октябрьгә кадәр мәдрәсәдә белем ала. Әбием Васбикамал белән гаилә корып, иген игеп көн күрәләр. Колхозлар оешкач, байтак еллар урман каравылчысы булып эшли. 1941 елны аны сугышка алалар һәм Мәскәү астындагы Калинин фронтында яраланып, бер кулын терсәктән өздереп кайта. Мин мәктәптә укыган елларда ул авылда мулла вазифасын башкара иде.

Әтием Мәгъсүмҗан 1942 елны Бөек Ватан сугышына китә. Үзенең сөйләве буенча, алгы сызыкка машина белән сугыш кирәк-яраклары ташыган. Бервакыт фронт сызыгына җиткәндә, атыш башлана, ул кызу барган машинасын юлдан читкә бора, әмма чокырга туры килеп, әйләнеп каплана һәм иңбашыннан кулын сындыра. Дәвалану озакка сузылып, аны Грузиягә Тбилиси шәһәренә озаталар. Ул бары 1946 елда гына демобилизацияләнә. Әти гомере буе авылда яшәп, төрле вазифалар башкара: клуб мөдире, авыл советы рәисе, бригадир, көтүче, ферма мөдире, атчы. Ул йомшак табигатьле, ярдәмчел кеше иде. Сугыштан өйрәнеп кайткан тәмәке тартудан, хәмер белән мавыгудан да баш тартмады.

Мин шактый каршылыклы даирәдә үстем. Әти – коммунист һәм ул моңа бик җаваплы карады. Партия җыелышларын, төрле уку-семинарларны калдырмады. Үзе шактый еллар «политуку» курсын алып барды. Мәктәптә яхшы укыдым, шуңамы әтинең укуым белән кызыксынуын хәтерләмим. Дөрес, ата-аналар җыелышына ул үзе йөрде, бер дә калдырмый иде. Җыелыштан кайткач, горурланып (мине мактап сөйләгәннәрен чамалыйм), бер-ике фикер әйтеп куя.

Бабай, әби, әтинең сеңлесе һәм аның улы күршедә яшәделәр. Билгеле инде, без аларда һәркөнне әллә ничә тапкыр була идек. Бала вакытта үги әнигә ияләнеп китү дә җиңел булмагандыр.Тормышыбыз авыр булып, тәм-том бик эләкмәде, шуңа да әби-бабайда печенье-прәннек белән чәй эчү теләге дә булгандыр. Бу өйдә Коръән сүзен еш ишетә идек. Әби-бабай намаз укудан тыш, авыл кешеләре дә төрле йомыш белән килә һәм өйгә дога кылудан алып, өшкерү, тәлинкә яздыру, бөти әзерләү, юл догасы язып бирү кебек эш-гамәлләр күп вакыт безнең каршыда үтәлә иде. Әбием Васбикамал бик хәрәкәтчән, җиңел гәүдәле булып, ике өйне бер итеп яшәде. Үгет-нәсыйхәт сүзен дә, бабайның теге яисә бу мәсьәлә уңаеннан җиткерәсе фикерен дә еш кына әби авызыннан ишеттек. Бу йортта хәмер-тәмәке кебек әйберләрнең исе дә булмады, анда тынычлык, үзенә бер рәхәтлек хөкем сөрде. Гомумән, әтинең коммунистлыгы, бабайның динилеге йогынтысында үстек без. Әмма иң мөһиме, алардан мин әдәп-әхлакка, намуслылыкка өйрәнеп калдым. Әби-бабайларның «тирә-күрше, авылдашлар каршында йөзгә кызыллык китермәгез» дигән сүзләре минем өчен яшәеш принцибына әйләнде.

Башлангыч белемне туган авылымда алдым. Сыйныфта без җиде кыз һәм ун малай булып, шунысы игътибарга лаек: малайларның 7-се гармунда уйный иде. Мин кечкенәдән чаңгыда шуарга, ярышларда катнашырга яраттым. Бакча артында гына биек тау, тау астында инеш булып, бик текә таулардан шактый оста шуарга өйрәндем. Өлкән егетләргә ияреп, ерактагы тауларга, урманга йөрүләр дә хәтердә. Бишенче сыйныфка үзебездән сигез чакрымдагы Кече Кирмән сигезьеллык мәктәбенә бардык. Бу авыл «Кызыл партизан» колхозының үзәге булганга, безнең авылдан бермә-бер зур, матур иде. Мәктәп директоры – киләчәктә шагыйрь, прозаик буларак танылу алачак Рафаил Газизов. Мин яңа бер мохиткә эләктем. Балалар күп, мәктәп кайнап тора, атна саен төрле-төрле чаралар үткәрелә. Пионер, комсомол оешмалары актив эшчәнлек алып бара. Кемгә ничектер, мин аларны сагынып искә алам. Билгеле, идеологиягә бәйле ясалмалылык күп булгандыр, әмма пионер-комсомол җыелышларында чыгыш ясарга, үз позициямне якларга өйрәндем. Җыелышлардан соң без һәрвакыт ял кичәсе оештыра идек. Татарча биергә шунда өйрәндем. Зурларның кичке уеннарында отып калган җыр-такмаклар, кара-каршы җырлашулар, парлап биюләр – барысы да башкарыла иде.



Кече Кирмән мәктәбендә укуга җитди таләпләр куелганы хәтердә. Укытучылар гаять таләпчән, начар укучыларны хәзерге кебек күз йомып сыйныфтан сыйныфка күчерү юк, шуңа да утырып калучылар да байтак булды. Математикадан Сәвия апа, физикадан Шамил абый, биологиядән Габделхак абый, татар теленнән Гамилә апа һ.б. дәресләре әле дә күз алдында тора. Хезмәт укытучысы Габделхәй абыйга безне чүкеч-пычкы, өтерге-ышкы тотарга өйрәтүе өчен гомерем буе рәхмәтле булдым. Сыйныф җитәкчесе Ринат абый Шакиров турында аерым әйтәсем килә. Ул бик кырыс, таләпчән, вакыты белән тупас иде, әмма дөньяга күзебез ачылуга зур йогынты ясады, чын мәгънәсендә тормышка өйрәтте. Безне физкультурага, спортка тартты, яраттырды. Минем чаңгы спорты белән мавыгып китүемә дә ул этәргеч бирде. Чаңгыда узышырга гына түгел, бәлки, үз-үзеңне җиңәргә, түземлеккә, ихтыяр көче тәрбияләргә дә юл күрсәтте.

9-10 (11) сыйныфларны безнең авылдан алты чакрымдагы Урта Кирмән урта мәктәбендә укыдым. Бу мәктәптә үзгә мохит урнашкан иде. Мәктәп директоры Әлфәт абый Рафыйков – чын демократ. Аның өчен синең кеше булып җитешүең мөһим, шуңа ул кайбер вак-төяк шаяруларга күз дә йома белә. Әлфәт Гаян улы укучылар белән педагогик хезмәттәшлеккә омтылды һәм олысы-кечесе тарафыннан хөрмәт ителде. Мәктәптәге эчке тәртип кагыйдәләре Рәшидә апа Әүхәдиева кулында. Тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булган ханымны кара тут йөзле булганы өчен «чегән» дип йөртәләр иде. Усал, таләпчән, кем әйтмешли, елмаюын күрергә тилмерә идек. 10 нчы сыйныфта укыганда, Рәшидә апа белән бергә-бер калып кая укырга керү, һөнәр сайлау турында сөйләшергә туры килде. Шунда мин аның бик тә ачык, нечкә һәм киң күңелле, гаять кешелекле, ярдәмчел булуын тойдым. Рәшидә апаның мәктәп тормышында нинди зур роль уйнаганын, бөтен барлыгын мәктәпкә биреп, укучыларыннан шатлык-куаныч алып яшәвенә соңрак, үзем дә укытучы булып эшли башлагач, тирәнрәк төшенә бардым. Билгеле, төп предмет укытучылары (Фәридә апа – физика, Әлфинур апа – математика, Галимҗан абый – биология, Иван абый – география, Сабирҗан абый – тарих һ.б.) теге йә бу сыйфаты, эш-гамәле белән күңелгә кереп калган. Физкультура укытучысы Рифкать абый Шәяхмәтов укытучы гына булмыйча, фикердәшемә, хәтта дустыма әйләнде. Спортка баш-аягы белән чумган бу кеше безне «хәрәкәттә – бәрәкәт» дип яшәргә өйрәтте. Тренировка вакытында, чаңгыда үзара узышып, без бергә күп дистә чакрым юл үттек, тренировкадан кайтканда, хәлсезләнгәнне күреп, өенә алып кереп чәй дә эчертә иде.

## Язмыш сынаулары

Балалык, мәктәп еллары кызыклы һәм гыйбрәтле вакыйгалары белән хәтердә кала. Андый хәлләр миндә дә аз булмады. Арада куркынычлары да шактый булып, югарыда әйткәнемчә, битлек белән тууыма бәйле, Ходай саклап калгандыр инде. Алтынчы сыйныфны тәмамлап, җәйге каникулга чыктык. Һәр авыл баласыныкы кебек, җәйнең җылы көннәре күбрәк су буенда үтә. Каз-үрдәк бәбкәләрен ашату, карга-тилгәннән саклау безнең өстә иде. Инешебез зур булмаса да, балык тотарга да ярата идем: маймычлар күп, ара-тирә кызылканат та эләгә. Шулай бервакыт, көрәк белән кәс кисеп, буа будык. Аның тирәнлеге 50-60 см артмагандыр инде. Шайтан котырттымы, белмим, яр кырыннан баш белән суга чумдым. Төбендәге ташка бәрелеп, судан чыкканда, башымнан кан ага иде. Авыртуы тиз басылдымы, мине врачка алып бармадылар. Берәр атнадан баш авырта башлады. Бәхеткә, шул көннәрдә кунаклар килеп, арада берсе – үз әнием ягыннан туганнан туган апа – балалар врачы булып эшли башлаган. Ул башымны карап, ярадагы иске кутырны чистартты һәм, хәлне өйдәгеләргә аңлатып, тиз арада машина табып, үзе үк мине район больницасына алып барды. Минем суда тишелгән башымның ярасы төзәлмичә, ялкынсыну башланган, бераз тоткарланган булсак, бик куркыныч хәлгә юлыгасы булганмын икән.



Икенче бер вакыйга ат белән бәйле булды. Бакча артындагы инешнең икенче ягында – биек тау өстендә иске фермалар бар иде. Аларны сүтеп, кайсын кая ташып бетерделәр. Күршедәге апа калдык агачларны җыеп, утынга әзерләгән. Миннән ат белән шуны алып кайтуда ярдәм сорады. Әтинең ишегалдындагы атын җигеп, утынга киттек. Төяп кайтырга чыккач, арбаның алгы өлешендәге утын агачлары тигез итеп салынмаганлыгы, кайберләренең очлары алга чыгып торганлыгы ачыкланды. Таудан төшә башлаганда, арт ягына агач төртелгән ат дулап китә, томырылып чаба. Тау астындагы борылышта арба авып, мин бер читкә очканмын. Аңыма килгәндә, чирәмдә ятам, янымда күрше апа «үтердем... үтердем...» дип башын тотып тора. Ат та егылып, камыты сынган иде. Минем хәлем авыр булгангамы, әти ачуланмады, каяндыр иске камыт табып, эшкә йөри башлады.

Мәктәп елларыннан истә калган икенче бер вакыйга техника белән бәйле. Җиденче сыйныфта укый идем кебек, велосипедта Кече Кирмәнгә укырга барам. Каршыга килүче тракторга юл бирим дип, кырыйга чыктым. Әмма велосипед белән барырлык түгел, яңгырдан соң балчык каткакланып кипкән. Бераз баргач та велосипедның тизлеге бетте һәм мин янга ава башладым. Буй кечкенә булгач, тиз генә төшеп булмады, мин утырган килеш юл ягына – инде килеп җиткән тракторга егылдым. Кулым белән «гусеница» чылбырына таянган мизгелдә трактор туктап калды. Тракторчы егетнең сизгерлеге, игътибарлы булуы гомеремне саклап калды. Мондый хәлләр минем белән олыгайгач та шактый булды. Ничек аңлатыргадыр, язмыш сынавымы болар, әллә йөзлек белән тууым сәбәпчеме, бер Ходай белә...

## Серле-сурәтле дөньяга беренче адымнар

Мин кечкенәдән китап укырга ярата идем. Аның башлангычы әти белән бәйле, күрәсең. Безнең буын өлкәннәр белән балаларның бергәләп кич утырганын күреп калган соңгы буындыр инде. Мин үскәндә, безнең телевизор юк иде. Дөрес, авылда берничә кешедә булып, бер төркем малайның, сыйныфташыбыз өенә җыелып, «Четыре танкиста и собака» кинофильмын карауны хәтерлим. Тирә-күрше апалар еш кына бездә кич утыралар иде. Билгеле, анда мал-туардан алып, дөнья хәлләренә кадәр барысы хакында сөйләшенгәндер. Әтинең әкиятләр, гыйбрәтле хәлләр,

әдәби әсәрләрнең әчтәлеген сөйләве хәтеремдә калган. Ул сөйләгән бер әкиятнең сюжетын язып, «Әтәч» исеме белән «Ялкын» журналына да җибәргәнем булды. Хәтта журналдан бу әкиятнең билгеле булып, китапта басылуы турында җавап та килде. 5 сыйныфка без Кече Кирмән мәктәбенә бардык. Кыш җиткәч, тулай торакта яши башладык. Ул клуб зурлыгындагы бина булып, 30лап малай янәшә куелган караватларда йоклый идек. Кем ничек башлагандыр, хәтерләмим, әмма өлкән малайлар соравы буенча, йокларга яткач, әкиятләр сөйли идем. Ахырына барып җиткәндә, барысы да диярлек йокыга китә. Шул рәвешле, малайлар арасында минем дәрәҗә үсеп, максатчан рәвештә әкиятләр, китапханәчедән сорап, кызыклы кыска хикәяләр укый башладым.

Безнең өйдә күп булмаса да, китаплар бар иде. Ул чорда китап бүләк итү киң таралып, яхшы укыган өчен чирек ахырында, бәйрәмнәрдә гел китап бирәләр. Аеруча сугыш турындагы китаплар бик популяр иде. Без үзебез дә ял вакытларында «сугышлы» уйнап, еш кына кызып китеп, үзара төрткәләшүгә, хәтта сугышуга барып җитә идек. Өйдәге китаплар арасында Г.Әпсәләмовның «Ак төннәр», «Мәңгелек кеше», «Ак чәчәкләр», К.Нәҗминең «Язгы җилләр», М.Әмирнең «Саф күңел», Г.Бәшировның «Сиваш», «Намус», Г.Ахуновның «Хәзинә», И.Газинең «Онытылмас еллар» кебек әсәрләр булып, аларны кат-кат укыганым хәтердә. Шуңадыр, күрәсең, әлеге әсәрләрнең геройлары мине гомерем буе озата бара.

Әдәбият-сәнгать дөньясына тартылуда Татарстан радиосында ял көннәрендә бара торган спектакльләрнең радиопостановкалары тәэсире күп булды. Без аны көтеп алып, бөтен гаилә белән тыңлый идек. Х.Вахитнең «Беренче мәхәббәт», «Туй алдыннан», «Соңгы хат», Т.Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә», «Ир-егетләр», «Адәм баласына ял кирәк», Ш.Хөсәеновның «Зөбәйдә – адәм баласы», «Әни килде» кебек пьесаларының гыйбрәтле сюжеты шул елларда ук күңелемдә калды.

Шулай да мәктәп елларында мин күбрәк спортка тартылдым. 8нче сыйныфта укыганда, чаңгы спорты белән мавыгып, мәктәп күләмендәге ярышларда матур нәтиҗәләргә ирештем. Ә инде 9-10 (11) укыганда, район укучылары арасында берничә тапкыр җиңүче булдым. Казанда үткән ярышларда катнашып, республиканың район мәктәпләре укучылары арасында ике тапкыр 3 нче урынны алдым. Күңелем үсеп, спорт белән шөгыльләнүне дәвам итү максатында Волгоград физкультура институтының Казан филиалына укырга керергә булдым. Әмма теләгем тормышка ашмады, укырга керә алмадым. Шуннан соң абыйларым янына – Түбән Кама шәһәренә киттем һәм Химкомбинат төзелешендә катнашучы оешмаларның берсенә балта остасы булып эшкә урнаштым. Тиздән 17 яшь тулды. Бу эштә озак эшләргә туры килмәде. Йөгерүдә, чаңгыда узышуда матур күрсәткечләремне белеп, мине трестның җыелма командасына чакырдылар һәм ике елга якын спорт белән шактый җитди рәвештә шөгыльләндем. Шулай да укырга кереп, югары белем алу теләге зур иде. Спортта әллә ни зур нәтиҗәләргә ирешә алмаячагымны аңлап, бу юнәлештә алга таба уку фикереннән баш тарттым. Яшьтән матур әдәбият яратуның тәэсире дә булгандыр, Казан дәүләт педагогика институтының татар теле һәм әдәбияты бүлегенә укырга керү максатында Казанга юл тоттым. Шуның белән тормышымның яңа сәхифәсе башланды.

**Әлфәт ЗАКИРҖАНОВ**

**Редакциядән:**

*Бу айда каләмдәшебез үзенең юбилеен билгеләп үтә. Аңа исәнлек-саулык, иҗат уңышлары телибез.*

# МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ МУЗЕЕ

Арча районы Гөберчәк авылы – бөтендөнья татарлары өчен таныш авыл. Чөнки бу авылда Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт ага Мәһдиев туган. Язучының иҗади мирасы барланып, мәгълүматлар тупланып, туган авылында, төгәлрәк әйтсәк, туып-үскән йорты янәшәсендә агач бина төзелеп, 2000 елның 6 июлендә музее ачылды.

Үзе исән вакытта ук Мөхәммәт ага туган авылында тарихи музей оештыру теләге белән хыяллана. Анда ул авылының тарихи үткәне, сихри табигате һәм, ниһаять, үзенең искиткеч әсәрләре белән яшь буынга белем һәм тәрбия бирергә тели. Кызганыч, язучының ул вакыттагы теләге тормышка ашмый кала...

Музей ишекләрен ачып кергән һәркемне Мөхәммәт ага үзе каршы ала сыман. Ут белән яктыртылган язучының фотосы бинага керүчеләрне серле елмаю, сынаулы караш белән каршылый. Экспозицияләр өч залга урнаштырылган. Аларга күз салсак, язучының әсәрләреннән өзекләрне фоторәсемнәрдә яки картиналарда күрергә була; кечкенә Мөхәммәт үскәндәге йорт эче, ишегалды, әти-әнисенең шәхси әйберләре, студент вакыты, армия хезмәте һәм аннан соңгы чорын күзаллау өчен куелган экспонатлар язучының иҗади тормышын төрле яклап ача дип саныйм. Эшкә йөргән дипломаты, студент чагында кулланган агач чемоданы, документлар саклаган әнисенең тартмачыгы, әтисенең шәхси тамгасы уелган мәчет таягы, кульязмалар, башка шәхси әйберләр музейга килүчеләрдә зур кызыксыну уята. Ел саен музей фонды язучы белән бәйле экспонатларга баеп тора. Бу эштә Мөхәммәт аганың гаиләсе, туганнары зур булышлык күрсәтә. Музей экспозицияләре белән төрле яшьтәгеләр кызыксына. Бигрәк тә студентлар, мәктәп укучылары язучының иҗатына еш мөрәҗәгать итеп, төрле конкурсларда катнашып, дәрәҗәле урыннар алалар, курс һәм диплом эшләре яклыйлар. Димәк, М.Мәһдиевнең һәр әсәре игътибарга лаек һәм аларда күтәрелгән темалар бүген дә көн кадагында.

«Торналар төшкән җирдә» әсәрендә М.Мәһдиев туган авылының тарихын сурәтли. Андагы һәр герой үз исеме белән бирелә. Алар – сабыр холыклы, эшчән, тырыш, булдыклы кешеләр. Язучы аларның күңел матурлыгын, җаннарының сафлыгын, илаһилыгын күрсәтә. Әсәрдә ул авыл табигатенә нык соклана, хәтта урманның һәр почмагына игътибар бирә. Чөнки урман – авыл кешесен авырлыклардан, ачлыктан саклаган урын. Андагы байлык, хәзинә кешеләргә гомерлек дәва да, ярдәм дә булып тора. Әсәрдә сурәтләнүче аксакалларның киңәшләре, яшьләрнең кичке уеннары, шәл бәйләүче киленнәре, балаларны бер йодрыкта тота белүче, төрле яклап тәрбияләүче Зөлфиясе һәм башка геройлары укучыда зур соклану тудыра, кешелеклелек сыйфатларын арттыра, башкаларга булган карашны үзгәртә.

Мөхәммәт Мәһдиевнең әсәрләре аша укучы авыл тарихына сәяхәт кыла, җирнең тәмен, ямен белеп яшәгән геройларының хезмәт сөючән, тырыш, уңган икәнлегенә инана, гаҗәеп табигатенә соклана, торналар төшә торган басу-кырларда йөри, челтерәп аккан чишмә суын күзәтә ала. Язучы әсәрләрендә татар халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын киң куллана, моңлы җырлары белән сәнгати яктан укучыны тәрбияли, яшьлеген сагына. Мөхәммәт ага, галим буларак, күптән онытылган яки иҗатлары өйрәнелмәгән шәхесләр турындагы мәгълүматларны да дөньяга казып чыгарган кеше.

Бүгенге көндә язучы, аның әсәрләрендәге геройлары, аларның прототиплары турында музей фондына өстәмә мәгълүматлар туплана. Моның өчен Мөхәммәт аганың сыйныфташлары, студентлары, авылдашлары белән очрашулар еш оештырыла.

«Гөберчәкнең бәрәңге сабагы исе башларны әйләндерә...» – дип язды шагыйрә Сания Әхмәтҗанова музейның истәлек китабына. Әйе шул, Мәһдиевчә әйтсәк, безнең авылда һәрнәрсә башкачарак: яз кояшы кыланчык, җәй кояшы рәхимсез, сентябрь кояшы – әдәпле, мөлаем.

**Халидә ГАБИДУЛЛИНА,**
*М.Мәһдиев музее мөдире*



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Марсель ГАЛИ**

## Тәгәрмәчле халык

Сиксәненче елларда Уфаның бер төркем галимнәре шау кузгаттылар. Имеш, дөнья цивилизациясен башкортлар башлап җибәргәннәр, тәгәрмәчне беренче булып алар уйлап тапкан икән. Моны ишеткәч, Мостай ага Кәрим үзалдына көлеп куйган да:

– Алай гына түгел...Тәгәрмәч уйлап табыласын алдан белеп, алар көпчәкне майларга башта деген уйлап тапканнар, – дигән.

## Бедгә ярамай...

Бер төркем Уфа һәм Казан язучылары шагыйрь Рафаил Сафинның авылдагы өендә кунак булып утыралар. Арада бер Рафаил Сафин гына, һу-һыулап, башкортча сөйләшә икән. Бераздан әнисе түзмәгән, бәлеш бүлеп торган җиреннән әйтеп куйган:

– Улым, әнә Мостай абыеңнан үрнәк ал. Үзебезчә генә сөйләш әле, кыланып утырма! – дигән. Рафаил Сафин шаһәдәт бармагын өскә чөйгән дә:

– Ярамай, әсәй, бедгә я-ра-май! – дигән.

## Сухой закон

Голицынодагы Иҗат йортыннан Мостай Кәримне Мәскәүгә партия съездына (1986) озатып җибәргән идек, бер атнадан, Сигезенче март алдыннан кайтып төште. Җыелышып каршы алдык, бүлмәсенә озата кердек. Мостай агабыз өстәлгә әллә нинди нигъмәтләр – съезд күчтәнәчләрен таратып ташлады да, күкрәгенә таккан Алтын йолдызын балкытып, гаепле бала сыман басып тора:

– Иң кирәклесе юк бит, егетләр. Сухой закон иде съездда да, – ди.– Рәсүл Гамзатов та бик кәефсез йөрде. «Чё ты, Расул, угрюмый?» – дигән идем, «Не угрюмый, а трезвый», – ди. «Горбачёвның хәмер эчүгә каршы указы хакында ни уйлыйсың?» – дим. «Мы-то випили своё, вот дитэй жалко», – ди. Менә шулай, егетләр, Кичтән, Горбачёвны каргап йокыга китәсе, иртән Горбачёвка рәхмәт әйтеп уянасы көннәр алда әле безнең!

***

Шул көнне ул Марсель Галигә съездан алып кайткан бик матур чит ил авторучкасы бүләк итә:

– Шәп әйберләр яз! – ди, аннары Мостай ага шактый калын бер төргәк чыгара. – Рауза апаң елкы ите җибәргән менә (хатынының исемен үтә бер җылылык белән әйтә). Моны кухня кызларыннан пешертеп аласы иде бит, фольгага төрдереп,тәмләткечләр сибеп...

Мостай аганың һәр сүзе үтәлергә әзер. Голицыно иҗат йорты зур түгел, утызлап кына язучы һәм кухня пешекчеләре егерме дүрт көн буена бер гаиләкебек яшәп ала.

Төшке аш вакытында ашханәдә гәҗәеп тәмле ис таралды. Мостай ага Рауль Мирхәйдәров бүләк иткән затлы хәнҗәр белән ит түтәрәмен юка гына итеп телемләп кисеп, өстәл башында ыру башлыгы кебек утыра. Һәркемгә матур сүз әйтеп, иттән өлеш чыгара. Шулай итеп, татарның ат ите ашавын мыскыллап язган әдипләрнең урысы да, яһүде дә ул көнне телеңне йотарлык елкы итеннән мәмнүн кала.

Берничә көннән, һава сулап йөргәндә, Мостай ага Марсель Галидән:

– Ничек, шедеврлар языламы? – дип сорап куя.

– Бер дә илһам килми әлегә, – ди, кыенсынып кына Марсель Гали.
– Шәп авторучка да биреп карадым, елкы ите дә ашатып карадым – булмаһа булмай икән! – ди Мостай ага, көлеп.

## Хаҗи дозасы

Батулланың хаҗ сәфәреннән кайтып төшкән көннәре. Сыгылып торган табынлы мәҗлескә эләгә бу. Кыстап-кыстап карасалар да, хәмергә кагылмый, хаҗи кешегә килешеп бетмәс дип, юаш кына кире кагып утыра икән. Урындыгы аның каршына туры килгән Марсель Гали, нечкә билле рюмканы Батулла алдына этебрәк:
– «Хаҗи дозасы» гына ярыйдыр бит, тотып куй, Батулла, – ди.
Марсель Галинең «Хаҗи дозасы» дигәнен ошатып, Батулла елмаеп куя һәм рюмканың нәзберек биленә үрелүен сизми дә кала.

**БАТУЛЛА**

***

– Батулла абый, нигә син үз спектакльләреңне утырып карамыйсың?
– Утырырга урын калмаганга!

***

– Кем ул урыс?
– Бывший татарин.

## Колакбай

Батулланың кече улы Байбулат зур колаклы булып туа. Күргән бер туганы, дус-ишләре:
– Уһу, бу углың колакбай икән! – дип шаярта.
– Бәйләнделәр шул колакка, – дип, хатыны зарлана башлагач, Батулла:
– Горурлан, хатын, – дигән. – Шәехзадә Бабич та зур колаклы булган.

## Аерма

Язучылар җыелышында Әхәт Гаффар кәгазьгә нидер язып утыра, үзе язганыннан аерылмыйча гына кем беләндер сөйләшеп ала. Шунда Батулла әйтеп куя:
– Әхәт ул язганнан соң уйлый, ә без уйлагач язабыз.

## Мәскәүгә туры юл

Заһид Мәхмүди:
– Россиядәге җинаятьчеләрне Чукоткага, Камчаткага, Колымага сөрәләр. Ә Чукотка, Камчатка, Колымада җинаять кылганнарны кая җибәрәләр икән?
Батулла:
– Мәскәүгә. Үзәк Комитетка.

## Каклаган хатын

Берничә язучы хатыннарның юанлыгы, нечкәлеге хакында фәлсәфә куертып торалар икән. Батулла хатынының кечкенә гәүдәле, ябык кына булуы хакында да сүз чыга. Шунда Батулла үзе әйтеп куя:
– Борын-борыннан татар халкы яхшы ризыкны, озак саклар өчен, каклап киптергән, – ди.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *алып бара.*

### ПРЕЗИДЕНТНЫҢ ЕЛЛЫК ЮЛЛАМАСЫ

Казанның С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында узган парламент утырышында Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов еллык юллама белән мөрәҗәгать итте. Республиканың тотрыклы үсешен саклау, социаль әһәмияткә ия программаларны гамәлгә ашыру, үзмәшгуль гражданнарның мөмкинлекләрен арттыру, уңайлы ипотека һәм социаль арендалы торак булдыру, туган телләргә ярдәм итү буенча оптималь шартлар тудыру, милли һәм динара мөнәсәбәтләрне ныгыту – юлламада күтәрелгән төп бурычлар. Р.Миңнеханов Бөек Җиңүнең – 75, ТАССР оешуның 100 еллыгын лаеклы үткәрү зарурлыгы турында да әйтте. «2020 – ТАССРның 100 еллыгы елы» дип игълан ителде. Президент 2020 елда Бөтенроссия халык саны исәбен алу уңаеннан киң аңлату эшләре алып бару, Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам кабул ителүгә 1100 ел тулуны каршыларга әзерләнү турында да искәртте.

### БЕРЕНЧЕ УТЫРЫШ

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының беренче утырышы булды. Парламентка 100 депутат сайланды. Ике – «Бердәм Россия» һәм КПРФ фракцияләре төзелде. Утырышта ТР Дәүләт Советы Рәисе, аның урынбасарлары сайланды. Рәис вазифасына Фәрит Мөхәммәтшин һәм Хафиз Миргалимов кандидатуралары тәкъдим ителде. Күпчелек тавышны Фәрит Мөхәммәтшин җыйды. Урынбасарлар итеп моңарчы озак еллар авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры булган Марат Әхмәтов, бишенче чакырылыш парламентта да әлеге вазифаны башкарган Юрий Камалтынов белән Татьяна Ларионова билгеләнде. ТР Дәүләт Советы Секретаре вазифасына кабат Лилия Маврина тәгаенләнде. Утырышта парламент комитетлары төзелде. Һәр комитетның рәисе, аның урынбасары билгеләнде. Депутатлар Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе вазифасына моңарчы «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе булып эшләгән Айрат Зарипов кандидатурасын хуплады. Аның урынбасары итеп Людмила Рыбакова билгеләнде. Әлеге комитет составына Илшат Әминов, Нияз Гафиятуллин, Илшат Гафуров, Ркаил Зәйдулла, Рәүфәл Мөхәммәтҗанов, Альбина Насыйрова, Мәкъзүм Саләхов, Александр Славутский, Рамил Төхвәтуллин, Айдар Шәмсетдинов керде.

Сессиядә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов чыгыш ясады. Ул яңа сайланган Дәүләт Советы депутатларын котлады, яңа парламентка уңышлар теләде. Утырышта ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, ТР Премьер-министры Алексей Песошин катнашты.

### «ТАТМЕДИА»ДА ЯҢА ҖИТӘКЧЕ

ТР Президенты Указы белән «Татмедиа» республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе вазифасына моңа кадәр ТР Президентының Мәгълүмат-аналитика идарәсен җитәкләгән Айдар Сәлимгәрәев билгеләнде. Аны коллективка ТР Президенты Аппараты Җитәкчесе, «Татмедиа» АҖ Директорлар советы рәисе Әсгать Сәфәров тәкъдим итте. Ул «Татмедиа» АҖ филиаллары җитәкчеләренә ТР Президенты тарафыннан бирелгән автомобиль ачкычларын да тапшырды.

### МИНИСТР ЗЫЯЛЫЛАР БЕЛӘН ОЧРАШТЫ

ТР Премьер-министр урынбасары – мәгариф һәм фән министры Рафис Борһанов татар зыялылары – язучылар, галимнәр, педагоглар, сәнгать әһелләре, мәгърифәт һәм мәдәният өлкәсендә эшләүче җитәкчеләр белән очрашып, татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре турында фикер алышты. Очрашуда сүз балаларны татар теле, мәдәнияте белән кызыксындыру юлларын табу турында барды.

### ХАЛЫКАРА ФОРУМНАР

Казакъстанның Нур-Солтан шәһәрендә Азия илләре язучыларының I халыкара форумы булып узды. Анда дөньяның 38 иленнән, шул исәптән Россия, Азәрбайҗан, Кыргызстан, Үзбәкстан, Әфганстан, Монголия, Иордания, Согуд Гарәбстаныннан язучылар җыелды, Әлеге чарада Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов та катнашты. Форумның төп темалары – язучылар арасында теләктәшлек, уртак әдәби проектлар, тәрҗемә мәсьәләләре. Әлеге зур сөйләшү кысаларында Татарстан һәм Казакъстан язучылары арасында хезмәттәшлек итү турында килешүгә кул куелды.

***

Язучы Рафис Корбан Махачкалада утыз өченче мәртәбә үткәрелә торган «Ак Торналар» Халыкара Гамзатов әдәби фестивалендә,

Анкарада күренекле балкар шагыйре Кайсын Кулиевка һәйкәл ачу тантанасында катнашты. Дагъстанның халык шагыйре, СССР Дәүләт премиясе лауреаты Рәсүл Гамзатовның туган көне уңаеннан үткәрелә торган традицион «Ак торналар» фестиваленә бу юлы Россиянең төрле төбәкләреннән тәрҗемәчеләр җыйналган иде. Р.Корбан соңгы елларда тәрҗемә белән актив шөгыльләнеп, авар, кумык, калмык, балкар, казакъ, мари, якут, урыс һәм башка халыклар шагыйрьләренең әсәрләрен татарчалаштырып, китапларын бастырып чыгарды. Аның Анкарага баруы да шул эшчәнлеге белән бәйле. Моннан ике ел элек ул күренекле балкар шагыйре Кайсын Кулиевның 100 еллыгына аның шигырьләрен татарчалаштырып, китабын бастырып чыгарган иде. 11 сентябрьдә Анкарада Кайсын Кулиев исемендәге парк һәм аңа һәйкәл ачу тантаналары булды. Р.Корбан анда К.Кулиевның Эльбрус тавына багышланган «Мәңгелек Тау» дигән шигырен укыды һәм үзенең шушы шигырь кергән «Дуслар җыры» дигән китабын Кайсын Кулиевның улы Азаматка бүләк итте.

## МӨСЛИМДӘ ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ КӨННӘРЕ

Мөслим районында инде матур традициягә әйләнгән татар әдәбияты көннәре булып узды. Әлеге чарага Казаннан Татарстан Язучылар берлеге рәисе Данил Салихов җитәкчелегендә бер төркем язучылар кайтты. Аларны Мөслим районы башлыгы Рамил Муллин каршы алды һәм озатып йөрде. Казан делегациясенә Чаллы язучылары һәм җирле прозаик-шагыйрьләр кушылды. Кунаклар иң элек Мөслим белән таныштылар, «Кояшлы Ык» ял зонасында, «Аргамак» ат спорты комплексында, киләсе елда узачак федераль авыл Сабан туе мәйданында, паркларда булдылар. Район үзәк китапханәсендә «Дәверләрне ачар ачкычым бар» дип аталган әдәби кичәдә укытучылар, китапханәчеләр, укучылар, әдәбият сөючеләр алдында чыгыш ясадылар. Яшь иҗатчыларның шигырьләрен тыңладылар. Кичен әдәбият бәйрәме район Мәдәният йортында дәвам итте. Иртәгесен язучылар шушы туфракта туып үскән язучы Флүс Латыйфи, шагыйрь Харрас Әюпов каберләрен зиярат кылды. Аннары төркемнәргә бүленеп, мәктәпләргә таралыштылар, укучылар белән очраштылар.

## МӘҺДИЕВ ЭЗЛӘРЕННӘН

Арчадагы «Казан арты» тарих-этнография музее Татарстанның халык язучысы Мөхәммәт Мәһдиевнең тууына 90 ел тулуны каршылап һәм әдипнең кызы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Гавриил Державин, Саҗидә Сөләйманова исемендәге әдәби премияләр иясе, ТР Фәннәр академиясенең фәнни оештыру бүлеге мөдире, филология фәннәре кандидаты Гәүһәр Хәсәнованың да юбилее уңаеннан «Әтием эзләреннән» дип аталган автомарафон оештырды. Ул Арчадагы әдәбият-сәнгать музеендагы күргәзмәне караудан, Арча үзәгендәге язучылар аллеясына чәчәкләр салудан башланды. Беренче тукталыш – Казанбаш мәктәбе. Монда М.Мәһдиев балалар укыткан, булачак хатыны Лилия ханым белән танышкан. Бу авылда кызлары Гәүһәр туган. Киләсе тукталыш – Бөек Ватан сугышы елларында Арча педагогия училищесы урнашкан, шул чорда М.Мәһдиев укыган Үрнәк авылы. Сәяхәт Мөхәммәт Мәһдиев хезмәт юлын башлаган Сеҗе, аннары ул укыган Сикертән мәктәпләрендә дәвам итте. Һәр ике мәктәптә дә укучылар язучының әсәрләреннән өзекләрне яттан сөйләп, кунакларны сокландырдылар. Автомарафонда катнашучылар Гөберчәк авылында М.Мәһдиевнең каберен зиярат кылды. Сәфәр әдипнең шушы авылындагы музеенда тәмамланды. Музей директоры Халидә Габидуллина кунакларга Мәһдиевнең шәхси әйберләрен күрсәтте. Шушында ук Арча районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Рамил Гарифҗанов Гәүһәр Хәсәновага район башлыгы Илшат Нуриевның котлавын ирештерде. Автомарафонда Мәһдиевнең Арча педагогия училищесында бергә укыган сабакташы Нәкыя Абдуллинаның улы, язучы, «Казан утлары» журналының баш мөхәррир урынбасары Вакыйф Нуриев, Тукай фонды рәисе, язучы-публицист Риман Гыйлемханов, Мөхәммәт аганың бертуган апасы Равиянең кызы Җәүһәр ханым да катнашты.

## БАКУДА ТАТАР МӘДРӘСӘСЕ

«Татар мәдрәсәсе» археологик һәйкәлләр исемлегенә кертелде. Азәрбайҗанның башкаласы Бакуның үзәгендә алып барылган тикшеренүләр нәтиҗәсендә табылган татар мәдрәсәсе бинасы бу елның апрелендә җирле әһәмияткә ия археологик һәйкәлләр исемлегенә кертелде. Министрлар Кабинетының тарихи 2 август карарына туры китереп, Баку шәһәре Нәсими районы Р.Риза, Н.Арсланов урамнары чатында урнашкан, совет дәверендә халык арасында «Татар мәдрәсәсе» дип аталып йөртелгән бина, мәчет статусында җирле әһәмияткә ия археология һәйкәле буларак, дәүләт тарафыннан сакла领ачак һәм торгызылачак. Тикшеренүләр күрсәткәнчә, ул XIX гасыр ахыры – XX йөз башында төзелгән булырга тиеш. Әлеге тарихи мәчет бинасы Баку үзәгендә мәдрәсә буларак ачылган дип фаразлана. Әмма инкыйлабтан соң дин эзәрлекләнә башлагач, ул ябылып, 1934 елдан 2011 елга кадәр балалар бакчасы итеп файдаланыла, 2012 елда бакча башка урынга күчерелгәч, бушап кала.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: роман-элегия К.КАРИМОВА «Письмо без адресата», рассказ А.ХАЛИМА «Удивительный Исмагиль», рассказ М.ШИКАЛЁВА «Дочь муллы» (перевод с русского Нурии Хайруллиной); стихи Р.БАШАРА, Л.ЛЕРОНА, Р.СУЛЬТЕЕВА, Р.ГАРИФУЛЛИНОЙ.*
*«Драматургия»: И.ЗАЙНИЕВ. «Родня». Сценки из татарской жизни.*
*«Новые имена»: стихи Н.ВАЛИЕВОЙ и Г.ЗАКИРОВОЙ.*
*«Актуальная критика»: рубрику ведёт Д.ЗАГИДУЛЛИНА.*
*Конкурс «Исцеляющие руки»: рассказ З.ГИМАЕВА «Повивальный».*
*95-летие журнала «Сабантуй» (ранее газета «Юный ленинец»): фотоархив.*
*«Татарстан. История. Личности»: очерк А.ЗУФАРОВОЙ.*
*«Отклик»: статья И.ФАТТАХОВА.*
*«Детская библиотека»: рассказ И.ИКСАНОВОЙ «Велосипед».*
*«100 лет со дня рождения Мустая Карима»: статья Р.МИННУЛЛИНА.*
*«Юбилеи»: статья В.АМИНЕВОЙ.*
*«Бриллианты эпохи»: Дневник К.САГИДОВА «Болезнь, смерть, церемония захоронения известного татарского писателя Фатиха Амирхана».*
*«Белый парус»: А.ЗАКИРЗЯНОВ. «Маленький Альфат».*
*«Наши музеи»: Х.ГАБИДУЛЛИНА. Музей М.Магдеева.*
*«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.*
*Дневник общественно-культурной жизни.*
*На наших обложках: музей Мухаммата Магдеева в деревне Губерчак Арского района. Фото Л.Губайдуллина; прозаик Айсылу Имамиева.*

## IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: novel-elegy by K.KARIMOV «Letter without addressee», story by A.KHALIM «Amazing Ismagil», story by M.SHIKALEV «The mullah's daughter» (translation from Russian by Nuria Khairullina); poems by R.BASHAR, L.LERON, R.SULTEEV, R.GARIFULLINA.*
*«Dramaturgy»: I.ZAYNIEV. «Relatives». Scenes from the Tatar life.*
*«New Names»: poems by N.VALIEVA and G.ZAKIROVA.*
*«Actual criticism»: the section is conducted by D.ZAGIDULLINA.*
*Competition «Healing Hands»: story by Z.GIMAEV «Male Midwife».*
*95th anniversary of the «Sabantuy» magazine (formerly the newspaper «Young Leninist») photo archive.*
*«Tatarstan. History. Personalities»: essay by A.ZUFAROVA.*
*«Response»: article by I.FATTAKHOV.*
*«Children's Library»: story by I.IKSANOVA «Bicycle».*
*«100th anniversary of Mustay Karim»: article by R.MINNULLIN.*
*«Jubilees»: article by V.AMINEVA.*
*«Diamonds of the era»: Diary by K.SAGIDOV «Disease, death, burial ceremony of the famous Tatar writer Fatih Amirkhan».*
*«White Sail»: A.ZAKIRZYANOV. «Little Alfat»/*
*«Our Museums»: H.GABIDULLINA. Museum of M. Magdeev.*
*«Pages of Humor»: column is conducted by M.GALIEV.*
*Diary of social and cultural life.*
*On our covers: the museum of Muhammat Magdeev in the village of Guberchak, Arsky district. Photo by L.Gubaidullin; prose writer Aysylu Imamieva.*

---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Мөхәммәт Мәһдиевнең туган авылы Гөберчәктәге (Арча районы) музее. *Л.Гобәйдуллин фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* язучы, журналист Айсылу Имамиева.